ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# Казан утлары

4.2007





**Тукайда кунакта.**
*Усман Абдуллов рәсеме.*

**Казан утлары**

**Qazan utları**

*2007*

**4**

**(1014)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы һәм Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. *Хикәяләр.* ... 6
Клара БУЛАТОВА. Гомернең кай төше?.. *Шигырьләр.* ... 34
Җәүдәт ИЛЬЯСОВ. Еланнар әфсенләүче. *Роман.* ... 38
Салават РӘХМӘТУЛЛА. Ут эчендә шигырь туачак. *Шигырьләр.* ... 72
Рөстәм МИНГАЛИМ. Елгам сөеп карый күземә. *Шигырьләр.* ... 76
Асия ЮНЫСОВА. Мадам Бовари. *Хикәя.* ... 79
Рашат НИЗАМИ. Мәчет бүрәнәсе. *Хикәя.* ... 90
Чыңгыз МУСИН. Көмеш сулар агар улаклардан. *Шигырьләр.* ... 98

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Ленар ШӘЕХ. Якты шәмнәр. *Шигырьләр.* ... 101
Рифат СӘЛАХ. Чиллә челтәрендә — кояш. *Шигырьләр.* ... 104

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Васил ГАЙФУЛЛИН. Фәннилек — милли мәгарифнең нигезе. ... 107
Шакир ЯҺУДИН. ТР Конституциясендә һәм законнарында милли үзенчәлекләр. ... 113

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Миңзифа ТАҖЕТДИНОВА. «Яңа» Такташ — ул нинди? ... 117

**СӘНГАТЬ**

Хәйдәр САФИН. Әгәр ул җырчы булмаса... 127
Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА. Төс-бизәкләр — милләт сагында. ... 131

**ХӘТЕР**

Замир НИЗАМЕТДИНОВ. Җәлил дусты Кашшаф. ... 136
Салих ШАМОВ. Мәңгелектер Сәйдәш моңнары. ... 143
Алексей ЛИТВИН. Күптәнге дуска хат. ... 151

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ... 157
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 163

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Радик ФӘИЗОВ. *Хикәяләр.* ... 166

**ЮМОР-САТИРА**

Тәлгат НӘҖМИЕВ. Уены-чыны бергә. ... 174

Марат ЗАКИР. Чишмәләр шагыйре. *(Рафаил Газизовка 60 яшь)* ... 181
Рафаил ГАЗИЗОВ. Шигырьләр. ... 182

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 189

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Дж. Ильясова «Заклинатель змей» (окончание);
рассказы А. ХАЛИМА, А. ЮНУСОВОЙ, Р. НИЗАМИ, Р. ФАИЗОВА;
стихи К. БУЛАТОВОЙ, С. РАХМАТУЛЛЫ, Р. МИНГАЛИМА, Ч. МУСИНА.
«Творчество молодых»: стихи Л. ШАЕХОВА, Р. САЛАХОВА.
«Публицистика»: В. ГАЙФУЛЛИН. «Научность — основа национального образования»;
Ш. ЯГУДИН. «Национальные особенности в Конституции и законодательстве Республики Татарстан».; «Литературная критика»: М. ТАЗЕТДИНОВА. «Новый Такташ...»
«Искусство»: статья Х. САФИНА о творчестве народного артиста Татарстана
А. ФАЙЗРАХМАНОВА; статья М. ГАЛИУЛЛИНОЙ о творчестве художника Р. Вахитова.
«Память»: статья З. НИЗАМУТДИНОВА к 100-летию Г. Кашшафа «Кашшаф — друг Джалиля»; статья С. ШАМОВА о вечности мелодии Сайдаша (продолжение);
А. ЛИТВИН. «Письмо старому другу». (Памяти Аяза Гилязова).
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение);
Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение).
В номере отмечаюся 275-летие С. Халфина, 150-летие Г. Ибрагимова, 60-летие Ф. Гильми.
«60 лет Р. Газизову»: статья М. ЗАКИРОВА и стихи поэта.
«Юмор-сатира»: миниатюры Т. НАЗМИЕВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Сон Тукая» — картина художника А. АБЗГИЛЬДИНА; писатель Миргалим ХАРИСОВ.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by J.Ilyasov «Snake charmer» (termination); stories by A.HALIM, A.YUNUSOVA, R.NIZAMI, R.FAIZOVA; verses by K.BULATOVA, S.RAHMATULLA, R.MINGALIM, C.MUSIN.
«Youth creativity»: verses by L.SHAEHOV, R.SALAHOVA.
«Publicism»: V. GAYFULLIN. «Science is a basis of national formation»;
Sh.YAGUDIN. «National features in Constitution and legislation of Tatarstan Republic».;
«Literary criticism»: M. TAZETDINOV. «New Taktash... «
«Art»: article by H.SAFIN about creativity of national actor of Tatarstan A.Faizrahmanov; article by M. GALIULLINA about creativity of artist R.Vahitov. «Memory»: article by Z.NIZAMUTDINOV to the 100$^{th}$ anniversary of G. Kashaf «Dzhalil's friend Kashaf «; article by S.SHAMOV about eternity of Saydash melodies (continuation); A.LITVIN. «Letter to an old friend «. (To Memory of Ayaz Gilazov).
«Science»: A.TIMERGALIN. «Dictionary of nation»: (continuation); F.GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
In issue it is celebrated 275$^{th}$ anniversary of S.Halfin, 150$^{th}$ anniversary of G. Ibragimov, 60$^{th}$ anniversary of F.Gilmi. «60$^{th}$ anniversary of R.Gazizov «: article by M. ZAKIROV and verses of poet.
Pages from «Tatar encyclopedia».
«Humour-satire»: miniatures by T.NAZMIEV.
Diary of a social-cultural life.
On our covers: «Tukay's dream», picture by artist A.ABZGILDIN; writer Mirgalim HARISOV.


* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.



Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.03.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–363 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2007 ел.

Разил Вәлиев

## Мәңгелек яз

Шатлыгыннан бүген апрель көлә,
Көлү тавышы — һәрбер инештә.
Карлар түгел, җирнең җаны эри, —
Апрель аңа шундый килешкән!

Апрель булып, илгә Тукай килә,—
Үлгән җаннар, каннар яңара.
Яз аенда кем соң хыялланмый
Тукай кебек яшәп янарга!

Апрель булып, җиргә шатлык килә,
Яз уяна һәрбер күңелдә.
Күзен ача агач бөреләре, —
Чәчәкләргә илем күмелә.

Апрель булып, җиргә Тукай килә,
Мәңгелек яз җиргә китерә.
Шул язларны йөрәкләргә салып,
Киләчәккә безгә илтергә!



Айдар
Хәлим

## ХИКӘЯЛӘР

### Әкчин

*Башкорт әдәбиятының беренче нигез ташларын салган якташым, язучы Гариф Гомәр истәлегенә*

Ике яктан да тыгыз рәткә тезелеп утырган эреле-ваклы иген келәтләре арасында, ындыр табагында иртәнге эшнең кызып кына килгән мәле иде.

Дөпе-дөпе, чахы-чухы килеп төрлесе төрле җирдә иген иләгән, җилгәргән, орлыгын орлыкка, халыкка дигәнен халыкка, малныкы дигәнен малныкына аерып әйләнгән триер-веер, зирнәпультләр, тагын да әллә ниткән җайланмалар шавына, туктаусыз игәүләнеп, басудан—комбайннардан килгән йөкләр керә. Шунда ук салам түбәле гаять зур япма астында дәүләткә дип әзерләнгән көшелләрдән төялгән машиналар сирәк-сарак кына гөрелдәп еракка—Әкчин станцасындагы элеваторга юл ала...

Ындыр табагы артындагы Өязе-елга ярларын биләп алган зирек, шомырт һәм вак таллыкны үткәч тә башланып киткән тугайлыкта казлар көткән малайлар еш кына ындыр табагында эшләгән инәләре янына кергәлиләр. Колыннар кебек ышкынып һәм ешынып, төенчеккә төйнәштереп килгән барлы-юклы ризыкларына "зыян" китереп, үзләренең барлыкларын сиздереп чыккалыйлар.

Менә әле дә малай-шалай халкының ындыр табагына үтеп керүләре булды, Канәгатьне Габдулла бабасы чакырып алды:

—Кил әле монда, ташбаш!..

Габдулла бабасы, инәсенең бертуган абыйсы, иген келәтләре хуҗасы, ягъни ындыр табагы мөдиреннән дә җаваплырак кеше. Ындыр табагы мөдире нәрсә ул? Колхоз игене каравылчысы гына. Ә менә аның бабасы дәүләт игеннәре хуҗасы. Саклауга салынган бар ашлык аныкы. Аны башкача "глубинка" нәчәлниге диләр. Димәк, Мәскәү кешесе. Барлык Ысысырныкы. Менә ул, һәрвакыттагыча, шома итеп кырынган, битләренә бар тирә-якны аңкытып, хушбуй да сибеп җибәргән. Бабасы, кайдагы ыспайның ыспае, шулай ук

Айдар ХӘЛИМ (1942)*—шагыйрь, прозаик, публицист; күпсанлы китаплар («Милли шигырьләр», «Татар вакыты», «Яңа Сагыш китабы» һ. б.) авторы. Чаллыда яши.*

һәрвакыттагыча, хәтта ындыр табагы кебек тузан патшалыгында да ап-ак күлмәген кияргә, муенына авылда бердәнбер булган муенчак—гластугын да бәйләп җибәрергә онытмаган, шуларга өстәп, һәрвакыттагыча, танау үркәченә алтын кысалы күзлеген дә сикерткән.

Әйе, урак өсте җитте дисә, аны дәүләткә иген озату һәм озатылмыйча колхоз келәтләрендә калдырылырга тиешлесен саклауны оештыручы итеп билгелиләр. Ышаналар ана. Ышанмаслыкмы соң. Иген комиссары булып та, өенә бер бөртек иген кертмә әле син. Кая ди анда кешегә тарату. Канәгать яхшы белә—бабасының гаиләсе дә, авыл халкы кебек, ярым ач яши. Менә хәзер бар син аларга, өйләренә кер, казаннарын ачып кара—анда, урак өстендә, бу иген комиссарының казанында кызыл чөгендер шулпасыннан башка нәрсә тапмассың.

Сугыштан аягын яралап кайткан ул. Әмма, ни кызык, чатанламый. Таякка таянып, аягын сөйрәп атлый. Брачлар кисәргә булгач, кистермәгән, имеш. Җәйге-көзгелектә, җир-су алышынганда, ул аякның ничекләр итеп гөбе кебек шешеп китүенең һәм тәннең үтә күренмәле ярыга әйләнгән тиресе аша эчтән шомырт кебек караеп күренгән ядрә сәйләнең, шул чем-кара сәйләннең үз тирәсендә күзенә ак салган башмак күзе сыман агарып үләкләгән күзен күрсәгез иде сез!.. Ул чакта бабасының аягы тездән аска таба кара-кучкыл зирек агачына әйләнә, үзе исә һушсыз диярлек аһ-уһ килеп ята. Зирек түмәре сыман аягын карават башына чыгарып сала да: “Аһ, дошман, алып китә бит бу мине! Әйтте мина ваянхирур Зинченко, кисик, Хисамов, кисеп ыргытыйк,—диде. Ә мин—юк. Зеррә генәләр дә кистермәгәнмен!”—дип үз-үзе белән сөйләшеп ята. Аннан, җир-сулар корытып, көннәр елыткач, көзен, суытып туңдыргач, тагын да аягына баса. Әмма югарыдагыларның ышанычын ул яралы аягы белән кызгандырып түгел, гадәттән тыш намуслы булуы, кеше өлешенә кермәве белән яулый. Шуңа күрә аның гәүдәсе дә өндәү билгесе кебек туры бит. Инәсе әйтүенчә, бар микән җир йөзендә аның кебек намуслы, иген көшеле өстендә ач утырган Хуҗа Насретдин?! Чынлап та. Әйе, чынлап, менә хәзер бар син аның өенә, күр дә тор, хатыны Хәтирә әби белән алты баласы кызыл чөгендер шулпасы чүмереп утыра!..

Менә бүген дә, гадәтенчә, гластук бәйләгән ап-ак күлмәгенә бер тап, бер тузан кәтрәсе төшертмәгән бабасы, аны янына чакырып алды да:

—Кил әле монда, ташбаш!—диде.—Синең Әкчин элеваторын күреп кайтасың киләме?

—Килә, бабай, килә!—дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды Канәгать.

—Акрын, ташбаш! Башка малайлар ишетмәсен!—Тегесе ниятләгән эшенә җитди төс бирергә тырышты.—Әтү без дә барабыз дигән булып, җибәрмәсләр дә үзеңне!..

—Ба-рам... барам...—Канәгать чак ишетелерлек итеп кенә пышылдап куйды.

—Барсаң, ялт анау машинага!—диде бабасы шулай ук пышылдагандай итеп.—Өстә утырып барганда синең бурыч: машина кузовыннан бер генә бөртек иген дә коелмаска тиеш. Монда миллион бөртек. Бер бөртек игенне дә коймаска!.. Бер бөртек иген коелу—ул Ватан алдында хыянәт, аңладыңмы, ташбаш?

—Аңладым, бабай!

—Әгәр иген коелгандай итә икән, тартынма, кабинасына кил дә, кабина калаена дөбердәт—шулай-шулай, дәдә Иннәкәнтәй, диген, дәүләт игене әләф-тәләф итәлә диген, ярыймы! Шофер абзыеңның исеме – дәдә Иннәкәнтәй, аңладыңмы? Камандирауаннай ул. Фамилиясе... фамилиясе... Тукта әле, аның фамилиясе ничек иде соң әле?..—Бабасы бераз туктап торды да, кесәсеннән кәгазь чыгарып, аңа күз төшереп алды.—Самодуров... Самодуров икән. Сикер

кузовка!..

Машина әрҗәсенә сикерергә генә иткән малайны бабасы тагын туктатты:

—Кара аны, Иннәкәнтәй дәдәң рөхсәтеннән башка беркая бер адым китәсе булма! Әкчин—зур, ул шәһәр, ул сина чабаталы Колтамагың түгел, анладынмы?

—Анладым!...

—Анласаң, сикер, ташбаш!..

Әтисез үскән ир бала, икенче ир затыннан, бабасыннан мондый зур вазифа алу, авылыннан беренче тапкыр читкә чыгу шатлыгын кая куярга белмәгән Канәгать Колтамакка уракка беренче тапкыр килгән мондый яңа машиналарга сокланып карады. Киң күкрәкле, шома маңгайлы, маңгаена хәрефләре кыеп, матур итеп "ЗИЛ" дип язылган (Канәгать аны гына шартлатып укый, быел беренче сыйныфны шау бишлегә тәмамлады) бу могҗизаи машиналардан әллә нинди чит дөнья, шәһәр исләре, тузанлы иген, урак кайнары белән бергә ят бензин, ягулык-май исләре аңкып тора. Малай ашлыгы әрҗәсенең күзенә кадәр төялгән машинага хуҗаларча менеп атланган арада Габдулла бабасы кечкенә буйлы, юан гәүдәле, сары чәчләре таралмыйча киезләнгән, зәңгәр шакмаклары танылмаслык булып карайган күлмәгенең изүеннән сары кыллары сикереп чыккан, ике күзе ничектер ике басуда иген урган дәдә Иннәкәнтәйгә ниндидер кәгазьләр, күрсәтмәләр биреп маташты.

"Иннәкәнтәй... Бигрәк мәзәк исем,—дип уйлап алды Канәгать.—Көлмичә әйтеп тә булмый. Үзе дә мәзәк кешедер."

Әлегә бернәрсә дә анламаган малайлар Канәгать янына менеп утырырга дип машинага үрмәли генә башлаган иде, Габдулла бабалары аларны сыргавыл белән куып төшерде:

—Көш-көш-шу!.. Көш-көшшу!..

Канәгатьнең абруе малайлар арасында бермә-бер күтәрелде, әлбәттә. Ул үзен бик тә лаеклы итеп тотарга тырышты. Күреп кайтсын әле ул машинада Әкчин якларын, юлда күргәннәрен барысын да тәфсилләп сөйләр!..

Менә әрҗәсендә миллион бөртек игене булган һәм миллион бөртегә өстендә үзенчә бер эре бөртек булып утырган малайны да алган автомобиль ындыр табагы капкасыннан чыкты, унга борылып, ат сарайлары янәшәсеннән үтте һәм тагын да унга борылып, нәкъ Габдулла бабаларының тәрәзәләре зәңгәр капкачлы йортлары янынннан "Кыргыз юлы"на чыкты да, бар куәтенә үкереп, Өязе тауларына үрмәли башлады...

Мондый яңа, зур, көчле машинага Канәгатьнең беренче тапкыр утыруы иде, әлбәттә. Юк, колхозның Гыйльфан абыйлары йөреткән бердәнбер "полуторка"га утырып йөргәне бар аның. Ул бит үзе дә, әрҗәсе дә кечкенә. Монандый биек үрләргә дә ых та итмичә менгән, монандый да гайрәтле машина белән чагыштырып буламы инде колхозның ямаулы иске комганын!.. Колхоз машинасын "иске комган" белән чагыштыру малайга ошап куйды. Житмәсә, бу машиналар Ватан башкаласы Мәскәүнең үзеннән үк килгәннәр ди. Габдулла бабалары әйтмешли, ярдан этәргә түгел, ярдәм итәргә. Аларның номерлары да колхозныкы кебек "ТИ" гына түгел, ә "МС", димәк, Мәскәүдән!.. Чынлыкта исә кем кемгә ярдәм итә ала? Көчле көчсезгә!.. Аның хәзер Мәскәүнең үзеннән килгән Иннәкәнтәй дигән "камандирауаннай" абзыйсы да бар. Канәгатьнең шундый ерак шәһәр җирләреннән аларга—авыл ятимнәренә, ярдәм итәргә килгән көчле Иннәкәнтәй дәдәсенә, кочаклап, рәхмәт әйтәсе килеп китте. Ярар, әйтер әле, әйтмичә диме. Урап кайткач. Ындыр табагында. Габдулла бабасы, иңәләре, дус малайлары алдында.

Әле Әкчин кадәр Әкчингә сәяхәткә чыгу шатлыгыннан айнып та җитмәгән малай күкрәгенә өргән, чәчләрен тузгытып тараткан тыгыз җилдән ләззәтләнде. Гади бер җилдән генә дә шул кадәр рәхәтлек килер икән! Аның өчен Мәскәүләр биргән кунак машинаның биек әрҗәсенә, миллион бөртек

иген өстенә утырырга кирәк икән. Их, тирә-якта нинди кинлек! Кара, күпме урман! Күпме яланнар! Аның машинасы, ана тапшырылган машина, аның үз кулына бирелгән машина, әнә, ничек итеп киң күкрәге белән шушы тыгыз, татлы әрем исләре белән аңкыган җилләрне ерып, күз күреме җитмәс күпме җирләрне, урман-яланнарны артында калдырып җилә дә җилә... Ул артына борылды һәм бер горурлык хисе белән авылының йорт түбәләрен, аннан үзләренең түбәсен, бәрәңге бакчаларын эзләде—табалмады, авыл чынлап та күздән югалып бара иде. Күрделәрме, күрәләр микән алар Канәгатьне? Белделәрме, беләләрме алар аның нинди җаваплы бурыч белән җитмеш чакрымлык юлга чыкканын?! Ул бит Әкчингә бара! Җитмәсә, бер үзе!.. Мәскәүләр биргән яңа машинада!.. Әнисенә әйтеп тә тормыйча!..

Әнисе исенә төшкәннән соң аның йөзеннән шәүлә үткәндәй булды. Әй, бабасы әйткәндер әле инәсенә Канәгатьнең кая киткәнен. Мондый зур эшне бабасы инәсенә әйтмичә эшли буламы?

Аның бер машина ашлыгы бар!.. Бер машина! Ул бу кадәр байлыкның хуҗасы булу сөенеченнән берничә бөртек бодайны чеметеп алып авызына кабып, чәйни башлады. Тәмле, үзле, туклыклы иде ул. Моның белән яшәп була. Әгәр ул үзеннеке булса. Тукта, ул бодай бөртекләрен рөхсәт сорап каптымы? Ул агарынып калды. Их, туйганчы бодай куырып ашарга!.. Куырган бодайның тәмлелекләре!..

Исән-сау йөреп кайткач, алла боерса, бабасы аның күлмәк итәгенә бераз бодай да салыр әле, шулай бит? Үзе салмаса, сорап алыр. Менә шунда куырачак ул бодайны!..

Гади ат юлыннан тирә-якка янтая-янтая барган машина урман эченә килеп керде. Элек гади генә күренгән имән, каен, усак яфраклары, җир өстеннән йөгергән үлән кыяклары инде берсе дә гади яфраклар, гади үлән кыяклары түгел иде. Аларның биекләре түбән, түбәннәре биек иде инде. Ул күкне дә онытмады. Көпә-көндез күк гөмбәзендә алкаланып торган сыек ай элпәсе аны таң калдырды. Ничек кенә чекрәеп карамасын, ул йолдызларны күрә алмады. "Алар да үз урынында,—дип уйлады малай.—Көндезен күренмиләр генә". Бела Канәгать, ай белән йолдызлар аның шатлыгын күтәрешеп, Әкчингә җәяү баралар. Канәгать кенә машинада җилдерә бүген. Чөнки хакы бар. Ул—иген хуҗасы. Барган җайга чайкалып, унга янтайган машинадагы малай сузылып кына имән агачыннан бер яфрак өзеп алды да, гүя сагынганда карармын дигән сыман, чалбар кесәсенә тыкты. Әйдә, ул да йөреп кайтсын Әкчин тарафларыннан. Машина аны урман юлы борылышларында йә унга, йә сулга суккалады, әмма ул хискә бирелеп, әрҗәдән коелуы мөмкин булган игенне түгел, ә бәлки исе-һушы китеп тирә-яктагы манзараны күзәтеп барды...

Юл урманнан тагын да ачыклыкка чыгып, киртәләр белән әйләндереп алынган кара баткаклыкка, тәбәнәк озын мал абзарларына килеп чыкты. Малай сасы истән тончыга язып, учы белән борынын каплады. Чем-кара баткаклыкта коенган башмак кадәр ак ит чүмәләләрен, аларның бихисап имчәкләренә сарылып имгән бихисап чучка балаларын үз гомерендә беренче тапкыр күреп, чучка дигәннәре шушы булырга тиештер дип уйлады. Күп тә үтми ике яктан кызыллы-зәңгәрле төсләргә буялган саман өйләр, һәр ихата алдында диярлек тирәкләр, сәрви куаклары, чиләкләре җилдә чайкалган баганалы коелар, бакчаларында тәгәрәп яткан сары кабаклар, эредән дә эре карбыз-кавын, кәбестә-кыярларны абайлап, бу хахул авылы Хлебороб булырга тиештер дигән фикергә килде. "Колтамак елга буена урнашса да, безнекеләр яшелчә үстерми, ә менә хахуллар елгасыз җирдә, кое чокып булса да, тәпән кадәр кәбестәләр, бәләк кадәр кыярлар, казан кадәр кавын-карбызлар, алтын башлы суганнар үстерәләр һәм аларның авылын тәэмин итеп торалар. Нинди тырыш халык!",—дип уйлап алды ул. Үскәч, үзе дә яшелчә үстерәчәк, Алла

боерса!.. Инәсе аш пешерә башласа, бер баш суган эзләп Хлеборобка чыгып йөгерергә әзер. Шулай яшәп була диме?!

Авыл очында машина туктады. Дәдә Иннәкәнтәй кабинасыннан төште, утыргычы астыннан мышный-мышный, нindидер капчык сыман нәрсәне чыгарды, аны кочаклап, эндәшми-тындашмый, кырыйдагы өйгә кереп китте. Озак тормады анда Иннәкәнтәй. Чыкты. Аның йөзе куз кебек кызыл, куллары буш, күнеле хуш иде.

Юл тагын да урман эченнән бара башлады. Болар инде Канәгать күргән урманнар түгел—юан кәүсәле эре, калын урманнар иде. Кинәт юл нык итеп сикертте һәм бу хәл көтмәгәндә малайны артка карарга мәҗбүр итте—моңа кадәр гел алга таба, бар тирә-якка сокланып барган карашы юлга чыкканнан соң беренче тапкыр үзе саклап барырга тиешле игенгә төште. Әрҗә белән бергә сикергән йөк Канәгатьнең үзе кебек яңадан урынына утырды утыруын, әмма утырганда иген җиргә коелгалаштырды. Әгәр сикергән саен ун, йөз бөртектән тора-бара мең бөртек коелып калса?! Бөртекләр урынына үзе коелып калырга әзер булган малайның тәнен салкын тир билəп алды. Йә, Ходай!..Тирә-юньдәге хәйран-вайран, уйлары-хисләре белән мавыгып, ул йөкне саклап барырга да онытканбит, ташбаш!.. Ул хуҗаларча җаваплылык белән йөкне күздән кичерде. Юк, кимемәгән иде кебек. Бәлки орлыклар коелмагандыр да әле. Машинасы да беренче тапкыр гына шулай нык сикертте бит.

Урман юлы чынлап та начар, тигезсез, чокырлы-чакырлы, язгы-көзгелектә гөрләвекләр буразналар ергалап бетергән иде. Бер сикерделәр—ун бөртек җиргә сикерде—түзде. Ике сикерделәр—тагын ун бөртек—түзде, өченче тапкыр сикерүдән түземе бетеп, малай бар көче белән кабинаның калай түбәсен төйде.

Киезләнгән сары чәчле, шешенгән табак битле Иннәкәнтәй дәдә кабинадан чыкты. Аның белән бергә тыштагы һаваны әче суган исе басып алды. Икесе ике басуда урак урган күзләрен бер ноктага—Канәгатькә төбәргә тырышып, акырды ул:

—Что стучишь, тв...тв...ю мать!..

Малай бернәрсә дә аңламады. Әмма аңламаса да, сүз бары тик йөктән коелган иген турында гына барырга тиеш дип уйлап, үз телендә аңлатырга тырышты:

—Дәдә Иннәкәнтәй!... Кызу барма!.. Син сикерткән саен иген коела!..

—Что за каля-баля еще?—дип зәһәр ыржайды Иннәкәнтәй дәдә.—Мой твой не понимай! Если еще раз настучишь, высажу—пешком попрешь!..[1]

Һәм ул сүзләрен шул кадәр дә сайлап, шул кадәр дә күп катлы, озын итеп, күзләреннән очкыннар, авызыннан төкрекләр чәчә-чәчә холыксызланып сүгенде, ишегең шул кадәр дә каты итеп япты һәм нindидер шешә шалтыраган, керәх-керәх килеп тамак кырган тавышлар чыгарып маташканнан соң, машинасын нindидер кыргый ачу белән, чамадан тыш үкертеп, урыныннан кузгалды. Мондый сүзләрнең бары тик ямьсез, шакшы, бары тик сүгенү генә була алуы Канәгать кебек нечкә, тере җан иясенә генә түгел, үле җаннарга да аңлашылган булыр иде. Моны аңлау өчен телне белү дә, тәрҗемәче дә кирәкми иде.

Әниләренең көннәр-төннәр йокламыйча, балаларының авызларыннан өзеп үстергән, тирдән, күз яшьләреннән алтынга әйләнгән бөртекләр коела, коела, коела—исраф була иде. Аны шул игенне үстергән инәләре, урдырган-суктырган бабалары-әбиләре, абыйлары-апалары—авылдашлары түгел, ә бәлки бөтенләй дә үстермәгән, күрмәгән-белмәгән, авыл иккән шәхси игенне

[1] Бу нинди кәлә-бәлә тагын? Минеке синекен аңламаган. Тагын да дөбердәтсәң, монгол токымы, куып төшерәм—җәяүләп җилдерерсең (Рус.)

дәүләткә җыеп алуда очраклы рәвештә генә катнашырга мәҗбүр ителгән килмешәк коя иде.

Канәгатьнең Габдулла бабасы күз алдына килде. Игеннең бөртеге коелу да үлемгә тиң иде.

Сикергән саен коелып калган бөртекләрне күрмәс өчен ул игенгә йөзтүбән капланды. Бар йөкне кочакларга тырышкандай кулларын бодай көшеленә тыкты. Бодай кайнар салам, эссе кибәк, кызган кояш исләре белән аңкый иде. Күзләрен ачты. Алтын-сары иген бөртекләре гүя үтә күренмәле иде. Малайның Иннәкәнтәй дәдәсе эттән алып эткә салып суккәннән соң кайнарланган, гарьләнгән зиһене миллион бөртекнең һәр бөртеге эчендә сугыштан танкка атланып кайтып килгән атасын, шунда ук шәм яктысында Коръән укып утырган инәсен күрде.

Ул үзен бик тә көчле җиңүче һәм бик тә көчсез җинелүче итеп тойды. Шушы гарь, шушы көчсезлектән тыела алмый елап җибәргәнен сизми дә калды. Гүя ул игенне коеп барганы өчен кояш алдында гаепле иде. Күпме елаганын хәтерләми. Озак, бик озак елагандай тоелды. Ана җир йөзендә бары тик ул үзе генә җиңүчеләргә хас кайгы белән кайгылы, бары тик ул үзе генә җиңүчеләргә хас елау белән елаган сыман иде.

Әмма Җир түгәрәк иде. Анда зарлылар бихисап иде. Кайдадыр Атлантик океанның Кариб утрауларында шикәр камышына чабам дип үткер китмәне белән үз аягына чапкан кубанос-малай һәм тагын бик күп, бик күп җиңгән һәм җиңелгән илләрнең ятимнәре елый иде. Ул бу хакта бары тик белми генә иде.

Башын күтәреп, кояшны күрмәс өчен, ул вакытны сузарга булды, башка бернинди гамәле калмагач, елаудан кинәеп киткән танау тишекләре белән янадан бодайны исни башлады. Бу юлы игеннән татлы балавыз, хуш исле әрем, салкын чишмә исләре килә, хәзер үтә күренмәле бөртекләр эчендә атасы сандал өстенә яткан да, чаң-чаң китереп чалгы чүки иде...

Ул һаман да башын күтәрергә тартынып, уң күз кырые белән кылыйлатып кына дөньяны сөзеп алды. Анын карашы тәрәзләре челпәрәмә ватылып коелган, күзсез чокыр кебек рамнары такталар белән аркылы-торкылы калакланган, соңгы чорларда кеше эзе, игътибары күрмәгән ниндидер пычрак, иләмсез өч катлы ташпулатны абайлап алды. (Үскәч, бу еллардан күп тапкырлар үтеп-сүтеп йөргән Канәгать бу бинаның әле революциягә кадәр үк төзелеп, суырткан орлык тартып, соңгы утыз-кырык ел эчендә иген булмау аркасында эшләмичә утырган бердәнбер американ механик-пар тегермәне икәнлеген белер.) “Миякәгә җитәбез, ахры”,—дип уйлап алды малай, мондый биналарның бары тик район үзәкләрендә генә була алуын чамалап.

Шулай икән шул. Юл инде ат юлыннан киң таш юлга әйләнгән, андагы атлы-машиналы хәрәкәт тә Колтамак юлындагы сыман сүрән түгел иде. Машина хәзер сикерми, иген дә коелмый башлады. Кәефе күтәрелгән Канәгать бер-берсенә каршы агылган арбалы атларны, машиналарны күзәтеп барды. Ачыш ясады: алар ягыннан, арттан — игенлеләр, каршы яктан, алдан — бушлар, игенсезләр килә икән. Менә автомобиль баганаларында ниндидер тимер чыбыклар, ак чынаяклар, эшләпәле лампалар эленеп торган урамнарга килеп керде. “Район үзәге шушыдыр”. Шулай дип уйлап та өлгермәде, урам чатында басып торган милицияләрнең кызыл билле фуражкаларын, самолет канатыдай җәелеп бүлтәйгән галифиләрен күрде.Тәне эсселе-суыклы булып китте. Яратмый ул «милиси»ләрне. Алар Колтамакта күренү белән малайлар базга кача, чөнки алар килү белән йә йортларга тентү керә, йә берәр кешене кулга алып китәләр...

Юл әллә тагын начарланды, әллә Иннәкәнтәй дәдәнең кәефе китте—тагын сикертә башлады. Гүя ул нәрсә беләндер сихерләнеп, яхшы юлны начар юлдан аермый башлаган иде. Орлыклар тагын да коелгалады.

Канәгатьнең башы өянәк кузгалгандай сызлый башлады, жаны сыкрады. Нишләргә? Ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә беркем дә юк—тирә-якта телсез таулар-урманнар, машина кабинасында холыксыз бер килмешәк, соргылт тузан баскан юлларда һәркем үз уе белән мәшгуль булган очраклы юлчылар гына иде. Ул куркып калды. Әмма туган авылыннан читкә чыгу белән, беренче тапкыр, шуны аңлады: бабасы кушкан бурычны үтәү тойгысы куркудан көчлерәк икән. Курку дигән нәрсә аңардан тәмам качкан иде. Ашлык өстеннән шуышып килде һәм, тәкате бетеп, кабина калаен дөбердәтте.

Иннәкәнтәй дәдәсенең туктап сүгенүен көткән малай тынсыз таяк булып катты. Теге юлын дәвам итте. Канәгать тагын дөбердәтте. Иннәкәнтәй һаман да туктамады. Инде елыйсы килми иде. Күңелсез булып китте. Әгәр мондый алтын бөртекләрне юл буйлап коеп барачагын алдан ук белсә, аны Әкчингә җибәргән кеше, бабасы түгел чуртым булсын, юлга чыкмаган булыр иде. Нигә кирәк ана мондый җәза? Мондый өтермә, мондый зиндан? Нишләргә белмәгән малай кайгыларына төренеп, ашлык өстенә сузылып ятты, машина белән бергә әрҗәдән сикереп төшеп калган бөртекләрне, ничек кенә әрнүле булмасын, күрмәмешкә салышып, Өязе буйларын, андагы дусларын, көтүчесез калган каз бәпкәләрен уйларга тырышты.

Югарыдан караганда, машина әрҗәсе—бишек, малай исә бишектәге бәбәй иде. Бишек сыман тирбәлгән машинада ул йокымсырап киткәнен дә сизмәде. Башы очында кемнендер мыш-мыш килеп казынып маташуыннан уянды ул. Туктаганнар икән. Малай башын күтәрмичә генә куян сыман кыеклап күз салды. Иннәкәнтәй дәдә машина көпчәгенә басып, күкрәге белән әрҗә читенә яткан да, берсе икенчесеннән ерак урнашкан, икесе ике басуда урак урган күзләрен бер ноктага төбәгән дә, көрәктәй сары йөнтәс куллары белән бидрәсенә бодай тутыра. Кемгәдер мыгырдап, бидрәсен аска сузды да, лапылдап җиргә сикереп төште. Ул кемгәдер иген сата иде бугай. Иннәкәнтәй күрмәсен дип, Канәгать чак кына башын калкытты: яшеллексез, кояшта көйгән авыл урамы, бик тә бетеренгән, ихаталары ауган, нужа хөкем сөргән, капкачсыз тәрәзәле, келәт сыман кечкенә өй ишарәтләре, шундый өйләрнең берсенә бидрәсен күтәреп кереп барган кеше... Теге кеше янадан чыкты һәм бидрәсен Иннәкәнтәйгә бирде:

—Ишшү әднә бидрә, Иннокентий. Итоко пут пудет...[1]

Сөйләшүләреннән аңлашылуынча, чуаш авылы булырга тиеш бу. Колтамак янәшәсендәге чуаш Өязебашыннан Пләги түткәйләрнең күп тапкырлар килгәне бар аларга җеп эрләргә!.. Чуашларны әллә каян таный ул!..

Иннәкәнтәй янадан машина әрҗәсенә артылды. Тагын да бидрәсен тутыра башлады. Камандирауаннай абзый Колтамак үстергән игенне сата иде!.. Канәгать чәнечкеле камгакка әверелде. Нишләргә? Нәрсә, нииндидер бер килмешәк туган авылының дәүләткә дигән ашлыгын урлап сатып ятканда ул һаман үпкәчел бала сыман авызын турсайтып торсынмы? Белми, нинди көч, нинди кодрәт, нинди зиһен, нинди хис аны урыныннан күтәргәндер, әле бүген, моннан бер-ике сәгать кенә элек туган авылыннан беренче тапкыр читкә чыккан сигез яшьлек малай, зур юл өстендә, чит авылда, чит кавемнәр арасында, бернинди уксыз-коралсыз, ике дә уйламый, сикереп торды һәм бүре баласы кебек ырылдап, үткер тешләре белән Иннәкәнтәйнең сары йонлы кулларына килеп кадалды:

—Бир-мим!.. Бу мин-нем иг-ген!...

—Молчи, монгольский выродок!.. Я тебе еще покажу, сопляк![2]

[1] Тагын бер чиләк, Иннокентий. Җәмгысы бер пот булачак.

[2] Тавышыңны чыгарма, монгол токымы! Мин сиңа күрсәтермен әле, селәгәй! (Рус.)

Иннәкәнтәй икенче кулы белән малайга сукты. Малай тешләрен җибәрде. Иннәкәнтәй исә, тагын да җиде катлы итеп сүгенеп, аны бар көченә җилләп очырды.

Малай әрҗәнең почмагына очып барып төште. Шофер өймәләмә бидрәсен астагы чуашка бирде һәм аның белән бергә теге өйгә кереп китте. Озак та үтмәде, кулына төргәк тотып килеп чыкты, аны утыргычы астына тыкты һәм ишекне япты. Ишек җиле белән Канәгатькә әчкелтем апра исләре килеп бәрелде.

Үкереп һәм гөрелдәп, машина киң үзәнлеккә килеп чыкты. Колтамакның кул яссуы кадәр генә булган ертык-пыртык басулары, тау-таш, урман-фурман арасында үскән сабый мондый сәхра-иркенлекне күреп тагын онытылды. Гүя әле биш минут элек кенә аның белән бернинди фаҗига да, бәрелеш-кыйралыш та булмаган. Мондагы матур табигатькә—чиксез басулар, болынлыклар, көмешләнеп кайнаган таллар, өянкеләр, бөтерелеп-бөтерелеп кызарган баланлыкларга сокланып, чабыласы чабылган, чүмәләләнәсе чүмәләләнгән, кибәнләнәсе кибәнләнгән, эскертләнәсе эскертләнгән печәнлекләр, чабылмый калган җирләрдә ат дугасы күмелерлек чабынлыклар күреп, малай хәйраннар калды. "Их, авылга алып кайтырга!"—дип уйлап куйды ул. Колтамак урманнарында син бүген эскәкләп чүпләргә дә үлән тапмасссың. Малай тактадагы "Река Дема" дигән язуны укып та өлгермәде, машина бөдрә таллар астыннан боргаланып-боргаланып, ярсуын кая куярга белмичә аккан киң елга ярына килеп чыкты. Канәгатьнең мондый зур дәрьяны күргәне юк иде әле. Башка машиналар кебек үк елга аша салынган күпергә җитәрәк кенә сулга сугып, көпчәкләрен комташ өстеннән шытырдата-шытырдата яртылаш суга кертте дә, Иннәкәнтәй моторын сүндерде.

Менә нинди икән ул җырларда җырланган Дим! Киң икән, ташкын икән. Капма-каршы ярлардан бер-берсенә кулларын сузган зифа таллар бу ташкынның өстеннән яшел чатыр корганнар. Бу Дим дигәннәре йөз, юк, мең Өязе, Кәркәле елгаларына торадыр. Дим белән беррәттән шуларны елга дип атап буламы? Инешнең дә тавык атлап чыгарлык инеше икән бит алар! Димнең суларын мичкәләргә тутырсаң, ничә мичкә булыр иде икән? Миллион? Әйе, миллион!.. Хәзер аның миллион бөртек игене янына миллион мичкә суы да бар!..Йөк өстендә утырган Канәгатькә җылы булып китте. Елга өстендә искән иләс җил мотордан килгән кайнар һава белән кушылып җылына икән. Янәшәдә шоферларның берсе моторын сугара, икенчеләре юа, өченчеләре яр буенда тамак ялгый иде. Иннәкәнтәй Канәгатькә эндәшмичә һәм кеше күзенә чалынмасын дип булса кирәк, елга яклап кабина ишеген ачты, төргәген сүтеп, шешәсен, кабымлыкларын чыгарды, аннан төргән чүпрәген җәйде, кабымлыкларын кискәләп, табынына тезештерде. Авызыннан әллә нинди ләззәтле мөңгерәү авазлары хасыйл итеп, ашыкмый-пошыкмый, ниндидер бер йолага әзерләнгәндәй әзерләнде...

Канәгатьнең ашказаны да чөрләп куйды. Ашказанын онытгырырга кирәк иде. Кеше-кара күрмәсен дигәндәй, як-ягына каранып, йөктән берничә уч бодай сыдырып алып, юка малюскин чалбарының кесәсенә салды да, аннан уч төбенә тагын да бодай өереп, авызына койды. Чалбар балакларын бот төбенә кадәр сызганды, ике куллап машина әрҗәсенә асылынып, аякларын көпчәккә төшерде һәм беренче тапкыр, чиркана-чиркана, чәлтерләрен Димнең ефәктәй йомшак агымнарына тыкты... Табаннары белән сары комга басуы булды, әллә инде шуны гына көткәндәй, Дим талларының көмеш яфраклары чайкалды, хәрәкәткә килде, гүя яфраклар кошларга әйләнеп, бар дөнья сайрый, моңнарда кайнаша башлады. И-һи-һи, мондагы кошлар җәй башындагы кебек ярышып сайрыйлар икән! Аның аяк чәлтерләрен нәрсәләр кытыклагандай итте. Үтә күренмәле, аяк бармакларының рәвешләрен үзгәртеп

тирбәлгән суларга караса, аяк йөзләренә агымсулар ташыган комнар, бака кабырчыклары түшәлә. Каян килә комнар, кабырчыклар? Өязедә юк бит алар!..

Малай авылыннан читкә чыккач кына, инде менә ничәнче тапкыр аптырады: бу кадәр бай, матур табигате, бу кадәр басу-болынлыклары, бу кадәр сулары-урманнары, бу кадәр барлыклары булган адәм баласы нигә үзара сугыша, нигә ул ятим, нигә ач?! Димәк, адәм баласын табигать түгел, ул үзе, үз табигате, йә булмаса икенче кеше—икенче көч ач итә?!

Ул күз кырые белән генә Иннәкәнтәйгә карады. Кечкенә юлдашы турында тәмам оныткан шофер, кәефе килеп, эченнән генә мекер-мекер и-һи-һиләп, инде ничәнче кат шешәсенең бөкесен бөкелдәтеп ачты, икесе ике басуда урак урган күзләре белән як-якка угрыларча караштырып алды, тагын да шул и-һи-һиләп авызыннан гына чүмерде, аннан ниндидер аксыл калҗаны тамак юлына тыгып җибәрде, аннан, тагын да кәефе килеп, мекер-мекер килеп, и-һи-һиләп майлы авыз тирәләрен йонтәс кул сырты белән сөрткәндәй итте, байларча гасабиланып кикерде, шартлатып һава чыгарды да, җыештырына башлады.

Анардан башка китеп барыр дип курыккан малай арткы яктан машинага күтәрелеп тә өлгермәде, тегесе моторны кабызып, кузгалып та китте. Иннәкәнтәй анын барлыгын бөтенләй дә оныткан иде бугай. Юлда нинди генә күңелсезлекләргә тап булмасын, Канәгатьнең күнеле күтәренке иде. Алай гынамы, рәхмәтле иде. Мондый озын күперләр аша чыга торган шундый ерак, җаваплы юлга чыгарган Габдулла бабасына, шушы юлга үзе белән алган Иннәкәнтәй дәдәсенә дә, ул ничек кенә ерткыч кыйланса да, рәхмәтләр укыды. Шул ук вакытта йөрәге әрнеп борчылды да. Әгәр урап кайткач, бабасы "Әйт әле, ташбаш, игенне юл буена коеп бармадыгызмы? Сатып эчмәдегезме?" дип сораса, ничек җавап бирер? Коелып барды, дисәң, нигә Иннәкәнтәйне туктатмадың, диячәк. Коелмады, дисәң—ялганлау булачак.

Анын каршында табигатьнең яңа могҗизалары ачылды. Шар тәгәрәтерлек тигез иген басулары сул яклап җан-фәрман йөгереп киләләр дә, Димнең уң ягыннан рәт-рәт булып күтәрелгән тау тезмәләренә бәрелеп туктыйлар. Ул тауларны гүя кемдер пәке белән кыеп, бер рәткә тезгән, кайберләрен аерып алып, күкрәк-күкрәк итеп өйгән, әвәләгән, түгәрәкләгән дә, бар кешелек күрсен өчен барчасыннан да югарырак күтәргән. Әнә, берсенең яссы күкрәгенә эре ак ташларны тезеп, "Л е н и н" дип язып куйганнар. Кара әле, җәйпәк ташлар белән дә язып була икән, ә? Юлга чыкмаган булса, ул мондый могҗизаны кайчан күргән булыр иде? Кара әле, йөреп кайткач, авыл каршындагы тауга дус малайлары белән бергә алар да берәр нәрсә язып куя ала бит, ә? Тик ни дип язарга? Иң кадерле сүз булырга тиеш бит ул. "Ленин" дип язарлар. Ярар, Ленин булсын. Шулай тиеш. Ә бәлки, ә бәлки... "Без җиңдек!" дип тә өстәргә кирәктер. Әгәр сугыш булмаган, без җиңмәгән булсак, шулай дип булган булыр идеме? Әгәр анын атасы сугышта һәлак булмаган булса, аны Габдулла бабасы Әкчингә җибәргән, мондый матур җирләрне күрә алган булыр идеме? Анын аша, ток суккандай, шаукым үтте. Кара әле, аларнын сыйныфында гына да кырык бер укучынын утыз икесе сугыш ятиме бит. Инәләре әйтүенчә, Колтамак үзенең бер генә ятимен дә детдомнарга тапшырмаган. Менә шундый бала җанлы аларның авылы!.. Бәлки тау битләвенә "Кайтыгыз, этиләр!" дип тә язаргадыр? Язарга кирәк, язмый диме!.. Өязе, Кәркәле тауларында ак җәйпәк ташлар җитәрлек бит. Язгач-язгач, тауларга янгырлар юган ак ташлардан киләчәккә хат язарга!..

Алда, уң тарафта, урманнар артындагы биек сөзәклектә йөзләгән шакмак йортлары белән авылмы-шәһәрме шәйләнде. Офыкта кап-кара төтен чылбырлары аркан булып ишелеп ала да, икенче карауга каядыр югала.

Нәрсә булыр бу? Поездлар йөри торган Әкчин шушы мәллә? Кара, вакыт ничек тиз үтте! Сәгать дигән нәрсәне төшендә дә күрмәгән малай йөзен чытып күккә карады. Кояш нәкъ анын баш түбәсендә балавыз булып эри иде. Төш житкән.

Юл тар агачлыклар буйлап барды-барды да, урамнары белән әллә каян күренеп торган жәйпе кебек тигез сөзәклеккә күтәрелә башлады. Офыктан үзе артыннан тагын да кара аркандай эз калдырып, бик каты кычкыртып, ниндидер кап-кара нәрсә үтте. Малай аңлады—бу анын әле беренче тапкыр ерактан күргән паравызы булырга тиеш.

Машина кинәт шып туктады.

Иннәкәнтәй дәдә кабинасыннан чәчрәп килеп чыкты. Анын кашлары һәм күз аралары ачудан тагын да таралыбрак киткән иде.

—Ну-ка, слезай!..[1]

Бернәрсә дә аңламаган малай нәрсә эшләргә белмичә утыруын дәвам итте.

Шофер тагын да каты итеп сүгенде һәм авызыннан ак күбекләр чәчрәтеп жиргә төкерде.

"Әллә куып төшерергә итә инде" дип шикләнергә өлгергән, әмма мондый да зур абзыйның аны, авылдан үзе белән бергә ерак юлга алып чыккан сабыйны, бер ялгызы кола-яланда торгызып калдыруын күз алдына да китерә алмаган Канәгать Иннәкәнтәйдән курыкмый, шул ук вакытта анын мондый явыз эш эшли алуына һаман да ышанмый иде.

Иннәкәнтәй дәдә кулына моторны әйләндереп кабыза торган кәкре тимер тотып кабинасыннан чыкты һәм селәүсен сыман күзләреннән яшеннәр сосып, кузовка сикереп менде:

—Ты еще не слушаешься, монгольский ублюдок!..[2]

Һәм Канәгатькә селтәнде.

Ашлыгы өстендә багана кебек каткан малай кымшанмады да.

Мондый сабырлыктан Иннәкәнтәйнең сары кыллар баскан йөзе аларып күгәрде, икесе ике басуда урак урган күзләрен кызыл кан басты, ул тирәюньне сасы ис белән тутырып, әллә нинди мекертәгән авазлар чыгарып, малайга ташланды. Малай дигәне акылияләренә хас кинаяле олпатлык, каршылыксыз затлылык, ул гынамы, өлкәннәргә, аксакалларга хас түзем, ихтыяр дә күрсәткәч, чыгырыннан чыккан Иннәкәнтәй, кыргый ачу белән дәжжалланып, сигез яшьлек ватандашын бодай көшеле өстеннән бөтерә салып күтәрде дә, шул бөтергән килеш кузовтан түбәнгә ыргытты.

Песи баласы сыман бөтерелеп, Канәгать аяклары белән һавада әйләнде һәм жиргә тәпиләре белән төшәргә өлгерде.

Таш юлда аны аксыл тузанга күмеп, Мәскәү "ЗИЛ"ы китеп тә барды.

Бая машина әржәсеннән коелган бөртек иген өчен үксеп елаган малай хәзер, кола-яланда, чит-ят тарафларда бер тиенсез, бер кыерчык иписез калып, хәтта кыйналып та, елау турында уйламады. Бу хәләт бик тә сәер иде, үзе бер күктән төшкән хәер иде.

Канәгать башта берни булмагандай машина киткән якка жәһәт-жәһәт атлавын дәвам итте. Ул кире борылып, авылына да кайтып китә ала иде. Ләкин ана кояш бары тик Әкчиндә чыга, Әкчингә кереп бата—дөреслек аны бары тик Әкчиндә генә көтеп тора кебек иде. Ул Иннәкәнтәйгә нишләптер рәнжемәде. Ана калса, сугыш иртә житлектергән сабый акылы белән аңлый иде: ул кичергән газап—ана тиешле газап, күктән төшкән гадел жәза. Гүя ул анын канын, тәнен сафландыра, иман-аманга сыгындыра торган бәрәкәте иде...

---

[1] Әйдә, төш әле!.

[2] Син әле тыңламыйсың дамы, уйнаштан туган монгол! (Рус.)

Кайдадыр берничә теленә берьюлы басып гармун кычкырттылар. Нәрсәдер тыкы-тыкы килеп тыкылдап якынайды һәм шулай ук тыкылдап ерагайды. Тирән чокырга төшкән юлдан килгән, офыкларны шул чокырның сөзәк үре һәм өйләр каплаганлыктан, Канәгатькә баягы төтен арканнары күренми иде.

Арттан килеп узып киткән, каршысына килгән йөк машиналарына юл бирә-бирә, ул, тәнендә жаны һәм бер кат күлмәк-ыштаныннан башка бер нәрсәсе булмаган сабый, тирән чокыр аша чыкты һәм картлар сыман кулларын артка куеп, жай гына үргә күтәрелә башлады.

Тагын да йөрәккә төшеп гармун кычкырттылар. Юк, паравызлар кычкыра түгелме? Ул чуен юллар нииндирәк була икән? Алардан поезд дигән нәрсәләр ничек йөри икән? Чокырдан чыгып житмәгән Канәгать паравызларның үзләрен күрә алмый иде, әлбәттә. Чуен юлларның ялгауларына суклыгып тыкылдаган тәгәрмәчләр тавышы анын зиһенен әллә кайларга алып китте. Ул барды да барды. Бу битабигый аһәңнәрдән ул бер башка үскәндәй булды һәм бүген кичергән кичерешләрдән кызарган күзләре белән инде йорт араларыннан ачыла башлаган офыкларга укталды. Кинәт ун һәм сул тарафтан дөпелдәп һәм тыкылдап, бар көчләренә кычкыртып һәм күк гөмбәзен тетрәтеп, станцада туктарга да уйламыйча, моржаларыннан кара төтен кисәкләре ыргыта-ыргыта, яшен тизлеге белән бер-берсенә каршы килеп, нииндидер зур, кара таракандай чем-кара галәмәтләр үзләре артыннан дистәләгән озынча йортларны өстерәп үтеп киттеләр. Малай уйлавынча, поезд дигәннәре шушы булырга тиеш. Бер очракта чынлап та күп телле гармун, икенче очракта жиз торба, көмеш быргы аһәннәрен хәтерләткән тавышлар озак кына һавада эленеп торды да эреп югалды. Малайга бу аһәңнәр атасын сугышка алып киткән моң булып тамагына торды. Анын жанында көтмәгәндә шигырь сыман әкәмәт яралды: “Бодае-арышлары, паравыз тавышлары, сугышлардан кайтмый калган әтәйнең сагышлары...” Каядыр еракка китеп бушанган бу һәлакәтле аһәңнәрдә еракта—житмеш чакрымда калган Ватаны, инәсе, дуслары, каз бәпкәләре бар иде. Менә кайчан анын тагын да елыйсы килеп китте! Йөк өстендә килгәндә, хәтта чуаш авылында иген өчен Иннәкәнтәйгә ташланган чакта да ул кайгысыз булган икән бит. Менә кайчан гына яралды аның жанында кайгы-сагыш! Таулар-ташлар арасында югалып калган кечкенә авылдан зур йөк башында зур дөньяга чыккан малайның кайгысы хәзер туган төягең, туган инәсен, туган абыйларын, туган кош-корт, туган мал-туарларын да кертеп зурайган иде. Менә тагын паравыз кычкыртты. Башта ул инәсенең әлүмин калак белән казан төбенә ябешкән касмакны кыруын, аннан көзге күк йөзенә чөй булып кадалып, көньякка очкан торна, кыр казлары тавышларын, аннан килеп, кышка керергә әзерләнеп куерган көмеш агымсуларда коенган сугым казларының кыйгылдашканын хәтерләтте. Ул бүселеп чыккан яшьләрен буш кулларының сырты белән тыйды. Кайта алырмы ул авылына? Сөйләүләренчә, сугыштан соңгы елларда тимер юл, вокзалларда үрчегән бандитлар, жиганнар тотып үтермәсме?

Әмма Жир түгәрәк иде. Кайдадыр жинелгән Германиянең нииндидер Магдебург дигән бер каласында, жимерек йортның подвалында, әнисез һәм әтисез калган нимес малае да, вокзалга чыксам, оккупацион гаскәрләр тотып алып үтермәсләрме дип, бер Аллаһка зарый кылып елый иде...

Вокзал жиганнары турындагы ачык, кискен фикер аны айнытып жибәрде. Ул мөмкин кадәр тизрәк Әкчин элеваторына барып житәргә, шуннан Колтамакка булмаса, һичьюгы алар ягына кайта торган берәр машина, атка эләгеп булса да кайтырга тиеш!..

Ул тау битләвенә сирәк итеп, киң итеп утырган авылга керде. Шушы да булдымы шәһәр!.. Тавык кетәклеге бит бу!.. Рәвеше белән Колтамакка

охшамагач, бу авыл, Канәгатьнең уйлавынча, татар авылы түгел иде. Паравызлар чакырган тарафка атлый торгач, аның юлы кинәттән унга борылды һәм сулда, биеклектә кешеләр белән кайнап торган ак ташпулат янына килеп чыкты. Бинаның уң канатындагы, югарыдагы "С-т-а-н-ц-и-я А-к-с-е-н-о-в-о" дигән язуны хәрефләп укыды. Эссе кояштан, борчылудан болай да тирләгән малай бу исемнән шыбыр тиргә төште. Авылдашларының кая барсалар, каян кайтсалар да, авыз суларын корытып сөйләгән "Әкчин, Әкчин вокзалы" дигәннәре шушы буладыр дип нәтиҗә ясады ул. Ниндидер эчке тавыш аңа әлегә вокзалга бармаска кушты. Еракта, юлның ниндидер стенага килеп төкәлгән очында чиратка баскан йөзләгән машиналарны күреп, малай шул тарафка китте. Бәлки дәдә Иннәкәнтәй, ялгышын аңлап, аны эзлидер, аны күрер дә, йомшарып китеп, үз янына чакырып алыр, тамагын да туйдырыр? Машиналарның күбесенең ишекләре шәррән-ярра ачык: шоферларның кайсылары каршыдагы йорт күләгәсенә тезелеп утырганнар да, кәрт сугалар, кайсылары тамак туклык итә, кайсылары гәп кора... Әгәр аны Иннәкәнтәй дәдәсе тотып алып, "Ник йөрисең монда?" дип кыйнаса, Әкчин милисияләренә, жуликларына тотып тапшырса? Нәрсә булса да булыр, дип ул машиналар арасыннан алга таба баруын дәвам итте. Ниһаять, машиналар чираты кереп чумган зур ябалдашлы капка, ихата эчендә, тирәндә йорт дисәң йорт, абзар дисәң абзар булмаган, үтә дә биек, сәер шакмаклардан өелгән, багана сыман шөкәтсез, бернинди тәрәзәсез бина каршына килеп чыкты. Укыды. "А-к-с-е-н-ов-с-ки-й э-л-е-в-а-т-о-р". "Ә-ә, иген жыя торган урын,"—дип уйлады ул. Капка төбендә милисия киемендәге коралды сакчыны күреп, кире борылды. Инде машиналар рәтен ерып чыктым дигәндә генә, гомуми рәттән чыгып, бер читтәрәк туктаган "МС 31-45" дигән сан язылган машинаны абайлап алды. Бу аның Колтамактан килгән үз машинасы иде. Түгәрәк күкрәкле матур бу машина аның өчен туганнары кебек кадерле, авылдашы кебек якын иде. Ул аның янына кочаклардай булып йөгереп барды. Машина астында, иген калдыгыннан үсеп чыккан чүп үлән өстендә ничектер ыржаеп һәм чалшаеп, битендәге сары кылларын, таркау кашларын, лайлалы иреннәрен чебен баскан Иннәкәнтәй дәдә йоклый иде. Машина аңа үз, ә менә аны йөртүчесе жиде ят иде. Ул жирәнгеч дәрәҗәдә ямьсез, котсыз иде. Малай жиргә иелеп, кулына таш алды. Менә хәзер, менә хәзер шушы ташы белән аны оятсыз сүзләр белән күмгән авызына тондырам дигәндә, ул тыелып калды. Бәлки ул, Иннәкәнтәй, тумыштан менә дигән кеше булгандыр, бәлки аны эчкелек чире генә шундый хәлгә төшергәндер?.. Күзем күрмәсен, дигәндәй, ашыгып китеп барды.

Коймалары урам ягына тигезсез чыгып-кереп торган, нигез буйларын кычыткан, әрекмән баскан, һәркайда ниндидер ятсөяклек тойгысы күзгә бәрелеп торган, барысыннан да бигрәк, аның туган телендә сөйләшкән, Колтамакка ничек кайту юлларын сорашырлык кешеләр бөтенләй дә очрамагач, кире вокзал ягына китте. Үзенә тукталыр урын тапмыйча, бу яланаяклы, карасу зәңгәр төстәге малюскин чалбар, ике сәдәпле аксыл күлмәк ишарәтендәге, житкән чәчләренең оч-очлары кояшта көйгән, жете зәңгәр күзле малай тора-бара вокзал белән элеватор арасын берничә тапкыр урады. Арыды. Ниһаять аның карашын авылларындагы Сәләхетдин картларның келәтсыман өе кебек бәләкәй өй жәлеп итте. Урам ягына ике кечкенә тәрәзәсе белән карап торган, почмагы сәрби куаклары белән яшәргән бу хужалык бик тә ярлы, әмма нәрсәсе беләндер мөлаем иде. Ул такта арата эченә туфрак тутырылган нигезгә утырды. Колагына каяндыр бип-бип итеп саркылып чыккан авазлар чалынды. Тирә-ягында бернинди каз бәпкәсе күренми иде. Әллә артыннан үзенең бәпкәләре килеп життеләрме дип ул өйне тирәләп чыкты. Кечкенә капканың ярыклары аша күрде—ихата эчендә яшел үләнгә

куелган зур бакыр ләгән тирәсендә сары йомарламнар булып оеп, каз бәпкәләре чемченә иде. Аның бәпкәләрне тотып яратасы һәм чемченгән бәпкәләргә карап торгач, тагын да ашыйсы килеп китте.

Кесәсендә кара көнгә дип саклаган бер-ике уч бодай орлыгы барлыгы исенә төшкәч, шуны булса да чәйнәштерим дип кесәсенә кулын тыккан иде, андагы шома, салкынча нәрсәгә кулы тиеп чирканып куйды. Чыгарса, аптырап китте—уч төбендә имән яфрагы!.. Туган авылы урманнарыннан чыкканда машина әрҗәсе өстеннән генә өзеп алган имән яфрагын бөтенләй дә оныткан ләбаса!.. Дымланган күзләре белән имән яфрагының яшел сумитенә, таза аксыл җепселләренә карап торганнан соң, янадан кесәсенә тыкты да, бодаен ашамаска—түзәргә булды. Ашамыйча бет тә бер ел түзә диләр. Канәгать кеше бит, югыйсә. Тамак ялгарга бирәр төрле ташландык ризык, үлән-мазар күренмиме дип тирә-ягына каранды. Иртәдән бирле авызына кәтрә дә капмый, тамак йотыгуы аркасында чамасыз сагайган, хиссияте нечкәргән малайның колаклары төбендә нәрсәләрдер мылтыктан аткандай шарт-шорт килә башлады. Бу сәрби куакларының өлгергән кузаклары шартлап ачыла икән. Малай кул яссуы белән кузакларны сыдырып алды һәм аларны арчып, эчләрендәге кечкенә кара борчакларны авызына коеп азапланды. Сәрви борчаклары теге кара нимес борчагы кебек туклыклы, тәмле түгел, болай да ач кешенең ачуын китерер дәрәҗәдә төче һәм лайлалы иде. Канәгать кузакларны кире куаклары төбенә атты.

"Сусын сазлык эчертә, тамак дингез кичертә", дигәндәй, ашказаны чөрләвенә түзә алмаган Канәгать ипи катысы булса да табылмасмы дип вокзалга барып урарга ният итте. Урамда кыргый этләрнең күбәюе, биредә туфракның соргылт булуы да ошамады аңа. Колтамактагы кебек яшел хәтфә үләннәр дә, йөзьяшәр өянкеләр дә күренми. Көн буена бер җырлаган кеше очратмады. Аларның Колтамакларында һәр тал яфрагы сайрый, һәр кеше җырлый. Кызган ташта аяк табаннарын пешерә-пешерә, ул платформага күтәрелде. Алдында көмеш өслекләре белән ялтырап һәм якты нурлар булып таралып, гомерендә беренче мәртәбә күргән чуен юллар ята иде. Озын-озак тоткарланмыйча, песи саклыгы белән ул вокзалның эченә үтте. Тамак туклыгы итеп утырган берничә адәм каршына туктальш торганнан соң, тегеләр, башларына килеп, бернәрсә дә сузмагач, ояла-тартына гына, чүп савытына якынайды, инде аңа килеп җитте дигәндә, туктап тормыйча, үткен карашы белән савыт төбен сосып алды да, өметле нәрсә күзгә ташланмагач, кискен борылды һәм песи адымнары белән шома басып, вокзалдан чыкты.

Платформада халык күп, алар барысы да үзләре күтәргән капчык-чумаданнары кебек телсез җитди һәм ифрат дәрәҗәдә үз кайгылары белән генә яшиләр иде.

Кинәт платформаның теге ягыннан башына зәңгәр сызыклы кызыл фуражка, өстенә тетелеп беткән күн кием, күкрәге өстеннән әлүмин тимерчыбыкларны хәрбиләрнең каеш портупеясы кебек итеп аркылы-торкылы ураган, бер аягына иске итек, икенчесенә бармаклары күренеп торган башмак кигән, йөзенә нindidер кызыл тимгелләр бүрткән кеше пәйда булды һәм саф татар телендә игълан ясарга тотынды:

—Гражданнар!.. Уфа-Симферополь поезды Шафран станцасыннан Әкчин станцасына таба килә!.. Билетларыгызны компостерить итәргә китерегез!.. Билетларыгыз белән бергә атланмайга, ипигә талуннар да таратачакмын!..—Ул поезд көткән кешеләр алдыннан үтеп, билетларын алган, нindidер жайланма белән тишкәләгән һәм кире кайтарып биргән булып йөри башлады.—Карагыз аны, ипи-майга талонсыз утырасы булмагыз!.. Бу поездда иптәш Сталин үзе килә!.. Иптәш Сталин үзе тикшерәчәк!..

Аның бу уенына күптән өйрәнгәннәр, шуна беркем дә, хәтта поездны

каршылаучы тимер юл хезмәткәрләре дә игътибар итмиләр иде кебек.

—Монда барысы да минем хужалык!..Без хәзер иптәш Сталин белән налукларны бетерәбез! Елмаеп, көлеп яшәгез!.. Менә минем кебек! Ха-ха-ха-ха!—Һәм күкрәгенә аркылы-торкылы тимерчыбык чорнаган адәм буылып-буылып көлә башлады.—Башта налукларны, аннан талуннарны да бетерәбез!..

Юлга чыкканыннан алып туган телендә бер кәлимә ишетмәгән малай Колтамакка ничек кайту турында менә кемнән сорашып калырга кирәк иде, дип уйлап өлгермәде:

—Эрәзве налуктан, талуннан башка яшәргә мөмкин?!—диде бер киез эшләпәле карт.—Тормышның ни кызыгы кала?

Аның янәшәсендә торган бер абзый аны тынычландырды:

—Борчылма юк өчен. Акылдан язган бит ул. Сугыш вакытында Әкчиндә станца начальнигы булып эшләп, нахакка төрмәдә какланган...—диде.—Төрмәдән, әнә, нинди матур чир—көлү чире йоктырып чыккан...

Тагын да йөрәген телеп һәм күк гөмбәзен тетрәтеп килгән паравыз кычкыртты. Вокзал бинасыннан халык күренде.

—Иптәш Сталин килә!.. Халыкны налуклардан азат итәбез!... Көлегез, шайтан токымнары!..

Тизлеген тәмам акрынайткан паравыз пар белән пошкыллап һәм ниндидер жиз тәлинкәләрдә чаңнар сугып, Канәгатьләр торган тәңгәлгә якыная башлады. Шулчак вокзалның кызыл кирпеч бинасы артыннан кызыл кикрикле, бәлшәйгән галифиле ике милисия йөгереп килеп чыкты, аларны күрү белән эләктерәләр дип шыр жибәргән Канәгать үзе килгән урам ягына сикерде һәм платформа артына чүкте. Әмма милисияләрнең анарда уйлары да юк икән. Кызыл кикриклеләрне күрү белән "Сталинны көтеп тилергән" абзый киң итеп елмайды һәм, кочакларын жәеп, аларга таба ташланды:

—Сагындым!.. Сезләрне сагындым, әхирәткәйләр!..

Күкрәгенә аркылы-торкылы әлүмин чыбыклар бәйләгән абзый милисияләрне кочакларга, чут та чут үбәргә тотынды. Тегеләр исә өйрәнелгән алымнар белән аның кулларын каерып, йөгертә-йөгертә алып та киттеләр. Ул артына борылырга тырышып, халыкка кычкырды:

—Хуш-шыгыз... Ыс-стал-лин барыбер кил-ләчәк!..

Бу күңелсез күренешләрдән үзенә урын, жанына рухи, ашказанына матди азык тапмаган Канәгать янадан теге өй янына килде. Ниткән шәһәр бу, хет бер сорашыр, киңәшер кешесе очраса!.. Элеваторы да, капкорсак, тирә-ягын чиратка баскан иген ташучылар белән чолгап алып, карынына туктау белми ашлык тутыра да ашлык тутыра, ә беркем белән күзгә-күз карап сорашып-сөйләшеп булмый! Бернинди элеватор да түгел—элеп атыр ул, чурту матыр!.. Тирә-ягы тулы кеше—кешесе юк! Ашлыгы таныш—кешеләре таныш түгел!..

Малай, уфырып, күз күреме житкән ераклыкларга карады. Кайдадыр Мәнәвез урманнары, Дим тугайлары артына барып батарга жыенган кояш станцаның таркалып яткан, көне-төне иген ташып, тыз да быз чабышкан йөк машиналарының тузаны белән генә тукланган ташландык өйләренә, аларның ятим, моңсыз тәрәзәләренә, тәрәзә төпләрендәге күшеккән сәрби куакларына ярала гына башлаган кечке шәфәкътән янгын кабызып, офыкка таба түбәнәя башлаган иде.

Ул инде авылына бүген кайта алмаячагына да ышанган иде. Кесәсендәге бодай орлыкларын кырып-себереп ашаганнан соң ашказаны бераз гына суырудан туктагандай итте. Көне буе көтелмәгән гамәлләрдә, хиссияттә талкынып арыган Канәгать паравызларның моңсу тавышлары астында өйнең бура очлары чыгып торган почмагына сенеп йоклап киткәнен дә сизмәгән...

Күпме йоклагандыр, янәшәсеннән генә үкереп үткән йөк машинасы гөрелтесеннән уянса—көне буе ялкынланып янган, инде хәзер үзенең артыннан

алсу байракларын жиргә ямаулык итеп коя-коя күзләрен кызарткан кояш инде чынлап та баюга бара иде. Төнен бередә үткәрер микәнни? Өендә нихәлләр икән? Аны югалтып елыйлар микән? Иннәкәнтәй авылга кайткан булса, балабызны кая куйдың дип измәсен изәләр микән? Кинәт күз алдына аның үзенең ак кәфенгә төрелгән үле гәүдәсе пәйда булды. Ул күзләрен йомды. Әнә, барча авылдашлары елый, имеш. Инәсе, абыйлары елый. Габдулла бабасы Иннәкәнтәйне ындыр табагы уртасындагы баганага бәйләгән дә: "Менә сина, кәнтәй, бер бөртек иген өчен! Менә сина, кәнтәй, икенче бөртек иген өчен!.." дип камчылапмы камчылый, имеш!..

Дөньяда үзен яклаучылар табылачагына ихластан куанган малай, кәефе килеп, танауларын мышкылдатып алды. Ул күккә карады. Гүя гаделлек шунда иде. Әмма анда шырпы кадалып күзе кызарган кеше сыман канаган кояштан, элеваторның иген исе белән аңкыган бай күген биләп, түгелгән орлык белән түшәлгән туфрагы өстеннән чайкылдап очкан бала чәүкәләр өереннән башка бернәрсә дә күренми иде.

Төн кунып чыгар урын кирәк иде. Кая барырга? Вокзалга? Элеп-атырга? Әллә җәяүләп юлга чыгаргамы? Төнгә каршымы? Урманнар-таулар ашамы? Ул урманнардан куркуын курыкмый, әмма аңа ниндидер эчке тавыш төнгә каршы Әкчинне ташлап чыкмаска кинәш итә иде. Ә ул нигә берәр кешегә кереп, бер кичкә генә сыеныр почмак сорамый? Бардыр әле монда юньле кеше, шулай бит? Аh, урысча да белсә!.. Ул ниндидер бер карарга килергә теләгәндәй, ихтыяри талпыну белән утырган нигезеннән күтәрелде, урамны кисеп чыккан тыкрык чатына килде һәм аптыраган кыяфәт белән таптанып тора башлады.

—Нишләп торасың монда?

Малай тавыш килгән якка борылды. Әннекәй генәм!.. Бүген үзе көн үткәргән өйнең ихатасы эченнән кече капкасына сөялеп, аңа бер мөлаем әби карап тора һәм... татарча эндәшә!.. Куанычыннан нишләргә белмичә, жай гына адымнар белән жирне жентекләп, туган аһәңнәр янгыраган тарафка килә башлады. Менә килеп тә житте. Мөлдерәмә күзләре белән ул әбкәйгә карады. Ана күп елаудан тозланып агарган ак керфекле, аксыл йөзле, кызгылт-сары күлмәген ыштан бөрмәләренә кыстырып куйган, кулына берничә баш кыяклы суган, сутлы кишер яфраклары тоткан карчык карап тора. Һәм ул, малай ишетмәде дип булса кирәк, янадан сорады:

—Нишләп торасың, дим. Тамчылы гөл кебек?

—Таптанып торам...—диде Канәгать нәрсә әйтергә белмичә.

—Күп таптанып торсаң, тапталып та куярсың әле... Әкчин диләр моны сина!..—Карчык урам ягына чыкты, каршысында басып торган үксез баланың өс-башын, килеш-килбәтен чамалап булса кирәк, сөйләмен балалар теленә күчереп дәвам итте.—Баядан бирле карап торам да, нишләп, мин әйтәм, бер ялгызы, ләкләк кебек йә бер, йә икенче аягында басып тора? Син ләкләк дигән кошның бер аягында торган хәлдә генә уйлый алганын беләсеңме?

—Юк. Белмим. Ләкләген дә белмим. Ул безнең Колтамакта юк.

—Белмәсәң, бел. Бәхет кошы бар. Аның исеме ләкләк. Бер аягында басып кына уйлана ул бәхет турында. Ике аягына да басса, уйлый алмый. Башы эшләми. Аңладыңмы хәзер?

—Аңладым.

—Аңласаң, ярый. Ә менә син нинди бәхет турында уйлыйсың?

Карчыкның ниндидер тирән моң, рыясыз кинәя, яшерен сабырлык белән сугарылган сүзләре малайда ышаныч тудырды.

—Мин адаштым. Мин адаштым, әби!..

Еламас та иде. Нәкъ шул мәлдә йөрәкне өзеп паравыз кычкыртты. Малай тулышкан яше белән бүселде дә куйды.

—Йә, йә!.. Тынычлан, улым!.. Кеше яше—алтын бәһасе!.. Хәер, кич еласаң, иртән елмаерсың, дигән борынгылар. Каян соң син?

—Колтамактан.

—Колтамактан? И-и, сабый!.. Кайлардан килеп чыккан якташым икәнсең. Мин үзем күрше Качаганнан гына бит. Кем баласы буласың?

—Минсылуныкы.

—Һи-и, Минсылуныкымыни?.—Ул Канәгатьнең аркасыннан дөпелдәтеп сөйде.—Өязе буйларында туып-үскән кешеләр мина туганнарым кебек якын. Шуннан күчеп килеп, нәселемне корыттым мин бу шайтан оясында!.. Бу якларга ничек килеп чыгар иттең?

Малай барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Инде тәмам баеп барган кояшның бәләкәй капка такталарына яткан канлы кызыл тукымасын бармак очлары белән сыйпап, аның күзгә күренмәс матдәсен тәсбих тарткандагы сыман изә-изә, вакыт-вакыт "Кара син аны, явыз!", "Кара син аны, балага үчләшкән бугавыз!" кебек тәгъбирләр кыстырып тыңлаган карчыкның йөзе житдиләнгәннән житдиләнә барды.

—Шулай, бәбкәм. Юлга чыккач кына күренә кемнең кем икәне. Шуңа күрә "Юл газабы—гүр газабы" диләр бит... Житмеш чакрымнан алып килеп, кола-яланда төшереп калдырды диген, ә? Урыс түгел бу—каткан, жулга аркылы жаткан курыс!.. Урысның да менә дигәннәре, татарына биргесезләре бар... Утыртып жибәргән кешеләрен әйтер идем!..

Карчыкның әле генә шәфәкъ алсуына баткан гәүдәсе түбәннән—әүвәлдә аякларыннан башлап, аннан бу кичкә энгер-менгер биленә житеп, биленнән соң иңнәрен дә биләп алды һәм, ниһаять, тора-бара шәфәкъ ялкынында бары тик башы гына ялкынланып калды...Ул карашы белән бер ноктага текәлеп, ниндидер бик тә катлаулы мәсьәлә чишә иде.

—Әйдә, булмаса... Үзебезгә керик. Илаһым үзе сине безнең нигезгә жибәргән.—Ул аның колагына иелеп пышылдады.—Тик... абыеннның тәмсез теленә, бездәге ярлылык, тишек-тошыкка аптырама, ярыймы?..Якташым, житмәсә, ерак кардәшләремнең бәлигъ булмаган баласын төнгә каршы шушы бандитлар арасына чыгарып жибәрәм буламы? Жук-жук!.. Хет үземнең жаным тыныч булыр. Әйдә!.. Бисмиллаһ!..

Ул әбисенең исемен сорарга тартынды. Эченнән генә аны Йомшак Әби дип атады.

Йомшак Әбисе аны-моны аңлап өлгермәгән малайны житәкләп алды һәм ямь-яшел үләндә никтер бик тә сонарып чыккан каз бәпкәләре бип-бип килеп үлән чиерткән ихатага алып керде. Аның үз бәпкәләрен Өязе буеннан кем алып кайтты икән? Көне буе ташландыклык хөкем сөргән авылда сәяхәт кылган Канәгать мондагы тәртип, жыйнаклыкны күреп аптырап калды. Әби кулындагы суганнарын һәм кишер сабаклары бәйләмен ялт итеп рәшәткә аратасына кыстырып куйды. Һәркайда бәйләм-бәйләм үлән, сары һәм зәңгәр мәтрүшкәләр, юкә, имән, карлыган һәм башка әллә нинди яфрак-үсемлекләр кипшенеп торган ихатаның эче үзе бер тере картинкә булса, андагы лапас өрлекләрендә шулай ук ниндидер дару үләннәре эленгән кечкенә кош-корт абзары тыштан уенчык кебек жыйнак иде. Өйнең акташлардан түшәлгән болдырына житәрәк, үзен аякларына авыр герләр тагылгандай итеп тойган карчык, адымнарын кискен акрынайтты, аннан тәмам туктады.

—Тик менә нәрсә, бәбкәм... Жир жөзендә никадәр төрле кеше, кайгысы да шулкадәр төрле булыр. Менә синең үз кайгың, ә менә минем үз кайгым...Тик син кеше кайгысын артык кайгыртып, үзеңнең жаныңның ап-ак үзәген карайтасы булма, ярыймы? Өйләре бигрәк бәләкәй шырпы кабы икән дип тә уфтанма. Күңелең киң булса сыясың ул. Салихжаным сугышка кадәр алты почмаклы йорт бураткан иде. Күтәртергә өлгерә алмыйча, шушы

бәдбәхет сугышта ятып калды.—Аның тел очы көрмәлде, тавышы өзлекте. Бер алга, бер артка каранды һәм, кеше анламасын дигәндәй, танау астыннан гына мөңгерәп сөйли башлады.—Син безнең өйдәге мәгыйшәткә, мәхшәргә... абыена игътибар итмә!.. Тәмугта яшим!.. Тәүбә-тәүбә, мин әйтмәдем!.. Минем белән бер кич гомер хакына хәзер син дә тәмугка керергә мәҗбүрсең. Игътибар итмә!..” Бер кичкә—кер мичкә” диләрме?.. Сугыштан шулай имгәнеп кайтты. Унҗиде җәшендә... бердәнбер улыкаем...фәрештәм...сугышта ярты сансыз калып, дәҗҗал булып кайтты!.. Курыкма,бездә озак торалмассың. Курыкма, чакырылмаган кунакның вакыты ике көн аның. Өченче көнендә аңа китсен дип тары боткасы пешерәләр!.. Җоласы шундый!..

Кинәт өйнең иске бишмәт чабуы кебек җилдә җиңеләйгән, калтайган ишеген эчтән этәреп җибәрделәр, ишек шаңгырдап ачылды, арткы стенага бәрелеп, кире килде һәм ябылмыйча бер урында калтыранып торды-торды да туктады. Эчтән дүрт елтыр тәгәрмәчләргә ныгытылган такта көймәсенә утырган килеш тәгәрәп, акайган күзле, тырпайган кара мыеклы, кайчандыр аклы-зәңгәрле булган дингезчеләр тилнәшкесе кигән, тилнәшкесе өстеннән берничә елтыр медаль таккан, башына шул ук дингезчеләр бескозыркасы чәпәгән адәмзат килеп чыкты. Ул ике кулы белән этәрелеп китеп, эчке идән сайгагыннан таш болдырга, таш болдырдан гокылдап җиргә сикереп төште дә, Йомшак Әбинең аяк очына килеп тәртелде. Канәгать куркып калды. Куркып калырлык та иде шул. Аларның авылында йә кулсыз, йә аяксыз, күзсез, колаксыз, хәтта кулсыз-аяксыз сугыш янбалитлары да бар, әмма ләкин аның моның кебек ике аяксыз, гәүдәсе билдән үк киселгән, шушылай билдән киселеп, түмәргә торып калып та, һавада очып сикереп йөргән янбалитларны күргәне юк иде.

—Син кайда йөрисең, кортка?! Баягы шешәне кая тыктың?!—дип акырды Ике Аяксыз.—Хәзер үк чыгар, живо!.. Балтфлот көтми!..

Малай чатыртап Йомшак Әбисенең итәгенә ябеште.

—Улым! Сабыррак!..—диде Йомшак Әбисе.—Бу бала Колтамак авылыннан...

—Колтамактан булмагае, фәлән... тамактан булсын!.. Мин синең авылыңны, фәлән-фәләнең белән!..

—Мәскәү шоферы игенең саклатып алып килгән дә, Әкчингә житкәч, төшергән дә калдырган...Бар бит шундый имансыз кешеләр дөньяда... Адашкан, мескен!..—дип улына зарын аңлатырга тырышты карчык.

—Дөрес эшләгән!.. Песи балаларын вакытында батыралар!..

Матрос шундый да ямьсез, шундый да катлы-катлы итеп сүгенде ки, ихатага әллә хәзер татарча сүгенергә өйрәнгән Иннәкәнтәй үзе килеп кердеме дип, малай тартышкандай итеп, тирә-ягына карады. Менә кадәр, авылда үзен хәтерли башлаганнан алып, “И-и, мәхәббәтсез! И-и, имансыз! И-и, миһырбансыз!” кебек йомшаккайдан башка нәрсә ишетмәгән, жир йөзендә бу кадәр дә ямьсез, котсыз сүзләрнең барлыгын күз алдына да китермәгән Канәгать боларны ишетмәскә тырышып колакларын каплады.

—Зинһар өчен, Дәләрис улым, сүзләреңне үлчәп сөйлә!.. Ашыңны ашадыңмы?

—Мин ашамыйм, эчәм генә! Ашарга тешләрем дә юк. Менә алар!..—Матрос тилнәшкегә ямап салынган кесәсеннән бер куш уч ясалма теш казнасы чыгарып кулында уйнатты, аннан аларны кире кесәсенә тыкты, тагын сүгенде, авызын киң итеп киерде, мәгарә сыман караңгы авызы эчендә бер генә теше дә юк иде.—Менә алар! Ватан өчен!.. Ил өчен!.. Теге шешәне чыгармасаң, хәзер йортына ут төртәм!..

Малай тагын шаккатты. Чынлап та үз авылында, үз тупсасында фетнәсез ихтирамда тәрбияләнгән Канәгать әле сигез яшьлек кенә акылы белән ата-инәнең йөзенә карап, сүгенүне кабул итә алмый гына түгел, мондый гайре

табигый хәшәрәтлекне аңлый, кичерә алмыйча, үзен ниндидер акылдан язганнар дөньясында тоеп, иләс-миләс хәлдә калган иде.

Канәгать хәрефләп аның бескозыркасындагы тасмасындагы язуны укыды: "Балтийский флот" дип язылган иде анда.

Матрос шул ук алым белән этәрелеп китеп, кире таш болдырга шакылдап сикереп менде, кесәсеннән шырпы алып, кабызырга әзерләнде:

—Чыгар тизрәк, дим!.. Бер!.. Ике!.. Өч!..

Нишләргә белми аптыраган Йомшак Әби өенә йөгереп кереп китте, мизгел дә үтмәде, тышлары лайлаланып беткән шешәне чыгарып, улына тоттырды.

—Мә, эч!.. Бу бәдбәхет сугыш синең ике аягыңны гына түгел, иманыңны, зиһенеңне алган икән!..

Матрос шешәне күтәреп, авызыннан гына бугазына койды. Аннан калмады микән дип төбенә карады да ыргытты—шешә тәгәри-тәгәри барып, бер бәпкәгә бәрелеп туктады. Канәгатьнең жене котырды. Әмма түзде.

—Син урысны да уздырдың,—диде Йомшак Әби.

—Нәрсә урыс? Без хәзер урысның үзенә сабак бирәбез!..—Матрос сүз араларын тагын да сүгенүләр белән чәчкәләде.—Без урыска үзебез сабак бирәбез!..

Болар арасында иң бәхетсезе Канәгать иде. Башкалар бу тәмугның ияләре булса, малай бу тәмугка мәжбүри, белмичә килеп кергән иде. Ул Колтамактан килгәндә Иннәкәнтәйнең сүгенүләрен урысча аңлый алмавы белән бәхетсез булган булса, хәзер бу кара мыеклы Матросның татарча сүгенүләрен аңлый алуы белән бәхетсез иде.

—Акча бир!..

—Акчам юк,—диде Йомшак Әби.

—Палас арасындагын алып бир.

—Үзең ал.

—Минем буем житми. Йә, җәһәт!..

Йомшак Әби кыяр-кыймас кына урыннан кузгалып, өенә кереп китте һәм күп тә үтми килеп чыкты. Аның кулыннан кырык тапкыр йомарланган кәгазь акчаны тартып диярлек алган Матрос инәсен җилләп очырды:

—Мине ике тапкыр сөйләттермә, кортка!..

Һәм ул кулларындагы агач калаклары белән этәрелә-этәрелә елтыр тәгәрмәчләрдә тәгәри-тәгәри бәләкәй капкага таба китте. Капкага килеп житкәч, артына борылды:

—Малай! Син Колтамактан мәле?

—Әйе,—диде Канәгать теләр-теләмәс кенә.

—Кем алып килде? Шоферыңның исеме?

—Иннәкәнтәй.

—Ә-ә-ә, Иннокентий Самодуров!—дип куанды Матрос.—Бүген ни китерде? Бодай түгелме?

—Бодай.

—Бик яхшы. Сигналыгыз өчен рәхмәт.

—Аек исерекне үгетләп бетүгә, исерек аннан бер эчәрлек акча сораган, имеш...—диде Йомшак Әбисе.—Кермәгәч тә кермәс икән кешегә!..

Матрос инәсенә нәрсәдер әйтеп жикерде. Сугыш аның гәүдәсен кыскартып, телен озынайткан иде. Канәгатьнең кинәт кенә бу телне кисәсе килеп китте. Малай ачуыннан тулышып кызарынды. Колак, борын тишекләренә, авызларына кадәр дыңгычлап тулган әшәке сүзләрдән арынырга теләп, үзенә урын тапмаган, бу пөхтәдән дә пөхтә ихатада, әле һаман да шәфәкъның соңгы ялкыннарыннан чыгып өлгермәгән башын кая куярга белми аптырап, кулларын күлмәк итәкләренә сөртеп азапланган Йомшак Әбисе каршында оялып телсез калган Канәгать тирә-ягына каранды, каз бәпкәләре өчен куелган

сулы коштабакны алды, йөгереп килде һәм Морякның башына каплады:

—Йомшак Әбигә кагылып кына кара!.. Күзле Бүкән дип тормам!..

Күзле Бүкән артына борылды. Чөгендер кебек кызарып бүртенгән йөзендә ике утлы тишек булып аларган күзләр. Ай-һай куркыныч, ай-һай дәһшәтле, ай-һай зәһәр иде бу караш. Әмма бу караштa барысыннан да күбрәк чарасызлыктан үкенү иде. Әгәр ул, башкалар кебек, ике аяклы, ике куллы, камил тәнле, камил бәдәнле ир-егет булган булса, шушы тәгәрмәчле тас сыман тактада утырыр идеме дә, шушы юк-бар килмешәк Иннәкәнтәй, әнкәсе-кортка һәм малай актыгыннан бәйле булган булыр идеме?! Ул аны бөтереп алып, тездән түбән ыргыткан һәм каз бәпкәсе кебек табан астында чыркылдатып изгән булыр иде. Ул еларга да, көләргә дә итте. Кәпәчен салып, башына каплаган казлар суының калдыкларын какты, аны буй-буй чаллары белән чаларып торган башына киде. Ниһаять, ачулы күзләрендә утлар уйнатып:

—Һи-и-и, син!.. А-м-е-б-а!...—диде.

Малайга бу сүз берничек тә тәэсир итмәде.

—Син, малай актыгы, амебаның нәрсә икәнен беләсенме?

—Юк. Безнең авылда амебалар юк...

—Маладис!.. Белмәсәң, бел, син ул!.. Без хәзер Иннокентий Спиридоныч белән синең бодаеңны сатып эчәчәкбез!.. Аяклыларда акча, алтын, хрусталь дә күп, ишекләре дә биш йозаклы!. Үскәч, минем кебек, за родину ике аягыңны югалткач, син шул байлыкларга сакчы булып торырсың, сүгенми-төкеренми генә яшәрсең, мина да берәр яртылык өлеш чыгарырсың, яме!..

Матрос тагын да аты-юлы белән сүгенде. Ачу белән капканы тышкы якка этәреп җибәрде һәм капка аша чыгып, елтыр тәгәрмәчләре зеңгелди-зеңгелди соры ташлы юл буйлап элеваторга таба китте...

—Иллебатырда үз кәмпәнияләре бар аларның...—диде Йомшак Әби тузан туздырып тәгәрәгән улы күздән югалгач.—Шуфирлар белән итәк астыннан иген сатып эчәләр. Сатып алучыларны бу... минеке әзерли... Нинди гөнаһларга баттык бит, Ходаем!.. Һич кенә дә андый түгел иде. Әкчингә күчеп килгәч, шушындагы урам ышпанасы белән уралды. Аннан фронтка китте дә, менә ике аягын өздереп, кәнтүжни булып кайтты... Акылын имансыз Әкчин станцасы, саулыгын имансыз сугыш алды. Бәддога бу сугышка, бәддога!.. Нәсел тамырларымны кимерде...Чәчләремнең карасын, йөрәгемнең парәсен ашады бу сугыш дигән бугавыз!.. Кемнәр ыслабудасы өчен, нәрсә хакына без ирсез дә, баласыз да калдык?!—Улының тәмсез теленнән вакытлыча гына булса да котылган Йомшак Әбинең күңеле йомшарып, тавышы сынды.—Эндәшеп тә булмый, котыра. Атасының бурасын сатып эчте. Хәзер шушы келәтебезне сатып эчү белән яный, Ходаем!.. Тегендә бераз буталган аның.—Йомшак Әби бармагы белән чигәсенә күрсәтте.—Бар кайгысын аракыда юа...

—Мин китәм инде, Йомшак Әби...

—Кая?—Карчык уянып китеп, үз халәтенә кайтты.—Төнгә каршы сине Әкчин урамына чыгарырга минем башыма тай типмәгән әле! Әйдә, кер!. Җибәрә ди сине, җибәрми ни!.. Минзыяга, күргәч, ничек җавап бирермен? Син Дәләристән курыкма, ул бүген кайтмый. Әйдә, тамагыңны туйдырыйк!..

"Тамагыңны туйдырыйк!" Йә, Ходай, монардан да җанга якынрак сүз бар микән?!

Алар өйнең читән белән генә кораштырып сыланган чиннегеннән эчкә үттеләр. Тыштан тавык кетәклеге кебек кечкенә күренсә дә, ул эчтән патша сарае кебек киң, иркен икән. Йомшак Әбисе аңа гомерендә беренче тапкыр салкын солы кесәле ашатты. Өстәвенә, өстәлдә тешкә сагыз кебек сылашса да, ифрат та тәмле кара арыш ипекәе дә бар иде. Канәгать көне буе ашамый ураза тотуының үчен алып, карыны бүлтәеп чыкканчы иште ул кара ипи

белән солы кесәлен. Мөмкин булганда нигә ишмәскә? Мондый кесәлне Колтамак солысыннан да пешереп була, ди Йомшак Әбисе. Тик дәрт кенә итәргә кирәк, ди. Әбисе үзе урак өстендә иллебатырда эшләштереп ала икән. Себерештерә-җыештырыштыра икән. Шунын өчен иген белән түлиләр икән. Бу кесәл дә шул иллебатырдан кайткан солыдан, ди Әбисе.

Тамагы туйгач, көне буе юлда һәм борчулы уйда иләнгән Канәгатьнең егылып китәрдәй булып йокысы килде. Йокысы килгәч, ана Йомшак Әбисе почмакка урын җәйде. Урын җәелгәч, туктаусыз кычкырып, йөрәккә төшеп торган паравыз тавышларына түшәлеп йоклады да китте ул. Төнлә төш күрде. Иннәкәнтәй дүрт тәгәрмәчле тактасына утырган Матросны машинасына таккан да, Әкчин урамнарыннан җилдерепме җилдерә!..

Иртән ул шул ук паравыз тавышларыннан уянып китте. Анын башы саф, кәефе яхшы, колагы сак иде. Тәрәзә аша елгасыз-сусыз, тар ишек алдында үлән чеметеп бәпелдәгән каз бәпкәләренен тавышын ишеткәч, айнып киткәндәй булды. Кичәге хәлләр, башыннан кичкән вакыйгалар турында бер мизгел уйланып ятты да, Колтамактагы инәсе, абыйлары, Өязе буйларындагы дуслары, каз бәпкәләрен исенә төшереп, сикереп торды.

Тышта якты, күз явын алырлык кояш, үләннәрдә көмеш чык тамчылары җемелди. Бу күренешләр барысы да анын бүгененен бәхетле булачагына—туган-үскән иленә исән-аман кайтып житәчәгенә ышандыралар иде. Әбисенен кайсы арада мичтә тәгәрәтеп өлгергән бәрәнгесен кичәгедән калган кара икмәк белән ашык-пошык менгезә башлаганын күреп:

—Ашыкмыйча аша. Артыннан кумыйлар,—диде малайга. Аннан фикерен белгәндәй, өстәп куйды.—Кунак кадерле булса, казан тиз кайный. Үпкәләп китәсе булма инде. Чакырылмыйча килсән, кыйналып китәрсен, диләр...

—Рәхмәт, әби,—диде Канәгать эчендәге кадерле рәхмәтләрен ничек анлатырга белмичә.—Мин бит Әкчиндә кыйналмадым. Мин сезгә килгәндә юлда кыйналган идем. Син мине коткардын гына бит, Әби...

Бәрәнгене шулай ук кичәгедән калган кесәл белән бастырып куйгач, малайнын уе янадан туган якларга очты. Кайтырга, кайтырга!

Ничек хушлашырга аптырап, ишек катына барып басты. Паравыз кычкыртты. Малайнын мангаена тир бәреп чыкты.

—Ашыкма. Сиксәндә сикерә алмассын. Менә бу төенчекне инәнә тапшырырсын, җәме.. Кечкенә, танау кычытмаслык кына күчтәнәч. Бераз солы оны. Сина кесәл пешерер. Бер баш икмәк. Тик кайтып житкәнче ашап бетермә, җәме!

—Капмыйм да, тимим дә, иллаһи-биллаһи, Йомшак Әби!

—Син бигрәк инде тагын! Капкала. Ашаштыр. Тик ашап кына бетермә.

Ишектән чыгу белән уратып алган каз бәпкәләрен ерып, алар урамга чыкты һәм элеватор тарафына китте. Кулына саллы төенчек күтәргән малай якты кояшка карап ант итте: Алла боерса, үсеп житсә, кеше булса, ул Йомшак Әбисен беркайчан да онытмаячак, Әкчиннән үткән саен, ана күлмәклек бүләкләр, тәмле-тәмле күчтәнәчләр кертәчәк. Юк, алай гына түгел, ул аны үзенә алып килеп, үзе тәрбияләячәк!..

Элеватордан килә торган юл чатында аларга кара мыеклары белән һаваны кисеп, дүрт тәгәрмәчле такта көймәсе өстеннән ишкәк ишкән шикелле ишә-ишә, як-якка янтаеп, төне буе эчеп шешенгән, чалыш киелгән бескозыркасынын тасмасы колак тирәсендә чайкалган Матрос тап булды. Кайдадыр аунап, тузанда туенып, иген кылчыклары белән чупләнеп беткән янбалит аларны күреп туктады. Малай белән Йомшак Әби дә туктадылар.

—Ән-кәй, гафу!.. Син первай груп-па инвалид Долорес Хәйбуллиннын супствинный әнкәсе! Гор-рур-рлан!.. Мин бу хакта бүген төнлә...элеваторда

безгә шмон[1] ясаган милиционерларга дә әйттем. Кешедән эт сигәнче милиция ясап була, ә менә милициядән беркайчан да кеше ясап булмый, дидем. Ха-ха-ха!..—Матрос кече телләрен дөньяга күрсәткәнче ыржаеп көлде, аннан Канәгатькә таба борылды.—Кара әле, амеба. Син әле яшь. Сиңа яңа Ват-тан сугышын күрергә... безнең ише Күзле Букәнгә әйләнергә нас-сыйп итмәсен, ям-ме. Мен-нә сиңа бер әкият. Иблис бер генә доганы ятлап оҗмахка керергә булган, әй-йе диген. Моны белеп калган Ходай бу доганы Иблистән оныт-тырган, әй-йе диген... Мин дә белгән догамны оныттым... Сугышта оныттым.. Мен-нә ун ел...аның ун юлын да искә төш-шерә алмыйм!..Прощ-щай, ам-меба!..

Ул агач калаклары белән ишә-ишә, көймәсенең майланмаган тәгәрмәчләре белән чыгыр-чыгыр китеп тә барды.

—Берәр нәрсә аңладыңмы?—диде әбисе.

—Юк.

—Мин дә. Исерек бит ул. Айныса, сүгенә. Исергәч, гафу үтенә дә, шулай акыллы сөйли. Тик сүзләренең мәгънәсе аңлашылмый...—диде Йомшак Әбисе тоз ашаган керфекләрен челт-челт йомып.—Тик барыбер утын түмәре түгел, изге күңелле бала ул... Минем балам!.. Сине күргәннән соң нindидер догасы исенә төшкән бит әле аның. Рәхмәт инде сиңа, бәбкәм. Бәлки догасы хәтеренә дә килер әле, әйеме? Аны урамнан аерасы бар. Урамнан аерсам, яңадан әвәлим мин баламны...

Иген төяп аларга каршы килгән машиналар ташкыны көчәйде.

—Сине озатам да, бәбкәм, урманга китәм. Дару үләннәре җыярга. Быел кыш Дәләрисемне егерме җиде төрле дару үләнендә дәвалап карыйм әле...

Канәгать нәрсәдер исенә төшкәндәй, кесәсенә кулын тыкты. Аннан биш чатлы имән яфрагын әбисенә сузды:

—Ал, Йомшак Әби!.. Сиңа истәлеккә!

—Нәрсә бу, бәбкәм?

—Имән яфрагы!.. Безнең "Урман арты" имәненең яфрагы, Йомшак Әби!..

—Имәнле... Нинди иманлы бала син!.. Ничекләр итеп кенә рәхмәтләр әйтим? Бәлки минем Дәләрисемне туган якларымнан килгән шушы бер имән яфрагы савыктырыр, ә?!

—Әйе, Йомшак Әби!..

Канәгать калтыранган куллары белән имән яфрагын сыйпаган әбисенең күзләренә карады. Тоздан агарган керфекләр яшькә сугарылган иде.

—Син мина яна исем дә бирдең мени инде?

—Әйе, Йомшак Әби!..

Кинәт элеватор ягыннан килеп чыккан грузовик кабинасында Канәгать алтын күзлекне, шул күзлек эленгән борынның хуҗасы Габдулла бабасын күреп калды һәм Йомшак Әбисе белән саубуллашырга да онытып, аңа таба йөгерде, бабасы аны күрүдән дулкынланып, барган җайга диярлек ишеген ачты, малай җан-фәрманга килеп, машинаның тупсасына сикереп менде һәм аның кочагына чумды.

—Син кайда йөрисең, ташбаш?!

Малай менә хәзер сынсыз-сансыз Дәләрисе янына кайтып керәчәк Йомшак Әбисе торып калган тарафка тартылды.

—Нинди карчык ул? – дип сорады бабасы.

Бәрәч, ул бит аның исемен дә сорамаган!.. Үскәч, зур кеше булгач, ничек эзләп табар?!. Канәгать кабина тәрәзәсенә башын тыкты һәм инде ераклаша барган Йомшак Әбисенә йөрәк ярырлык тавыш белән кычкырды:

—Ис-се-мең нич-чек, әб-би???

---

[1] Шмон (төрмә сүзлегеннән)—камау,тенту, облава.

Әбисе ишетмичә генә елмаеп, ана бары тик кулын гына болгый иде.
—Кулында нәрсә? — диде бабасы.
—Кучтәнәч.
—Һм. Син кучтәнәч кайгыртып йөрисең икән. Иннәкәнтәй дәдәннән сорамыйча китеп бардынмы? Ул бит сине табалмыйча Әкчинне аркылы-буйга чарлаган!—диде кабат бабасы.—Мин сина нәрсә дидем? Иннәкәнтәй дәдән рөхсәтеннән башка читкә адым да атлама, дидем. Шулаймы?
—Шулай...—диде малай яшен чак тыеп.
—Ә син нәрсә? Элеваторга житү белән дәдәннән сорамый-нитми башбаштак китеп баргансың. Бу бит сина чабаталы Колтамак түгел, бу сина итекле шәһәр дидемме? Бу бит Әкчин дидемме?..
Малай эндәшә дә, сөйли дә, аеруча аклана да алмый иде.
—Ну, ярар. Буласы булган, буявы сеңгән,—диде бабасы тынычланып.—Иң мөһиме—исәнсең. Шулай бит?
Беразга гына тын калдылар.
Тынлыкны тагын да Габдулла бабасы бозды.
—Юлда игенне әрәм-шәрәм итмәдегезме?
Бик нык итеп елыйсы, зарланасы, әләклисе, үксеп-үксеп, дөресен, бар күргәннәрен сөйлисе килсә дә, авылыннан чыгып, бер көн эчендә күпме вакыйга, кайгы-сагыш, кискен тәэсир, тетрәнүләр кичергән малай авылдан чыгуының икенче көнендә үк әләкчегә әвереләсе килмәде.
—Юк, әрәм-шәрәм итмәдек,—диде ул.
—Иннәкәнтәй авылларга туктап, игенне сатып эчмәдеме?
—Юк. Эчмәде.
Ялганлады. Матур итеп ялганлады. Бу минутта ул үзен Жир Шарындагы бердәнбер һәм соңгы ялганчы итеп тоя иде.
Әмма Жир Шары түгәрәк иде. Шушы минутта кайдадыр ерак Африканың инглизләр басып алган Көньяк Африка дигән илендә яшәгән кара тәнле банту малае да, бантустаннан, ягъни авылдан, Вааль елгасы аша башкалалары Иоханнесбургка очраклы гына килеп эләгеп, адашкач һәм табылгач, кеше булып калу хакына бабасына матур итеп ялганлый иде. Әмма Көньяк Уралның Бәләбәй-Бөгелмә калкулыгында яшәгән малай бу хакта белми иде.
—Ярар, алай булгач,—диде нәтижә ясап бабасы һәм янәшәсендәге бөтенләй таныш булмаган шоферга әйтеп куйды.—Әйдә, алга, Колтамакка! Әтү анда инәң син киткәннән бирле колак итемне ашый. Канәгать югала диме! Югалтырсың син безнең Канәгатьне!..
— Бабай, минем каз бәпкәләре исән микән?
— Исән, — диде бабасы елмаеп. — Сәлам әйтеп калдылар.

## Минрахманның үлеме

—Бәрәңгеләрдән кара жир генә калган!..
Инәсенең бу сүзләре Канәгатьнең йөрәген пычак белән телеп төшкәндәй булды.
Бу хәбәргә ышанмаган малай, чык белән тирләгән салкын болдыр ташыннан инде монысыннан да салкынрак чык сарган бәбкә үләненә сикерде, аннан чиркана-чиркана, ялан аяклы эзләрен калдырып, бәрәңге бакчасына үтте дә да, шаклар катты: бу таңда чынлап та көчле кырау төшкән һәм бу кырау, инде туфракны тишеп чыгып, урыны-урыны белән өченче, хәтта дүртенче яфракка сикереп өлгергән бәрәңге үсентеләрен карасу-шәмәхә ялкын белән

көйдергән иде...

Кояш таудан кул яссуы чамасында күтәрелергә өлгерсә дә, әле һаман да кипшенеп житә алмыйча боз суыгын саклап яткан чыкны игътибарга алганда, төшкән кырауның ни дәрәҗәдә кара, ни дәрәҗәдә көчле, аяусыз булганын чамаларга мөмкин иде.

Аның инәсе бер дә юкка йөрәк итен таламый шул. Бу кадәр дә афәттән соң бәрәңгеләре тернәкләнеп китә алырмы? Бәрәңге аларның бердәнбер яшәү чарасы бит!.. Әллә соң инәсе, июнь башлары дип тормыйча, орлыклык юнәтеп, кабаттан чәчтерерме? Алай иткән хәлдә, юраганнары юш килеп, уңышы өлгерә алырмы?

Кайчандыр чагыштырмача хәлле яшәгән картаталарының утызынчы елларда таланган, талана алмаганы җимертелгән ихатасында элек атлар бәйләнгән, бүгенгә кадәр исән-аман калып, бердәнберлек кыяфәте белән серәеп утырган, инде бәйләрлек аты да, сыеры да калмаган багана башыннан саескан шыкыртады. Күптән түгел генә ияләште ул имансыз саескан аларның баганасына.

—Үз башыңа гына шыкырта!—диде инәсе.—Икебезне алып киттең бит инде, житмәде мени?

Канәгать жирдән таш очтыгы сәрмәп, саесканга атты.

Аклы-кара кош очып китте.

Үзенә урын таба алмыйча вак-төяк мәшәкатьләре белән шул ихата эчендә кайнашкан инәсе сүзне икенчегә борды:

—Ә-әй, онытып торам икән!.. Минрахман өзелә ди. Әйдә, балам, бәхилләшеп чыгыйк!..

—Ничек... өзелә? Нигә?—Алты яшен чак тутырып килгән малай сүзнең мәгънәсенә буй сала алмыйча, инәсен җиңеннән талкыды.—Нигә өзелә ул, инәй?

—Өзелә инде. Өзелә дә куя. Өзелгәч, бәхилләшәләр...

—Бәхилләшкәч, кая китәләр? Мин дә шунда барам!..

—Тиле!..

Кулындагы калай чиләген өч япьле сәнәкне хәтерләткән тәбәнәк багананың үз ягындагы ябенә доңгырдатып элде дә, инәсе Канәгатьне житәгенә эләктереп алып, кайчандыр ике арада койма бурычын үтәгән, бүген килеп жимерелгән жәйге алачыкның таушалып, жиргә сеңешеп яткан кызыл саман кирпечләре аша күрше Минрахманнарга юнәлде. Аякларына (инде ничәнче тапкыр!)—пыяла керә күрмәсен дип, инәсенең житәгендә дә ничектер сакланып, кәжә бәтие сыман сикергәләп атлаган малайны һаман да шул бер уй борчыды: кеше ничек итеп өзелә? Бау өзелгән кебекме? Кеше абзар өрлегенә малай-шалай атынчак ясап атына торган кырык ялгаулы алган иске дилбегә дә, аркан да түгел. Нәрсә, кеше, бау кебек, бер өзелгәч ялганмый мыни? Бөтенләй дә ялганмыймы? Ул чакта нигә өзелә? Менә монысы малайга һич кенә дә аңлашылмый иде. Әле кайчан гына туп кебек йөгереп йөргән, Канәгатьтән нибары дүрт-биш яшькә генә өлкән булып, бергә бәләкәй арба тартып, урманга-яланнарга утынга-печәнгә, балтырган, кымызлык һәм башка яшел тамыразыкка, җиләккә барган Минрахман, инде мәктәптә укуга төшеп, алай гына дисезме, иң алдынгы укучы булуга ирешкән, бик тә тырыш, ачык йөзле, якты чырайлы, елмаючан Минрахман, әле күптән түгел генә Бөек Җиңүнең бер еллыгы уңаеннан үткәрелгән бәйрәмдә—анда Канәгать үзе дә булды—"Әтисез килде бу Җиңү—әтисез китеп бара!" дип талпына-талпына шигырь сөйләгән Минрахман ничек итеп кенә өзелергә мөмкин?

Хактыр, менә атна-ун көн чамасы булыр, урамда уенда-фәләндә борын күрсәткәне юк. Хәер, аның урамга күрсәтерлек борыны да калмаган. Әле

алдагы көндә генә алар инәсе белән Минрахман янына кереп чыкканнар иде. Урын өстендә ята. Танырлык түгел. Гөбе кебек шешенгән. Күзләре, авызлары, борыннары тоташтан сары тукыма булып күпергән, илаһым. Минрахман берничә көн элек авыл очы Тәминдар абзыйларга тамак ялына ялланып саман кирпече суккан булган. "Ач килеш иелеп эшләп йөгенгән",— диде инәсе. Әйе, әйтерлекме, Бөек Жинүдән сон авылларында гына түгел, бар тирә-якта шундый ачлык котыра—Канәгатьләр үзләре дә тәннәрендәге жаннарын чак-чак кына асрыйлар. Анын бит тап-таза инәсе, инде кул астына кереп, колхоз эшенә чыккалый башлаган ике абыйсы бар. Ә Минрахманнын нәрсә? Инәсе Фатыйма үпкә белән чирле, апалы-сенелле берсеннән-берсе кече кыз балалардан нәрсә аласын?

Авылда үлем-китем күзгә күренеп күбәйде. Үлем белән хәзер беркемне дә кызгандырып булмый. Зиратка көн саен мәет ташыйлар. Нигә ерак китәргә. Фронтта һәлак булган аталары артыннан Канәгатьнен үз абыйсы былтыр язгы бодай башагыннан агуланып үлде.

Бигрәк тә хәтәр ачлыклар килде шул ил өстенә. Жинеп йөгенгән илдәге ачлык бигрәк тә аяусыз өзлектерә икән ул. Канәгатьләрне сонгы чорда аталарына килә башлаган пинсә генә коткара башлады. Элегрәк ул да юк иде. Нәрсә була ул пинсә дисезме? Сугышта кеше үлә дә—балаларына акчасы килә башлый. Менә кызык: кеше үзе юк—акчасы килә. Үзе булмагач, анын акчасы нигә килә икән? Бер караганда, чирле аналы, апалы-сенелле Минрахман да сугыш ятиме. Сап-сау аналы, ике абыйлы Канәгать тә сугыш ятиме. Канәгать пинсә ала, Минрахман пинсә алмый. Ике ут күршесе—икесе дә сугыш корбаны. Берсе акчалы, икенчесе акчасыз корбан. Минрахманнарнын аталары хәбәрсез югалган, имеш. "Теге якта" югалган, имеш. Пинсәне "бу якта" югалганнарга гына бирәләр, имеш. Менә шул кайсы якта югалганы ачыкланмый торып, Минрахманнар ашамый торырга тиеш булып чыга микәнни?

Инәсе Канәгатьне үзеннән читкә жибәрмәскә, коткарырга теләгәндәй, июньнен бер болытсыз зәп-зәнгәр гөмбәзенә шундый ук ач, кара, телсез килеш ыржаеп яткан буш карбаз авызы тәнгәленнән жилтерәтеп алып китте. Әйе, салам кушып сугылган кызыл саман кирпечләренен канлы-алтын жепселләре белән кансырап яткан аралык аша сикертә-сикертә алып чыкты да, инәсе аны Минрахманнарнын келәт сыман шундый ук кечкенә, кызыл саман алачыкларына кертеп чумдырды.

Борынга мал чөгендеренен авырсу, күнел уйната торган әчкелтем-төчкелтем исләре килеп бәрелде.

Өйдә карангы һәм сөяккә үтәрлек суык иде.

Анда, мич аралыгында, бар нәрсә—утсыз казан асты, котсыз оеган су ләгәне, тәбәнәк аш-су сәкесе, шүрлекләргә куелган коштабак, ике-өч калай савыт, шүрлек киртләренә кертеп тезелгән берничә кашык, шунда ук эленгән кәкре саплы агач ижау, почмактагы кисәү агачы, койрыгы белән утсыз мичтән арты белән тырпаеп торган жәмкә һәм көл савыты да—нинди дә бөек бер вакыйга көтеп катып калган иде. Өйдә шомлы тынлык хөкем сөрә. Берничә чүпләмле чигү үрнәкләрен, Сталин бабаларынын гәзиттән кисеп ябештерелгән сурәтен исәпләмәгәндә, стеналарда башка бернәрсә дә шәйләнми. Апалы-сенелле Фәгыйлә белән Сәгыйдәләре өйдә дә юк иде шикеле; инәләре Фатыйма түтки мичне аерып торган чаршау арасыннан танавы белән очлаеп чыгып, көнбагыш яфрагы кебек саргайган гәүдәсен аралыкка тыккан да, башын шундый итеп игән ки, гүя бу баш кылыч белән нәкъ башак сыман сабагыннан кыелган да, бер генә тамырында эленеп калган; күзләре исә "Инде ниләр генә күрмәдек, алда тагын ниләр күрербез?" дигән куркыныч сорау белән дөньяга баккан...

Канәгать хәтерләми: тәрәзәләр бар идеме ул дөм караңгы алачыкта? Әмма шунысы хәтердә: Минрахман каршындагы урындыкка гарәп хәрефе кебек астан көймәләнеп бер карчык утыра... Каяндыр төшкән сүрән яктылык аның йөзенең ярты ягын пычак йөзе сыман яктырткан, ярты йөзе караңгыда йөзә. Башыннан алата кара бөркәнчек бөркәнгән, үзенең утырышы белән кабер ташын хәтерләткән бу карчык, кулларын тез өсләренә куйган да, иреннәрен бис-бис, лепер-лепер китереп укына...

"Минрахманга кырык бер ясин чыга, шауламыйча гына утыр",—диде Канәгатькә инәсе.

Алачыкта карчык пышылдаганнан тыш башка бернинди дә монаваз колакка чалынмый. Мондый монсызлык, чарасызлыктан аптыраган сабый, карашын кая куярга белми, Минрахманга юнәлтте. Аны стена буендагы тар сәкегә сузып салганнар, өстенә җәймә сыман соргылт тукыма ябып, ике кулын тышта калдырып яткырганнар. Минрахманның башы почмак караңгысында мендәргә охшаган энгер-меңгердә ята. Малай ут-күршесенең күзләрен күрергә теләде: күзләре юк иде. Ул аның кашларын, борынын, авызын-йөзен күрергә теләде—алар да юк иде. Әле кичә генә тәмамланган сугыш, гүя әтисе белән бергә аның күзен дә, йөзен дә алып киткән. Авызы белән танау тишекләре исә өреп кабартылган куыктагы өч тишекне хәтерләтте.

Үткән кышта Минрахман инәсе белән аларга кич утырырга кергәләде. Еш кына, уларын ияртеп, башка күрше хатыннар да керә иде. Инәләре җылы мичкә аркаларын терәп, чөкердәшә-чөкердәшә җеп эрләгәндә алар "Сугыш уены" уйный иделәр. Сугыш үзе генә уйлап тапкан бер уен гамәле инде ул югыйсә. Малайлар утыргыч бурычын үтәгән имән бүкәнне тәгәрәтеп мич арасына кертәләр, башларыннан ук чүпрәк палас ябынып, караңгыда калалар да, учактан чыгарылган кузлар өстенә иске-москы кәгазь, дәфтәр аламалары ташлап, төрлесе төрле яктан бу кузларга өрергә тотыналар. Кәгазьләргә ут каба, ниһаять, алар янып бетә, ялкын сүнә дә, кәгазьнең каралы-кызыллы сөлдәсе буйлап тере алтын очкыннар йөгерә башлый. Бу очкыннар гади очкын түгел, алар—"әтәйләр". Һәркем күзе күреп өлгергәнче эре, гайрәтле, пыр тузып чапкан очкынны сайлап ала да, аны "үз атасы" итә. Һәркем җан-фәрман чапкан, кинәт кенә икенче бер очкын өстенә менеп сүнгән, аннан тагын кабынып куйган очкын-атасын күзәтә:

—Әнә, минем әтәй, әнә!.. Фашистны үтерде!..

—Әнә, минем әтәй ике немесне берьюлы дөмектерде!

—Безнең әтәй бит ул!.. Синеке түгел!..

—Синең атаң үлде бит инде!—дип каршы төшеп, шаулаша башлый малайлар.

—Үлмәде! Синеке үлде ул!..—ди шул чакта ачуы чыккан Минрахман.—Сез бит шуңа күрә дә пинсә аласыз. Безнеке исән, шуңа күрә пинсә алмыйбыз!.. Исән йөреп, исән кайтсын дип кенә алмый торабыз без ул пинсәне...

—Кайта! Синең әтиең плиннәй!—ди күрше малайлардан кемдер.—Ул беркайчан да кайтмаячак!.. Сезгә пинсәне шуңа бирмиләр...

—Юк, минем әтәй плиннәй түгел!—ди ачуыннан елар хәлгә житкән Минрахман.—Минем әтәй башта танкта янган, танктан йөгереп чыккан да, немесләрнең пушкасын күкрәге белән каплаган. Безгә шуны күргән Сталин бабайның үзеннән рәхмәт хаты килде!.. Сезнең берегезнең атасына да андый хат килмәде!..—Инде Минрахман аяклары белән дөпелдәп, куллары белән имән бүкәнне төя башлый.—Минем әтәй кайтачак, акбүзатта кайтачак, ә менә сезнеке кайтмаячак! Күрегез дә торыгыз! Сезнең барыгызның да аталарыгыз үлгән!.. Минеке генә үлмәгән!..—

Инде менә-менә сугыша башлар хәлгә житкән, инде берсеrange аталары сугыш яланында ятып калуына, икенчеләренең хәбәрсез югалуына гамьсез куанган малайлар янган кәгазь ачысы, сөрем, ыс исеннән кикерә-кикерә, төчкерә-төчкерә палас астыннан атылып чыгалар да, шул ысның ачы зәһәреннән корымлы йөзләре буйлап яшь агызган күзләрен кызартканчы уалар...

Һәм менә шушы атасын бик тә көткән, аның акбүзатта гына кайтачагына чиксез ышанган, ул кайтсын өчен хәтта "пинсәсен дә алмый яшәгән" Минрахман бүген килеп барысы белән дә бәхилләшсен әле!..

Кинәт Минрахманның уң кулы жай гына сыпкылып хәрәкәткә килде һәм ул бармак очларын гәүдәсе буйлап бот тирәсенәрәк шудырды, аннан нәрсәдер чеметеп алгандай итеп, чеметемен калтырына-калтырана авызына китерә, кипкән, жир кебек караеп ярылган иреннәрен, теш казнасын чак-чак кыймылдатып, чәйнәгәндәй итә башлады.

—Исән әле! Саташа...—диде күз нурлары белән улының гәүдәсе өстенә сүтелеп төшкән хәлсез ана.—И, ходаем, мәддәт бир!.. Бүген иртәдән бирле тәненнән нәрсәдер чүпли... Ашарга тели, күрәсең... Бигрәк кеңәләр дә бетерендек шул. Ларыбызда он дигәннең кәтрәсе дә калмады... Әллә үтә дә инде... — Чарадан ничара Фатыйма түткинең тавышы өзелде, ул урыныннан күтәрелә төшеп, шүрлектән иске китапны алды да, Минрахманның баш очына куйды.

—Аның фәрештә жаны күптәннән инде ожмахта!...—Мона кадәр кабер ташыдай хәрәкәтсез пышылдап утырган карчык тел очындагы догасын тәмамлап, тыны белән сабыйның гәүдәсен әфсенләде.—Ожмах бакчаларындагы алма-хөрмә, жәннәт жимешләреннән авыз итеп ята инде бу ожмах кошы!..

Кинәт кенә бу сүзләрне әйтүгә әби үзенең өстендәге кара япмасын алып ташлап яктыргандай, кара кабер ташыннан якты нур чыганагына әверелгәндәй булды. Канәгатьнең күз аллары яктырды. Авызында сулары килде.

Аның да фәрештәгә әвереләсе, жәннәт бакчаларындагы жимешләрдән авыз итәсе килде.

Моның өчен аңа да Минрахман шикелле үләргә кирәк иде.

—Инәй... инәй...—дип пышылдады ул чак кына ишетелерлек итеп.—Минем дә үләсем килә...

—Авызыңнан жил алсын, тиле!—Инәсе шым гына янбашына шапылдатып алды.—Бар, чыгып ычкын!..

Канәгать тышка чыкты.

Тышта бар нәрсә дә исән иде. Кояш якты, өянкеләр, үләннәр, кычыткannар ямь-яшел, ихаталарның читәннәре һаман да шул ауган-янтайган килеш тора иде. Ул еллар буе читән буенда ятып черегән, муртайган бүрәнәгә килеп утырды. Черегән ботак күзенә оялаган кызыл бөжәкләргә игътибар итте. Аркаларындагы каты тышчаларын кара таплар биләгән, кирәк чакта бу кара таплар канатларга әйләнеп, очып киткән, кирәк чакта,бу канатларны янадан инене жыеп, "жәяү" атлаган бу матур, ожмах бөжәкләрен бик ярата Канәгать. Аларны Колтамак малайлары "кетнәкич" диләр. Солдат, мулла коңгызы дип тә атыйлар. Чынлап та кызыл солдатларга охшаган бу гажәеп бөжәкләр әле жир йөзендә бернинди ачлык, бернинди фажига булмагандай ду килеп кайнашалар. "Болар үлми, кешеләр генә үлә икән" дип уйлады малай. Тормыш өчен тырышып-тырмашып яткан бу бөжәкләрне күргәннән соң Канәгатьнең ашыйсы килсә дә, һич кенә дә үләсе килми башлады.

Тагын да берничә көн үтте.

Көннәрдән бер көнне инәләре лар төбен себергәләштереп, балтырган шулпасына бер-ике уч он әсәрәсе сибеп, аш ишарәте пешерде.

Иртәнге сәгатьләр иде.

Алар түрдәге сәкедә ашап утырганда болдырда ниндидер мышнау-кыштырдау шәйләнде. Барысы да игътибарын ишек ягына юнәлтте, әмма беркем дә күренмәгәч, яңадан шулпаларын чүмерә башлады. Инде мышнау якында, ишек катында ук ишетелде. Карасалар—әле ике-өч көн генә Канәгать бәхилләшеп чыккан Минрахман. Шартлардай булып шешенгән, авызыннан, күз чокырларыннан бары тик сызык эзләре генә калган ут-күршеләре, аякларын чак-чак сөйрәп, ишек яңагына килеп сөялде һәм, тупса аша үтә алмыйча, кулын сузды:

—Би-и-ир!..

Өйдә шылт иткән тавыш ишетелмәде. Минрахманның җәя сыман киерелгән авызында, эчтә, тамагының караңгы төбендә кармак сыман селкенгән кече телен күреп, Канәгать үзе телсез калды диярлек.

Канәгатьләр аптырап торса да, инәләре һич тә аптырап тормады. Ул җәһәт кенә сәкедән күтәрелде, үзе ашаган аш кәтәлүген өстәлгә китереп куйды һәм Минрахманны өстерәп диярлек савыт артына китереп утыртты:

—Аша, туганым, аша!..

Малай кашыкка тотынып тормады, калтыранган куллары белән кәтәлүкне күтәрде, ямалып беткән авызын киң итеп җәйде һәм савыттагы сыекчаны тыела алмый чүмерә башлады.

—И-и, Ходаем! Фатыйма нишләп аны караусыз калдырды икән?—диде хафага төшкән инәләре.—Аптыраганнандыр инде. Кызларын тамак ялына дип өй юышырга җибәргән иде... Үзе исә кырау суккан бәрәңгесенә алмаш орлык эзләп чыккандыр... Болай булгач, хәле яхшырган, димәк!.. Аша, туганым, аша!..

Ул арада Минрахман кәтәлүктәген чүмереп бетерде, авыз тирәсенә буялган яшел боламыкны кызыл тел очлары белән ялап алгандай итте дә, кан баскан күзләре белән тирә-якка акаеп карап, бушлыкка текәлде һәм ялварды:

—Таг-гын!..

Инәләре ашарга тиешле ашның кәтмәгәндә генә Минрахманга насыйп булуына әрнегән туганнар карашында нәфрәт дулкыннары яралгандай булды.

—Күрше хакы—тәңре хакы, балалар...

Инәләре абыйларының ашларын сорамый-нитми бүлеп алып, Минрахманның савытына салды.

Малай һаман да шул мышнаган, мөңрәгән, аһылдаган авазлар хасыйл итеп, монысын да чүмерде һәм инде өченче тапкыр кулларын сузды:

—Бир-р-р!..

—И, Ходаем, бирән чире булган бит мона... —дип уфылдады инәләре.—Туясы юк икән!..—Аннан кулларын җәйде.—Юк бит, Минрахман, каян алыйм?!

Чират савытында соңгы берничә кашык ашы калган Канәгатькә килеп туктаган иде. Әмма төпчек баласын, төпчек энекәшләрен бу изге өлештән мәхрүм итәргә беркемнең дә батырчылыгы житми иде. Абыйлары һәм инәсе аңа карадылар. Малай калай савытында калган яшел шулпасын, ике дә уйламыйча, Минрахманның кәтәлүгенә китереп салды.

—Аша, Минрахман...

Минрахман эндәшми-тындашмый, кыргый бер ачу белән монысын да элдереп куйды. Һәм беркемгә бернинди игътибар бирмичә, капшана-капшана урыныннан күтәрелә башлады. Ниһаять, күтәрелде һәм, егылмаска тырышып, стеналарга тотына-тотына, тышка юнәлде.

—Яхшыра болай булгач, яхшыра... Инде савыга гына күрсен, Галирахманның бердәнбер төсе бит, илаһым...—диде инәләре.—Әйдәгез, балалар, ашка дога кылыйк...

Күп тә үтмәде, багана башыннан теге саескан шыкыртады.

—Житте дим мин сина!—дип кычкырды ана болдырдан кулына табак-савытлар тоткан инәләре.—Болай да үлем-китемнән кайтып кергән юк!

Озак та үтми хәле беткән инәләре өйгә йөгереп керде:

—Бакчалары башында Минрахман үлеп ята бугай!..

Балалар яшен тизлеге белән тышка атылды.

Әйе, хак икән. Үзләренен бакчалары башында йөзтүбән капланып төшкән дә, Минрахман тын да алмыйча ята. Гүя ул жирне мөмкин кадәр кинрәк колачларга тырышкан сажин агачыдай сузылып, кара кырау суккан бәрәнге бакчаларын, бар дөньяны, бар жир шарын үзе белән алып китәрдәй булып кочкан да, ике кулын, шүре кебек шешенгән бармакларын шәмәхә төскә кереп көйгән бәрәнге төпләренә батырган да—ауган да куйган.

Өлкәннәр анын жен сугудан каткан бармакларын көч-хәл белән жирдән чыгарып, гәүдәсен чалкан салдылар һәм жан тамырын тикшерделәр. Минрахманнын тамырлары тынсыз, йөрәге типми иде. Ул чынлап та өзелгән, дөнья белән бәхилләшкән иде. Кеше бау кебек өзелми, бер өзелсә, аны һич кенә дә ялгап булмый икән.

Канәгатьнен күзләренә яшь бәрде.

—Бәхил бул, Минрахман абый!—дигәнен сизми дә калды.

Үзенә житкән акылы белән бу сугыш ятиме аптырапмы аптырады: нишләп Минрахман, өенә кермичә, бакчаларына чыккан? Әллә ул мона кадәр бары тик чүпрәк палас асларына яшеренеп кенә «сугыш уены» уйнаганда күрә, алтын очкыннарда гына таба, сүнеп барган кәгазь көлендә генә очраша алган атасын, инде бакча башларына чыгып каршыларга теләгәнме? Әллә һаман да исән санаган атасын, көтеп-көтеп тә морадына ирешә алмагач, ана охшарга тырышып, барлык жир шарын түгел, шушы бәрәнге бакчасын булса да күкрәге белән каплап, кара кыраулардан коткарырга теләгәнме? Әллә бу жирне, бу дөньяны ожмах жимешләреннән бергә авыз итү ниятеннән үзе белән бергә кара гүрләр аша жәннәткә алып китәргә иткәнме? Әллә ул, Жинүче Илнен бер гаепсез Ятиме, кырау суккан бәрәнге төпләрен куллары белән чокып, андагы сукыр күзле бүлбеләрне дә казып чыгарып, тамак туклык итәргә булганмы?

Минрахманнын үлеме Канәгатьнен жанын урталай ярды.

Күктә яп-якты кояш, жирдә ямь-яшел агачлар, үләннәр, аларда менләгән бөжәкләр гөжелдәшә, гүелдәшә, кошлар сайраша иде.

Шушы вакыйгадан сон Канәгать бәрәнгене бары тик чәчәргә, утарга, үстерергә генә яратты. Чыгарырга яратмады. Ана көрәк йөзендә кызыл, шәмәхә, зәнгәр, сары төстәге эре бүлбеләр түгел, ә Минрахманнын кан белән кызарган күз бәбәкләре актарылып чыгып, Жир буйлап тәгәрәп киткән кебек тоела иде...

*2004 ел.*



Клара
Булатова

# ГОМЕРНЕҢ КАЙ ТӨШЕ?..

## Сәвәләй тау буйлап...

**Сәвәләй тау буйлап без яшь чакта
Үсә иде, әнә, казаяк.
Бу елларда инде ул гөлләр дә
Кимегәннән кими, азая.**

**Сәвәләй тау буйлап төлке йөргән
Элек-элек, күптән-күптәннән...
Безнең таулардагы төлкеләр дә
Җырда гына калган үткәннән.**

**Сәвәләй тау буйлап ермак-ермак
Кар сулары төште быел да —
Әмма никтер хәзер безнең яшьләр
Тау буена йөрми уенга.**

**Сәвәләй тау буйлап йөргән төлке!
Эзең дә юк, еллар юганмы?
Төлке эзе дә юк, гөле дә юк.
Ни таптады әле дөньяны?!**

## Сорасам әгәр Умайдан...

**Июньнең җитте ахыры,
Иртәгә соңгы көне,
Алиһә Умай туп-туры
Мифларга әйди мине.**

**Ә мифлар туган чорларда,
Серле сөю илендә**

Умай - төрки мифларында үрчеткеч рух алиһәсе.

Клара БУЛАТОВА – *шагыйрә; унлап китап («Язлар алда», «Печән өсте», «Марс китабы» һ. б.) авторы. Әлмәттә яши.*

Гашыйклар өчен — июньнең
Булган утыз бере дә...
Сорасам әгәр Умайдан,
Өйрәнеп күкләр серен,
Кайтармас микән миңа да
Июньнең утызберен?...

## Өметен җуймыйк күкләрнең

Җәй яме — чәчәк таҗларын
Сыпырып — имләп шулай,
«Мул булсын орлык көзгә», — дип,
Ырымлап йөри Умай!

И, кеше!
Адәм баласы!
Тырышсаң гына бары
Сиңа чын уңыш китерер
Умайның ырымнары.
Без — төрки халык токымы,
Тапламыйк тарих гамен:
Өметен җуймыйк күкләрнең
Һәм Умай Алиһәнең.

## Көн белән төн озынлыгы тәңгәл

Көн белән төн озынлыгы тәңгәл,
Кыл урталай тәүлек бүленгән.
Табигатькә ияреп, тоемлы тән,
Акыллы җан шушы мизгелдән

Үз затына күпме өсти ала,
Җир әнкәнең тыңлап гозерен,
Һәр орлыктан сихри дәва таба
Һәм озайта ала гомерен...

## Кырларда аҗагай камчысыдыр...

Кырларда аҗагай камчысыдыр,
Уйнаклый яшендәй бизәге.
Бизмәндә бүленгән яртысыдыр —
Бу көннәр җәйләрнең үзәге.

Күргәннең барына түзәбездер,
Яшәүгә омтылыш, һай, көчле!
Бу көннәр җәйләрнең үзәгедер,
Бу җәйләр гомернең кай төше?..

## Бусы соңгы көнең булуы бар...

Бусы соңгы көнең булуы бар,
Бусы соңгы кичең булуы бар,
Бусы соңгы таңың булуы бар,
Бусы соңгы даның булуы бар.
Тәүге көнеңне син белмисең бит,
Тәүге кичеңне дә белмисең син.
Тәүге таңың сиңа ни калдырган?
Дан дигәнен мәңге күрмисең син.

Соңгысы ни аның, тәүгесе ни —
Тумаганның юк бит сан тамгасы.
Туман, булмаган, югалмаган —
Соң, кайгырма, Адәм Диванасы!

## Бит бер соңы
## була кунакның

Без килгәнбез Җиргә кунакка.
Әллә әзгә, әллә озакка.
Кай яклардан килгәнемне белмим,
Яшәвемне беләм бу якта.

Яшәвемне беләм бу якларда,
Балачакта, үсмер вакытта
Кайгыларга бу яшәү бай булды,
Юмарт булмаса да шатлыкка.

Шатлыкларга юмарт булмаса да
Гел булмады түгел анысы да.
Атам-анам, ирем, улым булды —
Шатлык түгелмени барысы да?

Инде җирдән китеп барган чакта
(Бит бер соңы булыр кунакның...)
И, Ходаем! Мин аларны түгел,
Оныкларым мине озатсын.

## Шунысыннан сакла

И, бу тарих инде күпме күргән
Каләм тоткан безнең ишене,
Менеп җителмәгән үрләреннән
Авыр түгел аның төшүе.

Биеклеккә менеп җитүеңә
Бәреп төшерсәләр —
ул чакта
Түзеп калу кыен, диләр менә,
Шунысыннан, тәкъдир, син сакла.

* * *

Әкият илләренә ияркән кебек
Агачларны ерып җил үтә.
Итәгеннән алтын яфрак түгеп
Урман иңләп йөри Көзбикә.

Мондый чакта дөнья өйрәткәннең
Бөтенесен читкә ташлыйсың,
Йә гел яшәмисең,
Йә бөтенләй
Бүтәнчәләй яши башлыйсың.

## Ике дус, ике чордаш сез

*Х. Т. белән Ш. М. га*

Ике дус, ике чордаш сез,
Ике яр, ике шагыйрь,
Кайсыгыз якынрактыр? —
Бар, таны аны, аер...

Сез язган шигъри хатларда
Күпме наз ла, көйле сүз!..
Чын булган яратуыгыз,
Җитмәгән сөюегез...

Каршымда менә ятасыз,
Янәшә... журналларда.
Кем өчен сердер, әмма мин
Хаклыкны таныйм анда.

Сүзләрдән генә түгел лә,
Җырыгыз — янган җаннан,
Илаһи олы сөюгә
Ватылмас һәйкәл салган.
Ышанып җитмим үзем дә:
Тик кенә торган төштән
Каләмнән җырлар түктергән
Шушы мин идем микән?

Ике дус, ике шагыйрь сез,
Мәхәббәт хисләрендә
Көйрәгән йөрәкләрегез
Туң йозак бикләрендә...
«Картайдым, сүндем», — дигәндә,
Таң ясап сезнең кичтән,
Җаныгызга язлар кайтарган
Шушы мин идем микән?

Җәүдәт
Ильясов

# ЕЛАННАР ӘФСЕНЛӘҮЧЕ

РОМАН

## Икенче бүлек

### Чаян йөрәге

*Үзен галим дип уйлаган наданга*
*Ишәк холкы килә, шиксез, таманга;*
*Ишәк булып кылан син дә, югыйсә*
*Алар әзер сине кяфер санарга.*

Исфахан. Алтын көз. Базарларда—алтын уңыш. Алар өстендә—зәңгәр гөмбәзләр. Якты кала! Бәхетле. Бирегә беренче тапкыр килеп, Гомәр әле юл тузанын какканчы ук инде үзен оясы авызында корбанын көтеп торган елан кебек үк куркыныч дошманы көткәнен башына да китерә алмады.

Ә, бер карасаң, солтанга унышлы, урынлы әйтелгән ике-өч бәете белән яраган, шуның өчен ике меңнән артык алтын динар, мең ман [1] ашлык һәм болар өстенә «шагыйрьләр әмире» дигән исем алган шагыйрь Абдаллах Борһани аның килүенә шат кына булырга тиеш иде кебек.

Чөнки бит шагыйрь—шагыйрьгә туган.

Әмма... Гесиод «Хезмәт һәм көннәр»ендә язганча:

Чүлмәкче үчле чүлмәкчегә,
Остада шул ук маза;
Ярлы—ярлыдан, җырчы җырчыдан
Көнләшеп үлә яза.

Борһанинең кәефе юк. Мескен, авырды хәтта. Ул Гомәр турында аның Бохарадан килеп ирешкән дистәләгән дүртьюллыклары аша фикер йөртә ала. Ул аларны эченнән генә һаман һәм һаман пычратырга тырышты, юлны юлга, сүзне сүзгә аерып, алардан хата эзләде.

Шулай да күренеп тора, бу Гомәр начар кешегә охшаган. Усал телле. Кахан янында мәкерле сарай ыгы-зыгысында астыртын эш итәргә өйрәнеп җиткәндер, мөгаен. Югыйсә Исфаханга ничек эләгер иде ул?! Анда, Елга аръягында, халык шомарган. Саклан, Абдаллах! Ул, әлбәттә, юлда килгәндә үк әллә нинди мәкерләр әзерләгәндер инде. Кысрыклар, ипиеңне тартып

[1] Ман—үлчәү берәмлеге.

*Ахыры. Башы 2,3 нче саннарда.*

алыр. Каян килә безнен башка бу хәйләкәр яшьләр!?

Йә Хода! Күпме түзәргә була?! Солтанга, вәзиренә ярарга кирәк. Аларнын—туган-тумачасынын, хәтта хезмәтчеләренен күнелен күрергә кирәк. Аларнын күз карашлары астында дерелдәп торырга, мыскыллап көлуләренә тиләләрчә елмаеп түзәргә кирәк. Жыеннарда гомергә куркып утырасын, тамактан аш үтми,—галижәнапнын кинәт кенә шушы очракка туры китереп шигырь әйтүенне таләп итүе ихтимал. Шунын өчен миенне тартылган җәя кебек көне-төне әзер тотасын, туктаусыз киеренкелектән тинтәкләнә барасын. Нәрсә хакына? Урын хакына.

...Шундый борчулы уйлар белән, төшкән аяк киемен барган унайга кия-кия, Борһани вәзир Низамелмөлек янына йөгерде. Анысы нәкъ шул вакытта Гомәр белән гәпләшеп утыра иде.

Вәзирнен ягымлы итеп:

—Тирә-ягы белән бергә бөтен Нишапур синеке,— дигән сүзләрен ишеткәч, Борһани хәтта тигез җирдә абынып куйды.

«Ай-һай! Шулай бик тизме?

Кара син ул эттән туганны! Үзен бик тә әдәпле тоткан була. Чама белән генә иркен, тыныч, артык тәлинкә тотмый, шул ук вакытта инсафлы да. Әнә бит, вәзир анын йөзенә ничек ягымлы карый. Беренче карашка тыйнак, бераз беркатлырак та кебек. Әйтерсен, башында йолдызлардан гайре берни дә юк. Әмма Абдаллахны алдый алмассын син, юньсез. Ул үтәли күрә сине. Беләбез без сезнен кебек әрсезләрне. Хәзер вәзиргә мактау шигыре—касыйдә әйтәчәк тә, мина дәрвишлеккә генә чыгып китәргә туры киләчәк».

Әмма—күр әле! Гомәр әдәпле генә җавап бирде:

—Мин хакимлек, халыкка боеру, аны тыю турында уйламыйм. Ин яхшысы—мина ел саен эш хакы бирергә куш.

«Хәйләкәр! Бәясен арттыра белә».

—Ярый,— дип баш какты вәзир, анын сүзләрен хуплап. —Шул ук Нишапур кеременнән... ун мен динар алырсын. Ризамы?

«Ә мин мен дә ике йөзне алам»...

—Аллаһы сезне мәрхәмәтеннән ташламасын. —Гомәр баш иде. —Мондый зур сумма турында мин хыялланырга да җөрьәт итмәдем. Ярый, ул бөтен килеш эшкә тотылыр. Минем башка акча тотар урыным юк —хатыннарым да, балаларым да, абзарым да, атларым да юк минем. Һәм тагын бер үтенеч: минем әтиемнен остаханәсеннән иктаны алып булмас микән?

—Иктадар кем?

—Рысбәк бәй.

—Ә! Беләм. Ул хәзер биредә. Сезненчә булыр, алырбыз.

«Беттен!— дип шатланды Абдаллаһ. —Беттен син, Хәйям. Син инде үлден. Бәй Рысбәк ул бит сине, ул бит... Рысбәк!

—Безнен сәләтле дустыбыз касыйдә язамы?— дип сорады Борһани бакыр тавыш белән Гомәрдән, эшне бетереп, барысы да җәймә янына утыргач.

—Юк.

—Ни өчен?

«Чынлап та, ни өчен?— дип уйлады Гомәр гаҗәпләнеп. —Булдырыр идем югыйсә. Һәм бу такмак чыгаручы белән анын дус-ишләрен көлкегә калдырыр идем. Әмма...»

—Мактау, данлау касыйдәләре язу өчен, минемчә, тыныч, салкын канлы, ә акыл белән... теге ни... сезнеке кебек, димме, күтәренке-ялкынлы, кайнар булырга кирәк. Ә мин башкачарак холыклы.

—Алайса, безнен сәләтле яшь шагыйребез каханнын күнеленә нәрсәсе белән ярады сон?— дип аптырап сорады «шагыйрьләр әмире».

—Чәчәкле бушсүзлелек кемнендер күнелен күрер өчен бердәнбер чарамы әллә?

—Патшаның өстенлекләрен данлау бушсүзлелекмени ул? —Борһани акайган күзләре белән вәзиргә карады. Ишетәсенме, бөегем?

Әмма тегесе ымлап кына куйды, ашавында булды. Дәшми генә тыңлады.

—Түгел,— диде Гомәр, —әгәр...

—Нәрсә «әгәр?»

—Өстенлекләре булса...

Әле генә капкан ризык кисәге Абдаллаһның тамагына тыгыла язды.

* * *

...Бойре калкулыгының түбәсендә кояш сәгатенең кыек ак җилкәне күккә юнәлгән. Мәрмәр плитәләрдән җәелгән киң циферблат мәйданчыгына килгәч, анда сәгатьләр һәм минутлар гына түгел, ә секундларның да билгеләнгәнен күрәсең. Аскарак төшеп, обсерваториянең түгәрәк төп манарасы урнашкан һәм ана тау итәгеннән йолдыз сараеның зур секстанты күтәрелгән.

Низамелмөлек белән Гомәр Хәйям Кашгардан алып Фәләстингә кадәр бөтен сәлҗук мәмләкәтеннән җыйган төзүчеләр: греклар, фарсы, әрмән, кытай, гарәпләр бизәлеше белән дә (сызыкларның ачыклыгы, чынаяк кирпичләр, челтәрләр), төгәллеге белән дә чын-чынлап искитмәле үлчәү җайланмасы төзеделәр.

Күп корылмалар әле төгәлләнмәгән яисә аларга әле тотынмаганнар да. Әмма Гомәр, геометрия буенча трактатын тәмамлап, Исфазари, Васитилар белән берлектә, Йолдыз сараенда булган нәрсәләр, бигрәк тә Әбурәйхан Беруниның эш коралларыннан файдаланып, инде ничә еллар астрономик таблицалар һәм яңа календарь төзи.

Шунысы ачыкланды:

Ай елы Айның Җир тирәли 12 тапкыр әйләнеп чыгуыннан тора һәм 354 тәүлек 8 сәгать 48 минут 36 секундка тигез;

Кояш елы—Җирнең Кояш тирәли бер әйләнеп чыгуы—365 тәүлек 5 сәгать 48 минут 46 секундка тигез.

Алар арасындагы аерма—якынча 10 сәгать. Шулай булгач, 100 Кояш елына 103 Ай елы туры килә. Гарәпләрнең Ай календаренда әнә шул 10 тәүлек һәм берничә сәгатьтә житми дә инде. Ул артык кыскартылган.

Ауропада кулланыла торган Юлиан календаре да бик үк төгәл түгел. Ул артык озайтылган. Христиан календаре буенча ел 365 тәү ек 6 сәгать—Җирнең Кояш тирәли бер әйләнеп чыгуыннан 11 минут 14 секундка озаграк дәвам итә. Ел саен җыелып килгән вак «гөнаһлардан» 128 елда артык тәүлекләр барлыкка килә.

Аларны кая куярга? Чиркәү әһелләре 1125 ел элек Юлий Цезарь раслаган календарьга үзгәрешләр кертүгә каршы.

Гомәр ел башын Нәүрүз бәйрәменә—язын көн белән төн тигезләшкән көнгә—21 мартка кайтарды. Бу көнне Кояш өйлә вакытында Кучкар йолдызлыгына керә.

Бирeдә, Йолдыз сараенда, Гомәр вәзиргә түбәндәгеләрне белдерде:

—Без вакыт аралыгы 33 ел булган календарь тәкъдим итәбез. Аның һәр 25 елы—365, 8 е—366 тәүлекле булачак. Бу—елның дәвамлылыгы 365 тәүлек 5 сәгать 49 минут 5,45 секунд дигән сүз. Кәбисә еллар—дүртенче, сигезенче, уникенче, уналтынчы... тәртибендә булачак. Хәзер инде ялгышу биш мең елга бер тәүлек кенә. Кешелекнең көндәлек эшчәнлеге өчен, галиҗнапләре, биш мең елга бер тәүлекнең әһәмияте юк.

Бик гади, төгәл, унайлы календарь хакында, әлбәттә, уйланырга кирәк әле. Һәм без кәбисә еллар турында уйланачакбыз, вакыты житкәч, аларга төзәтмәләр кертәчәкбез.

Әмма халык күтә алмый, галиҗәнапләре. Ана җир сөрергә, чәчәргә, уныш җыеп алырга кирәк. Яшәргә кирәк. Бөек вәзир яна календарь турындагы әмергә кул куйсын иде. Без аны данлы солтаныбыз хөрмәтенә «Мәликшаһ яки Җәләл ел исәбе» дип атар идек. Ул шатланыр. Ун елдан яна Кояш елы, Язгы тигезлек бәйрәме булачак. Яна календарьне гамәлгә кертү өчен бик унай ел.

—Һе!— дип ялкау гына әйтеп куйды вәзир. —Минутлар, секундлар. Ниндидер мескен секундлар җирдә нәрсәне хәл итә ала соң?

—Ничек инде хәл итә алмасын! Секундлардан—сәгатьләр, тәүлекләр җыела. Еллар, гасырлар, мен еллар. Мәнгелек тә секундтан тора, әфәндем!

—Әмер бирү кыен түгел, әлбәттә. Әмма...

—Ни дигән сүз ул—әмма? Кирәк! Бу эшне бит сез үзегез башлап җибәрдегез. Алайса, нигә дип тырыштык соң без?

—Менә шул-шул: нигә? —Вәзир көрсенеп куйды. —Календарьны үзгәртә алабыз анысы. Әмма кеше табигатендәге һичбер нәрсәне секундлар да, минутлар, гасырлар, мең еллар да үзгәртә алмый.

Чынлап та!

Гомәр игенчеләр дөньясын күрде, алар балачактан ук шуны белә: әгәр чәчмисең икән—ачтан үләсең. Шуна күрә тир түгеп икмәк үстерәләр—үзләренә һәм башкаларга.

Кирәкле бар нәрсәне: балта, кәтмән, чүкеч, пычак, савыт-саба, тукыма, бизәнү әйберләре житештерүче осталар дөньясын да күрде ул.

Галимнәр, табиб, рәссам, төзүче, шагыйрь, мөгаллим, җырчы, бауда биючеләр дөньясын да күрде: аларның осталыгы да кешегә хезмәт итә.

Әмма алар янында һәм алар арасында, алар тирәсендә, Гомәр начар белә торган башка дөнья—булдыксызлар, хәйләкәр эшмәкәр, оста алдакчы, эш рәте белмәүче, шома ялагай, теләсә кая үтеп керүче тел бистәсе, мескен язучылар даирәсе, дөньяга авыру һәм ангыра балаларыннан башка берни дә бирмәүче, шулай да яшәүче һәм, сөйләүләренә караганда, бик шәп яшәүче башкалар, шул исәптән төрле күренешләрне анлатырга тырышучылар дөньясы да мәш килә.

Ни исәбенә һәм ни өчен? Алла белсен. Алар ана бөтенесе дә җилкуарлар һәм алдакчы, караклар булып тоела. Аларга төгәл календарь кирәкми. Нинди генә календарь булса да барыбер аларга.

Ярый сон... Мәгърур дөге үскән туфракта кыргый зәйтүн дигән агулы үлән дә үсә. Һәм бу—котылгысыз. Аннан котылуның бер чарасы да юк. Пылау пешерер алдыннан гына хуҗабикә аның ялтыравык-яшел орлыкларын түземлелек белән чүпли.

Юкка хафалана вәзир. Язмыш-хуҗа кайчан да булса чынны ялганнан аерачак һәм соңгысын чүплеккә ташлаячак. Бәлкем ташлар. Чүп үлән яшәүгә чыдам, мөгаен, ул әле үзен дөгедән дә кыйммәтлерәк дип исәпли торгандыр.

Гомәргә инде—31.

Ул әтисен җирләде, әнисе белән сенлесен Исфаханга алып килде. Остаханәләрен саттылар. Туганнарының берсенен акыллы кинәшен тотып, Нишапурдагы йортларын үзләрендә калдырдылар. Төзүче греклардан Гомәр аларча укырга-язарга, сөйләшергә өйрәнде.

Көньяк Кытайның Чу патшалыгы шагыйре, туктаусыз үзара сугышларга ачыктан-ачык каршы чыгучы Цюй Юань 1357 ел элек хаким тарафыннан куыла һәм таш кочаклап елгага ташлана.

154 ел элек Шәрыкның иң күренекле акыл ияләренең берсе Әбубәкер Зәкәрия Рази үлә. Дөньяның мәнгелеге турындагы өйрәтүләре өчен аны диндарлар рәхимсез кыйныйлар һәм сукыра йталар.

Сәгъди—105 елдан, Коперник 394 елдан туачак. Джордано Бруноны 521 елдан соң яндырачаклар.

* * *

Ә бу вакытта сәлҗукләр мәмләкәтендә, тауларда ләм ташкыны җыелгандай, сиздерми генә тупланып, кискен вакыйгалар өлгереп килә иде. Алар, ахыр чиктә, Гомәр Хәйям өстенә дә ябырылды.

Вәзир аның янына бик тә дулкынланган хәлдә килде. Ачылган төргәк күрсәтте.

—Сәмәркандтан. Сиңа монда элеккеге дустың казый Әбуталиб Алактан сәламнәр һәм изге теләкләр җиткерелгән.

Гомәр бик шатланды:

—Исән-саумы?

—Ул исән-сау анысы... Тик караханиларның яңа хакиме Әхмәт бөтенләй акылдан язган эше кылана—башкаласын Сәмәркандка күчереп, тыныч, сабыр халыкның ачуын чыгарган. Дин әһелләрен һәм төрек сәрдарларын үзенә каршы куйган. Ул якын Елга аръягын безнең мәмләкәттән тартып алырга ниятли. Әйтерсең, аерым яшәү аңа яхшырак булачак. Ул, эт баласы, үзен шундук кайсы да булса бер каханның, көнчыгыш далалардагы бер бүренең тотып ашаячагын аңламый. Аңламый! —Вәзир төргәкне йомарлады да кыштырдатып баш очында селкеде. Утырды. Хатны келәмгә ыргытты, кулларын тезләренә куйды. —Мин көне-төне мәмләкәтебез турында кайгыртам. Аны ныгытырга телим. Хуҗалыкта, акча эшләрендә нинди дә булса тәртип урнаштырасым, бәкләрне—ачулы кара халыктан, кара халыкны комсыз бәкләрдән саклыйсым килә. Син математикка да, Алла колы Газалигә дә ярарга тырышам. Илебездә тынычлык һәм иминлек булсын, дим. Әмма ул хәсисләр, —вәзир кычкыруга ук күчте, —хайваннар кебек, тупас вә сукырларча, мин булдырганны туздыралар! —Аның тавышы кинәт әкренәйде: —Бөтенесен ташлап, сукбайлыкка китәрмен әле. Син боларны аңларга тиеш. Үзең үк җәфа чигәсең алардан.

Чөнки төптән уйлап карасаң, син эшләгәннәрнең барысы да, ахыр чиктә, ил өчен, халык өчен бит. Шулай түгелмени? Шул ук кешеләр сине беренче алласызга, уйнашчыга, сәрхушкә саный.

Китик, ә? Хәнакага—дәрвишләр янына. Дога укый беләбез—ачтан үлмәбез әле. —Ул тирән сулап куйды, аягы белән таралып яткан төргәккә сузылды, үкчәсе белән үзенә якын китерде, тигезләде һәм янадан тыгыз итеп бөтерде. —Их! Кая барыйк ди без?! Без синең белән шул ук коллар. Рәхимсез дәвер коллары. —Күсәк белән кизәнгән кебек, Сәмәркандта эшләнгән тирән, бизәкле кәса төргәгенә сукты. —Миңа солтанга... Җәйхун аръягына барып, ул урыннарда тәртип урнаштырырга вакыт җитте! Барып әйтим әле солтанга.

Китте ул...

Бернинди мәгънәсе булмавын аңлый башласа да, үзенең шул каһәр суккан эшенә ябышып тик ята. Елгага егылып төшкән кырмыска да бит кайдадыр саерак бер урында үзен елгыр ташбаш кабып йотканчыга кадәр, аяклары белән чәбәләнеп, күбек кисәгенә, яр читендәге ботаклар күләгәсенә ябышырга тырыша.

—Мин үзем дә күптәннән инде Елга аръягына барып чыгарга, караханиларны мөртәтләрне акылга утыртырга уйлап йөрим,— дип җавап бирде солтан вәзиргә. —Әмма... җинел эш түгел бу. Йолдыз белгечләреннән

сорарга кирәк —уңышлы булыр микән минем бу яу.

—Юк,— диде Исфарази, исәпләп. —Йолдызларның урнашуы «чыгу»ны түгел, ә «кайту»ны күрсәтә.

—Ярый, уңайлырак көн сайларга тырышыгыз,— диде кәефе кырылган вәзир. Аның солтанны тизрәк Елга аръягына җибәрәсе килә иде.

Ул арада Әбутаһирдан яна хәбәр килде: Сәмәркандта фетнә. Вәзир дулап Йолдыз сараена килеп житә. Исәпләүләр эшенә Васита тотына. Күк тагын уңышсызлык вәгъдә итә.

—Ачуланмагыз, галиҗәнапләре! Йолдызларның урнашуы яхшы якка үзгәрмәгән. Уңайлы көнне сайлый алмыйбыз.

—Ә син астрологиядән көләсең!— дип ташланды вәзир «Хәерчеләр тустаганы»—Төньяк Таҗны күзәтү нәтиҗәләрен язып утырган Гомәргә: «Зодиак тамгасы—алтынчы, 29 градус 6 минут...» Йолдызлар үзләренчә яши, алар безгә йогынты ясамыйлар, имеш. Ясыйлар шул! Нинди дер тинтәк йолдызларның ничектер юләрләрчә урнашуы аркасында дәүләт күләмендәге мөһим эш өзелә. Шушы зур һәм кечкенә йолдызлар көтүлегендә безнең файдага хәл итә торган бик кечкенә генә булса да бер йолдыз юкмыни соң?

Гомәр эсселе-суыклы булып китте. Менә бит, бу кеше бернинди йолдызга да ышанмый, —ни әйтсәң дә, үзе галим, — ә менә солтанга ярарга тырышу өчен ышанган булып кылана. Җир йөзендә күпме акыллы кеше дингә өйрәтүче-канунчы тукыганга оятсыз рәвештә «ышана»! Чөнки шулай яшәү уңайлы, файдалы. Башкаларны өйрәткән нәрсәләргә ул диндар үзе ышанамы соң? Ышана икән, аны әле гафу итәргә була. Әгәр инде ышанмыйча гына өйрәтә икән, ул алдакчы, аны базарда барча кеше алдында сукты рырга кирәк.

—Эзләрбез,— диде Гомәр коры гына.

Үзләренең файдасыз ыгы-зыгылары белән туйдырып бетерде инде алар! Акылдан шашарсың, валлаһи: канга сусагандай, көне-төне сөңгеләре белән калканнарга бәрәләр. Елга аръягы дип аталган, кояш тарафыннан яндырылган бер кечкенә җир кисәге сәлҗуклар хакимиятеннән аерылса, әйтерсең лә, дөнья җимерелә...

Алтыныгыз, икмәк, затлы киемнәрегез азмы әллә?

Икемөгез дигән нинди дер бер тинтәк тә дөньяда иң зур хакимият оештыру өчен акылдан язган кебек йөргән... Дарий шаулаган, Ксеркс котырынган. Рим дулаган.

Һәм һәрберсе, әлбәттә, үз дәүләтен мәңгелеккә корам дип ашкынган.

Нәрсә дигән сүз соң ул мәңгелек? Үң ел, йөз ел, хәтта мең ел да түгел. Мәңгелек—куркыныч, ул астрономик төшенчә. Җирдә бер нәрсә дә мәңгелек түгел! Шулай булгач, мәгънәсен аңламый торып, сүзләрне унга-сулга чәчмәгез.

Ас та кис һәммәсен, туракла,
Кан аксын, көл булсын, җимер;
Барыбер мәңгелек түгелсен,
Өлешең—өч аршын җирдер!

Гомәр күңелсезләнде:

—Сугыш?! Мин бернинди йолдызга карамыйча да әйтә алам: ул уңышсыз булачак.

Вәзир сагая калды:

—Нишләп алай, каян алып әйтәсең моны?

—Сугыш уңышлы була алмый! Сугыш үзе үк инде уңышсызлык дигән

сүз. Бөек бала. Күпме кеше һәлак була. Нәрсә хакына? Кан коюга уңай туры килә торган сәгатьләр һәм минутлар юк, вәзир. Иң яхшысы— шаһ беркая да бармасын. Бүген дә, иртәгә дә. Беркайчан да.

—Син... борының белән йолдызларга кадалгансың икән, аны шулар арасында гына тот инде. Кирәкмәгән җиргә тыкма! Безнең мәмләкәтебез сугыш белән төзелгән һәм сугыш белән яши,— диде вәзир дорфа гына.

Гомәр кызып китте:

—Әгәр йолдызлар, Җәйхунны чыккач та, Мәликшаһ әтисе Альт арыслан кебек үк шундук үләчәк, дисәләр?

—Юк! —Вәзир тешләрен ыржайтты. —Йолдызлар алай әйтмәс. Алай әйтергә тиеш түгелләр. Аңлашыламы?

—Аңлашыла.

Шаһ сараендагылар белән килешеп яшәве кыен.

Ул астролябиясен алды.

—Сабыр ит!— дип туктатты аны вәзир. —Мин солтанны чакырам.

Солтанның ярым балаларча игътибарлы, хәтта бераз кыюсызрак күз карашы астында Гомәр кояшның биеклеген үлчәде, хан йолдызнамәсенең градусын исәпләп чыгарды, таблица буенча йолдызларның торышын билгеләде. Кулына түгәрәкле һәм өлешләргә бүленгән сәер корал тоткан галим бу минутларда солтанга, мөгаен, сихерче булып та күренгәндер әле.

—Шу-лай. Кәҗәмөгез. Альфа. Зодиак билгесе—тугызынчы. 21 градус 46 минут озынлыкта, 7 градус 20 минут киңлектә. Гамәле—уңай.

Гомәрнең күңеле күтәрелде. Патша белән вәзир җиңел сулап куйдылар.

—Сукояр. —Әһә! Исфазари, Васити, сез ялгышкансыз. Менә ул сул иңбашындагы нәрсә, Сукояр бетасы! Аның исеме—Бәхетләр бәхете, шулаймы? Зодиак билгесе—унынчы. 10 градус 56 минут озынлыкта, 8 градус 50 минут кинлектә. Төньяк күрсәтелгән. Гамәле—уңай. Аңлашыламы? —Гомәр аерым басым ясап әйтте: —У-ңа-ай!

Нәрсә маташтыра бу баш астроном? Васити кыюсыз гына каршы төшмәкче булды.

—Кәҗәмөгез белән Сукоярның ни катнашы бар монда? Сүз бит Укчы турында бара...

—Әйе, әйе, Укчы турында,— дип җөпләде аны солтан, ниһаять, үзенең шул билге астында тууын искә төшереп.

—О, галиҗәнап! Карарга рөхсәт итегезче,— диде Гомәр җай гына. Ул астролябиясе белән йолдызлар таблицасына төртеп күрсәтте. —Укчыда— сугыш чукмары Маррих (Марс) йорты. Монда тагын—Бәхетләр бәхете. Бөтенесе бик тә уңай килә. —Ул калын астрологик җыелманы ачып карады. —Барысы да уңай-уңышлы булачак. Шунысын гына онытмагыз: әйбәт гаскәр алыгыз һәм уң кулыгызның урта бармагына асылташлы балдак киегез.

—Асылташны яратам мин!— диде солтан.

Исфазари:

—Ә-ә...— дип башлаган иде дә, Гомәр аны кискен генә туктатты:

—Ә Исфазари әле яшь! —Һәм ул ярдәмчеләренә каш астыннан шундый итеп карады ки, күзләре салкын сары-яшел асылташка әверелгән кебек булды.

Ана каршы әйтергә җөрьәт итмичә (гәрчә аның сафсата сатуын күреп торсалар да), дәшмичә чыгып китүне артыграк күрделәр.

Солтанның кәефе күтәрелде:

—Әгәр син дөресен әйтеп, яу уңышлы булса, мин сине биш шаһ бүләкләгәндәй бүләкләрмен,— диде.

—Мин дә—биш вәзир кебек,— диде вәзир, учы белән маңгаен сөртеп.

Шулай итеп, солтан Мәликшаһ уң кулының урта бармагына асылташлы балдак киде дә, күпсанлы гаскәр алып, Җәйхунны кичеп чыкты.

Йолдызлар мәсьәләсендә ул, әлбәттә, берни дә аңламый, әмма үзе батыр кеше иде. Караханиларны тәмам тар-мар итте, Бохараны, аннары, озак камап торганнан соң, Сәмәркандны басып алды. Хан Әхмәт әсирлеккә төште. Әмма ул Мәликшаһның яраткан хатыны Төрек-Хатынның туганы иде, шуңлыктан солтан аны үтермәде, тәхетенә кире утыртты, бөтен Елга аръягына дәһшәтле курку салып, күп табыш һәм зур дан белән Исфаханга кайтты.

Шул хакта белгәч, йокысыз төннәр нәтиҗәсендә ябыгып калган Мозаффар Исфари Гомәр янына килде дә аның аягына егылды.

—Мөгаллим! −диде ул күз яшьләре аша. —Минем башны катырган табышмакны чишеп бирче. Югыйсә авырырмын. Йолдызлар буенча «чыгу» юк иде бит, алар «кайту»ны күрсәтteләр.

—Солтан чыкмадымы? Данга күмелеп кайтмадымы?—диде Гомәр, һич тә аптырамыйча.

—Әйе, әмма ничек итеп алдан белә алдың соң син? Мин ничә төннәр буе йокламадым. Укчының градусларын һәм минутларын яңадан исәпләп чыгардым, бер нәрсәне дә истән чыгармадым, барлык йолдыз таблицаларын һәм астрологик иншаларны тикшердем. Йолдызларның торышы әле һаман да тискәре. Бәлкем, мин нәрсәнедер белмимдер? Аллаһы хакына аңлат, «чыгу»ны ничек исәпләдең син?

—Берничек тә исәпләмәдем,— диде Гомәр, иснәп. Бу төнне ул да начар йоклады. —Берни дә исәпләмәдем, башыма ни килде, шуны әйттем. Йолдызларның, дускай, безнең җирдәге ыгы-зыгыда эше юк. Кояш ул әтәч кычкырганга гына чыкмый, Солтанның каханны кыйныйсы килә икән, барсын да кыйнасын. Нәрсә көтәргә? Мин шуны белдем: икенең берсе булачак—йә бу гаскәр җиңеп, тегесе җиңеләчәк, йә тегесе җиңеп, монысы җиңеләчәк. Теге гаскәр җиңелә икән—Аллага шөкер, монысы җиңелсә—миннән сораучы булмаячак.

Аларның сөйләшүен кемдер тыңлап торган, мөгаен, Газалидер, һәм бу хакта солтанга җиткергән. «Менә ничек уйный икән ул ханнар язмышы белән!»— диде ачуы чыккан Мәликшаһ һәм Гомәргә вәгъдә иткән бүләкне бирмәде. Солтан аны күрмәмешкә салышты, хезмәт хакы да түләми башлады. Гомәрнең үткән еллардан калган акчасы бар иде. Өстәвенә яуның уңышлы төгәлләнүеннән риза калган вәзир дә аңа үз казнасыннан ун мең динар бирде.

Шулай итеп, Йолдыз сараенда төзелеш дәвам итте.

• • •

Өйдән ерак түгел, юл читендә, мәгънәсез мыгырдап һәм селкенеп, мескен бер карт дәрвиш аякларын бөкләп утырган. Йолдызлар галимен шул мизгелдә үткен караш өтеп алды. Әмма Гомәр аңа карамыйча үтеп китте. Күп йөриләр алар Көнчыгышта. Калкулыкка күтәрелгәч, математик вәзир турында онытты. Сарайдагы ызгыш-талаш, солтаннар, вәзирләр, тән сакчылары—аңа боларның берсенең дә кирәге юк. Алар үз эшен эшләсен, ул—үзенекен.

—Шушында, аста көт,— диде ул грек Кириакка. —Мин өскә күтәреләм, кайбер нәрсәләрне тикшерәсе бар.

Өстә ул бохаралы Әмид Камалины очратты. Яңа «шагыйрьләр әмире». Шигырь чыгара белә, Коръәнне хөрмәт итә һәм Аллага сораулар бирми. Яшь чагында Гомәр: шагыйрь өчен иң мөһиме—акыл, талант, дип уйлый иде. Хәзер аңлады—аларның һич кирәге юк икән. Шигырь язу серләрен белмәгән килеш тә шагыйрь дип исәпләнеп һәм хәтта «шагыйрьләр әмире» дигән исем йөртеп була икән бит.

Шигырь тирәсендә күпме шундый бәндә тамак туйдыра! Әрәмтамаклар.

Низами Арузи Сәмәрканди үзенең «Дүрт әңгәмә»сендә сәлҗуклар нәселеннән булгап шаһларның исемнәрен «мәңгеләштерүче» шагыйрьләрне санаганда башкалар арасында Борһанидан соң безнең Әмид Камалины да китерә.

Үзе үлгәч, аннан җирдә калачак нәрсә бары шул гына.

—Сиңа монда нәрсә кирәк?

—Кызыксынам!— дип җавап бирде «шагыйрьләр әмире», куштанланып.

—Ярый. Анысы гөнаһ түгел. Тик кара аны, йолдызларда янып үлә күрмә! Юкса монда берәү... авыр туфрагы җинел булсын, кызыксынган иде инде. Синнән алдагы «шагыйрьләр әмире»...

—Аллам сакласын, Аллам сакласын! Минем бернинди кара уем юк.

—Яхшы. Комачаулама.

Гомәр кояшның биеклеген билгеләде, тиешле саннарны теркәп куйды. Йөзләрчә тапкыр! Башын иеп һәм кулларын артка куеп, ул, төрмә каланчасындагы тоткын кебек, ашыкмыйча гына бүген төнне Әкдас белән үткәргән түгәрәк мәйдан буйлап йөренә башлады.

Балык, Балык. Көньяк Балыгы.

Көньяк Балыгы, шагыйрь калдыгы...

Һе! Шигырь кебек нәрсә килеп чыга түгелме соң?

Уйга баткан хәлендә көлемсерәп, Гомәр инде сызгыра ук башлады. Бу исә уйларга ярдәм итте. Артка яшерелгән бармаклар гадәт буенча әкрен генә селкенә-бөгелә башладылар.

«Шагыйрьләр әмире» әлеге озын, көчле бармакларның хәрәкәтләнүен башта гаҗәпләнеп, аннары инде шикләнеп күзәтә. Ул бармакларның очлары, хуҗа миендәге нииндидер шикләнүләрне кире кагып, кыюсыз гына сискәнеп куялар, сак кына нәрсәдер эзлиләр, икеләнеп, тураялар. Юк, тапмадылар һәм кинәт үзләренә генә билгеле нәрсәнедер тиз-тиз исәпли башладылар.

Менә инде икесе—имән бармак белән урта бармак—арырак киттеләр, исемсез бармак белән чәнчә бармак, ниһаять, үзләре эзләгәнне табып, кинәт кенә бөгеләләр һәм янадан, бу юлы инде ышанычлы төстә, табышны саный башлыйлар.

Шул чак Әмиднең башына искиткеч бер уй килде...

Ничә градус кинлек? Рәхим ит. Егерме өч, ә минутлар кая—ноль.

Аяк астында нидер ялтырады. Гомәр аны иелеп алды. Кечкенә генә кызыл якутлы алтын алка. Шушы көннәрдә генә, үбеп, Әкдаска бүләк иткән пар алканың берсе. Димәк, төнлә югалткан.

Кинәт әлеге кызыл тамчы Әкдасның каны булып тоелды, инде сәгатьтән артык нииндидер билгесез борчылудан әрнегән күкрәген яндырып алды да, көзге җилдәге салкын җимеш кебек, суынган йөрәгенә туптуры килеп төште.

Минутлар, градуслар... Чәнчелеп китегез лә! Әгәр май сыга торган кыскычта минем миемне сыксаң, аннан ни калыр иде икән? Почмаклар,

минутлар, градуслармы? Йолдызлыклармы? Шайтаныма олаксын! Кемгә һәм нәрсәгә кирәге бар аларның? Анын кинәт Йолдыз сараена жен ачулары чыкты. Тинтәк каланчаны түбәсенә кадәр Хәзәр нефте белән тутырырга иде дә яндырырга иде! Нәрсәгә, нигә дип монда мин? Бүген үк Әкдасны алам да анын белән Баге-Сангка китәм...

Әкдас! Ул алканы учына кысты? Бәла дигәнен менә шулай килә инде ул. Көтмәгәндә килә. Анын турында уйларга да онытканда. Акчанны да шулай югалтасын, кыйммәтле кәгазьләренне дә...

Ә аннары, башынны бәрсән дә, аларны кайда һәм ничек калдыруынны анлый алмыйсын.

Әкдас! Ул аска атылды һәм, аны күреп, катып калды. Еракта-еракта, аста. Кояш секстанты җәясенең башында. Башка планетада. Алар арасында илле мең ел озынлыгындагы бер көн. Әкдас, чайкалып, басмага утырды, башын тезләренә куйды, аннары авыр бакыр герне күтәргәндәй, көчкә күтәрде. Гомәр анын иң соңгы көчен жыеп, өзгәләнеп, торна тавышы белән әйтелгән бер сүзен ишетте:

—Тизрәк!

Ул аның янына менә алмый иде.

Гомәр, гашиш тарткандай мингерәүләнеп һәм югалып калып, йолдызлар белән тулы бөтен галәм аша секстант җәясе буйлап аның янына төште.

—Гомәр... ул мине агулады.

Шундук баштан каядыр аякларга таба кан агылды, һәм бер мизгелгә Гомәрнең салкын колакларына коточкыч улау килеп бәрелде. Кичәге Әкдас белән бүгенгесе, аның алдындагысы арасындагы аерма искитмәле зур балта булып бергә кушылды һәм аның инбашына килеп төште. Күздән йолдызлар чәчрәде. Юк. Әкдасмыни бу? Бу—Алголь.

—Кем?! —Аягын авырттырып, ул гранит басмага егылды, Әкдасның рәйхан яфрагы кебек каракучкыл-алсу йөзен кулына алды. Авызы янган. Күзләрендә—кан.

—Шайтан таягы.

«Саташа».

—Нинди шайтан таягы?

—Коры Шайтан таягы.

«Чынлап та саташа».

Әмма Гомәр озакламый шундый нәрсәләр белде, ана үзе саташадыр кебек тоелды.

—Карт Хушанг. Гашишчы ул. Мин дә... җәннәт кызы идем. «Назлы Күзлекле елан—Кобра» мин. Бар, йөгер, вәзирне коткар. Мин... алып киттем аның сакчыларын... иске тирмәгә. —Ул, соңгы көченә кадәр кешелек кыяфәтен сакларга тырышып, оялган кебек, икесе ике төстәге оятсыз күзләрен аска төшерде. Аның илаһи, әмма җимешсез гәүдәсен көзән җыера башлады. Әкдас үзенең елан тешләрен аның ак кулына батырды. Канны төкерде. —Гомәр, кадерлем! Аһ, әгәр син безнекеләрдән булсаң икән...

—Шушында ятып тор! —Ул аны басмага яткырды, сакчыны чакырды да аның белән бергә Хушанг өенә китте.

Ана каршы вәзир сакчыларының берсе йөгерә иде. Агарган, тиргә баткан.

—Галиҗәнап... галиҗәнап...

—Нәрсә?!

—Яралы.

«Яраланган гына. Терелтәм мин аны.»

Кече капка янында Низамелмөлек чайкалып басып тора иде. Йөзе балавыз кебек, авызыннан кан ага.

—Гомәр, балакаем... —Ул каршыга атлады, киемен канга буяп, аның иңбашына сыланды. —Минә ... минем атомнарым... таркалды. Син... кит моннан, кадерлем. Тегендә, кирегә... килгән жиренә. Юкса харап буласың. —Һәм, жан биреп, Гомәр кулларында асылынып калды.

Сак кына төрткәләп, чынлыкта япь-яшь теге дәрвишне алып чыктылар. Чал сакалы купкан һәм ияненең бер ягында асылынып калган. Ул инде уе белән кайдадыр жәннәттә, хур кызлары кочагында. Гомәрне күрми дә.

Аннан соң куллары артка каерып бәйләнгән Хушанг чыкты. Карт карашы белән Гомәрне эзләп тапты, кызганыч көлемсерәде.

Гомәр, әйтерсең лә, исмаилит аркасына пычак кадаган, куе кызыл томан эчендә Әкдас янына әйләнеп килде. Ул инде тагын бер мәртәбә секстантка күтәрелә алмаган басмаларда эчен тотып бөгәрләнеп ята, тәне суынган.

«Назлы Күзлекле елан»мы? Әйе, бик тә назлы идең син. Искиткеч назлы! Күрелмәгәнчә назлы.

Һәм аның Әкдас турында башка әйтер сүзе юк иде. Чөнки аның турында нигездә берни дә белми ул. Берни дә! Унжиде ел буе һәр төн саен диярлек бергә булып та, ул аңа ят булып калган, —монысын менә хәзер генә анлады. Табышмак иде һәм аның белән табышмактагыча аерылышты да.

Горгона Медузасының шашкан күзләреннән таш булып каткандай, Гомәр аның янында сүзсез озак басып торды.

Кулы әрни. Гомәр иренеп кенә әле һаман да тамчы якутлы алтын алканы кысып торган йодрыгына күз салды. Кулындагы кан зур тамчы якутка әверелде. Хушанг карт үз кызына биргән агу тешләре үтеп керсә, Гомәрнең дә үлүе ихтимал.

Үлсәни! Убырлылар арасында яшәгәнче үлүең артыграк.

Соныннан, ялгызы калгач, ул, мөгаен, үкереп елар, чәчен йолкыр, башын диварга бәрер. Йә булмаса, бар кешедән читләшеп, дәшми генә нык авырыр.

Ә хәзер... Ул учын ачты, алтын алканы ике-өч тапкыр сикертеп карады, аннары аны секстант басмасында бөгәрләнеп яткан Назлы Күзлекле елан өстенә ташлады да китеп барды.

Мин кырыс холыклымы? Бәлкем, шулайдыр. Әмма туйдым мин сезнең ахмаклыкларыгыздан...

«Әле дә ничек акылдан язмадым мин?— дип гажәпләнде Гомәр үз-үзенә. —Ә бәлкем шашып та, үзем шуны тоймыймдыр? Әйтәләр бит: тиле үзенең тилелеген беркайчан да белми, диләр».

...Шәһәрдән Йолдыз сараена «һайт-һайт!»лап мең кешелек отряд килеп төште. Бирегә үтерүче-гашишчыларның тулы бер гаскәре оялаган, дип Мәликшаһка кемдер әйткәнме, әллә куркуыннан үзенә шулай тоелганмы, әмма ул шундый нык саксыз сарайдан чыгарга жөрьәт итмәде.

—Сөйлә!

Гомәр сөйли. Башын иеп, Мәликшаһ сүзсез генә тынлый. Бер якта, әтисенең мәете янында, Гомәрнең әйбәт дусты Гыйззелмөлек үкси. Мәликшаһ дәшми. Аның әле әйтер сүзе юк. Чөнки вәзирнең үлеменә кайгырамы, әллә сөенәме—моны үзе дә белми.

—Үтерүчеләрне алып килегез!— ди вәзирнең улы, яшькә чыланган, ачулы йөзен күтәреп.

—Әйе! Әйе!— ди, ниһаять, солтан. —Алардан сорау алырга кирәк.

—Галиҗәнапләре үзенен мәхлук хезмәтчесен кичерсен, яисә җәзага тартсын, әмма бу... мөмкин түгел, —ди тән сакчысы, солтан алдында баш иеп. —Үтерүчеләр үлгән. Агуланганнар. Яисә агулаганнар.

Бөтенесе ни әйтергә белми катып кала. Тынлыкны Әмид Камали боза:

—Мин беләм: аларны агулаганнар! Кем агулаганын да беләм. —Яна «шагыйрьләр әмире» агарынып, дулкынлануыннан калтыранып, — шулай булмыйча, ул бит шундый зур батырлык эшли, анын баш очында дәверләр җиле сызгыра, —катгый төстә алга чыга һәм бармагы белән... Гомәр Хәйямга төртеп күрсәтә. —Тотыгыз аны! Ул да исмаилит. Ул вәзирне тозакка алып керде. Мин кечә манарада күреп тордым: ул бармакларын әйләндерде, тегеләй-болай бөкте. Гашишчыларнын яшерен сөйләшүе ул. Ишеткәнегез бармы шул хакта? Гомәр кем беләндер сөйләште.

—Манарада тагын кем бар иде?— дип дәһшәтле тавыш белән сорады Гыйззелмөлек.

—Юк. Без икәү генә идек.

—Шулай булгач, үз-үзеннән башка кем белән сөйләшә ала сон ул? Әллә син үзен дә гашишчымы?

—Ай-яй!— дип чәрелдәде «шагыйрьләр әмире» һәм лып итеп тезләнде. —Кичерегез, уйламыйча әйткәнмен.

—Уйларга кирәк, тинтәк!

—Ә шулай да ни өчен бармакларын тегеләй-болай бөккән ул?

Гыйззелмөлек Гомәргә борылды:

—Ник бөктен бармакларынны?

—Ни өчен?— дип кабатлады солтан.

Гомәр инде калтырана ук башлады.

—Әгәр дә бу юньсез шагыйрь икән... —Гомәр иренен тешләде, авыр сулап куйды, —шигырь чыгарганда без карандашсыз гына, бармакларыбызда иҗекләрне, үлчәмне саныйбыз. Белмим, ул нәрсә белән саныйдыр, тешләре белән микән әллә? Менә хәзер саныйм мин аларны!

—Җитәр!— дип тыйды аны солтан. —Тыныч кына тор. Әйтер идем инде, Алла бәндәсе... Тапкан шигырь чыгарыр урын... —Ул чигүле җиңе белән кызарган йөзен сыпырып куйды да «шагыйрьләр әмире»нә әйтте: —Кит моннан!

Аннары дустанә, гади генә итеп Гомәргә:

—Бу хәлләр солтан Мәхмүт Газни вакытында булса, беләсенме кайда булыр иден инде син?— диде.

—Беләм. Әмма якты дөнья, кешелек дөньясы, тормыш—бер солтан Мәхмүт Газни гына түгел бит әле. Җир йөзендә башка нәрсәләр дә бар. —Ул төксе генә Гыйззелмөлек белән карашып куйды, сүзсез генә анын ризалыгын алды һәм Мәликшаһка баш иде: —Җибәр мине, патша.

—Кая җибәрим? —Сәлҗук авызын ачып, аптырап Гомәргә карады.

—Өйгә, Нишапурга. Әниемнен каберенә барып килим дә китим.

—Юк, ни сөйлисен син, ни сөйлисен?! —Күрәсен, монарчы аз сүзле, үз уйларына гына чумып йөргән, бер нәрсәгә дә кысылмыйча, бөтенесеннән читләшкән астрономнын сарайда әле дә булса ышанырга мөмкин булган бердәнбер кеше икәнлегенә төшенде бугай. —Җибәрмим. Син монда кирәк.

—Нәрсәгә?

Солтан дәшмәде. Вәзирнен кызганыч мәетенә карады. «Эсад иде—Җәседкә калды»,— дип шаяртыр иде мәрхүм вәзир үз-үзе турында. Ягъни, арслан иде, мәет булды.

Мәликшаһ инде җитди итеп әйтеп куйды:

—Йолдызларга карап фараз кылырга, балаларыбызны укытырга кирәк син.

Утыз көн үткәннән соң, кем тарафыннандыр агуланып, солтан Мәликшаһ үзе дә шундый ук мәеткә әверелде.

Күрәм бер кошны: кунган юл ташына,
Тузанда аунаган Кавус башына;
Карап әйтә: «Бу синме, шаһ? Кайда,
Нигә юк тәхетең, таҗың башында?»

Солтанны җирләүләре булды, төнлә сарайда монарчы күрелмәгән ыгы-зыгы купты. Шау-шудан уянган Гомәр башкисәр карт Ораз кебек сүгенеп куйды:

—Трах-прах! Шаһ сараемы бу, әллә төнге караклар оясымы?

Дагалы үкчәләрнең авыр һәм еш шакылдавы ишетелә, әйтерсең лә, караклар, сәүдәгәр складына үтеп кереп, ашлык тулы капчыкларны күтәргәннәр дә төрле якка чабышалар. Ишекләр шыгырдый. Кылычлар чыңлый. Суккан тонык тавышлар, нәрсәдер нәрсәгәдер бәрелеп шыкырдаулар...

Һәм шулчак: «Баркъярукка—үлем! Дан солтан Мәхмүткә!»—дип кычкырганнары ишетелә.

Әнә эш нәрсәдә икән! Гомәр күрергә дип чыкты.

—Артка!— дип акырды мыегы асылынып торган Елга аръягы төрек сугышчысы.

—Карыйм гына.

—Шунда бас та кара.

Тәхет залына илтә торган диварлар буйлап таза гәүдәле сак гаскәре тезелеп баскан. Барысы да Елга аръягы төрекләре. Кулларында янып торган йөзләрчә факел яктысында кыннарыннан чыгарылган кылычлары ялтырый. Исерек яшүсмерләр, кылычларын һәм факелларын болгап:

—Солтан Мәхмүт! Яшәсен бөек солтан Мәхмүт!— дип акыралар.

Бүтәннәр ярдәменнән башка әле штанын кияргә-салырга да өйрәнмәстән, шундук «бөек солтанлыкка» эләккән, шул уңайдан матур итеп киендерелгән Төрек-Хатынның улы—биш яшьлек Мәхмүтне бәллүр вазаны күтәргәндәй сак кына тәхет залына алып баралар. Ә ул төрек абыйсы кулында, маңкасын чыгарып, йокы аралаш шыңшый иде.

Аның артыннан, якут, алтын һәм зөбәрҗәтләрдән торган ялтыравык бәллүр кисәк булып, Гомәрне искитмәле чибәрлегенә һәм һинд хуш исләренә коендырып, Зөһрә үзе үтеп китте, дөресрәге, uктай очты.

Ашыга. Кичә генә мәхәббәт ләззәтен татыган кыз янадан күрешергә ашыккандай ашыга. Югыйсә бит ана, тол калган хатынга, гореф-гадәт буенча жиде көн үз бүлмәсеннән дә чыгарга ярамый. Кичтән үк ятмагандыр, күрәсең.

Баркъярук яклыларның бер өлешен туракладылар, бер өлеше, җәберләнгән шаһ малаен үзе белән алып, кайдадыр яшеренде.

Этешә-төртешә, барысы да тәхет залына агылды. Шундый ук ыгы-зыгы, этеш-төртешне Гомәр Нишапурда, төнлә печән базары янганда күргән иде. Уттай кызарган йөзләр. Курку, кайгылы тавышлар—һәм кемнеңдер шатланып көлүе.

Әмма монда базар түгел, ә күп еллар дәвамында зирәк акыллы Низамелмөлек түземлелек һәм саклык белән төзегән сәлҗукләр мәмләкәте яна. Алайга калса, бу да искиткеч зур базар: анда һәркайсы сатарга, алырга, алдарга тырыша.

Малай-патша Мәхмүт инде шыңшудан туктаган һәм хәтта кызык бу уеннан күңеле үк күтәрелгән иде. Аны башта, гадәт буенча, күмәк кычкырып, ак киездә югары күтәрделәр, аннары алмазлар белән бизәлгән алтын тәхеткә утырттылар. Аның янәшәсендә, дерелдәгән иреннәрен кыйшайтып, бәхетле

әнисе, патшабикә Төрек-Хатын елмаеп басып тора. Хыялы тормышка ашты.

Тәхет залы гөмбәзе астында дога укучы Шәйхелисламның сузынкы тавышы яңгырады. Догасыз буламыни?!

—Хәзер инде... сак бул,— дип пышылдады кемдер Гомәрнең артында. Ә! Карт башкисәр Ораз икән. Үзе. Алар кайчакларда капка янында очрашалар иде. —Хәзер инде сак бул, галим дус. Йөз динар да өч фельс! Монда озакламый шундый хәлләр башланачак...

Һәм башланды да.

Менә өч ел инде, Мәликшаһ Елга аръягына барганнан бирле Гомәрнең хезмәт хакы алганы юк. Саклыкка куйган акчасы да бетте—бөтенесен Йолдыз сарае йотып барды. Бойредагы эшләр тукталды.

Бойре Низамелмөлек үтерелгәннән соң ук бушап калды. Аның үлеме унаеннан Солтан кискен сорау алулар үткәрде, тик җаваплар бер үк иде: «Без берни дә белмибез, галиҗәнап! Аның яшерен эшләренә бернинди катнашыбыз юк. Безгә шунысы гына мәгълүм: башлык булыр алдыннан ул берничә елга каядыр китеп торды, аннары кызы вакытлыча югалды. Без башка берни дә белмибез». Өч кешенең башын кистеләр, калганнарын таяк белән суктырдылар—алары таралышып бетте.

Гомәрнең ташландык сарайларда, кирмән, шәһәрләрдә бернича тапкыр булганы бар. Аларда сине һәрвакыт сагыш биләп ала. Әмма ул—якты сагыш, чөнки ишелгән дивар һәм манараларда, җимерелгән баганаларда, кипкән суагызгычларда вакыт, озак еллар тамгасы ята. Тормыш моннан хәзер генә түгел, әллә кайчан үткән. Шунлыктан синдә аның өчен кайгы түгел, ә сагыш кына калган. Һәм анда бернинди кеше ашаучы гульләрнең булуы мөмкин түгел.

Менә бер корылма тора. Теләсә кайсы мизгелдә почмактан кем дә булса килеп чыгар да, үзара сөйләшү, көлеш башланыр төсле, әмма биредә беркем юк, буш, синең җинелчә адымнарың куркыныч гүләүгә әверелә. Кычкыр, чакыр—кайтавaздан башка беркем җавап бирмәячәк.

Сарай яна түгел, шуңа анда күзгә күренми торган җан ияләре—әрәкләр яшидер кебек. Монда нниндидер йонлы явыз албасты килеп чыгуын көтәсең.

Солтанбикәнең рөхсәтен алып, Исфазари белән Васити Балхка киттеләр. Алар мөгаллимгә бик теләп ярдәм итәрләр иде дә, тик ничек? Үзләре дә ярык тагарак янында калдылар. Гомәрнең эше юк. Аның турында югарыдан бернинди әмер килми. Ялгызын хөҗрәдә тынып утыр да эч пошканнан Һинд әкиятләрен укы: «Бер әтәч ун тавыкның күңелен күрә, ә ун ир бер хатынны канәгатьләндерә алмый...» Акылдан язарсың. Ул әлегә әтисен алыштырып торучы Гыйззелмөлеккә мөрәҗәгать итте.

Әмма Гыйззелмөлек барыбер әтисе түгел шул инде.

Балалар бөек әтиләренә тиң була алмый. Күп булсалар, бигрәк тә. Чөнки табигать тарафыннан аңа тупланган зур талант балаларга өлешләп кенә бүленә, аз-азлап кына бирелә. Моннан тыш әнисеннән нидер өстәлә, әмма, ни кызганыч, анысы һәрвакытта да юньле булмый.

—Түз,— диде Гыйззелмөлек коры гына. —Минем белән ни буласын әле үзем дә белмим. Шау-шу тынсын. Бездәге мәхшәрне күрмисеңмени?

—Нинди мәхшәр?— дип җилкәсен җыерды Гомәр. —Шаккатырлык берни дә юк. Тарихны белергә кирәк. Яна Клеопатра сараенда ниләр булган—шундый хәлләрне күтәргә калды...

Кичә Гомәр аулак почмакларының берсендә каракучкыл йөзле, ак чапанлы, ак чалмалы, кәҗә сакаллы, сирәк тешле куркыныч бер диндар картны күрде. Ул коры сөяккә калган кулы белән балалыктан чыкмаган юан бер кызның авызына ширбәт коя, ә үзе, селәгәен агызып, аны капшый иде.

Әлеге кыз, Гомәрне күргәч, курыкты, кисәк борылды. Күтәренке юеш

борыны өске иренен тартып тора. Авызы ахмакларча ачылган, өске тешләре урты белән бергә күренә. Йә Хода! Патша сараен бозыклык оясының җирәнгеч рухы басып алды. Хәрәмсарайны саклаучы хәрәматаларга да эш калмады—бу сарай сакчы гаскәрләрдәге таза егетләр аранына әверелде. Керү ирекле. Көнен дә, төнен дә сыбызгы һәм шөлдер тавышлары тынып тормый.

Шушымы инде хак, изге тормыш?!

Гомәр туры сүзле кеше, бөтенесен ачыктан-ачык күрә. Аның өчен кешелек мөнәсәбәтләрендә серләр юк. Ул—барыннан да элек галим, тикшеренүче, оят күренешләрдән йөз чөерми. Клеопатраның әкияти сарае да пычрак уйнаш урыны булган. Фәкать күп йөз еллардан соң гына хыялый шагыйрьләр тырышлыгы белән аның үз-үзен тотышын алсу төтенгә күмгәннәр. Әмма Гомәр Хәйямга тупас хакыйкать бизәкле ялганнан өстенрәк. Алар әллә ниләр эшләргә оялмаганны, ни өчен әле безгә бу хакта сөйләү оят булырга тиеш?

Әмма Гомәр дәшми. Әлегә дәшми.

* * *

—Әфәндем, сез мондамы? —Ишек аз гына шыгырдап куйды. Хөҗрәгә хезмәтче кыз керде.

—Күргәненчә.

—Хәзер...

Ул ишекне япты һәм кулына зур җамаяк тотып янадан күренде. Алтын савытта—тавык ите белән пешерелгән пылау өеме, савыт ягында—бер кувшин шәраб һәм хуш исле Хәрәзм кавыны.

«Ай-яй!»— дип гаҗәпләнде Гомәр. Аңа инде күптәннән ашарга китермиләр, гомуми өстәл янына чакырмыйлар иде. Ул Ораз янында ярлы хәрби казаннан тукланды. Мәликшаһ артыннан китмәс өчен патша ашханәсендә ашамаячак та ул.

Нәрсә булды икән?

—Бар, кит!— диде боерулы тавыш.

Гомәр эченнән генә «аһ!» итте: Зөһрә! Төрек-Хатын.

Пәрәнҗәсен салды. Чигелгән җиңсез күлмәк, киң гарәп шальвары, җиңел бәрхет туфли кигән. Китапларны алып ташлап, хезмәтче җамаягын куйган өстәл янына утырды. Каушап калган Гомәр солтанбикәне каршылап аягүрә дә басмады хәтта.

—Бөркү... Моны син яздыңмы? —Күлмәк изүен буйдан-буйга ычкындырып, Зөһрә аннан бөгәрләнгән кәгазь алды, аны Гомәр алдына ташлады. Аңа якынрак елышып, шәрә уң терсәгенә таянды. Изүе ачык килеш калды. Күлмәк астында башка кием юк иде. Гомәр аның түгәрәк корсагындагы тирән баткан кендеген күрде. Патшабикәнең шәрә кара-кучкыл имиләре аска авышкан, алар өстенә, зур имчәк башларын алтынлатып, гәрәбә муенса яткан. Җыелмаган куе чәче келәмгә җәелгән.

О, бөек солтан Мәликшаһ! Урының җәннәттә булсын, мәрхүмкәем...

Ул кәгазьне ачты:

Кем өстәле шәраб белән тәм-том тулы?
Тинтәкнеке. Язмыш шулай инде:
Карап Төрек-Хатын күзләренә,
Сакчы-коллар ләззәт таба үзләренә.

—Үткен,— диде Гомәр. —Теле дә минекенә охшаган. Әмма бу шигырьне

мин беренче тапкыр күрәм. Бик оста эш иткәннәр.

—Танма,— диде Зөһрә. —Исфаханда ин агулы кеше син түгелме әллә? Шәраб телисеңме? Менә ул. Тәм-том? Хәрәзм кавыны—дөньяда иң яхшысы. Пылау кирәкме сиңа? Аша. Һәм күзләремә карап ләззәт ал.

Теге чактагы, тәхет залы янындагы кебек үк, аны муксус белән гамбәр исенә күмеп, —бу юлы аларга әшәке тир һәм шәраб исе дә кушылган иде, —кәнтәйләнеп, аның янынарак елышты. Клеопатра, ичмасам, үзенең мәрмәр бассейнында коенган.

Гомәр читкәрәк тайпылды.

—Кит!

—Жирәнәсеңме?— дип ысылдады солтанбикә. —Колыннан жирәнмәдең! Сабыр ит, матурым. Әй!— дип чакырды ул хезмәтчесен. Жамаяккка ымлады: —Алып кит боларның бөтенесен. Һәм мина Зур Хөсәенне чакыр. Кемне икәнен үзен беләсең...

Һәм чыгып китте.

—Их, ахмак,— дип пышылдады хезмәтче Гомәргә.

—Дөрес,— дип баш какты Гомәр, төзәтә алмаслык бәланен якынлашуын тоеп. Чын ахмак...

Гомәр сарайда үзен чит кеше итеп тоя башлады. Кая гына бармасын, һәркайда дошман караш, хәттә иң әшәке кол-хезмәтчеләр дә аны күргәч, мыскыл иткәндәй теш ыржайталар, ә хезмәтче хатын-кызлар каһкаһәле көлемсерәп пышылдашалар. Әйтерсең лә, ул аларга бер-бер начарлык эшләгән яки нәрсә дә булса бирәсе бар.

Гыйзззелмөлек очрашкан вакытларда күзен яшерә.

Нишапурдан ни өчендер Шәйхелислам килгән. Янасы, элеккесе күптән инде жәннәткә юл алды.

Ораз нидер көтә.

«Сарай ертлачлары өере мина каршы нәрсә әзерли икән сон?»— дип борчылды Гомәр.

Озак та үтмәде, аны хөкем итәчәкләрен әйттеләр. Аллага шөкер. Мәхкәмә, ичмасам, хакыйкыйлыкның нindидер бер күләгәсе. Чөнки бит мәхкәмәсез-нисез шул ук солтанбикә ялчысы Зур Хөсәен кулы белән юк итәргә дә ихтималлар иде.

Ул иртәдә Гыйзззелмөлек, иркен айванга чыккач, сарай капка төбендә ни өчендер күп кеше жыелып торганын күрде.

Нинди халык бу? Аның чырае бозылды. Төрекмәннәр. Күпчелек—урта һәм өлкән яшьтә. Авыр кара куллылар, кара йөзлеләр. Әле сүнеп бетмәгән көзге кояшта кызынып, дивар буйларына, мәйданга чүгәләгәннәр, кысык кара күзләрен яшерәләр, үзләре сүзсез.

Күпчелегенең жилдә яргаланып беткән битендә—иске яралар, кайбер бармаклары юк. Кулларында—кәкре кылычлар, ук тутырылган садаклар. Күзләрен Кашгардан Фәләстингә һәм Хәзәр дингезенә кадәр булган ерак юллар тузаны сукырайткан, яу учаклары төтене һәм исәпсез-сансыз сугышларның тозлы тире ашаган.

Вәзирне күргәч, аларның берсе дә аягүрә басмады, баш имәде. Карашлар—аннан читтә, аны күрмиләр. Әмма вәзирне күрми мөмкин түгел! Димәк, күрергә теләмиләрме? Гыйзззелмөлек куырылып калды. Кем чакырган аларны, сарайга кем керткән? Ораз, кулларын артка куеп, аякларын киң жәеп, күкрәген киереп, айванга яны белән басып тора. Гәүдә авырлыгын иренеп кенә бер аягыннан икенчесенә күчерә. Таза һәм алсу ефәккә төренгән сак гаскәре үсмерләрен күзәтә. Вәзиргә күз атты. Көлемсерәде. Әшәке көлемсерәде.

Ул да дәшми. Бөтенесе сүзсез. Кычкырсыннар иде, ичмасам! Кычкырып

белдерелгән ачу—ярты ачу!

Нәрсә соң бу? Арттан килеп эләктерүләреннән курыккандай, Гыйззелмөлек карана-карана айванга күтәрелде. Вәзирне тынлык газаплый. Гадәттә шау-шулы, халык тулы сарай бүген үлгән диярсең. Иң хәтәре—салкын һавадагы томан төсле ачык булып диварлар өстендә, сарай капкалары артында нидер борчый. Сәер иртә! Бүген сарайга һәм шәһәргә нидер җитми. Нәрсә? Вәзир һич аңлый алмый. Ул шуны тоя: анда, капкалар артында, нидер бар. Анданиндидер куркыныч бер нәрсә өлгереп килә.

Түзәр хәл юк! «Күрәсең, мин Гомәр Хәйям кебек акылдан шашамдыр». Вәзир гади чапан киде, далада кия торган йөнтәс бүреген күзенә кадәр батырды, үзе белән башкача киенгән тән сакчыларын алды һәм юан, тасланган бүрәнәләрдән эшләнгән капкаларның кечесен ачарга кушты.

Ул сарайга терәлеп торган, вак таш җәелгән мәйдан-регистанда Көнчыгышта иң хәтәр булып саналган нәрсәне күрде. Чәчәк, чума һәм ваба авыруларыннан да хәтәррәкне. Базар сатмый иде! Халык һәрвакыттагыча күп. Барысы да, гадәттәгечә, үз сәләмәләрендә. Әмма чүлмәкче үз чүлмәкләрен, чынаякларын читкәрак этәргән. Этәргән һәм аларга карамый да. Чәнчелеп китсен, таптасыннар әйдә. Авылдан килгән агай утын бәйләме өстендә—аны чишәргә дә уйламый. Икенчесе, көчәнеп, капчык бавын чишмәкче була, әмма берничек тә чишә алмый. Ачуы чыгып, кулына пычак ала. Ипи сатучы, яссы зур кәрҗиндәге көлчәләр тулы ашъяулыгын җәеп, көлчәләрне карамыйча гына ала һәм күршеләренә бушлай өләшә. Тегеләре дә карамый гына алалар һәм иренеп кенә ашыйлар. Су сатучы да, карамыйча гына, сулы күн савытын рәт буйлап җибәргән. Көнлекчеләр берниндн максатсыз-нисез кәйлә, балта, кәтмәннәрен селтиләр, алар ярдәмендә тыгызланган вак ташларда сызып, өчпочмаклар һәм квадратлар ясыйлар. Гадәттә базарга килгән диһканнардан күпләп сатып алып, аннары ваклап сатучы шәһәр алыпсатар-ертлачларының бүген эзе дә юк. Ахырзаман. Берсе дә дәшми. Дәшмиләр!

Бүген патша сараенда Гомәр Хәйямне хөкем итәчәкләрен кем җиткергән аларга!

—Хәлвәң кыйммәтме?— дип сорады танылмаган (әллә танылганмы?) вәзир тәм-том сатучыдан.

—Хәлвә?— дип уйчан гына сорады тегесе. —Ә-ә, хәлвә. —Аннары ярсып кычкырды: —Нинди хәлвә? Тапкансың вакыт! Кит моннан!

Әгәр булса кабарлык синдә икмәк,
Суың да чүлмәгеңдә булса—бик шәп;
Түбәннәргә нигә дип баш иярга,
Нигә ятларга ялынып хезмәт итмәк?

—Әгәр телисең икән, болай гына ал,— диде тәм-том сатучы, килешеп. — Барыбер тормыш яхшырак булмаячак.

Салып бир мәйне чүлмәккә сыйганчы,
Исәнлектә эчик рәхәт тойганчы,
Изеп безнең дә көл-туфрагыбызны,
Һөнәрчеләр яңа чүлмәк койганчы.

Юк, бөтенесе дә телсез түгел! Мәйдан почмакларында, әле тегендә, әле монда,ерактарак, саран гына сөйләшкәннәре ишетелә.

—Яңа календарь керткәч, бераз гына җиңеләйгән иде. Ә хәзер янадан бөтенесе искечәгә кайтып калды.

—Безнең кебек гади халыкның монарчы үз тавышы юк иде. Үз шат-лыгыбыз һәм кайгыбызны башкалар уйлап чыгарган мәсәлләрдә, җырларда

һәм догаларда гына беллерә ала идек. Фирдәүсиме? Сүз дә юк, бөек шагыйрь, әмма бит ул шаһларны гына данлаган. Аларга мәдхия җырлау өчен гомеренең өчтән берен биргән. Ә Гомәрдә таба аласызмы аларны мактаган бер генә булса да юл? Ул аларның тетмәсен тетә.

Нигә хан милке, тәхте, тажы безгә?
Кирәк тик гыйш вә гашрәт сазы безгә;
Сатам тәсбихне, чалманы, чапанны,—
Кирәк тик бер йотым мәй назы безгә!

—Гомәрдә үз тавышыбызны ишеткән генә идек, инде аны бездән аерырга телиләр.

Син эчмәсәң, тимә эчкәнгә, бәндә,
Эчең-тышың мәкер, гайбәт вә хәйлә...
Аек мин, дип нигә күкрәк кагасың,
Синең аеклыгыңда, йә, ни мәгънә?

—Ә без дәшмибез. Нишләп? Мәмләкәт безнең өстә тора. Безнең куллардан башка ул җимерелеп төшәчәк.

Йөзе каралган вәзир сарайга ашыкты. Ярамый! Куркыныч. Аларга сәбәп кенә бир: бөтен башкаланның астын өскә китерерләр. Төзәтергә мөмкин булганны төзәтергә кирәк.

• • •

Ярый, хөкем итегез! Нәрсә белән куркыта аласыз сез мине? Бик тә начар беләсез әле Гомәр Хәйямны...

Соңгы мөлкәтем—Нишапурдагы өемне тартып алырсызмы? Алыгыз! Сез ул, арзан җамаягыгызны ялгыш ватасыз да, дөньяда иң зур кайгы килгәндәй, күз яшенә коенасыз. Әгәр әйберләр минем өстемә авыр йөк булып ята икән, өе-ние белән бөтенесен бергә үзем үк җыеп яндырырга әзер.

Зинданга ябарга телисезме? Һе! Болай да балачагымнан ук зинданда түгелме әллә мин? Ябыгыз. Әзрәк кысыграк булыр, бары шул гына. Баш белән вата алмастай шул ук диварлар, кеше сүзе белән аңлата алмастай шул ук шымчылар. Шәрыкта безне төрмә белән куркыта алмассың. Бөек Әбугалисина да утырган төрмәдә. Бөек Әбурәйхан Беруни да утырган. Гомәр Хәйям дә үзенекен утырыр. Ялгызымы? Булсын. Әңгәмә кору өчен миңа үземә үзем дә житә. Сез ул, күп булып бергә җыеласыз да, бер-берегезгә ни әйтергә белмичә, тузга язмаганнарны сөйли башлыйсыз,— чөнки әйтер сүзегез юк.

Башымны кисәрсезме? Кисегез! Андый хокукыгыз бар икән—кисегез соң! Селкенмәм дә. Чөнки миңа куркыныч түгел.

Кеше кешедән туа, башка кеше өчен яши, әмма һәрберсе үзе өчен үлә. Вакыты җиткән икән, башкалар, башларын ташка бәрсәләр дә, аңа гомерен кире кайтара алмыйлар. Үлемне тизләтергә кулыгыздан килә сезнең! Әмма ул бит барыбер котылгысыз! Ун ел алданмы, ун ел соңракмы... барыбер түгелмени? Күпме кеше тугач ук үлә...

Шулай булгач, үз вакытында сездән башка да булачак вакыйганы ашыктырудан, алыштырудан нинди мәгънә бар соң?

Бернинди дә. Әле яңа гына кияүгә чыккан яшь кызны тугыз айдан соң бала табачагы һәм бу вакытта аңа бик авыр булачагы турында куркытып кыю белән бер бит бу.

Мәгънәсез нәрсә куркыныч булмый. Шулай булгач, үлем—башкаларны куркыту өчен кеше уйлап тапкан җәзаның иң ахмагы.

Начаррагы—җәзалау...

Яралган көненнән соң кешелек дөньясының күпме еракка китүен кызыклы бер нәрсәдән күрергә була: кыргый вакытта кешеләр бер-берсен ут, очлы таш һәм очлы таяк белән җәзалаганнар; антик дәвердә—ут, таш һәм бакыр белән; хәзер ут, таш һәм тимер белән җәзалыйлар.

Мең елдан соң нәрсә белән җәзаларлар икән?

Табарлар! Үз дәверләренең бөек казанышларына лаек җәза коралы табылыр. Ә менә инде бер-берсен җәзаламый башлагач, кешеләрне чын Кеше булды дип әйтергә дә ярый.

...Булачак җәзалауга Гомәр үзен әнә шулай әзерли.

Тирә-юнендә, корал белән куркытып, явыз сакчылар йөргәндә шулай уйламый хәлен юк. Бердәнбер коралың уйлау булганда бигрәк тә. Әлегә башын киселмәгән икән, уйларга гына кала.

—Сез әзерләгән нәрсәләр—кешелексезлек!— диде ул тәхет залын тутырган чалмалыларга. —Гомәр Хәйямны мыскыл итәр өчен сез аннан акыллыракмы әллә?

Төрек-Хатын юк. Аның урынына Гыйззелмөлек килгән. Әле шушы көннәрдә генә сабый кыз бала белән уйнаш кылган тешсез карт та монда. Ышанасызмы: ул мәмләкәтнең баш казые икән ләбаса.

Кешелеклелек турында нәрсә беләләр соң алар? Алар аны аңлатмадылар да бит.

—Без сине канун буенча хөкем итәбез.

—Нинди канун буенча?

—Үзебездәгесе белән.

—Аны кем уйлап чыгарган?

—Син түгел инде, әлбәттә.

—Алай булгач, аның белән үзегезне һәм үзегездәйләрне хөкем итегез! Миндә—башка кануннар, мин алар буенча үземне үзем хөкем итәм.

—Ул безне хөрмәт итми!— дип чәрелдәде баш казый.

—Хөрмәт итәрлек булмагач...

«Югары дин әһелләренең үгет-нәсихәтләренә һәм кинәшләренә колак салмыйча, денсез, кяфер булуын, үзенең явыз шигырьләрендә күкләргә каршы фетнә коруын, Аллаһыга тел тидерүен һәм кешеләрнең аңын бутавын исәпкә алып, Ибрагим улы Әбделфатыйх Гомәр башын кисү юлы белән үтерелергә тиеш».

Тәрбияле шәехләр хуплап шаулашты.

Бөтенләй агарынып һәм ни эшләргә белмичә, шагыйрь тирә-ягына каранды һәм, беркемнен дә күзендә кызгану тапмыйча, ачык ишеккә өметсез караш ташлады, әйтерсең лә, урыннан ыргылып, атылып чыгып китеп булмыймы, дип уйлады һәм бәрхет җәймә артында кулларына кылычлар тоткан озын буйлы сакчылар аягы астында аңгырарак түгәрәк йөз күрде. Ә! Теге, югарырак күтәрелгән юеш борын. Күрәсең, аның борыны беркайчан да кипмидер. Фәкать ул гына аңа дустанә карады. Гомәр аңа үз итеп күз кысты. Кыз гаҗәпләнеп авызын япты, шуның белән бер үк вакытта аскы күз кабагы кинәт кискен тартылып куйды, шунлыктан күзләре куркынып акайды.

«Әмма... —бүген иртән күргәннәрдән һәм ишеткәннәрдән курыккан Гыйззелмөлеккә бу «әмма»ны әйтү бик авырга төште, — аның патша йортына элегрәк якын булуын исәпкә алып, югары җыен аңа үлем җәзасын башкаладан кичекмәстән куу белән алыштыруны мөмкин дип тапты. Әлеге шәех Әбелфатыйх Гомәр Ибраһим углы бүгеннән һәм гомерлеккә Исфаханнан

куыла. Ул Нишапурда ата-анасыннан калган йортта дин әһелләренен туктаусыз күзәтүе астында яшәргә тиеш.»

«Безнен арада беркем дә яхшы булмасын,— дигәннәр кайчандыр Эфис кешеләре. —Булса, ул башка урында, бүтәннәр арасында яшәсен.» Һәм үзләренең күренеклерәк кешеләрен куып җибәргәннәр. Бу хакта Аристотель сөйли.

Геродат язып калдырганча, Милет тираны Фрасибул, Коринф илчесенен үз дәүләтендә гомуми буйсынуга ничек ирешүе турындагы сорауга җавап итеп, ашлык басуындагы барлык иң өлгергән башакларны йолкый, уа һәм җиргә ата.

Идел буе болгарлары янында булган Ибне Фаллан алар турында менә болай яза:

«Хәрәкәтчән, эшлекле кешене күргәч, алар: бу кешегә безнен арада урын юк, ул Аллага хезмәт итәргә тиеш, диләр. Шуннан соң аны тотып, муенына бау бәйлиләр дә агачка асып куялар».

Менә хәзер әйтәчәк ул аларга! Алар турында ни уйлаганынын барысын да әйтәчәк!

—Әлбәттә, —Гомәр көрсенеп куйды, — минем кебек кеше сезгә җайсыз. Ярый соң, үзегезгә унай кешеләр белән калыгыз. Ә мин китәм. Әмма исегездә тотыгыз: сезнен өчен мин бүтән юк. Ишетәсезме? Сезнен өчен мин бүтән беркайчан да юк. Һәм Аллага шөкер! Без үзебезнен игелекле ислам мәмләкәтебездә хәйләкәр математиклардан, тәкәббәр йолдызчылардан, денсез табиблардан башка да яшәрбез.

### Өченче бүлек

## Җиргә атылучы бөркет

*Берәүнең ризкы булса бер кабарлык,*
*Ятар җае да булса ял табарлык,*
*Үзе кол булмаса һәм тотмаса кол,*
*Яши бирсен—бәхет юк шуннан артык.*

—Гомәр Хәйям? Ә! Теге, ни... үлмәдемени әле ул? Кемдер әйткән иде, янәсе...

Юк, үлмәде, Гомәр исән!

Ничәмә-ничә шаһ заманында яшәде инде Гомәр: Тугрылбәк, Алыпарслан, Шәмселмөлек, Мәликшаһ—кайда алар хәзер дөньяны дер селкетеп торткан бу адәмнәр?

—Әнә ничек бит ул!— диде төрекмән Ораз, куркыныч йолдызчыны Ком капкасына озатканда. Аңа сарай әһелләре Гомәрнең шәһәрдә яшеренүенә яки качуына юл куймау бурычын йөкләделәр. —Әнә ничек. Әгәр дөньясы кемне дә булса эзәрлекләргә тели икән, ул чакта инде югары хакимияттән алып иң соңгы хәшәрәткә кадәр бу эшкә шатланып, хәтта тәм табып тотына. Нигә соң син ул... комсыз әнчек Зөһрәне... трах-прах итмәден? Ул да бит хатын-кыз инде.

—Эш бит Зөһрәнен үзендә түгел,— диде Гомәр, көрсенеп. —Ул ярыйсы. Юсаң, әлбәттә. Эш анын тирәсендәгеләрдә. Ә мин аларны «трах-прах» итә алмыйм. Җирәнгечләр. Кубәү бит алар, үзем генә башкарып чыгарлык түгел.

Алайса, атла инде Нишапурына хәтле бер фельссыз.

—Ничек тә барып җитәрмен әле. Авылларда Коръән укырмын, йолдызларга карап фал ачармын. Астролябияне үзем белән алдым. Югалмам.

Әмма хакимияттәгеләр Гомәрне күрмәмешкә салышты.

Әгәр син мөэминнәрнең гомуми көтүендә намазга йөрмисең һәм, барыннан да хәтәррәге, һәр нәрсәгә үз фикерең бар икән, утыр шунда читтәрәк үз фикерең белән.

—Анысы шулай аның. Әмма мин, карт башкисәр Ораз, шундый зур кешенең юлда хәерче кебек йөрүенә риза була алмыйм. —Ул Гомәрне читкәрәк алып китте дә аның кулына авыр янчык тоттырды.

—Монда нәрсә?— дип сорады Гомәр.

—Биш йөз алтын. Мин теге вакытта синең Гыйззелмөлек белән сөйләшкәнеңне ишеттем, ишек янында сакта тора идем. Шул да булдымы вәзир! Монда... безнең карт сугышчылар... бераз җыйганнар иде. Кем бер динар, кем икене яки өчне...

—Алмыйм!

—Ал, ал !

—Кайчан түлим ди мин аларны?! Һәм кайчан да булса түли дә аламмы әле?

—Тиле, без бит сиңа бурычыбызны гына кайтарабыз.

—Нинди бурыч?

—Бер капчык ашлык өчен. Фирүзгән юлын хәтерлисеңме? Һәм теге ни... аты кем әле... эшчегез Әхмәт өчен, үзе, корчаңгы өч фельс тормаса да. Ярый инде, озак вакыт үткәнлектән, күбрәк тә тиешбездер дә. Анысын да саный башласаң...

...Гомәр, каләмен бер читкә куеп, ишегалдына чыкты. Яз. Өрек чәчәк ата. Әтисе өендә ялгызына бик әйбәт аңа.

Яши Гомәр ялгызы гына үзенең иркен өендә. Беркемне дә кертми, үзе дә тегене-моны сатып алырга кирәктә генә чыга. Беркемгә дә: ир-атка—дустабындаш, хатын-кызга—ир-сөяркә, күрше балаларына—остаз булырга тагылып тормый. Яшәгез үзегез! Ходай сезгә...

Һәм Гомәр үзенең иң якты, яшь, яз китабы булган «Нәүрүзнамә»сенә тотынды.

Максаты шул ук: Кояш календареның Айныкыннан өстенлеген исбатлау. Ай календаре буенча салым җыю уныш әле өлгермәгән, терлек әле икмәк басуларыннан еракта һәм шунлыктан кешеләр газаплар кичергән вакытка туры килә. Бер караганда, барысы да гади: өч-дүрт биттә кыска һәм ачык итеп үз фикерләреңне бәян ит тә куй.

Әмма Гомәр кем белән эш йөрткәнен белә! Яңа календарьның солтан йортына һәм халыкка китерәчәк файдасы турында исәп-хисаплар белән нығытылган җитди, эшлекле сөйләшүне хәзерге тәкәббер, томана хакимият аңламаячак. Низамелмөлек тә, Мәликшаһ та юк хәзер. Халык мәнфәгате турында уйлау түгел, үз файдаларын да күрә алмыйлар алар.

Ә менә Гомәр бер сугу белән дошманның ун мең гаскәрен кырып сала, бер кул селтәү белән чит шәһәрне баш сөякләренә әверелдерә, яки бер өрү белән баш сөякләрен һәм кирпеч ватыкларын алтын тәңкәләр итә торган тылсымлы таякны ничек әзерләү турында яза алса—аның китабына ябырылып ятырлар иде.

Могҗизалар юк икән—без аларны мәсәлләр, булмас эшләр белән сыйлыйк. Буш хыялларны алар үлеп ярата һәм кайчандыр үзләре дә буш хыяллар гына булып калачак та.

Дөресен әйткәндә, почмаклар һәм градуслар, минутлар, секундлар, төгәл саннар үзен дә туйдырды аның. Күптәннән инде, аларның төгәл, тимердәй

салкын сызыкларыннан котылып, ирекле хыял, әкиятләр, матур риваятьләр, һич көтелмәгән вакыйгалар дөньясына чумасы килә. Табигать ана ялкынлы, яшь һәм язгы хыялны мул биргән. Ә дүртьюллыкларда барысын да әйтеп бетерә алмыйсын. Шул ук арифметика ул.

Гомәр яңа китабын, житди уйланулар белән бик оста аралаштырып, фантазия, мавыктыргыч хикәятләр белән чын күңеленнән баетты. Хикәятләрнең шактые—базарларда, чәйханәләрдә, кәрвансарайларда ишетелгәннәр, әмма күбесен ул үзе уйлап чыгарды. Хәтта кайчак үзенең фәнни карашларына каршы килеп булса да.

## АЛТЫН ТУРЫНДА

...Сөйләүләренчә, әгәр сабый балага сөтне алтын кувшиннан эчерсән, ул әйбәт сөйләшә башлый, кешеләрнең күңеленә хуш килә, батыр була, бума зәхмәтенә бирешми, йоклаганда курыкмый; әгәр күзенә кечкенә алтын таяк белән сөрмә тартсан, тавык күзе—күрә карау булмас һәм яше акмас.

Әгәр бөркетнең аякларын алтын чылбыр белән бәйләсән, ау вакытында ул тагын да кыюрак һәм житезрәк булыр.

...Ышанычлы бер дустымнан ишеттем. Бохарада акылдан язган бер хатын булган. Башка хатыннар үзләре янына чакырып алганнар да аны шаярта, үрти, сүзләреннән көлә башлаганнар. Аннары ефәк күлмәк кидереп һәм алтын бизәнү әйберләре тагып: «Без сине кияүгә бирәбез»,— дигәннәр. Үзендә алтын әйберләр күргәч, теге хатын кинәт бик тә акыллы сүзләр сөйли башлаган, кешеләр аны терелде дип уйлаганнар. Әмма аннан боларның барысын да салдыргач, ул тагын тилегә әверелгән.

## БАЛДАК ТУРЫНДА

Сөйләүләренә караганда, бервакыт Жиздегәр шаһ сарай бакчасының таш урындыгына утырган һәм бармагына Фирүзә балдак кигән. Кинәт ук очып килгән дә балдакның ташына тигән, таш ватылган...

Берникадәр вакыт үткәч, ул үлгән, аның династиясе беткән.

«Гарәпләр тарафыннан тар-мар ителеп, Жиздегәр ялгызы гына Мәрва тирәсендә йөргәндә, асылташлы балдагы һәм кыйммәтле киеме өчен берәр юлбасар үтергәндер».

## АРПА ҮСЕНТЕЛӘРЕ ТУРЫНДА

Арпа ашау өчен дә, дару өчен дә яраклы. Ул—акыл ияләре һәм дәрвишләр азыгы.

Табиблар арпа аракысын шифалы су дип атыйлар. Ул—билгеле булган егерме дүрт төрле сырхаудан шифа. Алар арасында пешү, үпкә ялкынсынуы, бизгәк, тиф, ютәл, тән кызышу, авыз кибү, чахотка, эч кату, сары сырхаулары бар. Ул йомырка капчыгын, ашны, күкрәкне, кабыргаларны ышку өчен, бавырга, ашказанына, сөяк сынганда, буыннар авыртканда, шулай ук суалчаннарга каршы файдалы. Арпа мае—бары корчаңгыны, ә бодайныкы кара корчаңгыны бетерә.

Кемнең дә булса аякларын көзән жыерса, аларны арпа аракысына тыгып утырырга кирәк.

Монда Гомәр ни уйлаганын әйткән.

Үзенең аякларын көзән жыерганлыктан, бу бүлекне язып бетергәч, ул бер чынаяк арпа аракысын эчеп куйган.

## ШӘРАБНЫҢ ФАЙДАСЫ ТУРЫНДА

Галим табиблар Гален, Сократ һәм Гиппократ, Әбугалисина... кеше

организмы өчен шәрабтән дә, бигрәк тә әче һәм сөзелгән йөзем шәрабыннан да файдалырак нәрсә юк, дигәннәр.

Анда кешеләр өчен файдалы нәрсәләр күп, әмма гөнаһысы файдасыннан зуррак.

Шәраб эчсәң, белеп эч, әһле мөәмин:
Кайчан, кайда, кем белән, күпме мөмкин?
Эчү хәләл шушы дүрт шарт үтәлсә,—
Шулай мотлак! Моңа өзмим өмет мин.

Акыллы кешегә шулай итеп эчәргә кирәк ки, азапланмас өчен, аның сихәте гөнаһтан зуррак булсын. Күнегүләр белән ул үз күңелен шундый хәлгә житкерә—эчә башлаганнан алып эчми башлаганга кадәр сүздә дә, гамәлдә дә бернинди явызлык һәм тупаслык эшләнми. Фәкать игелек һәм күңеллелек кенә эшләнә. Шул баскычка житкәч, аңа шәраб эчү лязем.

* * *

Иртән кесәләрен актаргач, Гомәр ... ике фельс тапты. Әйе. Моңа бер чынаяк ширбәт агызып бирергә мөмкиннәр. Ул, хәзер ни эшләргә инде, дип күңелсез генә уйланып, киң ишегалды буйлап йөренде.

«Нәүрүзнамә»не язганда Гомәр, аның өчен яхшы гына хак алсам, галимнәр турында «Алимнамә» дигән зур поэмамны башлыйм, дип уйлаган иде. Гел шаһлар турында гына димәгән.

Башка ниятләре дә бар иде аның.

Сәмәркандта чакта Мохтар кинәш иткәнчә, үлчәүләрне төгәл билгеләргә, яналарын булдырырга.

Төрки кабиләләренә тасвирлама язарга, аларның килеп чыгышын ачыкларга, телләрен чагыштырырга.

Фарсы шигырь төзелеше буенча кулланма булдырырга.

Һиндстанга, Кытайга, Кафтауга, Итил буендагы болгарлар янына барырга...

Боларның барысы да буш хыял булып калды.

Әллә йортны сатарга инде? Нигә кирәк анын ялгызына шундый зур йорт? Жыештырып, тузанын сөртеп бетерер хәл юк. Сатарга да, алмашка кечерәк, уңайлырак икенче бер йорт алырга. Калган акчага яшәргә...

...Кече капкада—тоныкк кына еш-еш суккан тавыш. Нинди шайтаны кемне китерде икән анда? Әле кайчан гына берәүгә дә ишек ачмаган Гомәр хәзер һәр кунакка шат. Ялгызлык туйдырды. Үзенең өйдә икәнлеген ишеткәнен белдертер өчен тамак кырып, Гомәр кече капканы ачты.

Каратут йөзле, күзләре уйнаклап торган малай басып тора.

—Әссәламегаләйкем. Минем хуҗам, сәүдәгәр Мозаффар, сиңа тизрәк Ефәк базарына килергә куша. Бик мөһим эше бар.

—Мина ... куша? Яле сыптыр моннан башың исән чакта! Анын мина йомышы бар бит, минеке аңа түгел.

Гомәр күңелсез генә капканы япты. Әле күптән түгел генә аңа солтаннар, вәзирләр тынгы бирми иде, инде хәзер ниндидер сәүдәгәр кисәге кысыла. «Куша...» Үзеннең хатынына куш, бетле көчек...

Акча каян табарга белмәгәч тә ул: берни дә эшләмим!— дип хәл итте. Беркемне дә эзләмим, беркемнән дә берни сорамыйм. Бикләнәм дә, өненә кергән аю кебек бер-бер хәл булганчы ятам. Кайчан да булса ни дә булса булырга тиештер бит инде?

Ятарга ирек бирмәделәр. Кече капканы ныклап кага башладылар.

—Мозаффар мин!— диде зур гәүдәле, әйбәт киенгән берәү.

—Уз.

—Синең минем хакта ишеткәнең юкмыни?— дип сорады сәүдәгәр, ул Гомәр анын аягына баш ормаганга гаҗәпләнә иде бугай.

«Тәкәбберлегенне бетерәм мин синең!»— дип уйлады Гомәр. Әмма гади генә әйтте:

—Юк шул. Алыпсатарлар күп, ә мин—үзем генә.

—Һе... —Мозаффарның йөзе кара-кучкылланды, аннары анар кабыгы кебек зәңгәрсу-кызылланды.

Күңеле болганудан йөзен җыерып, ул көзге купшы-сары тут агачы астындагы сәкегә күрсәтте һәм, маңгаендагы салкын тирне сөртеп, үзе беренче булып утырды.

—Хәрчәүнә хуҗасы сине ... йолдызларга карап фал ача белә диде, дөресме шул?— дип кырыс кына сорады Мозаффар, киез җәелгән сәке читенә унайсыз гына утырып.

—Шуннан?— диде Гомәр ваемсыз гына.

—Иртәгә Рейга... зур кәрван китә,— диде сәүдәгәр Мозаффар.

«Ә-ә!— дип исенә төшерде Гомәр. —Теге ике кеше кичә шул хакта сөйләште бит».

—Ун дөя—минеке. Яхшы мал. Шуңа борчылам. Юлларда янадан талау күбәйде. Галим дус ... күктәге йолдызларга карап күрәзәлек итмәс микән?— дип һәр сүзне көчәнеп әйтте сәүдәгәр, әйтерсең лә, сүз түгел, ә акча кысып чыгара. — Иртәгә Рейга юлга кузгалыргамы икән?

«Алай-алай... Бу күзле бүкән, ангыра баш, йолкыш алыпсатар күктәге йолдызларның аның мескен табышында эше бар дип чын күңеленнән ышана инде. Арт ягына тибеп куарга кирәк үзен! Исәпсез-хисапсыз йолдызлары белән бергә бөтен Галәм аның малы өчен куркып, дер калтырап тора, янәсе. Тик...»

—Ничә сумлык мал алып барасың?

—Бу фал ачу өчен кирәкме?— диде сәүдәгәр, аптырабрак калып.

—Әйе.

—Ике мең дә биш йөз динарлык.

—Егерме биш.

—Нәрсә?

—Фал ачкан өчен егерме биш динар.

—Шулкадәр күпме?— дип гаҗәпләнеп сорады Мозаффар.

—Ә син нәрсә!— дип ачуланып әйтте Гомәр. —Синең ике мең дә биш йөз алтын динарыңны бер көмеш дирһәмгә саклап калырлар дип уйлыйсыңмы әллә? Фал ачкан өчен йөздән бер өлешен алам. Йөздән бер өлешен кызгансаң, бөтенесен югалтырсың.

—Әгәр дә,— дип тотлыгып калды тук йөзле карт, алсу яңакларын ышкып, — әгәр дә юравың юш килмәсә?

—Килер! Мин солтан Мәликшаһның үзенә фал ачтым. Гел дөрес килде.

Авыр бөкрәеп, Мозаффар кулындагы кызыл бәрхет янчыгын озак әйләндерде. Аны карунлык һәм курку изде. Егерме биш динар! Акылыннан язарсың. Әмма ике мең дә биш йөз... бу бит аның мөлкәтенең уннан бер өлеше.

—Фалың дөрес булуга ышандырасыңмы?

Ул һаман як-ягына каранды, әйтерсең лә, аны менә хәзер килеп таларлар дип курыкты. Таламаслар, тинтәк.

—Әй, син нәрсә, моны базар дип белдеңме әллә? —Гомәрнең ачуы килде. —Телисең икән — ачтыр, теләмисең икән—сыптыр. Тик иртәгә күз яшеңне түгәргә туры килмәгәе.

Мозаффар авыр көрсенде, әйтерсең, махмырдан Гомәр түгел, ә ул интегә

иде, аннары калтыранган бармаклары белән яңгыравыклы егерме биш тәнкәне санады. Хәтта агарып калды, йөзе качты.

Гомәр ашыкмыйча гына тәнкәләрне өйгә кертеп куйды, астролябия белән йолдызлар таблицасын алып чыкты.

—Йолдызлыгың нинди?

—Үгезбозау.

—Куркыныч йолдызлык. Ала-ай. —Гомәр кояшның биеклеген үлчәде. —Бер Үгезбозау күктә йолдызлар арасында ялтырый,— дип таблицаны ачты. —Икенчесе умыртка сөяге белән аның мәетен күтәреп тора. Ә алар арасында... Изге нәрсә шобагасы,— дип, ул бу юк нәрсәгә җитди төс биреп, юри астрологик әкәмәтләр уйлап тапкан булды. —Бәхет шобагасы. Кушылу һәм каршы тору. Квадратура. Тригональ аспект—таслис. Секстиль аспект—тасдис. Менә карагыз әле! Түбән таба тәгәрәү йолдызлыгы. Уңай булмаган гамәл. Бик күпләр... Чыгу юлы—ябык.

Менә нәрсә, хөрмәтле Мозаффар. Иртәгә кәрван белән Рейга чыгудан сине Ходай сакласын! Ул таланачак. Башкаларга да әйт, чыга күрмәсеннәр. Кәрванны биш-алты көнгә тоткарлагыз.

«Бу вакыт эчендә юлбасарлар көтеп туярлар һәм таралырлар. Кара Якуб бернисез китәр», дип фикер йөртте Гомәр.

—Уйламыйм да,— дип мыгырданды Мозаффар. —Китсеннәр. Мин өйдә утырырмын. Авыруга сабышырмын. Көндәшләремне зыян килүдән саклый башласам, нинди сәүдәгәр булам ди мин?

—Анысы синең эш. Мин үз эшемне эшләдем.

...Икенче көнне өйләдән соң Мозаффар тагын капканы шакыды—бу юлы инде каты һәм ышанычлы итеп.

Сәке кырыена утырды, салкын тирен сөртте.

—Йә?

—Кәрванны талаганнар... Дүрт каравылчыны үтергәннәр. Ай-вай, галим дускаем! —Күзләре яшьләнде. —Син мине коточкыч бәладән коткардың. Хәзер мин синнән башка, синең акыллы киңәшләреңнән башка бер генә адым да атламаячакмын.

Гомәрне шаккатырып, ул аңа тагын... биш динар санап бирде.

* * *

Берничә көннән кече капканы тагын кактылар.

—Менә тагын очраштык, галим дус! —Җилдән кызарып беткән карт Ораз, үзенең көчле кочагыннан чыгармыйча, Гомәрнең аркасыннан сөйде. —Аллаһы рәхмәте белән очраштык бит.

Аның өч иптәше атларын лапаска бәйли иде.

—Дусларсыз йөреп булмый хәзер. Талыйлар. Казаның бармы? Сарык тәкәсен үзебез белән алдык,— дип, Ораз төрекмәннәр аттан төшергән терлеккә күрсәтте.

Ул йортны һәм ишегалдын карап чыкты, чоланга күз салды, йөзе караңгыланды. —Ала-ай. Бөтенебез өчен бәләкәйрәк икән казаның. Үзең генә яшисеңме?

—Үзем генә.

—Ничек инде алай?

—Шулай инде.

—Шәп яшисең. Күршеннән зуррак казан сорап тор әле.

—Мин аларга кермим.

—Нишләп алай?

—Анда... әтинең остаханәсе иде. Искә төшерәсем килми.

—Ярый алайса.

Казанны базардан алып кайттылар. Ашадылар, эчтеләр.

—Йә?

—Сине алырга килдем. Безнең белән Исфаханга барасын.

—Нигә?— дип гаҗәпләнде Гомәр.

—Вәзир таләп итә.

—Таләп итә? Һе! Беләсеңме, женем сөйми «таләп итә», «боера», «әмер бирде» дигән сүзләрне. Җавап итеп таяк белән сугасы килә. Ул берни дә таләп итә алмый миннән. Сорый гына ала. Бирәр нәрсә тиешме әллә мин аңа?

Йөзен чытып, бераз дәшми торгач, Ораз:

—Исфаханда... чәчәк авыруы,— диде.

—Чәчәк авыруы?— дип кычкырды Гомәр, агарынып. —Син аны мина алып килмәдеңме? Мин монда синең белән бергә эчәм дә...

—Юк, без чиста.

—Сон бит ул шундук сизелми. Ун-унбиш көн көтәргә кирәк.

—Көттек. Безне шәһәрдән читтә, тауларда булганыбыз өчен җибәрделәр дә инде. Вәзир килде дә ерактан гына: «Нишапурга барып әйтегез, Гомәр тизрәк килсен»,— диде. Әйдә, җиен, галим дус. Синең өчен махсус ат алып килдек.

—Шулай булырга тиеш иде дә,— дип мыгырданды Гомәр үз-үзенә. — Шулай булырга тиеш иде дә. Быел нинди ел әле безнен? Әһә. Ул гадәттә кышын була. Белдем, сизендем мин аны.

—Быел чәчәк авыруы буласын белдеңме?— дип гаҗәпләнде Ораз.

—Сизендем. Чәчәк булмаса, чума яки ваба авыруы...

—Йолдызлардан белдеңме?

—Үзебезнең бер йолдыз буенча. Беләсеңме, шунысы күптән мәгълүм: Кояш яктыртып һәм җылытып кына калмый. Аның үз холкы, беләсеңме? Ул йә тыныч, йә кыргыйларча котырына башлый.

—Аңлыйм,— дип баш какты Ораз. —Яхшы аңлыйм. Аның холкы—нәкъ синеке инде.

—Һәм бу хәл анда ун-унбер елга бер кабатлана. Ә миндә— ешрак. Тик мин бит Кояш түгел. Мин әз генә кечерәк. Һәм котыруым да тышкы сәбәпләр аркасында. Ә аныкы—эчтән. Гәрчә аңа да каяндыр гаять зур галәм көчләре тәэсир итәдер, мөгаен. Күзәтүчән кешеләр инде күптәннән беләләр,— дип уйчан гына дәвам иттерде Гомәр, — Кояштагы утлы давыллар, җиргә җитеп, әле су басу, әле корылык, җир тетрәү, янар тауларның ут атуын китереп чыгаралар.

—Беләм,— дип янадан баш какты Ораз. —Әгәр күк сәер төскә керсә, болытлар ук кебек очланса, аяк астында җир селкенсә, кояшта тимгелләр яки аның тирәсендә бөҗралар барлыкка килсә, бу—бәла-казага...

—Менә, менә! Вакыт аралыгы һәм еллары хайван исемнәре белән билгеләнгән унике еллык борынгы Шәрык календарьларында яхшы һәм яман еллар бар, бу, мөгаен, юкка гына түгелдер.

—Әйе,— дип җөпләде төрекмән. —Андый календарь турында бабамнан ишеткән идем. Быел Аждаһа елы, начар ел. Ә-ә, туктале!— дип нәрсәнедер исенә төшерде Ораз. —Бәла бит үзе генә йөрми. Тоташ авыру, үләт таралу—болар да бит шуннан—Кояш хикмәтләреннәндер?

—Бик мөмкин,— диде Гомәр зиһенле әңгәмәдәшеннән канәгать төстә. — Бөтенләй үк аның хикмәтләре түгелдер-түгелен дә ... Сәбәпләре төрледер. Әмма ул күп авырулар килеп чыгуга сәбәп була.

Гомәр торды, кулын җылы су белән юды.

—Гиппократ, Гален һәм башка бөек табибларның, шулай ук тарихчыларның

хезмәтләрен өйрәнеп һәм алар билгеләгән күренешләрне үзем Йолдыз сараенда күзәткәннәр белән чагыштырып, мин шундый нәтиҗәгә килдем: Кояштагы давыллар, Җирдәге табигый бәла-казаларның котырынуы, шул исәптән куркыныч авыруларның кинәт көчәюе вакыт ягыннан еш тәңгәл киләләр.

Гомәр үзенең чиста кулларына карады.

—Әле Фукидид ук язган: Аттикада табигый бәла-каза котыруы белән бергә коточкыч үләт таралган. Шагыйрь Овидий әйтә: Эгинада ниндидер яман чир бер үк вакытта кешеләрне дә, хайваннарны да, үсемлекләрне дә еккан.

Бераз уйлап торганнан соң Гомәр учына арпа аракысы агызды, кулларын шуның белән юды. Белмәссең дөнья хәлен...

—Андый мәгълүматлар күп. Әмма аларны мең тапкыр тикшерергә кирәк! Күпме китап актарасы да, күпме исәп-хисап ясыйсы! Әгәр миңа Йолдыз сараенда тыныч кына эшләргә ирек бирсәләр, мин, бәлкем, вакыты җиткәч, Кояшның үз-үзен тотышы буенча, әйтик, тауларның тирбәнүен генә түгел, ә бәлки үләт таралуын да төгәл алдан белә алыр идем. Кешеләр алдан белеп, чисталыкны саклап, әзерләнеп торырлар иде. Ә миңа, белгәненчә, алай эшләргә ирек бирмәделәр.

—Әйе, бирерләр сиңа! —Ораз, ачуланып, йодрыгы белән тезенә шундый каты итеп сукты, авыртуыннан чыраен чытып куйды. —Үзең утырган ботакны үзең кисү әнә шул була инде ул. Һәм менә нәтиҗәсе. Шаһның барлык балалары егылды.

—Ә... Зөһрә?

—Анысының хәле тагын да мөшкелрәк, трах-прах! Күзгә күренеп чери, ниһәндер кибә.

—Моны Кояшка карамыйча да белеп була иде. Хәер, кем белә. Әгәр аның зарарлы нурлары кешенең миенә һәм аның үз-үзен тотышына тискәре йогынты ясаса? Фукидид язган Аттикадагы бәхетсезлекләргә әле бөлдергеч Пелопонесса сугышы да өстәлгән. Күзгә күренеп чери, дисеңме?— дип сорады Гомәр, тирән сулап. —Менә нәрсә, дускай, Исфаханга бармыйм мин.

Аның исенә төште:

«Без изге ислам илебездә...»

—Башкаладагы һәммәсенә дә әйт: алар, ниһаять, үз морадларына ирештеләр—мин тәэлдем һәм хәзер беркемгә дә сөаль бирмим. Һәм һичкемгә җавап та бирмим.

«...Хәйләкәр математикларсыз, тәкәббер астрономнарсыз, денсез табибларсыз да яшәрбез».

—Мин үземнең адашуларымны таныдым, йолдызлардан, математикадан, табиблык итүдән, башка котырган фәннәрдән ваз кичтем һәм чып-чын мөэмин мөселманга әвереллдем. Шулай булгач,— дип буйсынулы гына әйтте Гомәр, — мин авырган кешеләр өчен дога укый алам, әмма башка берни белән дә ярдәм итә алмыйм.

—Йөз динар да өч фельс!— дип кычкырды ачуы чыккан Ораз. —Без, мескеннәр, башыбызны югалтып, таулар, далалар аша турыдан чаптык. Күпме ат алыштырырга туры килде. Ә син... Вәзир тиремне тунаттырачак минем. Көч белән булса да алып китәм мин сине.

—Тырышып кара! Яле, кәгазенне күрсәт.

—Нинди кәгазьне?

—Менә мондыйны. Гел генә ахмакларга санамасыннар безне. —Гомәр ачу белән торды, кыршылган сандыктан ефәк баулы, балавыз мөһерле төргәк алды. —Күрәсеңме? Изге шәехләрнең хөкем карары бу. Анда нәрсә язылганын тыңла: «Бүгеннән алып гомерлеккә, — гомерлеккә, сизәсеңме? —Шәех Әбделфатыйх Гомәр ибне Ибраһим Исфаханнан куыла». Димәк, мин

башкалага гомергә дә керергә тиеш түгел, юкса, теләсә кайсы мөэмин мина ташланып, мине суя ала. Бармы синдә иске карарны юкка чыгаручы яңасы? Юк? Олак, алайса. Мөһерле кәгазь алып килсәң, барырмын.

Оразның иреннәре дерелди, күзләре ялтырый. Үтерергә әзер.

—Әмергә каршы килеп булмый,— дип инсәләрен җыера Гомәр.

—Дөрес!— дип карлыккан тавыш белән көлә төрекмән һәм кулын селти. —Берәү дә телләреннән тартып әйттермәгән. Әмма шулай да... мин башкалага кайтып җитеп, казыйлар җыелып, алар яңа карар чыгарганчы... Һәм мин кире әйләнеп килеп, без барганчы... шаһ балалары кырылып бетәчәк бит...

Гомәр, чытык йөз белән, үгет-нәсихәт рәвешендә әйтеп куйды:

—Яшәү дә, үлем дә—Аллаһы кулында, шулаймы, хөрмәтлем?

«Табиблар катлавына кергәндә, мин тантаналы төстә ант итәм...»

—Ник бәйләндегез мина?— дип акырды Гомәр, берничә көннән аңа ... вәзир Гыйззелмөлек үзе килеп төшкәч. —Кануннарны бозмыйм, салымны түлим, вакытында ук булмаса да, бурычларымны кайтарам, ашар икмәгемне хәләл хезмәтем белән табам, тагын ни кирәк сезгә? Тынычлыкта калдырыгыз мине!

—Кануннарны бозмыйсынмы? —Юлда арыган Гыйззелмөлек үзен танымасыннар өчен кигән башлыгын өскә күтәреп куйды. Нишапурга ул яшерен төстә, ашыгыч эш белән килде, берничә купшы каршылауларны да теләмәде. —Мина житкерделәр: мәчеткә йөрмисен, шәраб эчәсен икән.

—Арпа аракысы,— дип төзәтте Гомәр. —Син мина шуны әйтер өчен килденме? Кадерлекәем! Мин бит инде утыз ел шәраб эчәм. Һәм мина берни дә булганы юк әле. Тагын утыз ел эчәрмен. Әмма син борчылма: сәрхуш шагыйрь сәрхуш ишәк куучы яки гашиш тартучы мулла түгел ул.

«Юк, бөтенләй бозылган бу,— дип көрсенеп уйлады Гыйззелмөлек, буш, салкын кунак бүлмәсендә җайсыз урнашып. —Акылдан шашкан. Мондый сүзләр өчен...»

—Син бу дөньяда ерак китә алмассың,— диде ул ишетелерлек итеп.

—Дөнья берәү генә түгел! Синен үз дөньяң, минем—үземнеке. Үз дөньямда ... мин инде шундый ерак киттем, син анда гомергә дә барып житә алмаячаксың. Аннан ничек чыгарга икәнен мин үзем дә белмим. Анда мина шактый рәхәт.

—Ярый, анысы синең эш. —Барысын да ничек бар, шулай кабул итәргә өйрәнгән тар маңгайлы вәзир Гомәр кебек усал телле кешенең арттыруларсыз һәм үткен сүзсез сөйли белмәвен аңлый алмый иде. —Мин синең белән бәхәсләшергә килмәдем.

—Ә ни өчен килдең, кадерлекәем? Бәлкем син «Нәүрүзнамә» өчен бүләк алып килгәнсеңдер? Яхшы булыр иде! Югыйсә, күрәсеңме, —Гомәр вәзиргә буш салкын өйдә күнелсез генә йөренгән яраннарына күрсәтте, —хәтта кунакларны утыртырлык, аларны сыйлар нәрсәләрем дә юк.

—Ярый, без озакламый китәбез,— диде вәзир, кыен хәлдә калып. —Ә «Нәүрүзнамә» өчен ул чакта казнада акча юк иде.

—Акча юк иде! Кая киткән соң ул алтын тавы?

Теге тиле ант алга таба ничегрәк яңгырый әле?

«Бөтен белемем һәм көчемне... кешенең сәламәтлеге өчен, авыруларны дәвалау һәм кисәтү өчен... —Якынча шулайрак бугай. —Намусыма беркайчан да күләгә төшермәскә... Кайда кирәк, шунда хезмәт итәргә...»

—Син хәзер минем белән Исфаханга барасың,— дип белдерде вәзир. — Минә әмер: хөкем карары юкка чыгарылды. Җыен.

—Уйламыйм да! Мин бит шундый кеше: әгәр мине ни өчендер бер өйдән куып чыгарганнар икән, мин ул өйгә бүтән кермим.

«Һәрвакыт тиешле ярдәм күрсәтергә, авыруга игътибарлы булырга, табиблык серләрен сакларга әзер торырга...»

—Җыен!— дип ачулы кычкырды вәзир.

Мантыйксыз, диварга китереп терәлгән хакимнәр нәкъ менә шушындый кайнар вакытларда үзләре акыл белән җинә алмаган кешеләрне үлем тумранына ташлыйлар да инде.

Әмма Гыйззелмөлек—бөек Низамелмөлекнең малае:

—Анда балалар ут эчендә кычкырып ята!

Их, ант булмаса...

—Әгәр аларны дәвалый алмасам, булдыра алмаганым өчен мине җәзаламаячаклармы? Әгәр дәваласам, сихерчелектә гаепләмәсләрме?

—Куркасыңмы? —Вәзир Гомәр Хәйямны нәрсә белән алдырырга белә.

Белә дип уйлый. Берни дә белми ул.

—Юк, кызыксынып соравым. Чөнки бу илдә нәрсә генә эшләмә—бөтенесе начар. Иң яхшысы—берни дә эшләмәү.

Вәзирнең сак сугышчылары, түзә алмыйча, кардан чистартылган ишегалдында зур учак яктылар.

—Минем соңгы утыннарым,— дип мыгырданды Гомәр, ризасызлык белдереп. —Талаучылар...

Ишегалды төтен белән тулды, төтен башка йортлар өстенә дә таралды. Күршеләрдән кемдер монда ни хәлләр икәнен белергә теләп башын тыккан иде, капка янындарак торган Ораз ана шундый итеп тондырды, тегесе, артына да борылып карамыйча, базарга хәтле йөгерде.

Базарга баргач, кяфер табиб үзендә Кара Якуб төркемен яшереп яткыра, дип белдерде.

Тыны кысылган мөхтәсиб, үзенең булышчыларын ияртеп, юлбасарларны һәм аларны яшереп ятучыны эләктерергә дип кузгалды. Вәзирнең килүен яшереп калып булмады. Бөтен шәһәр шаулады: йолдыз санаучы янына... галиҗәнапләре үзе... Димәк, ул янадан зур кешегә әверелә.

Вилаят һәм шәһәр хакимнәренең, имам, ишан, сәүдәгәрләрнең җылы, җайлы өйләрендә тынгысызлык, ыгы-зыгы башланды.

—Их!— дип үкенде кемдер. —Әле шушы көннәрдә генә исәнләшми башлаган идем аның белән.

—Йөз динар бурычка сорагач, бирмәгән идем.

—Кем уйлаган бит...

—Әйтәләр бит: төкермә коега...

—Валлаһи, шайтан үзе яклыйдыр аны.

Базарда, йортларда һәм мәчетләрдә чыш-пышлар куерганда, галиҗәнап вәзир буйсынмас табиб белән уңышсыз көрәш алып барды.

—Сузма! Юкса көч белән алып китәм.

—Кит,— диде Гомәр, көлемсерәп. —Колларымны артка каерып бәйләргә, аларга богау салырга онытма. Әнә шул хәлемдә, һичшиксез, дәвалармын мин сезнең авыруларны.

...Ант булмаса...

—Йә, ни телисең, әйт!— дип чәрелдәде Гыйззелмөлек.

Кувшинны алды, анда су дип уйлап, гөлт-гөлт эчә башлады. Арпа аракысыннан тончыкты.

—Артык көчәнмә. Йөзеңнең төсе куркыныч хәзер синең, чөгендернеке кебек зәңгәр-куе кызыл. Мина әле сине дәваларга туры килмәгәе. Кан җибәрергә кирәк иде дә. Мин нәрсә телимме? Мин шуны сорарга телим: кайда соң алар?

—Кемнәр?— дип күз яшьләренә тыгылып сорый алды вәзир. Аның кәкре борыны астында үтә күренмәле тамчы күренде.

—Теге, мине хөкем иткән кешеләр? Кайда алар хәзер? Шәехләр, голамаләр?
—Мыскыл итмә,— дип ялварды вәзир.
—Ә! —Хәзер үзенең чынлап та чыгырыннан чыга башлавын тоеп, Гомәр инде бөтенләй башкача, тынычрак итеп әйтте: —Биш мең динар.
—Нәрсә? —Ниндидер таныш, якын сүз ишетеп, вәзир айнып китте.
—Беләсеңме, кадерлем,— дип арыган кыяфәттә сулыш алды Гомәр. — Мин хәзер падишаһ хакимияте белән сезонлы төзүчеләр кебек эш итәм: мин эшлим—сез акча бирәсез, сез акча бирәсез—мин эшлим. Бер елдан, ун, йөз елдан ул хакимияткә ни була—анысы мине кызыксындырмый. Ул сезнең кулда, анысы сезгә ачыграк күренә.

Гүзәл дөнья! диярләр: сак колак сал,
Мавыкма, ул—хакимнәр ачмаган фал.
Алып китте синең күкләрне дөнья,
Ул алганчы, анардан син алып кал.

Гомәр бакыр ләгәнгә кувшиндагы арпа аракысын койды.
—Санап сал шушында биш мең динарны.
—Ә нигә—анда?— дип гаҗәпләнде вәзир, тукылган букчадан авыр зур янчык алып һәм аракы исеннән йөзен чытып.
—Йогышлы авыруны юар өчен.
—Мин авырмыйм, тикшерә аласың. Бу акчалар да минем казнадан. — Вәзиргә җиңелрәк булып китте. Аның кәефен зәм-зәм суы пары да күтәрде һәм, иң мөһиме, инде сүз алтын турында чыккан икән, димәк, бу тискәре белән килешергә була. Карлы юллардан Нишапурга туктамый чапканда, вәзир нәкъ менә аның, бернигә карамыйча, үз сүзендә нык торуыннан курыкты. Хәзер эш җайлана төште. Гомәр, әлбәттә, үзсүзле, кырысрак кеше, әмма бик тә сәләтле табиб.
—Ал, монда төгәл биш мең.
—Сана.
—Син миңа ышанмыйсыңмы?— диде вәзир, үпкәләп.
—Кадерлем, мин моннан соң беркемгә дә ышанмыйм. Бер тәңкәләп төгәл биш меңне сана.
—Вакыт үтә.
—Ә элек кайда идең?
Вәзиргә тешен кысып булса да тәңкәләрне санарга туры килде. Алтын өеме. Вәзир кешеләре аннан күзләрен ала алмады.
—Чынлап та, аракыны әрәм итәргә ярамый. —Гомәр аны кире кувшинга бушатты. —Эчик без аны. Телисеңме?
—Кит!
—Юкка киреләнәсең. Ул файдалы нәрсә. Мин эчәм. Юлда туңмас өчен. Санап бетердеңме? Яхшы. Карале, ничек тиз! Сиңа акча ваклаучы булып кына эшлисе бар. —Гомәр тәңкәләрне янчыкка салды, саллы янчыкны үз өстендәге толып эченә яшерде.
—Бу акча «Наурузнамә» өчен,— диде ул вәзиргә дустанә генә. —Син бит аны нәкъ биш меңгә бәяләдең, шулай бит? Падишаһ балаларын дәвалаган өчен синнән тагын алдан ике мең динар. Өч меңен Исфаханда бирерсең...
—Минем ... үзем белән башка акчам юк!— диде вәзир, аптырашта калып.
Ул үз кешеләре алдында оятыннан чак еламый иде. Зарар юк. Түзәр әле!
—Башка акчаң юк? Шәһәр казые Хөсәен ибне Гали ибне Микальны чакырт. Ул бай кеше. Галиҗәнапләре сәлҗук падишаһы балалары өчен ике меңен кызганмасын.
—Чакыртыгыз!— дип аптыраган төстә генә боерды вәзир үз кешеләренә.

Тегеләре мондый хәлне гомерләрендә беренче тапкыр күрәләр һәм ни дип уйларга да белмиләр иде.

Ораз исә, Гомәргә күз кысып, ишеттерми генә кеткелдәде: янәсе, шул кирәк ана. Гомәр бик үк әйбәт тамаша башламавын, анда үзен бик үк әдәпле тотмавын аңлады, әлбәттә. Әмма аның өстеннән оештырылган Исфахан һәм Нишапур мәхкәмәләре оятсыз тамашалар түгел идемени? Эш алайга киткән икән инде, ул алардан ким кәмитче түгел...

* * *

Исфахан, әйтерсең лә, үлгән. Базарлар бөтенләй буш. Пычрак, күптәннән себерелмәгән урамнарда җан иясе юк. Тиешле сәгатьтә бар тавышка кычкырырга тиешле мөәзиннәрнең намазга чакыруы да ишетелми.

Фәкать шәһәрдән читкә, үзәнлеккә чыгара торган ачык капка янында гына сакчылар йокымсырап утыра. Аларның эше юк. Ахмак булмаса, кайсы дошман керсен ди йогышлы шәһәргә? Әнә, алда мәет күтәргән кешеләр төркеме күренде. Күренде дә кырый тыкрыкка кереп китте. Сугыш булып узган шәһәрдә шулай: дошман гаскәрләре камалыштагыларны кыра, исән калганнарны үзе белән алып китә, хәрабәләр арасында очраклы гына исән калган һәм әсирлектән котылган берничә кеше казына.

Сарай килүчеләрне күңелгә авыр, күп тавышлы, әмма ничектер арыган, битараф ыңгырашып елау белән каршы алды. Төнлә Мәликшаһ белән Төрек-Хатынның улы—иң кечкенә солтан Мәхмүт үлгән икән.

—Менә күрәсеңме?!— дип йодрыклары белән чак ташланмады Гомәргә ачуы кабарган Гыйззелмөлек. Янәсе, синең аркада бу. Әгәр син соңармасаң... Сарайда ул янадан үз халәтенә кайтты.

Гомәр тыныч кына ислам диненең (анысы гынамы икән?) көндәлек, ваемсыз-тынычландыру сүзләрен әйтте:

—Аллаһы бирде—Аллаһы алды.

Һәм менә шушында, озак түзеп торганнан соң, бөтен ачуы, шамакайланусыз-нисез, ничек бар шулай тышка бәреп чыкты.

—Шунысы гаҗәп!— дип кычкырды Гомәр, эченнән генә бөтен әрнүләре белән үзен дә, Гиппократ антын да, ахмак чорны да, ахмак патшаларны һәм түрәләрне дә каһәрләп. Ул шат күңелле, матур Мәхмүтне исенә төшерде. Берninди гаебе юк иде бит аның. Беркатлы балалык уеннарында булса гына инде. Өлкәннәрнең акылдан шашуы өчен һәрвакыт балалар түли: күңеленең шатлыгы, карашының яктылыгы, сәламәтлеге, ә кайчакта гомере белән. Шунысы аңлашылмый: җир йөзендәге иң эшлекле вәзиргә нигә дип ялланган үтерүчеләр җибәрергә кирәк иде? Аларның куллары белән законлы ирне, үз баласының атасын агуларга? Һәм бу баланы намуссызлык, тәкәбберлек коралына әверелдерергә, галимнәрне куарга, дәүләтнең астын өскә китерергә нигә кирәк иде? Ә? Акылдан язган, тотрыксыз дөньядагы буш, юк-бар рәхәтлекләр өченме? Мин гөнаһлы, әмма минем гөнаһларымның беркемгә дә зыяны тигәне юк...

Тыны кысылып, Гомәр туктап калды. Юеш куаклар арасындагы кайгылы шакаллар төрле тавыш белән улаган кебек, сарайда авыр ыңгырашулар һәм үкереп елаулар ишетелде.

—Ишетәсеңме? —Гомәр тешләрен кысты. —Менә аның нәтиҗәсе.

Мәетне карагач, Гомәр җиде яшьлек Мәхмүтнең әле аңа авыру тимгелләре таралганчы ук үлүен ачыклады. Димәк, ул, мескен бала, аеруча нык авырган. Аның газаплары турында кем сөйли ала?

Падишаһның балалары һәрберсе үз бүлмәсендә ята. Өлкәнендә, уналты яшьлек Баркъярукта, өч көн элек бик нык тән кызышуы, баш авырту, хәлсезлек, оча башы сөяге авырту башланган.

—Бирешмә,— дип аның күңелен ачарга тырышты Гомәр. —Тән кызулыгын

иртәгә, берсекөнгә бетәр. —Ул сырхауга ешрак анар сүле бирергә кушты.

Уртанчы малайның—унике яшьлек Мөхәммәтнең тәнендә, күз, авызы һәм борын тирәләрендә бөрчекләр күренә башлаган инде.

—Хәзер ин читене башланачак. Ничәнче көн авырый инде? Ә, бишенче. Тән кызуы кичә төштеме? Бүген янадан күтәрелер. Бөрчекләр үлекле куыкчыкларга әверелер, аларга ак терекөмеш мае сөртегез,— диде сарай табибына.

Иң авыр хәлдәгесе кечкенәсе—сигез яшьлек Сәнҗар иде. Аңы томанланган, үз-үзен белми акыра, озын тырнаклары белән үлекле куыкчыкларны тырный. Аңына килгән минутларда ул Гомәргә йоклый алмавына, сулыш алуы, ризык йотуы авырлыгына, бөтен җире авыртуына, селәгәе агуына зарланды.

—Кулларын гәүдәсенә бәйләгез, терекөмеш мае кулланыгыз, анар сүле бирегез. Йокласын өчен—бераз әфьюн…

Авырулар янында утыручыларга Гомәр авызларын һәм борыннарын серкәдә чылатылган чүпрәк белән бәйләргә, кулларын серкә белән юарга киңәш итте. Ә үзе кулларын арпа аракысы белән юды, аны эчкә дә кабул итте. Балаларның ятак әйберләрен, киемнәрен алыштырдылар, йогышлыларын яндырдылар. Сарай бүлмәләрендә чистарткыч күкерт яндырудан чыккан төтен таралды.

Гомәр көнен дә, төнен дә сарай бүлмәләреннән чыкмады, түземлелек белән авыруларны дәвалады, үз балаларын карагандай карады. Аларның чарасызлыгы анда аталарча кызгану хисе тудырды. Ана бөек табибларның хезмәтләрен янадан карап чыгарга кирәк иде. Шуңа сарайда булуының бишенче көнендә китаплар саклана торган бинага китте.

Тузан. Идәндә, китапларда, киштәләрдә. Күрәсең, монда күптәннән инде беркем дә күз салмагандыр. Китаплар актарганда Гомәр үз артында кемнеңдер сак кына атлавын ишетте. Борылып караса—хезмәтче кыз! Ә! Нәкъ үзе, тимгел басканы. Алсулыгы инде бөтенләй унган, хәтта миңнәре дә тоныкланган кебек.

—Әфәндем,— диде ул, куркып кына тирә-ягына каранып, —галиҗәнап патшабикә үз янына чакыра сезне.

Гомәрнең йөрәге дерелдәп китте. Ул шулай буласын белде. Теләмәде—көтте.

—Әллә мине тагын сыйламакчымы? Беләсенме, сезнең сый-хөрмәтләрегездән…

—Юк, әфәндем. Тәм-том кайгысы түгел анда хәзер...

Ул аны әллә нинди яшерен юллардан солтанбикә бүлмәсенә алып барды. Һәркайда авыр ис. Барлык ишекләрне, тәрәзәләрнең капкачларын киереп ачарга иде дә, бер ун көн салкын җил бөтен сасы исне куып чыгарганчы, ачык килеш тотарга иде. Нәрсәгә кирәк сезгә алтын һәм бәрхет? Бер йотым саф һава сезнең барлык байлыкларыгыздан кыйммәтрәк.

—Монда борын очы калкурак бер кызчык йөгереп йөри иде. Исемен белмим инде...

—Хәдичә. Чәчәк авыруыннан үләненә биш көн инде.

—Һм. Күренекле табибларны ана чакырмаганнар, билгеле.

Башыннан ук җәймә бөркәнгән хатын, аякларын алтынланган башмакларга төшереп, сәкедә утыра иде.

—Әссәламегаләйкем!— дип баш иде Гомәр.

Җавап та бирмәде, селкенмәде дә. Әйтерсең, йоклый. Әллә аның мондалыгына күнегергә тырышамы, яисә, ана көтелмәгән һөҗүм әзерләп, бөркәнчеге астында бер-бер мәкер уйлыймы?

Берникадәр вакыттан соң Гомәр аның тонык, тынкышрак тавышын ишетте:

—Гомәр, мин хәзер патшабикә түгел. Мин хәзер беркем дә түгел. Кызганып дәвала, зинһар, мине.

—Галиҗәнапләре бөркәнчеген ачсын.

—Юк!.. Мин... оялам.

Хәзер ул ояла!

—Карамыйча гына ничек дәвалыйм ди инде мин, галиҗәнапләре?

Башын түбән иеп һәм авыр сулап, Зөһрә бөркәнчеген тартты. Аның баш түбәсендәге пеләшләнгән урыннарны күреп, Гомәр чак кычкырып җибәрмәде.

—Башынны күтәр!

Коточкыч күренеш. Йөзен кутыр баскан. Кашы да, керфекләре дә юк. Муены бәйләп эшләнгән якага охшаш ак тимгелләр белән тулы. «Зөһрә йолдыз ләйсәне». Борын очы ямьсез булып күтәрелгән, борын төбе инде иңә башлаган.

—Йөрәгем авырта, мием дә, бавырым да,— дип елап җибәрде Зөһрә. — Коткар мине, Гомәр! Бөтен хәзинәмне сиңа бирермен...

Соң инде, кадерлем! Соң. Сине хәзер фәкать әҗәл фәрештәсе Газраил гына коткара ала. Әмма бу хакта аңа әйтеп буламы соң? Кешене соңгы өметеннән аерырга ярамый.

«Ә нигә?— дип каршы төште аның бөтен әгъзалары. —Әллә ул үзенең нинди юлга басканын белмәдеме? Белде. Әмма белергә теләмәде. Болай гына үтеп китәр дип уйлады. Артык иреклектән һәм җиңел килә торган рәхәтлекләрдән котырды. Ул—чибәр хатын, ул—патшабикә, аңа бар да гафу ителә. Юк, җир йөзендә берни дә гафу ителми!»

Ул бу хәлдә бер нәрсә дә эшли алмый. Авыру нык көчәйгән. Дөньядагы бер генә табиб та коткара алмый инде аны. Хәтта табибларның табибы Ходай үзе дә. Әмма ярдәмсез дә калдыра алмады Гомәр Зөһрәне. Ә нәрсә белән ярдәм итәргә соң?

—Шуны беләсе килгән иде,— дип киная ташлады ул патшабикәгә, китәргә ашыгып, —синең ирең солтан Мәликшаһ нәрсә белән агуланган иде? Бик тиз, җиңел, озак азапланмый үлде.

—Каһәр суксын үзеңне!— дип тынкышланып әйтте Зөһрә, бөркәнчеген яңадан ябынып.

Унөченче көнгә авыруларның җәрәхәтләре кибә башлады, утызынчы көнгә инде кутырлары купты. Үлекле урыннарда тирән шадралар калды, Сәнҗарда алар бигрәк тә күп иде.

—Аның каравы сез чәчәк авыруыннан гомерлеккә котылдыгыз,— дип юатырга тырышты аларны Гомәр. —Хәзер инде аның белән бервакытта да авырмаячаксыз. Тирә-юнегездә бөтенесе ухылдап ятачак, әмма авыру сезгә йокмаячак.

—Аллаһыга шөкер!— дип иркенләп сулыш алдылар Баркъярук белән Мөхәммәт, барлык газаплардан котылуларына шатланып. Матурлыкка килгәндә, артык кайгырмыйк, шаһ малае теләсә нинди кыяфәттә дә чибәр, иң мөһиме—исән калдылар.

Тик Сәнҗар гына яндырып алучы, балаларга бөтенләй хас булмаган усал карашы белән Гомәрне борчулы аптырашта калдырды.

«Нәрсә булган аңа? Мескен,— дип уйлады Гомәр, кызганып. —Ул әле авырудан бөтенләй үк айнып җитмәгән. Мөгаен, кулларын гәүдәсенә бәйләп куярга кушканым өчен ачуланадыр. Үлекле урыннар бик нык кычыта шул. Ярый, озакламый онытыр.»

Юк, онытмас. Әгәр дә Гомәр Баркъярук белән Мөхәммәтне үтереп, Сәнҗарның үзен генә терелтсә, һәм ул, Мәликшаһның бердәнбер варисы булып, сигез яшендә тәхеткә утырса...

Шул ук көннәрдә, үзенең коточкыч кычкыруына тончыгып, патшабикә Зөһрә үлде, һәм моның өчен беркем дә кайгырмады.

* * *

Гомәр коточкыч баеды. Килешү буенча, шагыйрь-табибка өч меңне Гыйззелмөлек бирде. Әлбәттә, ул әле вәзир буларак үз йолдызының батып

баруын белми иде, югыйсә, мөгаен, бирмәс иде. Баркъярук белән Мөхәммәт—икешәр мен, кечкенә Сәнҗар йөрәгән кысып булса да бер мен бирде. Андыймондый очракка дип ике менне Мөәиделмөлек тамызды.

Хәтта «шагыйрьләр әмире» дә, Гомәрнең китүен ишетеп һәм үзен сарайдан кысрыклап чыгармаячагына шатланып, биш йөз динар тәкъдим итте, әмма Гомәр алмады.

Чынлап торган ун мең динарны җирле саррафлардан [1] чекларга алыштырып, Гомәр өенә кайтырга җыенды. Кыш кыска булды. Кар һәм боз тиз эреп бетте, юллар кипте, алар өстендә инде җиңелчә генә тузан күтәрелде. Халкының өчтән берен күмеп, Исфахан язгы кояш астында әкренләп җанлана башлады.

Хәзер инде Гомәр Бойрега кереп чыга ала. Адәм баласы, үткәнгә кире кайтып, таныш әйберләр: агач, йорт, койма эзли. Аларны таба алмаса, тирәюньдә бар нәрсәнең үзгәрүен, инде үзенең дә бөтенләй дә ул чактагы кебек түгеллеген аңлап, аптырап катып кала.

Әйтерсең лә, Йолдыз сараен моңарчы күрелмәгән көчле җир тетрәү җимергән! Алай гына да түгел, каты җирне киң ачып, эре һәм вак ватыкларны йоткан. Елгыр кешеләр обсерваториянең ташларын берәм-берәм ташып кына калмаганнар, хәтта известь гөмбәзне ватканнар—аны таш чыгару урынына әвереллдергәннәр. Калкулык чокырга әйләнгән. Өч тирәк тә юк—кискәннәр.

Гомәр әкрен генә читкәрәк китте, шәрә зиратка кереп, таныш каберне тапты. Бөтен тәненә суык йөгереп, таштагы язуны укыды: «Әкдас». Гашишчы Корбан шомарткан беренче таш. Гомәр аны бишенче постулатны төшенүе исталеге итеп озак саклады. Әкдас үлгәч, аның исемен язып, каберенә куярга кушты.

Аккошларныкыдай озак яңгырап торган әрнү тавышы чыгарып, Гомәр күкрәге белән ак ташка капланды һәм аны әче яшьләре белән коендырды. Җирдә аның бүтән бер нәрсәсе дә юк. Өмете юк. Киләчәге юк. Яшәүнең мәгънәсе юк.

> Сусыз чүлдә юлаучы тайса хәлдән,
> Көтә үлем—бетте иң соңгы дәрман,—
> Бәхетле шул—кем иртә китсә җирдән,
> Бәхетлерәк бөтенләй тумаган җан.

Гомәргә инде—46. Мәрхүмә Төрек-Хатынның энесе караханлы Әхмәт бер елдан үтереләчәк, Тәре йөртүчеләр, «Аллаһы табутын» коткарып, Иерусалимны биш елдан соң алачак.

Хорасан галиме, пыяла сегментының әйберләрне зурайта алуын алдан әйткән, «явыз көчләр белән элемтәдә торганы өчен» үлемгә дучар ителгән, аннары, акылдан шашкан булып кыланып, үлем җәзасыннан котылып калган Әбуҗаффар әл-Хәсән 89 ел элек үлде. Ә бит ачышы күзләре начар күрә башлаган күпме кешегә файда китерер иде!

334 елдан соң Олугбәк Сәмаркандта обсерватория төзиячәк. Тагын 21 елдан аны суячаклар. Джордано Бруноны учакта 506 елдан соң яндырачаклар. Әмма фәкать 32 елдан (1126), әле Гомәр Хәйям исән вакытта, үзенең «Кире кагуны кире кагу» дигән искитмәле китабында чирләшкә мистик Әбухәмит Газалины һәм хак динне котырынып яклаучы башка шундыйларны хурлык баганасына мәңгелеккә кадаклап куйган Ибне Рушад (Аверроэс) туачак.

***Миргалим Харисов** тәрҗемәсе.*

---

[1] Сарраф—процент алып, акча ваклаучы.



Салават
Рәхмәтулла

# УТ ЭЧЕНДӘ ШИГЫРЬ ТУАЧАК

## Татар халкы

**...Аллабызны тартып ала-ала:
«Татар — денсез халык!» — дигәннәр.
Монголларның бәла-казаларын
Җиде йөз ел (!) безгә өйгәннәр...**

**...Туган телне тартып ала-ала:
«Татар — телсез халык, — дигәннәр. —
Телсезләрнең иле буламыни?
Татар — илсез халык...» — дигәннәр...**

**Динле!
Телле!
Илле татар халкы! —
Куш кул сузып:
—Исәнме сез?
Без — бар! — диябез.
Түбәтәйне нәкъ Тукайча киеп:
—Без — мәңгелек, дуслар! — диябез.**

* * *

*(Әдипнең «Алмачуар» хикәясе тәэсирендә язылды.)*

Автор

**... Атлар килә!
Мәйдан белми әле:
Алмачуар алдан киләчәк! —
Моны әле бер Галимҗан белә,
Бәйге узгач — мәйдан беләчәк!**

Салават РӘХМӘТУЛЛА (1942) — *Башкортстанда (Эстәрлетамак шәһәре) яшәүче татар шагыйре; татар һәм башкорт телләрендә дөнья күргән берничә китап авторы.*

… Халык белми әле:
Алмачуар
Йөрәккәе ярылып үләчәк… —
Моны әле бер Галимҗан белә,
Чорлар узгач — дөнья беләчәк!..

## Русия

…Кыйбласын да табалмаган урыс
Ил баскан да мәңге, ил баскан:
Юлын канлы күз яшьләре баскан,
Хәрабәләр баскан, көл баскан.

Илләр арты — илләр: чәчәк-гөлләр… —
Байлыкларын талап, «үз» иткән:
Халыкларын, коллар итеп изеп,
«Рәсәй» дигән дәүләт төзеткән.

Һәр җиңелгән ил… урыска «калган»,
Урыс тамга салган: «Бүленмәс!…»
Илләр язмышлары — кара хәсрәт
(Карталарда — кызыл: беленмәс…).

… Кол биләсәң, мәңге тирләр түкми,
Йөзеп була мәңге муллыкта!..
Колбиләүчеләргә — коллар кайда
Билләр бөккән мәңге коллыкта?!

Коллар юлы — көрәшчеләр юлы,
Көрәш аша — җиңү! (Кем белмәс!..)
Чыңлап оча богау боҗралары,
Кисәк-кисәк куба «бүленмәс!..»

Кыйбласы юк һаман (буласы юк!):
Халыкларның төшкән каргышы…
… Русиянең, әллә кайдан килеп,
Әллә кайда китеп барышы…

## Сынаулар

*Сау бул инде, хуш, бәхил бул,*
*И минем торган җирем…*
Г. Тукай

Эх…
Безнең язмышлар белән
Уйный ил гомер буе:
Ачлыкта, ялангачлыкта
Сыный ул гомер буе.

Башта — пособие белән,
Аннан — стипендия.
Шуннан… шуннан — эш хаклары,
Иң соңыннан — пенсия…

… Өч сынавын үттем инде
(Бик аз калганбыз — күрәм):
Ач килеш, ялангач килеш
Соңгы сынауга керәм.

Соңгы сынау… Комиссия:
Рәисе — Әҗәл-Үлем!
Эх…
Сау бул инде, хуш, бәхил бул,
И бөек Туган илем…

* * *

Күз җитә — китәр чак җитә:
Кошлар бит тоя барын!
Калдырып китәрләр алар
Яз корган ояларын.

Үзләре корган оялар —
Үзләре корган дөнья:
Яз буе корган дөнья бит,
Җәй буе торган дөнья!

Бәхет-шатлык, кайгы-хәсрәт,
Хыяллар сыйган анда:
Анда — йөрәкләр кавышкан,
Кошчыклар туган анда…

… Күз — китәр чак:
                кошлар көн дә
Сыныйлар канатларын.

(Бала кошлар да сизенә
Зур юллар алда барын!)

Ояларын — дөньяларын
Урап очалар һәркөн:
Китәселәр килми дә бит…
Китми дә булмый ләкин!

Чит җирдә яңа оялар
Әллә кора, әллә — юк.
Кайтуга — корган оялар
Әллә тора, әллә — юк…

Дөньяларын ташлап китә,
Нәкъ безнең сыман алар!
… Кошлар — инстинкт колы,
Безме? Без — томаналар…

* * *

И якты бу дөнья!
Көннәре бит —
Гел кояшлы, төннәр — гел айлы;
Җир — түгәрәк:
Мәңге яшәр өчен
Бигрәк җайлы, бигрәк уңайлы!..

Мәңгелектә
Мәңге яшәр өчен
Хыялланган — мин дә бар әле!..
Эх… мәңгелек белән
«Мәңгегә!» дип
Хушлашасы көн дә — бар әле…

* * *

*Кайгы кайгыларга охшамый,*
*Кайгы савытлары бушамый…*
Халык җыры

… Кайгы савытларым — тулы
(Булырмы бер бушаган?!):
Эх…
Беркемнең юктыр кайгысы —
Минекенә охшаган…

… Шатлык савытларым — тулы
(Булырмы бер бушаган?!):
Эх!
Беркемнең юктыр шатлыгы —
Минекенә охшаган!..

* * *

**Аралардан шаулап гомер узган...**
**Бүген минә ара — бер адым:**
**— Ялгызсыңмы?..**
**Һаман, һаман, һаман —**
**Берүзеңме?... — диеп сорадың.**

**Аңламаганга йөз сүз дә — җитмәс,**
**Аңлаганга — җитәр бер сүзем:**
**— Берүзем мин һаман,**
**Синең белән**
**Яшәгәнгә күрә... берүзем...**

***

**Бәхетме, бәхетсезлекме? —**
**Чәчкәнеңне урырмын...**
**Бәхетләрдә йөзәчәксең!**
**Мин... мин — оныттылырмын...**

**Оныттылыйм... Шатланырмын,**
**Бәхетле була алсаң...**
**... Утлардан алып чыгармын,**
**Утларда торып калсаң!..**

***

**... Син — янымда, мин — яныңда:**
**Тәүдә —**
**Якынлыкны тәннәр тоячак,**
**Тәннәр тойгач — җаннар тоячак...**

**Аннан —**
**Йөрәктән йөрәккә очкын чәчрәп —**
**Дөньябызны ялкын чолгап алгач,**
**Зиһеннәрне... янгын җуячак...**

**Аннан...**
**Аннан...**
**Аннан — иң соңыннан! —**
**Икебезнең җан кушылмасыннан**
**Ут эчендә... Шигырь туачак!..**



Рөстәм
Мингалим

# ЕЛГАМ СӨЕП КАРЫЙ КҮЗЕМӘ

## Ни күрсәң дә

Бу дөньяда кайгырдым да,
Шатландым да, елмайдым да...
Дөресен әйтим, ни күрсәң дә
Яшәү рәхәт, рәхәт монда.
Озын да ул, кыска да ул,
Ләззәтле дә җан һәм гомер —
Киткәннәре күреп китте,
Киләчәкләр килеп күрер.

Әй сез, Җиргә килмәячәк
Гүзәл кызлар, шәп малайлар!
Беләм инде, арагызда
Менә дигән кешеләр бар.
Тик саңгырау юклыкта сез —
Телсез, өнсез... юк көчлеләр —
Сезне шундый зур бәлагә
Дучар итте бит кешеләр.
Зарыгыз юк кешеләргә,
Үпкәгез юк — тоям аны,
Бу хәлегез сезгә җиңел,
Тагы кемгә?.. Миңа авыр.

Җирдә сезнең кешеләр бар,
Әниләр бар, әтиләр бар —
Нечкә туташ, тулы ханым,
Купшы егет — күпләр алар!
Шулар бар да җыелып бүген
Баса кебек минем иңгә —
Әйтерсең лә авырлыктан
Әкрен генә иңәм җиргә...
Һәм уйлыймын: сездән торса
Килү-килмәү бу дөньяга,
Хәтта бер кайгырыр өчен
Килер идегез сез аңа.

Ә мин мең кат кайгырдым да,
Шатландым да, елмайдым да...
Дөресен әйтим, ни күрсәң дә,
Яшәү рәхәт, рәхәт монда.

## Ашыгасың

Заман шулай куша инде,
Тормыш шулай куша инде.
Күп йөрергә,
Күп күрергә,
Күп эшләргә, күп белергә...
Син яшәргә ашыгасың.
Ашыгасың!!
Син бит —
Ярты гомер йомгагыңны
Җилгә сүткәнсең бит?!
Калганын тормыш җиле
Үзе җиңел сүтә.

Гомер җебең киерелеп
Көннәр аша үтә.

Рөстәм МИНГАЛИМ (1937) — *шагыйрь, драматург; күпсанлы китаплар («Эзләр», «Дәрт чүлмәге» һ. б.) авторы. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Гомер җебең, киерелеп
Дөнья аша үтә,
Ә җил сүтә, сүтә...
Җепне җилгә тыебрак
Биреп була бит, ә?!
Җепне тәмам җил иркенә
Куеп була бит, ә?!
Ә җил сүтә, сүтә...

Аһ, чынлап та шулай ич,
Әллә хәзер ашыкмыйммы,
Әллә һаман ашыгыймммы,
Нишлим икән, дисеңме?
Анысын үзең кара —
Кеше үләргә соңгармый,
Яшәргә соңгара.

## Өмет гөлем

Ак кар яуды кабат-кабат.
Яуды ла килеп-килеп;
Һәм ал гөлем калды әле
Ак карларга күмелеп.
Йөрәгемнән ул гөлемә
Карлар аша көч бирәм —
Бик сизәм лә, кыш озын ла,
Кар салкын ла, кар тирән.
Яз җитүгә — карлар эрер.
Ал гөлем чыгар көлеп.
Юк, сулмый да, коелмый да,
Ул — минем өмет гөлем!

* * *

Кайчак шулай күзләремне йомам.
Барлык мәшәкатем онытыла,
Уйлап торам...
Дөнья тына...
Тыныч хисемдә,
Йомык күзләрем эчендә
Яналар җемелдәп
Мин күргән шәһәрләр,
Мин белгән, ишеткән шәһәрләр —
Җемелди
Йолдызлар булып,
Җемелди
Уйларымның чиксез күген бизәп.

Йолдызлар арасында
Якты ай сыман
Казан йөзә...
Йөзә...
Минем шәһәр,
Минем бетмәс бәхет!

Күзләремне ныграк кысам,
Ә шәһәрләр кысылмый,
Ә Казан кысылмый —
Шуңа
Сабый күк елмаям,
Миңа рәхәт!

* * *

Юллар божрасы мине моннан
алып китте, тагы китерде...

Су өстендә балык сикерде,
елгам сөеп карый күземә.
Иркәм кая икән?
Асыл ташлы балдак
алып кайттым әле үзенә.
Елгам сөеп карый күземә:
«Ул шул ятлар белән чуалды, — ди, —
Шәүләләре төште йөземә».

Елга шавы...
Уйларымда — давыл...
Таллар сыгылып,
камышлыклар актарылып, егылып,
ят эзләрне миңа ачалар.
Эзләр калтырыйлар, йөгерәләр,
куелыкка кереп качалар...
...Елгам сөеп карый күземә.
Минем елгам! Хыянәтсез елгам!
Мә ал,
асыл ташлы балдагымны
бүләк илим әле үзеңә.

## Юл бирегез...

Таулар,
Озын гомерле таулар —
Җирдә күп алар.
Ә таулардан аста елгалар
Кайнап-кайнап агалар
Сикереп-сикереп агалар...
Уралып-уралып агалар...
Арып агалар —
Ләкин агалар,
Һаман агалар елгалар.
Кемнәрнеңдер кайгы утын сүндерергә
Баралардыр алар. —

Юл бирегез, зинһар, юл бирегез, таулар!

*Хикәяләр конкурсына*



Асия
Юнысова

# МАДАМ БОВАРИ

Сап-сары өрәңге яфрагы жил белән качышлы уйный. Трамвай юлының шпалы астына качып торгандай итә дә, жил алан-йолан караган арада тагын, житез мәче баласыдай койрыгын уйнаклатып, икенче бер ышык урын табып сыена. Мәүлия өзелеп төшкән сары яфракның жил белән куышлы уйнавын үзенчә аңлады. Кышка керер алдыннан ышык урын эзли ләбаса. Жылы урын эзли. Югыйсә берәр агач төбендә жирне кочаклап ятса, үзенә дә, жиргә дә унай булыр иде. Юк шул, башсыз яфрак шпал арасыннан йөгерә.

Бу трамвай дигәне ник озаклады соң әле? Берәр почмакта тагын машиналар тыгылышкандыр инде. Тәмам әрсезләнде алары. Жәяүле юлы дип тормый, трамвай рельслары дип тормый, өстенә менәргә килгәндәй чабалар. Бәләкәй кешенең хокукы беткән, кадере киткән заман. Талкый торган заман. Әрсез жил өрәңге яфрагын талкыган кебек. Трамвай көтүчеләр дә ишәя бара. Озак көтәсе булыр микәнни?

Мәүлия трамвай юлына аркасын куеп басты. Чын хатын-кызларча, имеш, трамваена да ялынмый! Юлда машиналар конвейердагы кебек агыла гына. Берсенең ишеге ачылып китсен иде дә әллә кайчангы бер танышың: "Нишләп торасың, Мәүлия? Утыр әйдә машинага, чум тизрәк!", – дисен иде. Таныш булмаса да ярый, яхшы кеше генә туры килсен. Туктар, бар – и хыялый! Машиналар арасында ырып-ерып йөргән хәер эстәүче хатыннар бимазалаудан, гарип-гораба бәйләнүдән куркып, тәрәзә пыялаларын да төшермиләр.

Мәүлия үзе руль тотып утырмаслык хатынмы соң?! Машинасы гына юк. Ул машина йөртүче хатын-кызларны санарга кереште. Әнекәем, бер ир-атка бер хатын-кыз туры килә инде әллә? Мәктәбен дә бетереп өлгермәгән чәчбиләренә кадәр руль тоткан. Алар тотар инде, ата-аналары узындыргач. Ни йөрәгең белән баланны шушы тимер ташкын арасына кертеп жибәрмәк кирәк! Ничә йөз меңлек машинана китереп төртсәләр, хәсрәтеңнән йөрәгең ярылып үләрсең. Юк, Мәүлиягә машина кирәкми, бушка бирсәләр дә кирәкми. Ә менә утырып йөрер иде... Бер сөмсезе шунда жыелган янгыр суына выжлап килеп керде дә, янәсе күп мыгырданып торма, Мәүлияне бензинлы түгәрәкләр уйнаган пычрак су белән коендырды. Мәүлия, шакшыдан

йөзен яшерергә теләп, кинәт артка, абайламастан, трамвай юлына таба тартылды. Шул мизгелдә колакны тондырып трамвай кыңгыравы шалтырады. Тукталыштагы халык аһ итеп куйды.

– Ай Аллам! Трамвай астына керә бит инде!

Куркудан агарып калган Мәүлия киң ачылып киткән ишектән трамвайга үтте. Трамвай йөртүче кабинасын кыршаулаган тимергә тотынып, сулышы тигезләнгәнне көтте. Аннары, янчыгын чыгарып, җиде сум көмеш санады. Югыйсә, юл йөрү билеты бар иде. Сумкасында актарынасы килмәде. Әллә, акча түләп билет алуы үзенә күрә сәдака бирүе идеме соң? Исән калган сөенечтән. Кондуктор да бар иде бугай. Мәүлия, нишләптер, акчасын трамвай йөртүчегә сузды. Ир кешенең юлдан күзен алмый гына сузылган кулына кулы тиюдән Мәүлия әллә нишләп китте. Трамвай йөртүченең учы зур, коры, җылы иде. Менә шушы учка йомарланып кереп ятсаң, бик рәхәт булыр иде кебек. Кулындагы билетның озаграк алынмавын сизепме, трамвай хуҗасы каерылып Мәүлиягә карады: "Ә синмени әле бу? Йөрәкне алдың бая". – Мәүлия аклангандай елмаеп куйды. Бүтән хатыннар кебек тиз генә сүз таба алмый ул кирәк чакта. Хыялый булгангадыр инде. Гел уйланып йөргәнгә...

Мәүлиянең чын тормышы хыялында. Болай ул үзе башкалар кебек – эшкә бара, кайта, кешеләр белән аралаша. Ашарга әзерли. Ашый, юына. Әмма, көнне тәмам итеп, урын-җиргә менеп ятуга ул хыялындагы яшәешенә күченә. Хыялда яшәү шундый рәхәт. Анда синең күзләрең ни күрергә теләсә, шуны күрә, колакларын ни ишетергә тели, шуны ишетә. Хыялда ирешелмәгән теләкләр юк. Чынбарлыктан качуның хыял ишегеннән кереп китү юлын ул бик бәләкәй чакта ук тапты. Һәрвакыт рухи киеренкелектә яшәгән бәләкәй кыз өчен шифалы ачыш булган икән ул. Бәләкәй балаларның үен дөньясы кебек үк шифалы. Сабыйлар да үз-үзләре белән сөйләшеп, япа-ялгыз уйный беләләр бит. Башка балаларның ничектер, Мәүлиянең хыял дөньясында мәхәббәт хөкем сөрә иде. Мәхәббәт дигәннәре башта зурларның кыланышын күреп торып чамаланган сәер дөнья кебек керде аның күңеленә.

Алты яшьләр булгандыр Мәүлиягә, күршедәге чибәр Зәрәне урладылар. Зурларның аһ-уһ килеп сөйләшкәннәрен кыз колагын торгызып тыңлады. Югары очның Мәхәсим исемле бер егете чибәр Зәрәне тарантаска салган да алып киткән икән. Кыз карышкан, елаган, тешләшкән. "Яратмыйм мин сине, яратмыйм!" – дигән. Шуннан Мәхәсим яшь кәләшен, беренче көннән үк ефәктәй итү өчен, кыйнаган икән, имеш, – ул бит кызны ярата, нигә карыша!

Кичтән күз тирәсе кара янган Зәрә таба сорап керде. Кыяфәтеннән бик оялып кына ишек төбендә таптанды. Мәүлиянең әнисе бик җәлләде аны: "Илаһым, бу бала да минем ише кыйналып гомер итәр микәнни соң?!" Бу төнне Мәүлия озак йокыга китә алмады. Хыялында тарантаска төялеп килгән егетләр аны урларга иттеләр, ул алар белән кышкы юллардан каядыр очты. Әбисенең такмагындагыча иде:

Кызым, кызым кыз кеше,
Кызыма килер йөз кеше.
Шул йөз кеше арасыннан
Алып китәр бер кеше.

Дилбегәсен урап тоткан егет шул йөзнең берсе икән дә, Мәүлияне бик ярата икән... Мәүлия әле үзе яратуның ни нәрсә икәнен белми. Әмма үсә-

үсә анысын да төшенде. Сыйныфташы Вәдүт гел дингезче булам дип сөйләнә, абыйсының матрос фуражкасын киеп мәктәпкә дә килә иде. Үзенә тормыш хыял өчен ин кулай малай итеп Мәүлия Вәдүтне сайлады. Хәзер ул хыялында айлар буе дингездә йөзгән Вәдүтне өйдә сабыр гына көтүче инсафлы хатын, алты бала анасы иде. Өстендә дворян хатыннарыныкы кебек озын бәрхет күлмәк... Бу тәти хыял озакка бармады...

Инде сигезенче сыйныфка житкәннәр иде. Бервакыт, мәктәпнен утын әрдәнәләрен аралаганда, капкадан ялкау гына килеп керүче Тәмизне күреп, кулындагы пычкысын төшереп жибәрде Мәүлия.

— Бик вакытлы килден Тәмиз, әйдә Мәүлияне алыштыр, — диде хезмәт укытучысы.

— Юк, юк, арымадым, абый. — Бер башыннан Тәмиз тоткан пычкыга кыз кабаланып килеп ябышты. — Кисәбез әле.

Яна гына эшкә тотынган Тәмиз белән кулдаш булып пычкы тарту тәмам сулышына капса да, Мәүлия сынатмады. Булдыра ул, шәп ул, көчле ул, чыдам ул! Шул төнне Мәүлия күктәге тулган айны тәүге тапкыр күрде бугай. Элек тә балкыгандыр инде ул. Ләкин бу төнне айның серле нурына түзәрлек түгел иде. Кыз торып утырды, ак пәрдәләрне ачты. Кышкы төнгә көмеш нурлар сибеп балкучы ай тәрәзәдәге бозлы бизәкләр аша Мәүлиягә карый. Белә ул анын өр-яна серен, белә. Бусы чыннан да мәхәббәт иде. Озакка иде. Бәлки гомерлеккә дәдер әле.

Хәзер инде Мәүлия хыял дөньясына төннәрен генә түгел, көндезләрен дә китә. Мәктәп юлында дус кызларын көтми. Уйланып барырга комачау итәләр, сөйләштереп. Инештән су ташу жан рәхәте. Инеш ерак. Көянтәнне элсәң дә тар сукмактан жырлый-жырлый барасын. Су ташып йөргән кызга эшлексез дип әйтүче дә юк. Рәхәте белән хезмәте бергә. Кайвакыт эт өйрәтергә чыккан Тәмиз очрап куя. Хәзер инде анын эте дә таный Мәүлияне. Тәмиз мәктәптә кызны күрми. Малайның мәктәптә соңгы елы иде. Мәүлия хыяллана калды, ә ул укып бетерде дә каядыр техникумга китеп барды. Аннан армиягә. Армиядән Мәүлиягә "дусларча" хат язды. "Синең адресынны дус малайга бирсәм, үпкәләмәссен бит", — дигән. Мәүлия инде үзе дә шактый тәвәккәл кыз булып үсеп житкән иде. Дус кызларына да сөйләмәгән серен ачып жавап хаты юллады: "Тәмиз, дусларына бүләк итәр өчен үстерденмени син мине, суга барган-кайтканымны этең белән бергә саклап...", — дип уенкөлке белән башланган бу хатта башы булган егет анларлык киная бар иде. "Ялкау бит мин, Мәүлия, хат язарга иренәм. Ә син язсан, рәхәтләнеп укырмын. Алай да көт әле син мине", — дигән сөенечле — әллә ничә мең хыялый төнгә аш булырлык жавап килде.

Тәмиз армиядән өйләнеп кайтты да Себер ягына нефть эшенә китеп барды. Мәүлия Казанга килеп, эшкә урнашты. Әчкече әти кызын укытырлык акча таба алмады. Мәүлия ирсез генә бала тапты. Хыялында улын Тәмизнеке дип, үз-үзен ышандырды. Малай гажәп акыллы булып үсте. Төрек-татар лицейлары андый малайлардан бер дигән кешеләр тәрбияләде. Укуы әйбәт иде. Тиздән, жиз иләктән үткәреп, малайны Төркиягә үк жибәрделәр. Хәзер инде шунда урнашып та калды. Укый да бугай. Башлы малай Мәүлиянең хыял дөньясына ныгытып кереп урнаша алмады. Чөнки хатын, улы яшәгән мохитне начар белгәнлектән, ни рәвешле хыялланырга белмәде.

Мәүлиянең үз дөньясына бикләнеп яшәргә яратуын, әмма олы мәхәббәт хакында хыялланып яшәвен эштә дә беләләр иде. Озак кына Мөслим Могамаевка гыйшык тотып йөргәнен үзе сөйләде. Жырчының жырлары язылган тасмаларны, хәтта элеккеге патефон тәлинкәләрен Мәүлия өчен

бергәләп эзләделәр. Хисләреңне яшермәсәң, яхшырак икән. Шуңа күрә хатын хәзер һәр яңа гашыйклыгын эштәге әшнәләре белән уртаклаша.

– Малакаем, сиңа кияүгә чыгарга кирәк, – диләр аңа.

– Кирәк тә соң, юк бит. Кешедән артканга үзем кызыкмыйм. Буе да, холкы да килгән булсын миңа. Мин җырлаганда кушылып уйнарлык булсын. Каршы дәшмәсен.

– Син бигрәк тагын. Алайса, кинода күргәннәреңне, китаптан укып белгәннәреңне генә ярат ит инде син, Мадам Бовари!

Мадам Бовари! Китап төреп торучы Талия апа сүзеннән ябышты да калды шушы кушамат. Типографиянең экспедиция дигән җирендә эшлиләр алар. Әзер китапларны, газета-журналларны төреп, озатып торалар. Мондагы халык та укымышлы. Газета- китап ише әйбернең дә брагы чыга. Әмма укымаслык түгел. Укыйлар хатыннар. Талия апа да кайчандыр Флоберның "Госпажа Бовари" дигән романын укыган икән ләбаса. Менә белеме ярады. Мәүлия кушаматлы булды. Кушаматның ниндие булмас. Китапны үзе дә табып укыды. Кушаматы белән килеште Мәүлия: ул чыннан да Мадам Бовари!

Бовари мәхәббәт иясен таба белгән. Мәүлиягә күренми әле монда. Хатыны үлгән ирләрне юри димләгән булып котыртулары да туйдырды. Бу уенны үзе башлаган иде дә бит. Кабатлана торгач, тәме китә икән. Шуңа күрә Гөлчирәнең газеттагы некрологларны юри мәгънә салып, укуына ачуы чыкты.

– Хафаланмасаң да була, дустым. Менә дигән кешем бар минем.

– Кем?

– Кем симәннең кече улы. Белми торыгыз әле бу юлы. Сәгате җиткәч, әйтермен.

– Эрләмәгән, сукмаган – кызым сиңа ыштанлык, дигәндәй бер өметсез хыялыңдыр әле тагын.

– Түгел, иртәгә үк хатларын алып килеп укытырмын. Озакка командировкага китте әле ул.

– Менә-менә! Командировкада мыни әле... Төрмәдә түгелме тагын? Аннан сырлап-сырлап хат язарга яраталар.

Өстенә басты бит каһәрең. Серле адреслы хат килеп төшкәч, Мәүлиянең үзенең дә йөрәге иң әүвәл рәхәт сулкылдап алган иде. Әмма хатны ачып укыгач, конверт тышындагы адресның мәгънәсенә бик тиз төшенде. Гөлчирәнең, әле конвертны күрмичә дә нәкъ өстенә басуына үртәлеп, Мәүлия елап җибәрде:

– Түгел! Син нәрсә, әллә мине юньле кеше карамаслык карачкы дип беләсеңме? Кай җирем кешедән ким?

– Юк, юк, җаным, тынычлан. Син безнең арада үзең бер, синдәгедәй куе бөдрә чәчләр артистларда да юк. Сәхнәдән җырлап йөргән җырчылар синең каршыда чыпчык кына. И, и-и, Мәүлия бәгырькәем. Без барыбыз да, теге театрда әйтмешли, синдәй-миндәй бозау. Безнең кимлек бер инде: байлык юк. Китапта гына ул урамда барганда миллионер егеткә бәрелеп, ярлы кызы бәхет таба. Гади генә бәхет тә ярар иде безгә. Шофер булса да, эчми торганы. Үзе белеп кулмәген, оекбашын алыштырып кия торганы. Үтүкләмәсә дә... Нәрсә елап торасың инде. Йә сәнә. Дөресен әйтеммени соң? Өстенә бастыммыни? Төрмәдә булса ни соң! Хәзер буй-сынлы, егәрле ирләрнең бөтенесе төрмәдә. Беркөн газетада күрдем әле. Камал театры артистлары төрмәгә спектакль күрсәтергә барганнар да шуннан фотосын басканнар. Исләрем-акылларым китте. Тамаша залы тулы тупырдаган тайдай егетләр.

Рахманның хатын бергәләп укыдылар. Җавап язарга да күндерделәр. "Яз әле син, яз. Кайчан кайта әле ул. Аннары уйларсың тагы... Син хыялыйга

хат алышу да бер дәва", — төпле акыллы Талия апа Мәүлия өчен хәл итте дә куйды.

*"Исәнмесез, сез ки минем өчен таныш булмаган Мәүлия. Мина сезнең адресны сезне белгән бирәү бирде. Кем икәне секрет. Ул сине яхшы белә, мактады. Душевный хатын дип әйтте. Әй, апасы, монда кара әле, без "ял иткән" жирдә иң житмәгән әйбер дә шул бит.*

*Мин үзем начар егет түгел. Не за что утырам. Беренче хатта ук статьямны әйтеп тормыйм. Ну, Мәүлия-жан жавап яз син мина. Үкенмәссен. Фотонны жибәрсәң, күкрәк кесәмдә генә йөртер идем. Үзем дә салырмын фотканы. Монда ул нәрсәне бик тиз генә эшләтеп булмый. Почмак саен фотосалон юк, диюем. Син аңлыйсың инде!*

*Кайнар сәлам белән Рахман дип белерсез".*

Сезе белән сине буталган, өтере, ноктасы югалган хатны Мәүлия кат-кат укыды. Адрес бирүче кем булыр икән дип тә уйламады. Күзе һаман бер жөмләгә тукталды: "Фотонны күкрәк кесәмдә генә йөртер идем...". Мәүлия серле сүзләр алып килгән конвертны кат-кат әйләндерде. Конверт тышындагы: "Почтальон агай, быстро шагай", диган язуны укып елмайды.

Жавап язарга өлгергәнче хатның икенчесе килеп житте. Хат эчендә фото бар иде. Фотода күкрәк тинентен шәрә ир кеше. Кулларын чалыштырып, гәүдәсен кочаклаган. Кырылган башында керпе чәчләре шактый куерган инде. Күз карашы кыеп карый торган. Бу Рахман бер дә акылсыз кешегә охшамаган. Аның кебекләр сугыш вакытында геройлык кылсалар, тыныч, (хәер, кая ул тынычлык!) заманда кемнедер яклап пычак астына керәләр.

Мәүлия аны герой итеп кабул итте. Хәтта өченчеме-дүртенчеме хатында Рахман зонага эләгүенең сәбәбен "чистосердечно" язгач та, ул Мәүлия өчен бүрек караклары кәкре каенга терәткән әрекмәнбаш түгел, бәлки үз өстенә гаеп алып, бүтәннәрне бәладән коткарган Алып батыр булып калды.

Жавап хатларында Мәүлия ана үз тормышын түкми-чәчми сөйләде. Әз акчага кысан көнкүрешен, малай укытуын, жыр яратуын, назга сусавын... Бәлки бер күрмәгән кешегә бу кадәр ачылып китәсе дә түгелдер. Ләкин... Кәгазьдән дә түзем ни бар. Әле ырудан калмаган яшь хатынның — ул үзенә бик яшь тоела — күнеленә тәңгәл ярын табарга омтылышы гаеп мени? Кабырчыгыңны ачып, үз йөзеңне күрсәтми генә жавап "биюенә" исәп тоту дөрес тә түгел. Ачылды, Мәүлия ачылды. Ана инде Рахманны ярата ук кебек тоела башлады.

Төрмә ишеге ачылыр сәгатьне алар зонаның икесе ике ягында көннәрне берәмтекләп санап көттеләр. Хәзер инде Мәүлия кибетләрнең ирләр киеме сатыла торган бүлекләренә дә кагыла. Юк акчасын бар итеп, Рахманга кием-салым да сатып алды. Вак-төякне инде. Зурысына акча кая ди? Төннәрен хыял дөньясында Рахманның татуировкалы зур куллары Мәүлиянең битләреннән назлап сыйпый. Алар, имеш, диңгез буена ялга китәләр... Рахман биек-биек тауларга Мәүлиясен күтәреп кенә менә... Ә диңгезгә алар үз машиналарында гына барганнар икән. Әй, гел-гел диңгез буена йөрү дә туйдыра. Инде хатын хыялында Рахман белән Мәүлия Мишә буенда өй салырга керешәләр. Мәүлия төне буе кирпеч бәясен чутлый, такта юллый, жиһаз сайлый... Иртәгәсен төнге мәшәкате сәбәпле юньләп йокы күрмәгән килеш эшкә китә. Төнге хыялларын исә Рахман хәере белән кайткач булачак тормыш рәвеше итебрәк колония адресына озын хатлар итеп яза:

*"И Рахман, жанымның алашкан кисәгедер лә син. Кайтыр көннәренне санап, календарьда һәр үткән числоны сызып барам... Син үзенне балта тотып эшлим дигәнсең. Хәзерге заманда бик кирәкле һөнәрең бар икән,*

*бәгырь генәм. Хәзер бит бөтен кеше йорт салып женләнә. Хәле барлар. Үз йортын белән яшәү рәхәт булыр иде. Син дә кайтып әйбәт эшкә урнашсаң, әллә без дә берәр матур өйгә тырышып карар идек микән? Тәрәз каршына ясмин куагы утыртып, шунын хуш исен иснәргә хыялланам. Эштәгеләр белән Сембергә сәяхәткә барган идек. Анда урамнарга чыршы да, тирәк тә түгел, ясмин куагы тезеп утыртканнар. Исләр китмәле...*

*Төзү материалы табып була хәзер. Кулы белгән кеше осталар ялламыйча да булдырып чыга ала. Менә нинди синең Мәүлиян. Тумаган тайның билен сындыра торган хыялый хатын. Минем хыялда әле ул өйнең бакчасында бер бәләкәй кыз да йөгереп йөри...*"

Эштәгеләр Мәүлиянең бу юләрләнүе озаккарак китүенә, көткәненең әллә кем түгел, бәлки "төрмә кошы" булуына көенәләр. Төрмәгә киткәнче гел әйбәт кенә булган кеше дә, аннан бозылып, үзгәреп, женлегә әйләнеп кайта ди бит. Мәүлия үзе генә исе китмәгәндәй көлә. Төннәрен гел "төрмә кошын" уйлап саташып чыгулары хакында хәбәр бирми. "Кайткач күз күрер, ахирәтләр. Миңа анын бүгенгесе кыйммәт. Теш сызлаганда уйлар кешең дә булмаса, бүген ятып үлешле".

* * *

Рахманнан хат бар. "Мәүлия-жан, чәенне куя тор, 30 ноябрьдә миңа капка ачыла", — дип тәгәлләнгән ул хат Мәүлиянең хәрәкәтләрен тизләтте, итәк астына жил үтеп, этеп йөртә диярсең. Ул өен Рахман кайту көненә ни рәвешлерәк бизәсен әллә кайчан ук хыялланып куйган иде инде. Ялга каршы авылына кайтып китте. Аннан казның түш мамыгыннан тутырылган ике мендәр сатып алып килде. Яңа туган бәби өчен генә тотарлык ул мендәрләргә башын куеп-куеп карады. Бер мендәрдә үзенең башы, икенчесендә — Рахманныкы.

Мендәрләргә карап-карап йөрде дә, бер кичне киергесен табып, мендәр тышы чигәргә утырды. Анын бит әле бу яшенә житеп, туйлап, бирнәләп, кияүгә чыкканы юк. Шуны уйлап, Мәүлия үзенә бирнә әзерлисе итте. Әзере юк сыман, ал чәчәкле зәңгәр сатин алып, юрган сырды. Идәндәге паласны алыштырды. Яңа пәрдәләр элде. Югыйсә, Рахман үзгәрешне сизмәс тә. Анын бит Мәүлия өендә булганы юк. Хәтта савыт-сабага да чират житте. Юшкын каплаган чәйнек урынына яңасы алынды, кеше килгәндә генә тота торган чынаяклар шкафның өске киштәсеннән төште.

Азык-төлек, тәм-томга да чират житте. Һәр төрле ризыкны Мәүлия күпләбрәк алып куйды. Пешерәсен пешерде. Хәзер бозылмый. Бер таба гөбәдия, алып кереп жылытканны гына көтеп, балконда утыра, койкасын да пешереп чыгарып куйган. Рахман кайткач, вак-төяк мәшәкать белән иң изге эштән — яратышу, бер-беренә якынаюдан бүленмәс өчен алдан ук күрелле бу хәстәр.

Рахманнын ишектән керер сәгатенә кадәр үк уйланылган иде. Ишек төбендә аны яңа башмаклар көтә, ванна бүлмәсендә пижама. Төрмәдән соң ванна гына аз булыр. Чиста киемнәр тоттырыр да мунчага жибәрер ул аны. Төрмәнең бөтен әшәкесен ир шунда калдырып кайтыр. Мунчаны уйлагач, базарга чыгып, каен себеркесе алып керде. Барысы да булды дигәндә генә, кырыну әсбабы юклыгы исенә төште. Монысына хатын аптырабрак калды. Яхшы әсбаплар шактый кыйммәт икән. Акчасы саекты бит әле. Жаен тапты тагын. "Жиллет" жыелмасы алды — бер тапкыр тоткач, ташлый торганнарын.

Инде үзен карасын Мәүлия. Парикмахерга йөрисе юк — табигый бөдрә чәче кемне дә кызыктырырлык. Тырнак буяп, маникюр ясап йөрүне өйрәнә алмады. Алайса нишләсен икән сон? Уйлый торгач, кичтән үк үзе мунча

кереп кайтырга булды. Чиста тәннең исе тәмле. Матур халаты бар.

30 ноябрь тоташ көтүдән гыйбарәт булды. Тавык шулпасын балконга бер чыгарды, бер кертте. Бәлешкә дип тураган итен суыткычтан бер алды, бер куйды. Караватт түрендә чигүле тышлык кигән мендәрләр, без әзер дигәндәй, кукраеп утыра. Ак ашъяулык җәйгән өстәл өстендәге чәчәкләр дә көтеп зарыкты. Ишек кыңгыравына кагылучы булмады да булмады. Төштән соңрак Мәүлиянең хәлиткеч көне икәнен белгән ахирәтләре телефоннан бимазалый башлады. "Юк шул", "күренми әле", "белерсез әле" – кебек өтек-өтек җаваплар бирү хатынны йөдәтте. Телефонны алмаска тырышты. Тора-бара билгесезлек ачуын китерә башлады. Капка янына каршы алырга бармавына үкенеп тә куйды. Һаман горур булам дигәч тә инде...

Икенче көнне Мәүлия эшкә бик кәефсез килде. Һаман шул ук: "юк", "күренмәде", "белмим" кебек җавапларны ишеткәч, аны бүтән аптыратмадылар.

Бер атнадан, шулпалар түгелгәч, гөбәдияләр күрше-тирә белән ашалгач, ишектән ишелеп килеп керде ул. Итәгенә аю басып карамаган бу ир-ат өммәте уйлаганы юш килмәгән хатын-кызның гел тәртәгә тибү гадәте барлыгын белми иде шул. Мәүлия киресенә каткан иде. Күрешү салкынча булды. Чишенеп, киемнәрен чөйгә элгәч, Рахман өй эчен күздән кичереп соклангандай итте:

– И-и апасы! Синең өең бик кәттә икән. "Кысан яшим", дип язган идең. Монда полный шәһәрчә муллык лабаса. Безнекеләрнең авылда телевизорлары да юк. Түбәләре кыйгайган, коймалары ауган. Шуларны рәтләп, атнам үтте дә китте. Прости, синең янга кичегебрәк килдем. Но зато бөтенләйгә! – шулай дип ул, баш бармагын канәгать тырпайтып, шаркылдап көлеп җибәрде.

Мәүлия хатлар аша белгән кеше түгел иде бу. Каш, борын, авыз – шул ук, фотодагыча. Әмма сүз төзү тәртибе хатлардагыча түгел, бүтән. Аннары кемнәр ул "безнекеләр"? Әти-әнисеме? Авылда Рахманны гаиләсе көткәнме әллә?? Үзеннән алты яшькә кече икәнен белгәч, Мәүлия аны өйләнмәгән егеткә чыгарган иде. Авылда хәзер егетләр кырык яшькә кадәр буйдак йөри бит. Ике арадагы хатларда бу турыда, нигәдер, сүз кузгалмады. Мәүлиягә утыз сигез яшь, димәк, бу "арысланга" әле утыз ике генә!

Кашык-тәлинкә өстәлгә менгәч, шкафтан бер матур шешә төшкәч, йөзләр ачылды. Озак кына сөйләшеп утырдылар. Күп нәрсә ачыкланды. Рахман килеп керүгә тыгынаеп калган өендә Мәүлиягә кысан ук була башлады.

Рахманның чыннан да хатыны белән малае бар икән. Алар икәүләшеп аларны төрмә капкасы янына ук килеп каршы алганнар. "Ну мин ана кайтмыйм. Ул сатты бит мине!" Шешәдәге сыеклык телне ача. "Сату" тарихы да мәгълүм булды. Һич тә бүрек урлаган караклар юлында ялгыш очрап тотылмаган икән Рахман.

– Дуслар кайтканые. Шашлык та шашлык диләр. Минем үземнең сарыклар юк. Ул тинтәкләр авыл кешесендә бар да бар һәм дә бушлай дип беләләр. "Әйдә, суй инде сарыгыңны безнең хөрмәткә!", – дигәч, тагын "саран тәре!" дип тә өстәгәч, кытык килде бит, апасы. Колхоз көтүеннән бер сарыкны алдым да киттем. Сыйландык малайлар белән бик шәпләп. Өй борынча эзли башлаганнар теге малны. Минем Хәтирә тоткан да әйткән. "Зинһар өчен тавыш куптармагыз, түлибез", – дигән. Каян килгән алла бәндәсе. Честный! Үземне саткан, төрмәгә олактырган шул хатынны гафу итәмме мин! Так что мин синдә калам, Милашка! Кара, исемең матур икән синең.

Бөтен кич буена ишеткән беренче ягымлы сүз иде бу. "Апасы да, апасы!" Яратмый Мәүлия шулай эндәшкәнне, җене сөйми. Авылы аша урап килгән

Рахманны мунчага җибәреп торасы юк инде алайса. Чигүле тышлык кигәч, кунак кызы кебек күркәмләнгән мендәрләрне дә, мөгаен, ишмәс Мәүлия. Төнгә каршы куып чыгармас, әмма иртәгәсен ишеккә күрсәтер.

Ике елга сузылган хыялының чынбарлыкка әверелмичә генә чәлпәрәмә килүенә Мәүлиянең артык исе китмәде. Рахманны тиешенчә каршы алу ыгы-зыгысына бирелеп, өченче көн сыйныфташы Зәмзәмия белән сөйләшкәндә ишеткән хәбәрне колак яныннан гына үткәргән иде. Югыйсә, Зәмзәмия иң мөһим хәбәрне әйткән икән бит: "Малакаем, базарда йөргәндә Тәмизне очраттым. Хатыны белән йөриләр иде. Әй, малай! Киендергән соң хатынын. Киенүен киенгән дә бит , чирле икән... Табибка күренергә дип килгәннәр Казанга. Эшләүләре һаман Себердә икән".

Мәүлиянең ике җиргә урын җәя башлаганын күргәч, Рахман кайнап чыкты:

– Ты брось. Утыз ике яшьлек ябь-яшь ирләр бусагаңда аунап ята мәллә?! – Мәүлиянең каш астыннан сөзеп кенә караган күзләрендә шайтани очкыннар кабынуын күргәч, юашлана төште. – Сагындым бит мин сине. Хатларыңны укыганда бөтен барак көнләште миннән.

Хатын эсселе-суыклы булып, дертләп китте. Аның йөрәк серләре язылган хатларны бөтен барак белән бергә җыйнаулап укыганнармы?!

– Син! Ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы. Сиңа гына язган хатлар иде ул!

– Шулай, апасы, шулай. Кызыгулары да шуңа – миңа гына язган хатлар булганга!

– Җавап язучысы да син түгел иде диярсең! – Эчке шикләнү белән әйтелгән бу сүзенең рас икәнен белгәч, Мәүлия җенле өермәгә әйләнде:

– Бар, чыгып кит. Миңа хатларны кем язган, мин шуны көтәм...

– Кызма әле. Мәүлия-җан, мин алай килештереп яза белмим бит. Шуңа күрә генә инде. Түләдем мин. Һәр хат өчен бер кап сигарет! Бик кыйммәт бәя ул анда. Йә, кил инде монда. Кочаклыйм үзеңне. Ачулану килешә үзеңә, алсуланып чыктың. Йә, бер үбим әле...

Эче-тышы ялган белән тулган бу кешенең үбүе дә, кочуы да, олы куллары белән хыялындагыча назлап, битеннән сыйпаулары да кирәк түгел иде хатынга. Китсен, күзеннән югалсын! Ике ел тормышын эчтәлекле итүенә рәхмәт анысы. Бетте, фильм тәмам. Әйе, кинодагы кебек яши шул Мәүлия – Милашка, Мадам Бовари!

Күнеленә хуш килмәгән кеше белән араны кистереп өзә белү гадәте бу юлы да ярады. Рахман, шәһәр янындагы авылдан иде. Казандагы туган-тумачасын исенә төшерде. Ничек кергән – шулай җыенып, Каравай бистәсенә таба юнәлде. Кабат-кабат килер әле ул. "Синнән башка яшәр хәлем юк", – дип, Мәүлиянең алдына килеп тезләнер. Утыз ике яшьлек тап-таза ир-егетнең Мәүлия кебек яшьлеге узган хатынга кирәкмәвен аңлый алмый интегер. Ни кирәк соң бу хатынга? Әйтте бит, авылга кайтмыйм, сине генә яратырмын, диде. Ә ул куа, кабул итми. Аптыраш, билләһи.

Икенче көнне Мәүлиянең эштән кайтуына Рахман бусагада утыра.

– Йөрәгемә урын таба алмыйм. Бармадым мин җизниләргә. Төрмәдән чыктым әле дип, ничек барып керәсең. – Карасана, намус әсәре бар икән үзендә. – Бомжга әйләнү озак түгел икән.

Мәүлия ул урам сукбайларын кызгана. Һәркайсының бер каргалган язмышы бардыр инде дип уйлый торган иде. Инде менә чиратка басканы үз бусагасында җирәбәгә ни язганын көтеп утыра. Хатын ишекне дәшми генә ачты. Кыяр-кыймас иярep кергән Рахманга ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде. Чәен куйды, ашын җылытты.

— Нигә мескенләнәсең, дустым. Синең бит өең, гаиләң бар. Хәзер олы-олы түрәләр дә авылга кайтып, кыйшаеп беткән өйләр сатып ала. Авыл һавасына, җирдә казынуга кызыга, — диде ул, ниһаять.

— Анда син юк, Мәүлия-җан. Өч ел буе язган хатларыңны укып, җаным белән беректем мин сина. Бер атна торып килдем бит инде. Ябышмас миңа андагы тормыш. Син кертмәсәң дә, китмим мин анда. Хатларыңда язган иден бит, өй салырбыз дип. Салам. Үзем эшлим бөтенесен, Мәүлия-җан. Челтәр бизәкле итеп. Кызыбыз да туар. Кума мине... Әйдә, бер генә кич булса да, йоклап карыйк. Күкрәгемә кысыйм сине, — Рахман хатларындагы кебек сөйли иде. Аек баштан акыллы гына күренә бит әле бу!

Мәүлия урынны бергә җәйде. Яңгыр көткән иген басуы кебек, наз тансыклап коргаксыган хасияте бер кинәнергә тиештер бит инде ләбаса! Бу төн әллә булды, әллә юк. Аңламассың. Хыял дингезенә кереп югалмаган бу төне, әйтерсең лә, чын түгел, төш булгандыр. Иркәли белә икән Рахман. Мәүлия ишетергә зарыккан сүзләрне дә тапты. Иртәгәсен алар татуланып уяндылар. Ләкин беренче очрашудагы шикле күләгәләр якында гына йөри иде әле. Бер алдаган, гел алдар. Гаиләсен ташлаган кеше, сине дә ташлар... Рахман хәзер Казанда эш эзләп карар. Урнашыр. Җизниләрендә, яисә, җае чыкса, тулай торакта яшәп торыр. Ике ай чамасы Мәүлиядә күренмәс. Янәмәсе, сынау вакыты узар. Сынау хакында йөзенә бәреп әйтмәде хатын. "Улым ике айга каникулга кайта. Килеп йөрмәсәң, яхшы булыр иде", — дигәнрәк матур хәйлә тапты. Кыш уртасында нинди ике айлык каникул инде, югыйсә. Рахман килеште. Шулай аерылыштылар.

Яңа ел алдыннанрак Оренбургтагы дус хатыны килеп төште. Зөлфә шулай ел да бер урый. Шәлләр төяп килә. Төрле оешмаларга кереп сата. Яшәве Мәүлиядә була. Килгән саен берәр матур шәл бүләк итеп китә. Бу юлы да әйбәт кенә сату итте Зөлфә. Әмма беркадәр шәлләре үтмәде. Мәүлия сирәк күренгән дустына Рахман тарихын сөйләде, әлбәттә. Нишләп йөри микән, диештеләр. "Бер дә бүтән түгелләр әле, хатыны янына кыяклагандыр. Казанда булса, чуар ир йөрәге түзмәс, Мәүлиянең юлына биш чыгар иде. Көнләшеп булса да, күзәтер иде, — диде Зөлфә. — Авылы якын гына дисең бит. Әйдә, шәл саткан булып, урамнарыннан бер урап кайтыйк. Җайлап кына белешербез. Партизаннар кебек".

Партизанлык ярады. Капка төбендә кар көрәп йөрүче беренче очраган малайдан ук Рахман Фәйзетдиновлар өен сорадылар:

— Минем әти ул — Рахман Фәйзетдинов. Бәй, менә безнең өй. Әти эштә. Ул хәзер газовик булып йөри. Газ баллоннары тарата.

— Юк, наным, әтиең кирәкми безгә, шәл сатабыз. Әниең өйдәдер?

Малайның әнисе укытучы икән. Ул да мәктәптә. Өйгә кереп торасы булмаганга сөенделәр генә. Аның каруы, мәктәпкә кагылып ике-өч нәзек шәл сатып чыктылар. Челтәр-шарфның берсен Хәтирә алды. Юка гәүдәле чандыр гына хатын икән Рахманның хәләле. Шарфны ана Зөлфә юнь бәягә бирде. Кардәш кебек бит инде.

Бая әйткән тезләнүләр булды булуын, әмма Мәүлия хәзер чакматаштан катырак иде.

• • •

"Төрмә кошы вакыйгасыннан соң Мәүлия боегып калды. Әмма сынатмады. "Әйттем мин сезгә. Кайтып күренгәнче генә кирәк ул миңа дип. Миңа ир кирәк түгел. Кемгә кирәк — шул асрасын". "Асрасын" сүзенә юри басым ясады. Эштәге хатыннар каршы дәшмәде. Һәркемнең өендә үз ире—чире бар шул. Тоткасыз чемоданы. Тотып йөрергә җайсыз, ташлап калдырырга җәл булганы.

* * *

Тәмизнең хатыны үлү турындагы хәбәр Рахман вакыйгасын тиз оныттырды. Һаман шул, бөтенесен алдан белүче саескан Зәмзәмия ирештерде бу хәбәрне. "Шалтыратып кайгысын уртаклаштым. Миндә мобильнигының номеры бар. Син дә язып ал. Хәлен белерсен. Авылдаш бит. Чит җирдә ят кешегә бик кирәк түгел анын хәсрәте. Ә без уртаклашыйк кайгысын. И жал инде аны. "Кырык яшендә ике бала белән ялгыз калсын әле ир кеше. Шылтырат син дә, ташламыйлар дип юансын, ичмаса".

Көне-сәгате белән кыймады Мәүлия, бер айлап вакыт үткәч кенә шылтыратты. Ашыкмавы яраган икән. Тәмиз иркенләп сөйләште. Казанга юл төшсә, керермен, диде. Әле башы каткан чагы икән. Балалары зур инде, өлкән сыйныфта укыйлар, ди. Игезәкләр. Ике елдан аларны укырга урнаштыру хәстәренә керешәсе булыр, ди. Институтка Казанга кодалыйм, ди.

Тәмизнең газиз тавышын ишетүнең рәхәтлеге! Сөйләшүе дә һаман шулай риясыз. Ялган вәгъдә бирмәс, буш сүз сөйләмәс. Тәмиз, Тәмиз – чиста дигән сүз икән ул. Төркиядәге улының теленә шул мәгънә белән кергән инде тәмиз. Мәүлия дә, җае белән, бу сүзне әйләнешкә кертте. "Янәсе, бу сөлге бик тәмиз", я "бу су тәмиз күренә". Күңелгә якын кешенең исемен кабатлап йөрү өчен нинди матур юл тапты!

Тәмиз белән сөйләшүдән соң ике еллап вакыт үтте. Өйләнде микән? Шылтыратканы булмады. Мәүлия үзе кыймады. Егет армиядә чагында күңел хисләрен сиздереп, бер авызы пешкән иде бит инде.

Трамвай йөртүченен Мәүлия кулына кагылган җылы кулы әле һаман да булса очкын көтеп яткан тырбызык шикелле мәхәббәткә сусаган күңелне дөрләтеп җибәрде. "Их, йөрәгенне шушы учка саласы иде!" – дип уйлады ул, трамвайдан төшеп калгач. Рельслар буйлап тырт-тырт китеп барган сары трамвай аңа бик якын булып тоелды. Номерын хәтерләп калды.

Икенче көнне тукталышка чыккан Мәүлия беренче килгән трамвайга утырмады, икенчесен дә, өченчесен дә үткәрде. Дүртенче булып килгәне сары иде. Шул! Мәүлия бу юлы да йөртүче кабинасы артына килеп басты. Урта яшьләрдәге, басынкы кыяфәтле ирне күзәтеп барды. Колагы, янак сөяге генә күренә иде ирнең. Шунда Мәүлиянең күзе йөртүче каршындагы көзгегә төште. Күзләре очрашты. Әмма трамвай хуҗасының игътибарлы карашы Мәүлиядә озак тукталмады. Бүгенгә бәхетле булу өчен хатынга шул да җиткән иде.

Ничек якынаерга икән соң бу соры күзләр иясе белән? Уйлый торгач, Мәүлия бер хәйлә тапты. Кондуктор белән дуслашырга кирәк. Көн дә шушы трамвайга утыра торган хатынны кондуктор апа күптән абайлаган иде инде. Мәүлия үзе башлап эндәшкәч, ачылып сөйләшеп китте. Мәүлиягә юньрәк бәягә айлык юл йөрү билеты тәкъдим итте. Алды Мәүлия, билеты болай да бар иде югыйсә. Үз чиратында яхшылык кылып, гел бушлайга газеталар тәкъдим итте. Эшләгән җирендә аз-мәз сыйфаты киткән газеталарны бракка чыгаралар. Укымаслык түгел. Көн дә күчтәнәч калдырып төшә торган чибәр хатынны трамвай йөртүче дә таный башлады. Еракта Мәүлия күренсә, кузгалмыйрак көтеп тора. Күп вакыт Мәүлия үзе көтә.

Хәзер инде Мәүлиянен төнге хыял дөньясына шушы басынкы кыяфәтле ир керә. Хыялында Мәүлия аны тәрбияли, авырса, терелтә. Аркасын сылый, эшенә алып бару өчен термоска кайнар аш сала. Ризыкны тәмиз, әй лә.., кершәндәй ак сөлгегә төрә. Трамвай депосындагылар ирнең моңача аксыл янакларына төс кергәнгә гаҗәпләнәләр. Сораштыралар. "Әллә кайчан өйләнәсең калган!" – дигән булалар. Болар барысы да хыялда. Чынбарлыкта

исә Мәүлия трамвай йөртүче кабинасына карап-карап алудан уза алмый. Кондуктор хатын белән дуслашып беттеләр инде. Шул рәвешле гыйшык тотып йөрүенә өч айлап узды бугай. Алга китеш юк.

Отпускада, авылында булып килде. Трамвай йөртүче анда да исеннән чыкмады. Ялдан соң беренче көн эшкә барышлый сары трамвайны тагын озак көтәсе булды. Көтмәс тә иде. Өметләнеп бу көтүләрдән башка дөньясы бигрәкләр бушап кала шул. Ниткән заман житте бу. Мәүлия кебек кырыкка житкән хатынга түгел, япь-яшь кызларга кияү юк. Кайсы эчкече, кайсы наркоман, кайсы асылына, кайсы авариядә һәлак була, кайсы армиядән имгәнеп кайта, кайсы зәңгәр – кемне яратырга, кем белән оя корырга, хыялдагы матур кызны кемнән табарга? Хәер, бала табып үстерергә вакыты калмады инде хәзер Мәүлиянең. Ипле, төпле, тәмле сүзле бер иптәш табып керсә картлыгына, бәлки, бәхет шул булыр иде. Укымышлы малае Төркияне яратты. Кунакка гына кайтып йөрер кебек.

Килде трамвай. Кондуктор хатын гына түгел, трамвай йөртүче ир дә ачылып каршы алды. Мәүлиянең инде дус хатынга әйләнгән кондукторга авыл күчтәнәче бар иде. Тегесе, жире-күге белән сөенеп, рәхмәт әйтте. Пассажирларын да онытып, хәлләрен сөйли башлады. Мәүлиянең сүзне үз уңаенарак борасы килә:

– Ниме соң, болай сине эштән аерганга трамвай йөртүче сукранмыймы? Кайсы чакны көтеп тә аласыз..."

– И-и, исең китмәсен. Ачуланмый да, сукранмый да. Сабыр холыклы адәм ул. Егерме ел торабыз. Ирем ул минем...

Кондуктор тагын күпме сөйләгәндер, Мәүлия анысын ишетмәде. Башына кирпеч кебек орган хәбәрдән ул аңгыраеп калган иде. "Базарга керәсем бар", – дип, тиз генә трамвайдан төшеп калды. Ничә айлар бәллүр савыттай кадерләгән хыялы тагын чәлпәрәмә килде. Үзенә кирәксез тукталышта ул шундый озак басып торды. Аннан кинәт кенә башына тапкыр уй килде: "Карале, бу кондуктор юри генә әйтмәдеме икән? Ул ир бит анардан шактый яшь күренә". Икенче трамвайны көтеп алып, утыргач, кыенсынып-нитеп тормыйча гына сорады да куйды: "Үндүртенче маршруттагы 417 нче трамвайдагы бригада ир белән хатынмы, түгелме?". Әйе икән...

Шушы кирәкмәгән яңалыкны төяп, Мәүлия әкрен генә үзен бер кем көтмәгән өенә кайтты. Ике фатирга уртак ишекне ачып кергәч, үз ишегенең тоткасына кыстырылган чәчәк бәйләмен күреп, сискәнеп китте. Әллә тагын Рахман килгәнме? Ишеккә тагын нидер сөялгән. Сәгать! Сәгать тартмасына язу кисәге кыстырылган. "Туган көнең белән тәбрик итәм, Әүлия! Озак эшлисең икән. Сәгать алтыларда кабат әйләнермен. Насыйп булса, күрешербез. Мин".

Язуы Рахманныкы түгел. Кем булыр бу? Бүген Мәүлиянең туган көне икәнен дә белә бу кеше. Кырык яшьне билгеләргә ярамый дигәнгә ышанып, махсус "оныткан" иде Мәүлия бу көнне. Трамвайда ишеткән хәбәр дә кырык яшьнең бәхетсез яшь икәнен раслаган иде. Ә монда ... бүләк. Ә монда... әйләнеп килүне вәгъдә итәләр. Кем булыр бу? Әүлия–Мәүлиянең мәктәптәге кушаматы. Димәк, бу кеше аны мәктәптән үк белә!

Мәүлия бәхетле минутлар, сәгатьләр, тәүлекләр саныйсы сәгатьне өйгә алып керде.



Рашат
Низами

# МӘЧЕТ БҮРӘНӘСЕ

Кеше хәтере, диләр. Ә менә агачларның да хәтере барлыгын белә микән соң алар? Юктыр, мөгаен. Чөнки тормыш-яшәешнең мең төрле мәшәкатьләре арасында көн саен әвәрә килгән адәм баласының бу хакта уйланырга вакыты, ай-һай, кала микән?

Ә табигать — искиткеч сизгер һәм хәтерле. Күкләр кодрәте аңа әнә шундый сыйфатларны да бүләк иткән. Таза орлык туфракта тамыр җибәрсә, гөлләрдә яки агач ботагында гөлт итеп яшел яфрак кабынса, ябалдашлары этешми-төртешмичә генә күккә, кояшка үрелсә — Ходай боларны үзенең илаһи көче белән тәгаенләп, дәртләндереп тора, аларга үзенең шәфкатен юллый. Яшисе дә яшисе! Бар тереклек әнә шундый сулыш белән алгы көннәренә ашкына, ел фасылларын кичеп чыгар өчен үзендә көч һәм мая туплый.

Кешеләргә маңгай күзе генә түгел, күңел күзе дә бирелгән. Ул соклана, гаҗәпләнә, ярата яки нәфрәтләнә белә, тел ачкычлары ярдәмендә уен уйдырып сала. Тапкыр сүзле берәү «түгәрәк имәнем» дип ничек матур әйткән әнә! Безнең Яңык урманындагы бер аланда да булган андый түгәрәк имән. Агачларның бөтен сере, хәтере, яшәеше — еллар боҗрасы рәвешендә балдак-балдак булып кәүсәсенә уелган. Аларны «сүтеп» карасаң, — үзе бер гыйбрәтле кыйсса. Җөмләдән, шул тарихның сәхифәләрен вакыт төпкелләреннән актарып алыйк булмаса...

### Беренче боҗра

Тупырдап торган тап-таза, йомры-алтынсу имән чикләвеге көздән үк бик бәрәкәтле туфракка килеп эләкте. Юргандай калын кар астында салкын кышны хәвеф-хәтәрсез генә кичеп чыкканнан соң, язгы-ягымлы бер дулкын эндәште аңа: « Уян, бала, уяныр чагың җитеп килә синең». Турыдан-туры җавап бирерлек хәле булмаса да, ул әчке бер аваз белән әле үзе татып та өлгермәгән таныш түгел дөньяга беренче сәламен җиткерергә ашыкты. Ә аннары! Язның ягымлы-йомшак куллары, бик-биектән шифалы нурларын юмарт өләшүче Кояш һәм әйләнә-тирә мәгыйшәте аны үзенең сусыл, назлы, яшькелт кочагына бөтереп алды.

Барысы да — хәтерендә... Ул туфрак катыш иске яфрак белән томаланган дымсу урман җиренең сутларын эчте, көчәйде; бүртә-кабарына торгач, үзе дә сизмәстән, ялтыравыклы конгырт кабыгын салып ташлады. Борнап чыккан кечкенә-нәзек үсентесе өскә, кояшка таба атылды. Югарыга баккан нәни-

яшькелт яфраклары тирә-юньдәге илаһи матурлыкка таң калды, күкнең тинсез зәңгәрлегенә ашкынды.

Хәзергә арыш сабагыдай бер генә кылдан торган гөнаһсыз, яшь имән кәлшәсен алда башланмаган өр-яңа олы тормыш көтеп тора иде...

**Өченче бөжра**

Урман эчендәге зур агачларны шаулатып, кышын һәм җәен дә вакыт җиле исте, әнә шулар ышыгында япь-яшь имәнкәй өченче яшенә буын утыртып та өлгерде. Ул инде чибәрләнде, як-ягына сыгылмалы канатлар җибәрде, үзәк тамырын ныгыту гамәленә керешә. Моның өчен кирәкле бар нәрсә дә бар иде: Җил, Кояш, Яңгыр, Илаһи табигать гармониясе... Кәүсәр суыдай иртәнге чыклар коендырганда яшисе килү теләге бигрәк тә көчәя барды аның.

Шулай гап-гади көннәрнең берсендә беренче тапкыр курку тойгысы биләп алды аны. Вакыйга исә болайрак булды.

Яшәр өчен кешеләр җәйләрен ягар утын, мал-туарына печән әзерләү белән мәшгуль икән. Әле тоныкланып, ныгып кына килгән яшь имән янәшәсенә берзаманны җигүле ат белән икәү килеп туктамасынмы! Ике кеше дигәнең: берсе аларның утыз-кырык яшьләр тирәсендәге ат хуҗасы, икенчесе аның улы — җиде-сигез яшьләр чамасындагы малай иде. Әтисенең өстендә — каптырмасыз юка камзул, чүпрәк кәпәч, ә инде улының башында касмаклана төшкән иске кара кәләпүш.

Шушы тирәдәге ачык бер аланлыкта клевер һәм яфраклы сусыл үләннәр бик мулдан үсә иде шул. Атны җиңелчә тугарып, аландагы кипкән печәнне һәйбәтләп кенә чапканның соңында аны япьле сәнәк белән арба төбенә төяп тә салдылар. Бар да әзер булгач, урман юлына туры кереп борылыр өчен, хуҗа кеше атының сыртына каеш чыбыркысын төшереп алды!.. Йә Ходаем, менә шул чакта, тимер хутлы арбаның каерылып бер борылган мәлендә, аның дегетле тәгәрмәче имән үсентесе тамыр җибәргән аулаграк почмакка килеп чыкмасынмы! Шунысын яхшы хәтерли: нәкъ менә шул чакта аның өч яшьлек зифа буе һич уйламаган җирдән арба күчәре белән тәгәрмәч арасына килде дә кысылды... Тәгәрмәч битараф кына узды да китте, ә ул күчәрдәге тәмсез дегеткә буялган хәлдә, ярый әле исән-имин килеш кире үз урынына кайтарылып төште...

Бу - аның исән калуы иде. Таң сулары, аннары икенче көнне иртән шаулап яуган шифалы-җылы яңгыр яшь үсентенең бөтен авырткан җирләрен шифалады, акрынлап дегет ефәкләреннән аралады. Аның бик тә яшисе килә иде. Киләчәк көннәр, еллар өчен дип, Ходай аны саклап калды, яшәргә фатихасын бирде шикелле.

**Унынчы бөжра**

Кышын имән йокыга чума, карлы-буранлы көннәрне бик томанлы итеп, йокы аралаш кына хәтерли. Язлар-җәйләр җиттеме, ул тагын яшәү кочагына атыла, дөньяның барлык төс һәм авазларын үзенә йота-сеңдерә бара...

Җиләк вакытын әйткән дә юк, печән өсте җитте исә, урман юлында һәм ешлыкларда кешеләр һаман саен күбрәк күзгә чалына. Чалгы чүкегән, чалгы янаган авазлар, канатлы кош сыман кыйгачлап, офыкларга чаклы күтәрелеп менә дә каядыр еракка — урманнар артына китеп югала.

Көннәрнең берендә яшь имән үсеп утырган аланлыкка тагын җигүле ат килеп туктады. Атны тугарып, таза бер усак агачына арканлап куйдылар да

ике ир кеше печән чабарга кереште. Чалгылары чаж да чож килә, үлән арасында яшен булып уйнаклый. Малай кеше кулындагы таяк белән алар артыннан печән пакусларын кабартып йөри.

Ял иткән араларның берсендә малай әллә ничек кенә яшь имән каршысына килеп туктады. Аның таза яфраклы ботакларын тотып-тотып карады, чебиләгән куллары белән кәүсәсен селкеткәндәй итте. Имәнкәй моны ни дип аңларга да белмәде. Ул арада малай янәшәдәге куаклар күләгәсенә кырын яткан өлкәннәр янына килеп сүз башлады:

- Әти, әти, дим, миңа әнә теге имән агачы бик ошады.

- Бик әйбәт, дуслашып калыгыз.

- Күрше Шакирҗан үзенең чыбыркысы белән көн саен диярлек мактана... Син миңа каеш чыбыркы үреп бирәм дигән иден.

- Әйткәнмен икән, булыр. Беләсең ич, үрәсе каеш тасмалары, кипшерә торсын дип, чормага элеп куелган.

- Мин аның кипкәнен түземсезлек белән көтәм... Әтием, ә менә теге имән куагын чыбыркы сабына кисеп алыйк әле. Өйгә кайткач, мин аны бик матурлап шомартыр идем. Көнләшүдән Шакирҗанның ике күзе ут булсын әле менә...

- Чү, улым! Мондый эшне уйлап эшләргә кирәк. Безнең урманда имәннәр сирәк очрый. Үссен, яшәсен ул... Аның гомеренә кизәнмик. Чыбыркы сабына ин кулае — өрәңге агачы. Алар әрсез, алар урман тулы...

Нииндидер күзгә күренмәс көчләрме, әллә өлкән кешенең миһербанлыгы, зирәклеге булдымы, язмыш дигәнең бу юлы да имәннең гомерен һәлакәттән йолып калды. Ул, эчке бер куаныч белән дерелдәп, инде куәт җәеп килгән тамырлары белән урман туфрагына тагын да ныграк елышты.

### Утызынчы бөҗра

Еллар әкерен генә уза тора... Әле кайчан гына ялтыр кабыкка төренеп утырган имәннең кәүсәсендә акырынлап еллар чалымы — таза-кытыршы көрән кайрылар барлыкка килде.

Шулай утызынчы яше белән талпынып-яшәп ятканда, җәйләрнең берендә, бик гыйбрәтле хәлнең шаһите булды имән. Кешеләрнең кулында ат һәм арба дигән нәрсә бар. Урманга, гадәттә, һаман да шуңа утырып менәләр. Күкрәгән җилләргә куеп, иң очтагы ябалдашлары белән болытларга тиярдимәс булып тын гына, салмак кына яшәп яткан имән катына көннәрнең берендә җигүле ат белән янә ике кеше килеп туктады. Килеш-кыяфәтләренә караганда болай бер дә начар, имансыз кешегә охшамаган үзләре. Кулында дилбегә тотканы арбадан ялт кына сикереп төште дә иптәш егетенә җиргә төшәргә булышты. Яшь кенә булса да, бу егет нигәдер чатан, агач аяклы иде. Аягына ни булган аның — аңламассың...

Күләгәлерәк урынны сайлап, җиргә ашъяулык җәеп, табын хәстәрләделәр. Кургашын болыт төсендәге шешәгә бәрелеп стаканнар чылтырады. Аннары тозга манып яшел суган, пешкән йомырка ашарга керештеләр. Телләре ачылып, ничектер тавышлары да көрәеп китте. Сөйләшеп утыруларына колак сала торгач, сүзләреннән азмы-күпме шул аңлашылды: кайдадыр җиде диңгез артында ике ил арасында бик каты сугыш барган икән! Елга булып кан коелган, меңәрләп-меңәрләп гөнаһсыз җаннар кыелган... Әлеге сөйләшүдә «япун» дигән сүз бик еш яңгыраса да, түгәрәк имән бу сүзнең мәгънәсенә берничек тә төшенә алмады.

«Тормышта, кешеләр арасында да урмандагы мәңгелек тәртипне, туганлыкны урнаштырасы иде ул! Төрле төстә, төрле яшьтә, төрле кыяфәттә булуларына карамастан, агачларның беркайчан сугышканы яисә чәкәләшкәне

юк. Агач ул, берәр сәбәп белән ауса да, иптәшенең кочагына барып ава. Алар беркайчан да үпкәләшмиләр, төртешмиләр, берсен-берсе рәнҗетмиләр...»

Әгәр теле булса, имән әнә шундый сүзләрне әйтә алган булыр иде бу минутларда.

Дилбегәче егет, ниндидер сылтау белән, кинәт кенә урыныннан кубарылды да, якындагы ешлык арасына кереп югалды.

Шулвакыт чатан аяклы егет, гәүдәсе белән бераз читкәрәк янтая төшеп, утырган жиреннән аксый-аксый кузгалды. Янәшәсендәрәк яткан киндер букчасыннан бау сыманрак нәрсә тартып чыгарды да аны имәннең кеше биеклегеннән өстәрәк яткан ботагына аркылы ташлады! Авыз эченнән үзе нидер сөйләнә... Менә бау кисәгеннән адәм башы сыярлык итеп элмәк ясап та өлгерде. Нишләргә, ни кылырга жыена бу?

Гажәеп бер житезлек, үжәтлек белән төеннәрне бәйләп бетергәннән соң кап-кара чәчле башкаен әнә шул элмәккә тыгып азаплана... Чү! Түгәрәк бау кисәге тап-таза муенына төшеп тә ятты лабаса... Аңлашылды: үз-үзенә кул салырга, гомеренең иң матур чагын өзәргә жыена...

Имәннең бәхетсез ботагы адәм гәүдәсенең авырлыгыннан кинәт куырылып килде, утыз бoжралы кәүсәсе төптән шыгырдады. Мизгел! Мизгел генә түгел, күктә йөзеп барган ак болытлар да бер мәлгә туктап калды шикелле. Бау тозагында сынар аягы жирдән аерылган егетнең авыр гәүдәсе тыпырчына...

Коткарасы, гөнаhсыз егетне бу hәлакәттән ничек тә коткарасы иде! Менә шушы мәрхәмәтле уй имәннең кан тамырларын дәррәү хәрәкәткә китерде, ботакка таба куалады. Вакытны әрәм итмичә ничек тә урталай сынарга, сынарга, яфраклары калтырап торган ябалдашы белән жиргә — үләннәр өстенә егылып төшәргә! Бер ботагын югалтканнан гына дөнья кителмәс...

Тагын бер кат тетрәп-каерылып көчәнүе кая, имәннең ие-теләге чынга ашты: баулары-ние белән ботак гөрселдәп жиргә ауган иде...

Бәхеткә күрә, нәкъ шул чакта иптәше куаклык арасыннан атылып та чыкты! Кулларын hавада болгый-болгый ачуланып, жикеренеп шундук юлдашы кулындагы элмәкле бауга ташланды:

—Син нәрсә, ахмак?!. Акылдан яздың мәлле? Шундый юләрлеккә баралар димени?

— Туганым... Аяксыз, гарип килеш мин хәзер кемгә кирәк? Атам белән бергәләп печән чапкан аланда дөньядан китим дигән идем...

— Мөселман бәндәгә мордар китү гөнаh эш санала, шуны беләсеңме?

— Туганым, син мине аңлыйсынмы?.. Аяксыз килеш мин хәзер ничек итеп кызлар янына барыйм ди? Бар да бетте, минем гомерем тоташ газапка әверелеп бара...

— Ташла! Үзеңне кулга ал. Урыс-япун сугышында иптәшләрең әнә чебен урынына кырылды, дисең ич. Ә син исән, башың сау...

— Әйе, ул япун дигәннәре бик яман икән. Кораблары белән әллә каян гына килеп чыгалар да туптан аталар... Порт-Артур дигәннәрен йөз илле көн буена сакладык. Менә шунда өзеләр дә инде минем аякны. Их, брат!..

Күз яшьләренә батып елаучы бу чатан егет — малай чакта әле кайчан гына пакуслар әйләндергән, чыбыркы сабы ясау турында хыялланган, хәзер инде егерме тугыз яшен тутырып килгән егеттер дип уена да кертеп карамады имән. Ул бары кешеләр тормышындагы фажигале хәлләргә эчтән тетрәнеп, гажәпләнеп калган иде ул чакта.

### Кырык тугызынчы боҗра

Чибәрлекләре, яшьлек дәрте ташып торган бер кыз белән бер егет түгәрәк имән янына килеп туктадылар. Иң әүвәле егет берьяк инсәсе белән имән

кәүсәсенә сөялде, кыз исә йомшак-нәфис куллары белән аның кытыршы кабыкларын сыйпагандай итте. Сөйләшүләре күнелле генә башланып китсә дә, бераздан алар икесе дә кинәттән ничектер җитдиләнеп, моңсуланып калды. Сөйләшүләре исә болайрак дәвам итте:

—Мин сине... Әйтер сүзләр таба алмыйм... Мин сине ошатамын, Гөлчәчәк!

—Әйтмә шулай, оялтасың бит, Мәхмүт...

— Бер-береннән күпме шулай оялып яшәргә мөмкин? Минем сина өйләнәсем килә...

— Чү! Чит-ятлар ишетә күрмәсен... Безнең арада сыйнфый киртәләр ята. Мин бит мулла кызы, әтиемнең сүзеннән чыга алмыймын...

— Гатият муллага хөрмәтем зур. Ярлы баласы булсам да, ул мине аңлар димен... Сорап барсам, ничек тә хәлемә керми калмас әле.

— Әтиемнең бик тә мәшәкатьле чагы бу арада. Ак патшадан мәчет салдырырга рөхсәт сорап йөргән көннәре. Ашау-эчүен дә онытты. Әле күрше авылга старостага чаба, әле ат белән кантонга чыгып китә...

— Ишеткәнем булды. Халык өчен җан тырышып йөрүе аның. Изге эш бу, азагы уң булсын!

— Үзем дә шуны теләп йөрим.

Егет янадан тора салып әйтә куйды:

— Ишетәсеңме, соңгы чиктә мин сине барыбер урлап китәчәкмен. Тәкъдиребез шундый...

— Бик кыен хәлгә куясың син мине, Мәхмүт...

— Ә мина бик җинел диеп уйлыйсыңмы? Сине уйлап төн катыш күнел сызлап чыга...

— Мин дә гел борчылам шул. Безнең арада нидер булыр шикелле...

— Нәрсә булсын, бөтенесе үзебездән тора.

— Мәхәббәт—фаҗига булырга тиеш, дигәннәр. Бу безгә дә кагыла микәнни?...

— Нәрсә, үз кулыбыз белән фаҗига ясап торырга без дуракмени? Күнелен яхшы синең... Синең хакка мин барысын да эшләргә әзер.

— Әйттем ич инде, минем язмыш хәл ителеп ята... Күрше авылның кулак малае Мөбәрәкҗан безнең өйгә яучы җибәргән. Үзләренең утарында туй итәргә җыеналар, дигән хәбәр дә колакка чалынды.

- Юк, ул түгел, сина мин өйләнәчәкмен! Ишеткәнең бармы, өйләнәсе егет куш йөрәкле була, диләр.

— Әйе, әбиемнән ишеткәнем бар.

— Менә шул. Әгәр Мөбәрәкҗан чынлап торып үзенекен куа башласа, мин сине хәтта аның туеннан урлап китәчәкмен!

— Урлап кына мине кая куярсың икән?

— Нишләргә икәнен яхшы уйладым... Әткәй әнә җиде бөкресе чыкканчы байларга бил бөксә дә, әллә ни мантый алмады. Урал-мәгъдән якларына чыгып китәчәкбез...

— Әй, Мәхмүт, куркам мин чит җирләргә чыгып китәргә.

— Илдә чыпчык үлмәс, дигәннәр. Китәсе икән — китәрбез! Килештекме?..

Икесе дә беркавым тын калдылар. Егетнең очкынлы күзләре каядыр еракка таба төбәлгән иде. Кыз исә ут кочагына эләккән күбәләк сыман талпына, газаплы уйлар эчендә йөзә шикелле. Егет белән кыз урман юлы буйлап китеп тә бардылар. Кызның чәчәкле ситса күлмәге отыры кечерәя барды да үлән-яфраклар эргәсендә эреп югалды...

Бу мәхәббәткә сокланудан имәннең эче-тышы яктырып китте, яфракларыннан көмеш нур тамды.

...Кай арада болытлар җыелып өлгергән диген — менә шуннан соң урман өсләрендә галәмәт күренеш пәйда булды. Тыгыз-салкынча җил агач башларын

шаулатты, дымык янгыр исе һаваны тутырды. Чү! Күкләрне тутырып, ялтыр кылычларын айкап, кинәттән яшен яшьнәве кая, ниндидер бер көч имәннен күкрәгеннән яндырып төште. Утлы-кайнар яшенташ иде бу. Шөкер, кояш чыгыш ягындагы кайрыларының бер өлешен сыдырып төшерде дә жир асты тамырларының берсеннән жир астына китеп тә югалды үзе...

Исән-аман хәлендәге имән яралы күкрәген шыбырдап яуган янгыр кочагына, дымлы җилләргә каршы куйды.

### Илле өченче бөжра

Билгеле бер тәртиптә кышларны — язлар, язларны жәйләр һаман алыштыра килде.

Менә бүген дә табигатьтә көләч, ягымлы жәй тантанасы. Кояш үзенең бихисап нурлары белән бар табигатьне истирәхәттә коендыра... Бал кортларыннан уздырып, каты гүләп, һавага төклетура күтәрелә. Агач башларын талгын гына шаулатып, вакыт жиле исә.

Шундый көннәрнең берсендә авылның балта-пычкы тоткан ирләре имән каршына килеп тукталды.

— Тәрәзә асты нирәгсенә менә дигән бүрәнә булачак! — дип соклануын белдерде араларыннан берсе.

Баш-башындагы сапларыннан тарта-тарта, имәннең төпкел өлешенә пычкы белән аяусыз рәвештә кереп тә киттеләр, менәтерә. Ни-нәрсә икәнен абайламый да калды имәнебез, бары тик ничәмә-ничә еллар буе түшәлгән нечкә бөжраларының бер сызыктан киселә-өзелә баруын гына тойды... Кечкенә ак йолдызчыклар булып, үлән арасына пычкы чүбе коелганын да аермачык күреп торды ул.

Шушы минуттан башлап илле өченче бөжра вакыт кинлегендә мәңгелеккә туктап калды. Ул инде, үзе дә абайлап бетермәстән, өр-яна бер дөньяга күчеп бара иде.

...Аны үзеише бүрәнәләр янына кайтарып аудардылар. Биредә, авыл читендәге калкурак бер урында, эшләр гөрләп тора иде. Берәүләр агач каезлый, икенчеләр почмакларын үлчи- үлчи бүрәнә башларын кисә. Чарт та чорт итеп балта асларыннан йомычка кисәкләре оча. Авыл өстенә мул булып йомычка, агач исе таралган.

Кәжә сакаллы, камзул һәм жилән кигән Гатият мулла бу эшләрнең уртасында кайный. Иркәләргә теләгәндәй итеп, үзенең артыш таягы белән кабыгы төшерелгән бүрәнәләргә кагылып-сугылып китә. Куанычыннан сөйләнеп тә алгалый үзе:

— Иншалла, мәчетебез аякка баса... Аллаһыбызга тагын да ныграк якынаячакбыз. Ходайның рәхмәте белән инде түбәсенә ай куярга да насыйп әйләсен...

• • •

Ул көн дә килеп житә: агач манараның очына, алтынсу нурларын сибә-сибә, галижанәб Ай менеп кунаклый! Халык күп жыйналган. Сокланалар, шаулашалар, үзләренең мөкиббәнлеген белдереп кайсылары мәчет эчендә, кайсылары яшел чирәм өстендә озын-озаклап дога кылалар. Малай-шалайлар исә чирәмгә сибелгән конфетларны чалбар кесәсенең түрәнәрәк яшерә.

Ниһаять, авыл мәчетле булды. Бүгеннән алып безнең түгәрәк имән яна бер әверелештә — хәзер инде мәчет бүрәнәсе рәвешендә яши һәм сулый башлады. Мәчет үзе кешеләр белән тәмам якынайды, аларның ихлас үй-теләкләрен, кылган догаларын һәр күзәнәгенә сеңдерергә тырышты. Ләкин еллар бик тә болганчык, болгавыр, гади халык хәтта үзе дә тиз генә

анламаслык бер вәзгыятьтә иде шул.

Мәчеткә кереп мөнәҗәтләр укыган Нәсимә абыстайның сүзләре дә мәчет диварына оран шикеллерәк килеп кагылды:

Табынында ашы булыр,
Күзләрендә яше булыр.
Тамган бере ачы булыр, —
Шундый заман житәр, имди.

Бу ирләрдән гайрәт китәр,
Хатыннардан хәят кәтәр,
Табынынnan тәгам китәр, —
Шундый заман житәр, имди...

* * *

Кинәттән давыл кубарылды, илдә зил-зилә купты! Нинди генә үзгәрешләр кичермәде бу заман. Ак патша очты, инкыйлап дип сөйләделәр. Илдә кызыл йолдызлы совет власте урнашты. Яңа хакимият яңа тәртипләрне алга сөрә башлады.

Монын җиле, шаукымы көннәрнең берендә мәчеткә дә килеп кагылды. Замананың шушы ава-түнә килгән елларында Борчак Сәлиме дигән адәм аеруча активлык күрсәтте һәм авыл советы рәисе кәнәфиенә менеп кунаклады. Кушаматының тарихы болайрак икән... Малай чакта шулай анын борынына, уйнаганда микән, сынар борчак бөртеге кереп калган. Борын эчендә дым житәрлек, бүртә берзаманны борында теге борчак! Алай итәләр, болай итәләр, ниһаять, имче карчык ярдәме белән котыла Сәлим бу жәфадан. Әмма «борчак» кушаматы мәнгелеккә ябышып кала үзенә.

Яңа кәнәфигә менеп утыргач та Борчак Сәлименең иң яраткан сүзләре һаваны тетрәтә башлый:

— Сәвиткә каршы сөйләмәгез! Әйткәнне эшләгез! Ә бу зур нәрсә! Налуг түлисеңме? Калхузга керәсеңме? Аллаһыдан ваз кичтеңме? һәм башкалар... Анын өчен болар барысы да — «зур нәрсә». Кемдер юанып, кемдер куанып, кемнәрдер нәфрәтләнеп яңа тормышка ияләнмәктә...

Гатият мулла үз тормышында иң авыр көннәрен кичерә. Чөнки динне кысу башланды. Аллаһыга нәләт ташлыйлар, мөэмин мөселманлыкның тамырына балта чабарга җыеналар... Бу совет власте дигәннәре патша заманыннан да яманрак булыр микәнни?

Беркөн шулай Борчак Сәлиме көн уртасында мәчеткә килеп керә дә япьялангач фикерләрен ачып сала:

— Мәчетнең манарасын кисәргә, бетте-китте! Өстән шулай кушалар. Халык өчен клуб ясарбыз... Клуб!

Мәчет хуҗасының күмердәй чем-кара кашлары ачудан шундук өчпочмакланып килде:

— Син нәрсә, ахмак, телең белән һава кыйныйсың, мөртәт! Аллаһ йортына тел-теш тидерергә ни хакың бар?

Гатият мулла әнә шулай дип өздереп җавап бирә юлдан язган дәһригә. Ләкин Борчак Сәлименең мона әллә ни исе китми. Үзенең яраннарын ияртеп алып килә дә балта-пычкы тотып мәчет манарасы эргәсенә юнәлә. Һавадан төшкәндәй, ике милиционер кисәге халык арасында бөтерелә, тырыша-тырыша аларны буйсынырга өнди.

— Кагылмагыз! — дип кычкыра Гатият мулла дәһри адәм затларына. Әмма анын бу газаплы авазын җилләр йолкып ала да Рәсәй киңлекләренә куалый. Ниндидер бушлык хасил түгелме соң? Юк, бушлык түгел бу, һава сон чиккәчә киеренкелек белән сугарылган, җаннарнын исә ук-җәядәй тартылган чагы...

Мулланың кайгылы-хәлсез куллары күкләр хозурына таба сузыла. Ул күнелендә ярсып яралган сүзләрен әйтеп калырга ашыга:

— Менә шушы сакалым белән ант итәм, динебезгә кизәнде икән, совет власте озак яшәмәстер... Халыкка, кояшка каршы эштер бу!

* * *

Авыл өстендә, китеп баручы торналар тавышыдай, ыңгырашкан сәер аваз яңгырый. Бау белән арканланган манара шималь якка таба авыша... Манараның дөбердәп җиргә ауган, очындагы алтынсу Айның исә бәрәнге буразнасына төшеп югалган чагы бу.

Йөрәк өянәгеннән күкрәген кысып торкан Гатият мулла соңгы сүзләрен әйтеп калырга өлгерә:

— Авылдашлар... Аллаһының исемен телдән дә, күңелдән дә беркайчан чыгармагыз! Тәнемне көч ташлап чыкканда да мин сезне онытмамын...

Икенче көнне көтмәгәндә авылны мәхшәр басты. Озаклап, коеп-коеп дуамал эре яңгыр яуганнан соң урамнардан шаулап су ташкыны акты, ул югары очның бүрәнәләрен авылның түбән очына хәтле тәгәрәтеп агызган иде. Хәтта аркандагы бозауларга хәтле ташкын эчендә тыпырчынган, дип сөйләделәр. Табигатьнең дәһриләрдән үч алуы дип аңлатырга тырышканнар моны.

Болар барысы да — мәчет бүрәнәсенең хәтерендә.

Борчак Сәлиме максатына иреште — авыл читендә хәзер клуб гөрләп тора әнә. Пионерлар, комсомоллар, авыл яшьләре гөр килә анда: гармунга кушылып җырлыйлар, бииләр, спектакль кую белән дә мәш киләләр.

Әмма да ләкин активист Сәлимнең гомере бик тә аянычлы тәгәлләнде. Гөнаһлы эшләре өчен Аллаһының каргышы төштеме, әллә теге борчак дигәненең зәхмәте булдымы икән, борыны череп үлде, бичаракай.

* * *

Галәмдә янәдән күп сулар акты, күп җилләр исте. Тормыш сәхнәсенә яңа заман, яңа кешеләр килде. Ходаның рәхмәте белән халык янәдән дингә, иманга кайта башлады. Колхоз рәисе, Гатият мулланың икенче буын оныгы Бикмөхәммәт, бабасы рухына багышлап, авылда өр-яңа мәчет тергезергә ният салды.

Иске клубны сүтеп ташладылар, чөнки хәйран гына какшаган һәм коргаксыган иде ул. Менә шул чакта балта осталары клуб тәрәзәсе нигезсенә яткан бүрәнәнең тазалыгыннан хәйран калып: «Бу бит яңа төзеләчәк мәчет бурасына бер дигән булачак», — дип тел шартлатып сөйләделәр.

Уйлаганнары рас килде. Чөнки фасыл арты фасыл кабатлана торган җил-бураннар, кар-яңгырлар шаукымы имән бүрәнәнең тазалыгына, ныклыгына тамчы да зыян-зәүрәт салмаган иде.

Яңа мәчет ачу тантанасына халык ташкындай агылып килгән иде. Казаннан махсус чакыртылган яшь мулла, кайбер хөтбәләрне укыганнан соң, иске-яңа мәчет бүрәнәсенә үзенең игътибарын ташларга да онытмады: «Рабби әнзилини мүнзаләм мүбәрәкә-үв-вә әнтә хәйруль минзилини».

Аңлаешлы итеп безнең телгә авыштырсак, моның асыл мәгънәсе болай дигәнне аңлата иде: «Әй, Раббым! Мине мөбарәк урынга урнаштыр. Син бит урнаштыручыларның иң хәерлесе».

Шулай итеп, шаулы елларны кичә-кичә, мәчет бүрәнәсе үзенең изге урынына кабат әйләнеп кайтты. Амин.

*2006 ел.*



Чыңгыз
Мусин

# КӨМЕШ СУЛАР АГАР УЛАКЛАРДАН

## Акбүз атым

**Акбүз атым, зинһар, өзгәләнмә,**
**Сабыр гына атлап, акрын бар!**
**Без узасы юллар чикләнмәгән,**
**Алда әле бик күп чакрымнар...**
**Нәслегезне яхшы хәтерлим мин,**
**Әйбәт иде безнең татулык:**
**Сугыш елларының газапларын**
**Алар белән бергә татыдык...**
**Авыр иде, авыр ул чакларда,**
**Сездә булды бөтен таяныч.**
**...Кадерегез бетеп бара никтер,**
**Шунысы менә бигрәк аяныч...**
**Сез кешегә юлдаш булсагыз да,**
**Гомерегез уза йөгәндә.**
**Кешеләрне дә бит йөгәнлиләр,**
**Юлларыннан язып йөргәндә.**
**Их!..**
**Маңгайга да буй-буй сырлар сызды**
**Бергә йөргән еллар арасы.**
**Тик намусны кайчак рәнҗетәләр,**
**Әрнеп куя йөрәк ярасы.**
**Шуңа нинди дәва табасы?**
**Кырын ятып уйга чумып барам,**
**Кар шуыша чана астыннан...**
**Гомер юлы күпме узылса да,**
**Кылган эшләремне азсынам.**

Чыңгыз МУСИН (1934) — *шагыйрь; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, берничә шигырь китабы авторы. Әгерҗе районында яши.*

Акбүз атым, артык өзгәләнмә,
Сабыр гына атлап, акрын бар! —
Максатларга кайчан житәбез соң?
Артта калды күпме чакрымнар!

## Бу туфракта

Тау артыннан — офык ягы алсулана,
Күпереп торган туфрак исе басуларда.
Таң алдыннан ал офыкка каршы барам
Туып килгән яңа көнне каршыларга.

Жирне назлап йомшак кына жилләр исә,
Жирнең өстен жилләр тарый, гөлләр үсә.
Бал кортлары ширбәт жыя, ширбәт эчә,
Чәчәкләрдән чәчәкләргә күчә-күчә.

Ак болытлар агыла кыйбла тарафына,
Мин дә очам гүя жилләр канатында.
Назлы жилләр күңелләргә татлы дәва,
Зәңгәр күктән нурлар булып бәхет ява.

Бу туфракта — һәркемнең дә хәләл көче,
Ишетелми гүя дөнья гөрелтесе.
Һәр тарафта — күңелләрдән жуелмаган
Саф, табигый, тапланмаган гомер төсе.

Еллар узар, гомер үтәр, көннәр үтәр,
Тагын жиргә кемнәр килер, кемнәр китәр...
Без күчәрбез мәңгелеккә...
Изге мохит
Оныкларга инде ниләр бүләк итәр?! .

## Улаклар

Авыл яши — изге туфракларда,
Чишмә суы тулы — улакларда...
Чишмә суын эчеп үскән күпләр
Еракларда инде, еракларда.

Күпләрне бит башка тарафларда
Читләр корган жәннәт кызыктыра.
Ятим калган авыл өсләреннән
Агымсудай еллар узып тора.

Без таптаган таныш сукмакларны
Каплап китте инде кыргый үлән.
Замандашлар инде сирәгәя,
Жир куенына керә берәм-берәм...

Кемдер корган чишмә улаклары
Чүпләнерләр, мүкләнерләр инде.
Бик күпләрнең гамьсез йөрәкләре
Мүкләнделәр бугай күптән инде.

Җылы җәйләр ел да кабатлана,
Җир җылысы — туган тарафларда.
Тал-тирәккә кунып, тәүге тапкыр
Җырчы кошлар монда канат кага.

Авыл халкы гади, җыйнак кына,
Гомер итеп ята тыйнак кына.
Тик нигәдер заман чыбыркысы,
Авыл сыртын әле дә кыйнап тора...

Көмеш сулар ага улаклардан,
Тирәсенә кошлар кунаклаган...
Авыл тарафына, ара-тирә,
Сагыну хаты килә — ераклардан.

## Сиңа

Хәтердә язгы кичләрдә
Беренче таньшулар...
(Һәркемнең гомер юлында
Онытылмас табышы бар!)

Елмаеп, иләс күңелемне
Нурыңа манган идең.
Мин-тиле — өнсез хәлемдә,
Югалып калган идем.

Йөрсәң дә яшьлек язында
Читләшеп, ялындырып.
Сизмәдең: калдың язмышта
Гомерлек ярым булып...

Сизелми үтте гомерләр,
Елгадай акты гына.
Күңелдә тәүге хисләрем
Көннән-көн якты гына;

Бу — гүя татлы гомернең
Беренче киче генә...
Җитәкләшеп киләбез күк
Җәннәтнең ишегенә!

## Иҗади рухым минем

Төн караңгы, хисем бөтен,
Бер тәңремә мең шөкер.
Тик менә шигъри җанымда
Бер фикер юк — зур фикер...
Иҗади хисләр тудырган
Язмышым иркендә мин.
Бу төнем бушка узды дип,
Янмамын, үкенмәмен.
Шигъри йомгагым очында
Серле дөнья шәйләнә.
Бу гамәл — хак бер гамәлдер,
Корылмаган хәйләгә.
Бу гамәлем — мең дәвадыр
Тынгысыз йөрәгемә.
Тик кичектем, җитә алмам
Хыялым үрләренә.
Җаныма нурын иңдергән
Иҗади рухым минем.
Күңелем чиксез дәрья вә
Йөрәгем дулкын минем.
Әле тышта төн карасы,
Кич түгел, иртә түгел:
Шигъри газәлем туарга
Берни дә киртә түгел.
Бу гамәлнең хиссезләргә
Кирәге юктыр кебек.
Тик мине никтер газаплый
Шул өмет, тик бер өмет.
Кышкы озын төннәр үтә
Сихерләнеп, хисләнеп...
Хисле җанга зур фикерләр
Торса икән өстәлеп!

Ленар
Шәех



# ЯКТЫ ШӘМНӘР

## Тукай кайта...

**Язлар белән күңелләргә Тукай кайта,
Пар атларда Казанына килгән кебек...
Бөтен халык телсез калып карап тора,
Бар кайгысын, мәшәкатен җиңгән кебек...**

**Каеннарда инде энә бөре төртә,
Күңелләрдән саркып чыккан хисләр кебек...
Шигъри ямьне, пәйгамбәрне көткән чакта
Сизгер йөрәк түзмәс, әллә нишләр кебек...**

**«Пар атларда Тукай кайта!..
Тукай кайта!..»—
Ераклардан балкып торган изге кыйбла.
Иман сызлар...
Имансызлар да кайчакта
Тукаеның каршысына килеп егыла.**

## Каурый төште...

*Нур Баянга*

**Мылтыгыңда утлы пуля ята,
Күңел ишегеңнән моң бәрә...
Атмый тору синә бер бәладер,
Язмый тору исә — мең бәла...**

**Айлы төндә, окоп ышыгында
Ак кәгазьгә күчә моңнарың.
Чорлар аша үткән җырларыңны
Агыйделгә төшеп тыңладым.**

Ленар ШӘЕХ (1982) — *яшь шагыйрь; Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. «Авылдан килгән мендәр» исемле китап авторы. Казанда яши.*

Пар аккошлар йөзә тып-тын суда,
Актарыла йөрәк ызаны.
Сугыш барган кырлар янда кебек —
Җаным буйлап сагыш сызамы?..

Үткәннәрдән кайта йөрәк шавы,
Шарлавыклар булып ага моң...
Актарганда, милләт сандыгыннан
Тарих тузаннарын кагамын.

Исән әле, исән синең җырың,
Йөрәкләргә бәрә җылысы...
Үзәгендә чәчәк балы исе,
Кош сайравы, нарат ылысы...

Тарих тузаннарын кояр өчен,
Эх, куясы утлы минаны!.. —
Аккош канатыннан каурый төште,
Кулларыма алдым мин аны...

## Җан—ирекле, Рәсәй!

*Мохтар Мутинны уйлап...*

Нахак ягып, сөргеннәргә сөреп,
Ач этләргә ташлап үтердең дә...
Хәзер инде аклап маташасың,
Кұләгәңә кояш китердең дә.

Гаеплисең—әйтерсең, син Алла,
Ярлыкыйсың Ходай шикелле...
Кешеләргә хуҗа,
а җаннарга
Тешең үтми, алар—ирекле!..

Аклыйсың син, бер дә акланмыйсың,
Гөнаһларың ашкан муеннан...
Су юарлык «изге» караш йөздә,
Элмәк чыгып тора куеннан...

Акланма син, акланма син, Рәсәй,
Синең тарих тоташ кан гына.
Үткәннәрдән килгән ташка бассаң,
Кара таштан сыкрап кан чыга...

Талант җаны әчтән дөрләп яна,
Син сибәчәк бозга ул бикле.
Кешеләргә хуҗа,
а җаннарга
Кулың җитми, алар —ирекле!..

* * *

Дөньяның өмет ишеген
Киереп ачып керәсең дә...
Арттан килә тик бер аваз:

«Кирәкме мин бирәрсенә?..
Кирәкме мин бирәрсенә?..»

Тормышның ваклыкларыннан
Еларсың да, көләрсең дә...
Ә күңелдә тик бер аваз:
«Мин кирәктер бирәрсенә,
Мин кирәктер бирәрсенә...»

Ялгыз калсаң, хыялыңны,
Өметеңне күмәрсең дә...
Җанны яра тик бер аваз:
«Мин кирәк бит бирәрсенә,
Мин кирәк бит бирәрсенә?!.»

* * *

Карлар ява инде, ап-ак карлар—
Без таптаган юллар өстенә.
Пар каплаган тәрәз. Янәшәдә
Моңлы гына итеп көз көлә.

Карлар ява инде, ап-ак карлар,
Чыклы күкне тоташ томалап.
Юлны сарган сары яфраклардан
Көз елмая, җанны юмалап.

Карлар ява инде, ап-ак карлар—
Бергә салган эзләр өстенә.
Кар ята да, эреп юкка чыга...
Саубуллашып, тышта көз көлә.

## Альберт Фәтхи сурәтенә

Син—тырыш, син—омтылучан,
Тик күзләрең уйчан, уйчан...
Шәмең яна куышыңда,
Үткәннәрнең юлы шунда...

Тарих өчен тугансыңдыр...
Казанда да туңгансыңдыр...
Чып-чын дөнья шушы инде:
Ялгыз янган шәмең сүнде...



Рифат
Сәлах

# ЧЕЛЛӘ ЧЕЛТӘРЕНДӘ — КОЯШ

## Эндәшү

Ак болытлар гамьсез йөзә күктә,
Офыкларны ярып дәшсәм дә.
Кояш нуры керә күзләремә,
Җил тузгыткан «җанлы» чәчләргә:

Шаян җилләр чәчләремне тарый,
Аларга да моңнар ят кебек.
Күңелемдә синең давыл шаулый,
Күңелемдә синең яктылык.

Болыннарда үскән чәчәкләргә
Сөйләп йөрим бөтен хисемне.
Үзләре дә синең кебек гүзәл,
Йөртә гүя синең исемне.

Болыннар да болытларга гашыйк —
Җилләр аша сәлам җибәрә.
Сөю белән тулган күңелемне
Җырлар итеп сибәм җилләргә.

Җилләр гамьсез алар… Ә шулай да
Әманәткә кылмый хыянәт.
Җавабың да көтмим, тик хыялда
Йөрим әле офык тирәләп.

Җавап бирү кирәк түгел, җаным,
Җырларымны гына тыңла син!
…Мең чакрымнар аша, офык ярып,
Миңа таба карап торасың.

Рифат СӘЛАХ — *яшь шагыйрь, КДУ студенты. Шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. Казанда яши.*

## Истә тоту

*(этюд)*

Яннарымнан
Үтеп бара вакыт җиле.
Юлларның да
Була икән ватык җире...

Яңгыр ява,
Ул да истә тота сине.
Мин генә сине уйлыйм, дип
Йөрдем, тиле!

## Җиде

Дәфтәремдә җиде генә чиста бит,
Язар идем сүзләрем аз, кыска бик.

Җиде күкне кичеп, фәзаларга менәм,
Җиде җир астында — кайнар тимер, беләм.

Җиде йолдыз — җидегән йолдыз — тустаган...
Җиде нота көен кемнәр сызмаган.

Җиде буын — җидегез дә белегез:
Җиде тәмуг, җәннәт — сигез!

* * *

Фәрештәдә канат була диләр...
Болытлармы синең канатың?
Әкрен генә шәфәкъ яктысында
Җир-күкләргә иңә кара төн.

Төн яктысы җиргә таралганда
Офыкларга офык кушыла.
Күкләр буйлап очып әйләндең дә,
Канатыңны салдың учыма.

Канатыңны сиңа кире бирәм,
Бүләк итәм күкләр дәрьясын.
Җир-күкләрне тоташ бәхеткә төр,
Күзләреңдә генә калмасын!

Җир-күкләргә аклык кына юра —
Актан гына торсын бу галәм!
Каурыйларың очсын кайнар җилгә —
Сагышларын үзем күтәрәм!

Син — фәрештә, бар күкләрне иңләп,
Болытларны иңләп оч кына!
...Күк гөмбәзен очып әйләндең дә
Канатыңны салдың учыма.

***

Төнлә сине төшләремдә күргәч,
Килә алмый йөрим аңыма.
Җирдән китә алмас йөрәгемә
Әйтерсең лә күкләр кагыла.

Май кояшы кебек балкып йөрим,
Тик моңланам сине күргәчтен.
...Ак күгәрчен тирәсендә йөри
Гади күгәрчен...

## Романтика

Һәр адымда сине генә уйлыйм —
Йөрәгемә кереп уелдың.
Өйгә таба кайтып барган чакта
Бозлы юлда таеп егылдым.

Әрнү сизмәдем дә,
Киресенчә,
Бәхетемнән генә елмаям.
Уйлап кына кара:
Романтика! —
Егылу да сине уйлаудан...

## Июль ае

*(этюд)*

Көн эссе. Кайнар җилләрдән
Шаулап куйды арышлар.
Чиллә челтәрендә кояш
Үзен күккә багышлар.

Ялгышып кычкырды кәккүк
(Сайрамаска тиеш тә!).
Күзне камаштырып, әнә,
Ак рәшәләр биешә.

Күкләр офык якларына
Алып китте кыр юлын.
Чәчәк аткан юкәләрдән
Яфрак
төште
коелып...



Васил
Гайфуллин,
*Татарстанның атказанган
фән эшлеклесе, профессор*

# ФӘННИЛЕК — МИЛЛИ МӘГАРИФНЕҢ НИГЕЗЕ

Мәгариф ул гомумкешелек культурасының бер тармагы гына түгел. Югары дәрәҗәдәге мәгариф системасы (тирән белемнәр стандарты, тиешле матди-техник база, сәләтле һәм тотрыклы кадрлар, алдынгы педагогик технология һ. б.) булган илнең икътисады да югары, халыкның тормыш, культура-әхлак дәрәҗәсе дә тиешенчә, милләтләр дә тату.

Мәгариф системасы башкарган чараларда җәмгыятьтәге икътисади бәйләнешләр да, сәяси интеграцияләү процесслары да, мәдәни үсеш юнәлешләре дә фокуста җыелган кебек очрашалар. Шуларны истә тотып уку йортлары яшьләргә дөрес хезмәт тәрбиясе, тирән белемнәр бирергә, төрле халыклар арасында дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга, башка халыклар мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләргә тиеш.

Россия Федерациясе — күп милләтле дәүләт. Аның мәгариф системасы да унитар принципта корыла алмый. Һәр халыкның үзенең мәгариф системасы була. Анда халыкның милли үзенчәлекләре дә, тарихи үткән юлы да, гореф-гадәтләре дә, этнопедагогик һәм этнопсихологик үзенчәлекләре дә исәпкә алынырга тиеш. Мәгариф үсешен тәэмин итү өчен төзелгән концепциядә болар исәпкә алына.

Мәгариф системасына реформа башланган 1990 нчы елларда милли идеологиягә нигезләнгән мәгарифне үстерү концепциясе булмау бу эшне катлауландырды. Демократияләшү юнәлешендә барган үзгәрешләр, милләтләрнең үзаңы үсү, мөстәкыйльлеккә омтылу күренешләре милли мәктәпнең теоретик-методологик нигезләрен эшләүне көн тәртибенә куйды. Бу чорга Россия Федерациясендә дә, Татарстанда да мәгариф үсешенә юнәлеш бирерлек концепция юк иде. Заман таләбе нигезендә бу документлар булдырылды. Хәзер шул процессның этапларын карап китик.

Элекке СССР һәм хәзерге Россия Федерациясе күләмендә бу эш түбәндәгечә барды. Совет мәктәбе белем бирү системасында милли мәктәпне мөстәкыйль уку йорты тибы итеп раслаган беренче норматив документлар 1918 елда чыкты. Анда милли мәктәпкә түбәндәге билгеләмә бирелгән: «Россия Республикасында милли мәктәп дип азчылык халыкка хезмәт күрсәтүче мәктәп атала. Күпчелек мәктәпләрдән ул теле белән аерылып тора. Милли мәктәптә укыту ана телендә алып барыла... Ана теле белән беррәттән, милли әдәбият һәм ул халыкның тарихы өйрәнелә... Азчылык халык укый торган милли мәктәпләрдә бу өлкәдә күпчелекне тәшкил иткән халыкның телен өйрәнү

мәҗбүри» (Возрождение народов Российской Федерации и формирование национальных систем образования. Вып. 1-3. — М., 1992-93.).

Совет властеның башлангыч 15 елында мәдәният һәм мәгариф өлкәләрендәге сәясәт төрле милләтләрне үстерү юнәлешендә барды. Моңа кадәр үз телендә укый-яза белмәгән 40 этноска әлифба булдырылды, барлык милләтләр өчен башлангыч мәктәпләр эшләде, милли мәктәпләр өчен укытучы кадрлар хәзерләү оештырылды.

1929 нчы елда Россия Федерациясендә 85 педучилищеда һәм 8 пединститутта милли кадрлар хәзерләнде. Моннан тыш тагын 24 пединститутта милли мәктәпләр өчен укытучылар хәзерли торган аерым төркемнәр эшләде.

Утызынчы елларның икенче яртысыннан илдә шактый үзгәрешләр башланды. Индустриаль үзәкләр барлыкка килү, шәһәрләрнең үсүе, авыл халкының промышленность үзәкләренә күчүе, армиядәге реформа, андагы команда теленең рус телендә генә алып барылуы һ. б. сәбәпләр рус теленең кулланылу сферасын киңәйтте. Бу хәлләр милли мәктәпләргә дә үзгәрешләр кертте. 1938 нче елның 13 нче мартында СССР хөкүмәтенең «Милли республикалар һәм өлкәләр мәктәпләрендә рус телен мәҗбүри укытуны кертү» турындагы карары чыкты. Карар СССРдагы рус булмаган 71 миллион халыкка кагылды.

Бу карарны хөкүмәтнең мәгариф өлкәсендәге яңа идеологик доктринасы башлану дип әйтергә була. Аның төп максаты алга таба илдә милли беришле (бертөрле) җәмгыять төзү иде.

1958 елда чыккан мәктәп турындагы закон милли мәктәпләр тормышын тамырдан үзгәрткән хәлиткеч документларның берсе булды. Бу вакытта СССРда милли мәктәпләрдә 94,7 миллион укучы белем ала иде. Закон нигезендә ата-аналарга балаларын укыту өчен мәктәпне үзләренә сайлап алырга хокук бирелде. Рус теленең кулланылу сферасының көннән-көн үсүен күреп торган ата-аналар, әлбәттә, үзләренең балаларын рус мәктәпләренә бирә башладылар. Милли мәктәпләр әкренләп кимеде, аларның күбесе ана теле укытыла торган рус мәктәпләренә әйләнде. Төмән, Чиләбе, Свердловск, Пермь, Ульяновск, Куйбышев һ. б. өлкәләрдәге йөзләгән татар мәктәпләре шушындый язмышка дучар булды.

Закондагы үзгәрешләрне коммунизм төзүдәге алда торган яңа бурычлар белән аңлатырга тырыштылар, ләкин прагматик максат ачык билгеләнде: милли үзенчәлекләре булмаган җәмгыять төзү. Бу максат 1960 нчы елларда тагын да конкретлашты: яңа җәмгыять күпмилләтлелектән котыла, яңа җәмгыятьтә бер генә милләт — «совет халкы» гына булачак, алар социалистик идеологиягә буйсыначак, рус телендә сөйләшәчәк.

1966 елда союз күләмендә Мәгариф министрлыгы оеша. Ул үзенең эшен милли мәктәпләрне кысрыклаудан һәм мәгариф системасын руслаштырудан башлый. 1968 елдан 1980 елга кадәр КПСС Үзәк Комитетының һәм СССР Министрлар Советының дүрт карары чыга. Болар барысы да милли мәктәпләрдә рус теленең ролен киңәйтүгә юнәлдерелделәр. Югары уку йортларында ана телендә белем бирү кискен тәнкыйтьләнде. Мәгарифнең барлык буыннарында унитар система хакимлеге башлана.

Казан дәүләт педагогия институтында 1950-60 нчы елларда белем алган кешеләр хәтерлиләрдер, ул елларда һәр факультетта параллель ике бүлек эшләде: рус бүлеге һәм татар төркемнәре. Физика-математика факультетында ул елларда саф татар телендә безгә белем һәм тәрбия биргән укытучыларыбыз хәзер дә күз алдында: математиклардан профессор М. Әлмөхәммәтов, доцентлар К. Йосыпов, К. Юнысов, Б. Газизов, физиклардан фән кандидатлары, доцентлар Г. Кудашев, Ш. Таҗетдинов, М. Галиев, С. Зиннәтов һ. б. Бу укытучылар әзерләгән белгечләр СССРның бик күп өлкәләренә эшкә китәләр иде.

Алга таба пединститутта татар бүлекләре ябылдылар.

1950 нче еллар ахырыннан башлап милли мәктәпләр миллилек сыйфатын бетерә башлады. Югары классларда, аннан 5-8 классларда, алга таба башлангыч мәктәпләрдә дә укыту рус теленә күчте, ана теле укыту теленнән уку

предметы дәрәҗәсенә әйләнде. Рус теле милләтләр арасындагы аралашу теленнән икенче ана теле статусына күчте. 1974-75 нче уку елында милли мәктәпләрнең уку планында ана теле һәм әдәбиятына атнага 39 сәгать, ә рус теле һәм әдәбиятына 70 сәгать вакыт бирелгән иде. Милли мәктәпләрдә рус теле һәм әдәбиятын укытканда класстагы укучылар 15 кешедән артмый торган төркемнәргә бүленде, укытучыларның хезмәт хакларына 15% өстәмә түләнде.

СССРның барлык регионнарында да мәктәптә укытыла торган фәннәр бер үк программа нигезендә укытылды. Фәннәрнең эчтәлеге сыйнфый һәм пролетар кыйммәтләр идеологиясе белән сугарылган иде.

1958 елгы мәктәп турындагы закон кабул ителгәнче Россия Федерациясе мәктәпләрендә укулар 46 телдә алып барылды. Сиксәненче еллар уртасына бу сан 18 гә генә калды. Татар һәм башкорт мәктәпләре тулы урта белемне ана телендә бирсәләр, тува һәм якут мәктәпләрендә ана телендә уку 7-8 классқа кадәр, чуаш, мари мәктәпләре башлангыч классларда гына, ә калган 12 телдәге милли мәктәпләрдә ана телендә уку ике-өч елдан артмады.

Ана телендә укытыла торган милли мәктәп рус телендә укытыла торган милли мәктәпкә әйләнде. Гадәти рус мәктәбеннән аның аермасы шунда — мондый мәктәпләрдә атнага берничә сәгать ана теле дәресе керә. Татарстан мәктәпләре өчен дә бу бик табигый күренешкә әйләнде. Казанда гына да, мәсәлән, бу чорда утыздан артык татар мәктәбе ябылды, милли мәктәпләрдән 2 генә мәктәп калды: Бауман районының 35 нче һәм Совет районының 106 нчы мәктәбе. Аларда барлык фәннәр дә рус телендә укытылды, татар теле укыту предметы гына булып калды. Мәктәпләрнең исемнәре «рус телендә укытыла торган милли татар мәктәбе»нә әйләнде. Кызыграк яңгырый, әлбәттә.

Мәгариф эшендәге мондый юнәлеш үзенең нәтиҗәләрен дә бирде: берничә буын мәктәп баласы туган теленнән һәм мәдәниятеннән, милли традицияләреннән читләштерелде, чит телдә тәрбияләнде. Милләтләрнең ана теле кысрыкланды, җәмгыятьтә кулланылышта бер генә тел калды.

Милли республикаларда милли мәктәпләр кимегәннән кими барды. Ул республикаларда яшәүче руслар андагы җирле халыкның телен өйрәнүдән «котылдылар». Җирле халыкның теле кухняда гына файдаланырга ярый торган тел булып калды.

Марксистик идеология буенча милләтләр, ахыр чиктә берләшеп, бер генә төрле халыкка әверелергә тиеш. Ләкин, классиклар фикеренчә, билгеле бер шартта гына: милләтләрнең экономикасы һәм мәдәнияте чәчәк аткан очракта. КПСС идеологлары бу чорны кәтеп тормаска булдылар, бердәм совет халкын төзүне ашыктырдылар. Ләкин бу кешелек җәмгыятенең үсеш законнарына тулысынча каршы килә. Табигать тудырган үсемлекләр һәм хайваннар дөньясында һәрбер җан иясе — табигатьнең күпьеллык иҗат нәтиҗәсе. Шуңа күрә дә үсемлекләр һәм хайваннар дөньясындагы һәр генетик төрне саклау өчен күп көч куела, законнар чыгарыла. Шуның кебек үк, һәр халыкның, кечкенә генә этносның да теле, мәдәнияте, үзаңы, менталитеты кешелек дөньясының иҗаты, байлыгы дип саналырга хаклы. Аерым этнос-халыкның мәдәнияте — ул бөтен халык байлыгы. Бу байлыкны сакларга, үстерергә кирәк. Моны аңламыйча күп милләтле дәүләт төзеп булмый.

СССРның таркалуы, тоталитар партия-совет системасының җимерелүе демократияләшү элементларына юл ачты, халыкларның үзаңы уянуга ярдәм итте. Милли мәгарифнең кирәклеге көн тәртибенә килеп басты: милли мәгариф системасы унитар дәүләт таләпләрен генә түгел, ә халыкларның, милләтләрнең теләкләрен дә канәгатьләндерергә тиеш, милли мәктәпләр яңадан торгызылырга, уку ана телендә алып барылырга, белемнәр эчтәлегендә милли мәдәният, тарихи мәгълүмат тиешенчә урын алырга тиеш.

Таләпләр урынлы булса да, кызганычка каршы, бу чорда милли мәгарифне үстерүнең, фәнни яңартуның төпле концепциясе һәм Россия хөкүмәтенең моны эшләргә теләге дә булмады. Кайбер инициатив төркемнәрнең Россия Федерациясендә милли мәгарифне җайга салуны күз алдында тоткан программалар һ. б. төр документлар тәкъдим итүен күрсәтеп үтәргә кирәк. Шуларның

берничәсенә тукталыйк.

1. РСФСР мәгариф министрлыгы 1990 елның 22 февралендә «РСФСР-ның милли (рус булмаган) уку йортлары программасын» кабул итте. Ул 1990-1995 елларга исәпләнгән иде. Ләкин программа милли мәктәпләрнең яңадан тууы һәм үсүе өчен берни дә чаралар тәкъдим итми, милли мәктәпләргә яңа шартларда косметик ремонт үткәрүне генә күздә тота. Милли мәктәпнең статусы элеккечә кала бирә: уку рус телендә алып барыла торган милли мәктәп.

2. СССР Педагогия фәннәре академиясенең авторлар группасы милли мәктәпләрнең яңа моделен тәкъдим итте. Авторлар мәгариф системасында белем стандарты инвариант һәм вариантлы өлешләрдән торырга тиеш дип исәпли. Инвариант өлеше барлык типтагы гомуми урта белем бирүче уку йортлары өчен дә мәҗбүри. Ул белем стандартының гомумсоюз компоненты дип атала. Вариантлы өлешләргә аерым республикалар һәм мәктәп компонентлары керә. Авторлар фикере буенча, аерым республикаларда (мәсәлән, Татарстанда) уку йортлары өчен уку планы төзегәндә болар исәпкә алынырга тиеш. Татарстанда милли мәгарифне үстерү концепциясен һәм программасын әзерләгәндә без моны исәпкә алдык. Уку планнарында «Татарстан һәм татар халкы тарихы», «Татарстан географиясе», «Татарстанның экономикасы», «Татарстанның экологиясе» h. б. үзенчәлекле уку предметлары кертелде. Бердәм уку планы урынына күп төрле уку планнары барлыкка килде. Һәр мәктәпкә үзенә туры килгән уку планын сайлап алырга мөмкинлек бирелде.

Милли мәктәпнең бу моделен тәкъдим итүче авторлар укыту-тәрбия процессында милли традицияләрнең, этнопедагогика һәм этнопсихологиянең дә роленә игътибар бирергә тәкъдим иттеләр.

3. 1989 елда СССР Фәннәр академиясе «Мәктәп» исемле Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү коллективы оештырган иде. Алар да милли мәктәпне үстерүнең яңа вариантын тәкъдим иттеләр. Авторлар фикеренчә, мәгариф системасында төп буын булып башлангыч мәктәп тора. Башлангыч классларда һәр милләт үз баласын үз ана телендә укыта ала, тәрбиядә милли мәдәният исәпкә алына, аннары укыту һәм тәрбия гомум Россия җирлегенә һәм дөнья культурасы дәрәҗәсенә күтәрелә.

Милли мәгарифне үстерү юлында өч принцип тормышка ашырыла:

— Милли мәктәп милли мәдәнияткә таяна, укучыда милли үзаң формалаштыра;

— Милли мәдәният башка халыкларның мәдәнияте белән баетыла;

— Милли мәктәпнең белем стандарты цивилизацияле илләрнең белем стандарты белән тәңгәлләштерелә.

Бу концепциянең милли мәктәпләр өчен уңай яклары күп иде. Шуңа күрә ул РСФСР мәгариф министрлыгының коллегиясендә (1991 елның марты) уңай бәя алды. Ләкин концепциянең җитешсезлеге дә бар иде. Күрсәтелгән принципларга нигезләнгән программалар, технологияләр булмау бу концепциянe тиешенчә тормышка ашырырга мөмкинлек бирмәде.

Татарстанда да 90 нчы еллар башында милли мәгарифне торгызуга омтылыш зур иде. Ләкин бу эшне башлап җибәрергә теоретик белемнәребез юк дәрәҗәсендә булды. Татар мәктәбен яңадан торгызу, үстерүнең теоретик-методологик проблемаларын тирәнтен өйрәнергә, аның концепциясен яңадан тудырырга туры килде.

Татар мәгарифен үстерү концепциясе 1991 елда Татарстан мәгариф министрлыгы коллегиясендә кабул ителде. Концепциядә татар мәгарифенең халык һәм дәүләтнең күп баскычлы тәрбия системасы булуы, аның милли традицияләргә, дөнья педагогикасының алдынгы тәҗрибәсенә таянуы ассызыклана, укыту һәм тәрбиядә ана теленең роленә, дөнья мәдәниятен өйрәнүдә рус теленең әһәмиятенә басым ясала (Концепция развития татарского просвещения // Панорама, №8, 1991.).

Татар милли мәгарифен үстерү принциплары «укыту һәм тәрбия процессы төрки халыклар, көнчыгыш һәм ислам культурасына таяна, шуның белән

берләттән, дөнья илләренең, беренче чиратта көнбатыш дәүләтләренең алдынгы педагогик тәҗрибәсенә таяна» диелә.

Безнең концепциянең шушы принцибы Россия Федерациясенең мәгариф концепциясе төзү идеологларына ошап бетмәде. Ничек инде ул Татарстанда татар мәктәбендә христиан дине кануннарына түгел, ислам кыйммәтләренә табыналар? Ләкин татар мәгарифен үстерү концепциясен бу нигездә төзүнең сәбәпләре һәркемгә ачык. Тоталитар дәүләт системасының унитар мәгариф системасы эчтәлеге белән дә, милләтләрне рухи канәгатьләндерү ягыннан да гамәлгә яраксыз иде. Милли мәктәпне яңа шартларда торгызу һәм үстерү өчен икенче идеология кирәк булды. Татар халкының борынгыдан килгән тәрбия кануннары бар. Төрки халыкларның үзләренә генә хас үзенчәлекле традицияләре бар. Көнчыгыш һәм ислам культурасы күп гасырлар буе укыту һәм тәрбия эшендә уңышлы файдаланылган.

Югарыда күрсәтелгән принцип татар милли мәгарифен үстерү концепциясенең нигезен тәшкил итәргә тиешлеге аңлашыла булса кирәк.

Татар мәгарифен үстерү концепциясе Татарстаннан читтә яшәүче татарларны да күздә тотып төзелде.

Концепциянең безнең Республикада киң фронт белән гамәлгә ашырылуының сәбәбе шунда, бу эш концепция төзү белән генә тукталмады, ә концепцияне тормышка ашыруның конкрет программасы төзелде һәм аның үтәлеше мәгариф министрлыгы, район һәм шәһәр мәгариф бүлекләре тарафыннан даими контрольдә булды.

Татар мәгарифен үстерү программасындагы кайбер чараларны искә төшерү урынлы булыр. Иң беренче чиратта татар теленең дәрәҗәсен, ролен күтәрү чаралары күрелде, аның иң үтемле һәм нәтиҗәле юлы итеп балалар бакчасында тәрбияләнгән балалардан алып урта мәктәпләрдә укучы һәр сыйныф баласына да татар теле һәм әдәбияты мәҗбүри дәрес итеп кертелде. 1991 елның 1 сентябреннән бу эш гамәлгә керде.

Балаларны татар мәктәбендә ана телендә укытуга күчерү чаралары түбәндәгеләр иде:

а) татар гимназияләре, лицейлары ачу. Махсус уку планы буенча белем бирә торган бу тип уку йортларының гадәти урта мәктәпләрдән өстенлекләре күп иде. Шуңа күрә гимназияләрдә укырга теләүчеләр дә күп булды. Шәһәрләрдә, район үзәкләрендә шактый санда лицей һәм гимназияләр ачылды;

б) лицей һәм гимназияләрдә укырга барлык балаларның да хәзерлекләре җитмәскә мөмкин. Мондый очракта алар татар мәктәпләрендә укый алалар;

в) тулысынча татар мәктәбе оештыру мөмкинлеге булмаганда рус мәктәбендә I класстан башлап татар класслары ачу;

г) рус мәктәпләрен татар мәктәбенә әйләндерүнең тагын бер юлы тәкъдим ителде. Бу шәһәр шартларында микрорайоннарда балаларны бер мәктәптән икенчесенә күчерү уңайсыз булган очракта эшләнде. Рус мәктәбенең I классына татар балалары гына алына, башка классларда укулар рус телендә дәвам итә. Киләсе елга тагын I класска татар балалары алына. Шулай итеп 10 елдан рус мәктәбе татар мәктәбенә әйләндерелә.

Республикада барлык балаларга да татар теле керү һәм татарча укыта торган уку йортларының саны арту укытучы кадрларны күпләп хәзерләү кирәклеген китереп чыгарды. Шул уңайдан яңа шартларда эшләүче педагогик кадрларны хәзерләүнең яңа концепциясе төзелде.

Программаны үтәүнең конкрет чараларыннан районнардагы һәм шәһәрләрдәге мәгариф бүлекләре мөдирләренең милли мәгариф буенча ярдәмчеләре, урта мәктәп директорларының милли мәгариф буенча ярдәмчеләрен билгеләүне дә санарга кирәк. Программаны үтәүдә аларның файдасы күп булды.

Милли мәктәпнең күтәрелеше халыкның этнос буларак үсүенә китерде. Чыннан да этник күтәрелеш белән милли мәктәп арасында турыдан-туры бәйләнеш бар. Беренчедән, этник культура элементлары милли мәктәп үсе-

шенең нигезен тәшкил итә. Икенчедән, милли мәктәп халыкның этник үсешен тормышка ашыручы магистраль юл ул.

Милли мәктәп этносның милли культурасын формалаштыра, дидек. Ләкин милли мәктәпнең максаты бу гына түгел әле. Милли мәктәп этносны соңгы елларда дөньяда барган цивилизацияле үсешкә, мәдәни-социаль-демографик үзгәрешләргә дә хәзерләргә тиеш. Ә моның өчен милли мәктәпләрдәге укытуның эчтәлеген, уку планнарын бу үзгәрешләргә яраклаштырып үзгәртеп, камилләштереп торырга кирәк.

Милли мәктәпләрдә хезмәт тәрбиясенең әһәмияте зур. Укучыларны тормышка әзерләү иң мөһим проблемаларның берсе. Этносның хезмәткә әзерләү традицияләре исәпкә алынырга тиеш. Гомер-гомергә татар халкында агач эшкәртү, агач материалы белән корылмаларны бизәү, алтын, көмеш белән, тире белән эшләү, чигү һ. б. юнәлешләрдә эшләү алга киткән булган. Болар милли мәктәптә үз урынын алырга тиеш. Чөнки онытылып баралар иде. Бу уңайдан Ерак көнчыгыш һәм төньяктагы аз санлы халыкларның балаларын хезмәткә әзерләүдә җибәрелгән хаталар гыйбрәтле. Унитар мәктәп системасы тәртипләре буенча ул балаларны шәһәрләрдә укыталар, интернатта торалар, аларны хезмәткә әзерләү дә шәһәр шартларына яраклаштырыла иде. Мәктәпне тәмамлап өйләренә кайткан бу балалар эшкә керешергә тиеш. Ул җирлектә халыкның төп шөгыле болан асрау һәм аучылыктан гыйбарәт. Ә балалар әлеге хезмәткә өйрәтелмәгән. Мондый хәл килеп чыкмасын өчен милли мәктәпләр укучыларны хезмәткә хәзерләүне көчәйтергә тиеш. Шуның белән беррәттән хезмәткә хәзерләре хәзерге заман икътисадына яраклаштыру да мөһим чараларның берсе. Милли мәктәпләрдә укучыларны тормыш өчен түбән квалификацияле эшче кадрлар итеп кенә әзерләү дип аңламаска кирәк, цивилизацияле җәмгыять нинди кадрларга мохтаҗ, шуңа хәзерләнергә кирәк. Хәзерге көндә Япония дәүләте тормышның барлык юнәлешләрендә гүзәл уңышларга ирешкән икән–моның сәбәбе мәктәптә. Япония мәктәпләрендә укучыларга тирән белемнәр дә бирелә, тиешенчә хезмәткә әзерлек тә булдырыла.

Милли мәгарифне тиешенчә үстерүдә объектив һәм субъектив кыенлыклар да бар: федераль һәм милли-региональ дәрәҗәдә милли мәктәпләрнең максаты һәм укучыларга биреләсе белемнәр эчтәлеген килештерүдә каршылыклар бар, күп сандагы уку планнарыннан кирәклесен сайлап алу өчен нигезле рекомендацияләр юк дәрәҗәсендә, белем стандартының милли-региональ компоненты тиешенчә эшләнмәгән һ. б.

Алга таба эшләнергә тиешле чараларга тагын түбәндәгеләрне өстәр идем:

— бүгенге көн һәм алдагы еллар өчен милли мәктәпнең укыту эчтәлеге буенча гомуми теориясен булдыру;

— белем стандартының федераль һәм милли компонентларында милли культура, күршеләр культурасы һәм дөнья культурасы кыйммәтләренең оптималь бәйләнешен булдыру;

— милли мәктәпләрнең матди-техник базасын ныгыту, аларда эшләү өчен хәзерлекле кадрлар хәзерләү.

Бу шартларны үтәгәндә милли мәктәпләрнең алда торган бурычларны үтәп чыгуына шикләнмәскә мөмкин.

Шакир
Яһүдин,
*Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы аппаратының
Хокук идарәсе башлыгы,
юридик фәннәр кандидаты*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕНДӘ ҺӘМ ЗАКОННАРЫНДА МИЛЛИ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР

Татарстан Республикасының, сәяси-хокукый табигате ягыннан дәүләт буларак, үзендә яшәүче күптөрле милләт вәкилләренең, шулай ук үзбилгеләнү хокукын тормышка ашыруга ирешкән татар халкының ирекен чагылдыру юллары шактый. Татарстан Республикасы Конституциясе һәм законнары — шуларның берсе.

1992 елда кабул ителгән Татарстан Республикасы Конституциясе республика законнарының төшен-үзәген тәшкил итеп, Татарстанның яңа дәүләтчелеген гәүдәләндерә, аның үсешенең каршылыклы чорларын да чагылдыра. Татарстан Конституциясе кабул ителгәннән соң үткән 14 ел эчендә генә дә Төп канун ундүрт мәртәбә үзгәреш кичерде. Әлеге өстәмәләр һәм үзгәрешләр Татарстан Республикасының дәүләти табигатен камилләштерү, шулай ук конституцион нормаларны яңа федераль законнар белән тәңгәлләштерү зарурлыгыннан чыгып кабул ителде. Татарстан Республикасы Конституциясе — Татарстан җәмгыятенең һәм дәүләтенең үсеш үзенчәлекләрен чагылдыручы төп сәяси-хокукый һәм программачыл документ.

Россия федерализмының милли-дәүләти үзенчәлеккә ия булуы — аның иң мөһим һәм аерылгысыз факторы. Россия Федерациясе составындагы республикалар шуның бер чагылышы инде. Милли дәүләтчелек Россия дәүләтенең тотрыклылыгын, бердәмлеген һәм бөтенлеген тәэмин итү өчен шулкадәр мөһим ки, хәтта шуннан башка аның тиешенчә, демократик мәмләкәт булып, һәръяклап үсешен күз алдына да китереп булмый.

Шуңа күрә дә Россия Федерациясендә милли дәүләтчелек ягына игътибарны киметмичә, киресенчә, эзлекле рәвештә аның үсешен тәэмин итү, килеп туган мәсьәләләрне үз вакытында хәл итү зарур.

Ләкин Россия федерализмының милли-дәүләти үзенчәлеген күрмәмешкә салышу тенденциясе, милли һәм дини принциплар буенча кеше хокукларын бозу очракларының ешаеп китүе республикада җитди борчылу тудыра. Чөнки бу Россиядә гомер бакый яшәгән халыкларының конституциячел хокукларын, шулай ук халыкара хокукларын, гомумтанылган принциплар һәм нормалар белән гарантияләнгән хокукларын бозуга китерергә мөмкин. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары шул уңайдан Россия Федерациясендә милләтара һәм динара тынычлыкка һәм татулыкка тукынуны булдырмау буенча кичекмәстән дәүләт чаралары күрү кирәклеге турында узган ел башында ил җитәкчелегенә мөрәҗәгать кабул иттеләр. Бу мөрәҗәгать Россия Федерациясенең күп кенә субъектларында, шул исәптән республикаларда да хупланды.

Республикалар — Россия сәяси тормышының уникаль бер күренеше ул. Үз территориясендә яшәүче барлык күпмилләтле халыкның ихтыярын һәм мәнфәгатьләрен чагылдырып, алар субдәүләтләр буларак бер үк вакытта милли туплану үзәген дә тәшкил итәләр, үзләрендә яшәүче, сәяси яктан үзбилгеләнгән кечкенә һәм аз санлы халыкларның милли үзенчәлекләрен саклап калалар һәм үстерәләр, моңа исә федераль дәрәҗәдә дә, милли-мәдәни автономияләр аша да ирешү мөмкин түгел.

Республикалар, бер яктан, федерациянең барлык субъектлары өчен уртак булган функцияләрне үтәсәләр, икенче яктан, халыкларны гомумроссия сәяси тормы-

шында яшәтеп, үзбилгеләнү хокукын гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функцияләрен башкаралар. Республикалар, күргәнебезчә, актуаль сәяси бурычларны үтиләр.

Татарстан Республикасы Конституциясе, аның преамбуласында бәян ителгәнчә, халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукына, аларның тигез хокуклыгы, ихтыяр белдерү иреклелеге принципларына нигезләнеп, Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм татар халкы ихтыярын чагылдыра.

Республикадагы реаль икетеллелектән чыгып, Татарстан Республикасы Конституциясенең 8 маддәсендә (статьясында) тигез хокуклы татар һәм рус телләре дәүләт телләре дип билгеләнә, һәм алар Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында, дәүләт учреждениеләрендә бертигез нигезләрдә кулланыла.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституциясенең 34 маддәсендәге 2 өлеше нигезендә «һәркем туган теленнән файдалану, аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат итү телен ирекле сайлап алу хокукына ия».

Республикабызның күпмилләтле халкы ихтыяҗларын, үтенечләрен һәм мәнфәгатьләрен әлеге органнар һәм учреждениеләр генә тәэмин итми, республиканың дәүләт телләрен — татар һәм рус телләрен Татарстан территориясендә урнашкан Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең территориаль органнарында, «вертикаль»ләкләренә карамастан, теләсә кайсы учреждениедә һәм оешмада да тулысынча һәм тигез дәрәҗәдә куллануга ирешергә кирәк. Бу эш эшләнә, әмма һәрвакытта да һәм һәркайда да түгел.

Татарстан Республикасында дәүләт телләрен куллану «Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләр турында»гы Закон белән җайга салына. 2004 елның 11 октябрендәге Татарстан Республикасы Законы нигезендә 2004-2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклап калу, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы расланды.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 9 маддәсендәге 4 өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең барлык органнарына үз вәкаләтләрен башкарганда Татарстан Республикасының тарихи, милли һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алу бурычы йөкләнде.

Татарстан Республикасының конституциячел төзелеш нигезен аның 14 маддәсендә язылган, «Татарстан Республикасыннан читтә яшәүче татарларга милли мәдәниятне, телне үстерүдә, аларның үзенчәлекләрен саклап калуда ярдәм күрсәтә» дигән нигезләмә ачык чагылдыра. Бу — Татарстанның тышкы вазифаларының берсе. Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр буенча әлеге вәкаләтләрне башкару өчен кирәкле мөлкәт «Татарстан Республикасының дәүләт мөлкәте турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә республиканың дәүләт милкендә булырга мөмкин.

Конституциядә Татарстанның, дәүләт буларак, мәдәни эшчәнлегенең интернациональ төстә булуы күрсәтелә. Мәсәлән, 57 маддәнең 5 өлешендә «Татарстан Республикасы интеллектуаль һәм сәнгать мирасын саклап калуны һәм яклауны, татар халкының мәдәниятен, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче башка халыклар вәкилләренең милли мәдәниятләрен саклап калуны һәм үстерүне тәэмин итә» диелә. Шуны билгеләп үтү мөһим, Татарстан Республикасы Конституциясе текстында милли дигәндә «татар милләте» генә түгел, «башка милләт» тә аңлашыла. «Татарстан Республикасында Милли-мәдәни автономияләр турында» Законны мисал итеп китерергә мөмкин.

Шуңа бәйләп, бер фактны әйтеп үтәсем килә. Россия Федерациясендә «милли» сүзе «гомумдәүләт» сүзенә синоним буларак кулланыла башлады, мәсәлән, «өстенлекле милли проектлар». Ләкин Россия Федерациясе Конституциясендә һәм федераль законнарның күпчелегендә әлеге термин үзенең беренчел мәгънәсен дә, «этник» сүзенең синонимы буларак кулланыла. Чит ил алынмаларын кулланган очракта, үз сүзләребезнең мәгънәсенә һәм, барыннан да элек, аның конституциячел хокукый асылына саграк карау теләген җиткерәсе килә.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 80 маддәсендә һәм Татарстан Республикасы Регламентында Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус телләрендә кабул ителүе һәм бастырып чыгарылуы, татар һәм рус телләрендәге

законнарның текстларын тәңгәлләштерү турында нигезләмә бар. Тәңгәлләштерү максатында парламентта махсус комиссия эшләп килә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламенты һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетлары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Парламентының, аның Президиумының һәм комитетларының эше ике дәүләт телендә алып барыла. Моннан тыш, Дәүләт Советының структурасында аның милли үзенчәлеге исәпкә алына. Парламент депутатларының 65 процентын татарлар тәшкил итә. Дәүләт Советында Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты актив эшли. Татарстан Республикасы Президенты — Татарстан Республикасының дәүләт башлыгы, иң югары урындагы заты. Әмма, вакытлыча дип әметләник, Татарстан Республикасы Конституциясенең 91 маддәсендәге, аерым алганда, Татарстан Республикасы Президентының дәүләт телләрен белү турындагы нигезләмәнең гамәлдә булуы туктатылды. Чөнки вәзгыять үзгәрде, Татарстан Президенты, элеккечә, республикада яшәүче халык тарафыннан сайлап куелмый. Аңа, Россия Федерациясе Президенты тәкъдиме буенча, Татарстан парламенты тарафыннан вәкаләтләр бирелә.

Россия Федерациясе Дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм вәкаләтләр бүлешү турындагы яңа Шартнамәдә, язма авторы аны әзерләүче эшче төркемгә керә, әлеге өстәмә таләп исәпкә алынды. Хәзерге вакытта әлеге Шартнамәне раслаучы федераль закон проекты Россия Федерациясенең Федераль Җыены каравында.

Татарстан Республикасы Конституциясенең 93 маддәсендәге 3 һәм 4 өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Президенты үз вазифасына керешкәндә Татарстан Республикасы халкына һәм Конституциясенә тугрылыклы булуы турында ике дәүләт телендә дә ант итә, ә бу ике телне дә ким дигәндә ант текстын игълан итәрлек дәрәҗәдә белүне күздә тота. Татарстан Республикасы Конституциясенең 121 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасының Дәүләт гербы, Дәүләт флагы һәм Дәүләт гимны Татарстан халкының үзенчәлеген һәм традицияләрен чагылдыручы дәүләт символлары булып тора, алардан файдалану тәртибе «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Закон белән җайга салына.

Милли үзенчәлекләр Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты юлламаларында, Указларында, Хөкүмәт карарларында, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары актларында күбрәк исәпкә алына.

«Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында» Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы көне — 30 август, Татарстан Республикасы Конституциясе көне — 6 ноябрь һәм Корбан бәйрәме — ял көннәре дип билгеләнә. 26 апрель — Туган тел көне шулай ук бәйрәм көне дип игълан ителде. Республикада язгы кыр эшләре тәмамлангач, татар халкының милли бәйрәме «Сабан туе» һәм рус халкы бәйрәме «Каравон» билгеләп үтелә. Законда башка милли-этник, шулай ук дини бәйрәмнәрне үткәрү дә регламентлана. Республикада милли әдәбиятны, сәнгатьне һ. б.ларны үстерүдәге казанышлары өчен гражданнарга дәүләт бүләкләре бирелә. Мәсәлән, «Татарстан Республикасы Дәүләт бүләкләре турында» 2004 елның 24 мартындагы Татарстан Республикасы Законында аларның түбәндәге төрләре каралган: «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, «Фидакарь хезмәт өчен», «Ана Даны-Материнская Слава» медальләре, Татарстан Республикасының Мактау грамотасы һәм Татарстан Республикасының Мактаулы исемнәре (барлыгы 44 мактаулы исем).

«Мәгариф турында» 1993 елның 19 октябрендәге (һәм аннан соңгы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Законы нигезендә татар һәм рус телләре, дәүләт телләре буларак, татар һәм рус әдәбияты мәктәпкәчә, гомуми, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә бертигез күләмдә өйрәнелергә тиеш. Россия Федерациясе Конституция судының 2004 елның 16 ноябрендәге 16 нчы карарында Татарстанның мондый хокукы расланды.

Тиешле дәрәҗәдә белемле белгечләр әзерләү максатында югары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә уку-укыту Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, шулай ук чит телләрдә алып барыла.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты халыкара килешүләр һәм Рос-

сия Федерациясе субъектлары белән төзелгән килешүләр нигезендә Татарстан Республикасы территориясеннән читтә яшәүче, татар милләтеннән булган затларга туган телдә тиешле белем алырга ярдәм итә. Мәктәпкәчә белем бирү өлкәсендә ата-аналарга яисә аларны алмаштыручы затларга, беренче педагоглар буларак, балада туган телгә мәхәббәт уяту һәм туган телне өйрәтү бурычы йөкләнә.

Дәүләт телләрен куллануның төрле аспектлары шулай ук «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге (аннан соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы (аннан соңгы үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлаулар турында» 2003 елның 22 сентябрендәге ( аннан соңгы үзгәрешләре белән), «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы, «Татарстан Республикасында муниципаль сайлаулар турында» 2004 елның 24 мартындагы һ.б. законнар белән регламентлана.

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» Закон нигезендә гражданнар үзләренең тәкъдимнәре, гаризалары, шикаятьләре белән Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, туган телләрендә яисә Россия Федерациясе халыкларының үзләре белгән башка теләсә кайсы телендә мөрәҗәгать итәргә хаклы. Гражданнарның тәкъдимнәренә, гаризаларына, шикаятьләренә җаваплар мөрәҗәгать иткән телдә бирелә. Мөрәҗәгать иткән телдә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

Югарыда бәян ителгәннәр Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм законнарында милли үзенчәлекләрне исәпкә алу системасының шактый киң кырлы булуын дәлилли һәм бу республикада милли һәм дини толерантлыкны, милләтара дуслык һәм татулыкны тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Шуның белән бергә, әгәр федераль хакимият Россия Федерациясендә конституциячел төзелеш нигезләренә таянып, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен тиешенчә җайга салып, милли һәм дини үзенчәлекләрне исәпкә алу өчен хокукый мөмкинлекләр тудырса, ә уртак эшләрдә бары тик хокукый җайга салуны билгеле бер кысаларда гамәлгә ашырса, нәтиҗә тагын да зуррак булыр иде.

Шул рәвешле эш итү халыкара хокук принципларына һәм нормаларына, аерым алганда, граждани һәм сәяси хокуклар, икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында 1966 елның 16 декабрендәге Халыкара пактларның карарлары бернинди чикләүләрсез һәм чыгармаларсыз федератив дәүләтләрнең барлык өлешләренә дә кагыла дигән нормаларына туры килер иде. Ә бу пактларда халыкларның һәм кешенең фундаменталь хокуклары таныла. Әлеге Халыкара пактларның беренче өлешләрендә һәм маддәләрендә үк халыкларның хокуклары күрсәтелә һәм аларның өстенлеге билгеләнә. Бу мәгънәдә Татарстан Республикасы Конституциясенең 34 маддәсендәге беренче өлешендә «һәркем үзенең милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә хокуклы, беркем дә үз милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә мәҗбүр ителә алмый» дигән нигезләмә зур әһәмияткә ия.

Пактларда барлык халыкларның да үзбилгеләнүгә хокукы таныла. Бу хокук нигезендә алар үзләренең сәяси статусларын ирекле рәвештә билгелиләр һәм үзләренең икътисади, социаль һәм мәдәни үсешләрен ирекле рәвештә тәэмин итәләр.

Барлык халыклар да үз максатларына ирешү өчен үзара файдалылык принцибына нигезләнгән халыкара икътисади хезмәттәшлеккә, халыкара хокукка бәйле нинди дә булса йөкләмәләргә зыян китермичә үзләренең табигый байлыклары һәм ресурслары белән ирекле эш итә алалар. Бер генә халык та, бер генә очракта да үзенең яшәү чыганакларыннан мәхрүм ителә алмый.

Пактларда катнашучы барлык дәүләтләр үзбилгеләнү хокукын гамәлгә ашыруны хупларга һәм ихтирам итәргә тиеш.

Күргәнебезчә, халыкларның халыкара танылган хокукларын гамәлгә ашыру өчен Россия федерализмының һәм парламентаризмының эше җитәрлек әле.

# «ЯҢА» ТАКТАШ — УЛ НИНДИ?

Совет чоры тәнкыйтьчеләре Һади Такташ иҗаты турында сөйләгәндә әдипнең үзен «революциянең бөек шагыйре» дип атадылар, ә иҗатына «социалистик илгә, Ленин идеяләренә чын күңелдән бирелгәнлек хисе белән сугарылган» дип бәя бирделәр (Х. Госман, Х. Хәйри, М. Мамин һ. б.). Аларның уртак фикере мондый иде: Романтик гыйсъянчы-бунтарь шагыйрь революцияне котлап, зур өметләр белән каршылады, иске тормышка ризасызлык белдереп, Аллага, төрле кануннарга, дини богауларга каршы протест белән чыга.

Әйе, «гыйсъянчы» дигән атама шагыйрь Такташка шактый ук нык ябышкан. Шуңа күрә безгә дә бу очракта иң элек «гыйсъянчылык» төшенчәсенә тукталып китү кирәк. А. Әхмәдуллин төзегән «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә Ш. Садретдинов тарафыннан бирелгән белешмәдән аңлашылганча, гыйсъянчылык — XX йөз башы, бигрәк тә егерменче еллар татар романтик әдәбиятында Алла һәм дин-шәригать кануннарына, иске тормыш тәртипләренә, социаль явызлыкка каршы ярсып баш күтәрү, аларны тулысынча инкарь итү, билгесез яңа тормышка омтылу белән характерлы юнәлеш.

«Гыйсъян» төшенчәсенә халыкның иске стройга нәфрәте ташып, баш күтәрүе, яу булып калкып чыгуы, революция ясау шикелле зур иҗтимагый мәгънә бирелә. Әмма революциянең стихияле көчләре, шәхес бунты алгырак планга чыга. Гыйсъянчы лирик герой иске җәмгыятьтә изелгән һәм җәберләнгән, ә хәзер инде азат һәм горур көрәшчеләр сафына килеп кушылырга омтылучы, әмма әлегә индивидуалистик төсмерен саклаган, бунтарьлык һәм трагик сыйфатларыннан арынып бетмәгән кеше булып күз алдына килә. Анардан ярсулы сугышчан рух бәреп тора, теләк-омтылышлары кискен, драматик, шигъри монологында патетика һәм полемика тоны өстенлек итә.

Егерменче еллар татар поэзиясендәге мондый мотивларны әдәбият галимнәре К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Максуд, Н. Исәнбәт, М. Җәлил һ. б.лар иҗатында зур урын алды дип билгеләделәр. Мәсәлән, филология фәннәре докторы Г. Халит: «Егерменче еллар башындагы татар поэзиясендә үзен көчле генә бер романтик агым итеп күрсәткән гыйсъянчылык хәрәкәтен Такташтан башка күз алдына китерү кыен. Гыйсъянчылык героик индивидуализм романтикасын дәвам иттерде һәм аны мещанлык индивидуализмына, аның сәнгатенә, мораленә, диненә каршы куйды,» — дип аңлата. «Һади Такташ иҗатының беренче чорында да тыныч кына сөйли алмый иде. Ул гыйсъянчы булып, индивидуаль бунт күтәреп чыкты, илаһи көчләргә кискен протест ясады,» — дип билгеләде М. Мамин[1].

«Романтик ашкынулы шашкын хисләр дөньясы, чынбарлыкны космик киңлек белән масштаблы итеп, социаль контрастларда, һәртөрле искелеккә, явызлыкка каршы кискен көрәш рухы, ярсу хисле лирик геройны алгы планга чыгару — Такташ балладаларында, лиро-эпик поэмаларында ачык күзгә ташланган мөһим хасиятләр»[2].

Шулай итеп совет чорында әдәбият белгечләре Һ. Такташны искелек дип кабул

---

[1]Мамин М. Һади Такташ поэзиясе. — Казан: Таттосиздат, 1952.
[2]Госман Х. Егерменче елларда татар поэзиясе. — Казан: Казан университеты нәшрияты, 1964.

ителгән милли идеяләргә, дини йола, гореф-гадәтләргә каршы аяусыз бунт күтәрүче гыйсъянчы шагыйрь, революцияне шатланып каршы алучы көрәшче буларак күрсәттеләр.

Идеология кысаларыннан арынып, әдәбият тарихына карата гадел булган карашларны белдерергә ярый торган заманалар житкәч, Такташ иҗатына бәя бирү шулай ук жинелләрдән түгел. Шунлыктан Такташның башлангыч чор иҗаты турында сөйләгәндә әдипнең гыйсъянчылык серләре ачылмый кала бирде. Бу хакта язучы Рабит Батулла да: «Такташның беренче чор иҗаты әле һаман тиешле бәясен алмаган[1]», — дип саный.

Т. Галиуллин да шундый фикердә. «Дөрес, хәзер хәлләр яхшы якка үзгәрде, халыкның рухи дөньясында дини мохиткә дә урын табылды. Сталинчыл кара еллар, торгынлык чорында, ышаныч-иманга кизәнү абруй саналган елларда Такташның башлангыч чор иҗаты тиешенчә бәяләнмәде, — дип саный галим, — символик, абстракт образлар белән мавыккан бер модернистик чоры буларак кына каралды, идеологиясе мөгез шикелле алга чыгып, күзгә бәреп торган әсәрләре күкләргә чөелә, мәдхиягә күмелә[2]».

Чынлап та, тарихи мәгълүматларны барлап, әдип әсәрләрен кайта-кайта укып анализлаганнан соң, Һади Такташ иҗатының беренче яртысына совет чорында бирелгән бәяләр белән килешәсе килми. Безнең фикеребезчә, Такташ иҗатының беренче яртысы әле өр-яңадан өйрәнелеп, дөрес бәягә лаек булуны таләп итә. Совет чорында Такташ иҗаты партиялелеккә нигезләнеп аңлатылса, бүгенге шартларда шагыйрь иҗатына объектив бәя бирүдә тарихилык мөһим методологик принцип булып тора.

Такташ иҗатын үз чорына, андагы вакыйгаларга бәйле рәвештә анларга тырышу унай нәтижә бирә. Төрле бизәкләргә буямыйча, чынбарлыктагыча язылган-тарихи вакыйгаларны белү Такташны борчыган мәсьәләләрне, әдипнең теләк-омтылышларын ачыкларга ярдәм итә. Ә чын тарих бүтәнрәк иде. Социалистик революциягә әзерлек елларында большевиклар бик кешелекле лозунглар күтәреп чыктылар: жир, азатлык, тигезлек, тынычлык вәгъдә иттеләр. Шуның белән алар халыкны инкыйлаб хәрәкәтенә жәлеп итә алдылар. Әдәбият, сәнгать тә шул ук идеяләр белән рухланды. 1919-елда гына да Ф. Бурнаш революция казанышларын яклап көрәшүнең изгелеген, бу юлдагы фажигаләрне яктырткан берничә поэма язды. Ләкин чынлыкта тигезлек дигәннәре жәмгыять әгъзаларының күпчелеген, һәрхәлдә житәкчелектән читтә торганнарын, ярлылык ягыннан тигезләү булып чыкты, рәсми документларда, әсәрләрдә фәкыйрьлек озак вакытлар буенча горурлык күрсәткече булып йөрде, фәкыйрьлек гүзәллеге, бушка эшләүнең күркәмлеге жырланды. Ярлылыкны тотрыклы саклау юнәлешендә дәүләт дөнья күләмендә сизерлек уңышларга иреште. Тигезләү мөлкәтне тартып алу, талау юлы белән барды. Нәтижәдә тынычлык урынына илдә гражданнар сугышы кабынып китте. Авыл халкы жирдән мәхрүм ителде, азатлык урынына партия, хакимият диктатурасы урнашты. Эзләнүләр Такташ шушы вакыйгаларны алдан ук сизеп, белеп торган, дип уйларга этәргеч бирә.

Һ. Такташ 1914 елгы сугыш елларында яза башлый. Бер гаепсез кешеләрнен бер-берсен үтерүләре, илдәге ачлык яшь шагыйрь күнеленә коточкыч явызлык, хаксызлык булып кереп утыра. Такташ яшьлегенең бөтен ялкыны, хисләрнең бөтен дәрте белән Жир шарындагы явызлыкны гаепләргә керешә. Октябрь революциясе, гражданнар сугышындагы кан коюлар да, егерме беренче елдагы ачлык та аның явызлыкка каршы көрәш дәртен сүндерми, киресенчә, көчәйтеп кенә жибәрә.

Такташның 1914 — 1922 елларда ихлас күңелдән, килешмәүчән рухта язган әсәрләрен башлангыч иҗат чорына кертеп йөртәләр. Бу елларда Һади Такташ дөньяны бөтен бер бәхетсезлек итеп күрә.

[1]Такташ: Истәлекләр, шигырьләр / Төз. Р. Батулла, Р. Корбан; — Казан: Татар. китап нәшрияты, 2001.

[2]Галиуллин Т. Бөек хыяллар, олы хисләр жырчысы: (Һ. Такташның 100 еллыгына) // Татарстан. — 2001. №1

«Фәрештәкәй, кач бу илдән! Монда вәхшәт, монда үлем», — ди ул «Газраилләр» шигырендә. «Фәхеш җир! Куенына шомлы еланнар ояласын инде!» — ди «Караңгы төннәр» әсәрендә. «Нишли дөнья, нишли ул? Ник күренми якты көннәр? Ник томанлы алгы юл?» — дип, «Төркстан сахраларында» шигырендә үзенә үзе һәм бер үк вакытта укучыларына да сорау бирә. «Күктән сөрелгәннәр», «Үтерелгән пәйгамбәр», «Ачлык патша» шигырьләрендә, безгә таныш «Җир уллары» трагедиясендә дә Һ. Такташ чынбарлыкка ризасызлыгын белдерә.

Әдипнең «Төркестан сахраларында» шигыре 1917 нче елны язылып, 1918 нче елның 21 нче январенда Ташкентта чыга торган «Олуг Төркстан» газетасының 54 нче номерында басыла.

Бу шигырьдән М. Мамин[1] Такташның революцияне яклап чыгуын, аны түземсезлек белән көтүен, шатланып каршылавын күрсәтергә тырыша. Совет чорындагы башка тәнкыйтчеләр дә шундый фикердә иде.

Такташның «Төркстан сахраларында» әсәре турында Р. Батулла[2] да үз фикерен әйтә. Бу әсәрне Такташның шул яклардагы сәяхәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип саный ул. «Урта Азиядә үзбәкләр, казахлар, төркмәннәр генә түгел, татарлар да бихисап күп яши иде. Татар язучыларының әсәрләрен татарлар гына түгел, бөтен Урта Азия мөселман халыклары үз итеп укый торган чак. Яңа гына Октябр революциясе булган. Бу революцияне беркем дә аңламый. Хәтта революционерлар үзләре дә анык кына аңламый, аңлата алмый. Тигезлек, туганлык, сәгадәт — коммунизм була, дип, буш сүз кычкырудан ары китә алмыйлар. ...Төркстан сахраларында йөргәндә дә Такташ Русиядә яшәүче ислам турында уйлый, кайгыра. Әлбәттә, әдип Русиядәге куркыныч хәл — революция турында сөйли. Революция Такташны сискәндерә. Ул аңа битараф түгел, әмма Такташ большевикларның Җир йөзендә фәкыйрьләр оҗмахы төзергә алынуларына шикләнеп карый кебек», — ди автор, шагыйрьнең түбәндәге юлларын мисалга китереп:

*Юк төсле ак күңелгә...*
*Монда михнәт, монда төн,*
*Монда сахра, моңлы сахра...*
*Барчасы тоткын бүген!..*

Чынлап та, ассоциацияләр Батуллача уйларга мәҗбүр итә.

Шагыйрьнең «Газраилләр» шигырен Х. Госман[3] империалистик сугышның ерткычлыгын, тинсез явыз җинаять булуын фаш итүче әсәр буларак бәяли. Совет чорындагы башка тәнкыйтьчеләр дә әлеге әсәргә шундый ук мөнәсәбәттә иделәр.

Р. Батулла[4] бу шигырьнең барлык сугышларга да каршы, шул исәптән, революциягә дә, гражданнар сугышына да каршы көрәш рәвешендә язылган булу ихтималлыгын әйтә. Болай уйлауның сәбәбе итеп, шигырьнең 1918 — 1920 елларда (автор бу хакта Гөлчирә Такташева-Мансуровадан сорашып белә), ягъни «илдә революция, кырылыш, үтереш барган вакытта язылган булуын китерә. «Такташ аның язылу вакытын, кызыл тәнкыйтьчеләр бәйләнмәсен өчен шулай — 1914 елгы Европа сугышына каршы дип куйган», — ди Батулла.

Шигырьнең 1923 елда гына басылган булуын исәпкә алсак, чынлап та, бу шигыре белән Такташ җир йөзендәге бөтен сугышларга каршы нәфрәтен белдерә һәм, шул исәптән, революциянең, гражданнар сугышының да барлык башка кан коюлар кебек үк ерткычлыгын тасвирлый дигән фикергә килә алабыз.

Һәр уңышлы әсәр — ул бик үзенчәлекле күренеш. Аны тикшерү өчен, үзенә генә яраклы ачкыч табу сорала. «Газраилләр» шигыре — фаҗигале әсәр. Гүзәллек корырга теләгән фәрештәнең гөлбакчасын газраилләр туздырып киткән. Җир йөзе гакылсызлар йортына әверелгән.

[1] Шунда ук. Алда күрсәтелгән хезмәт.
[2] Алда күрсәтелгән хезмәт.
[3] Госман Х. Такташ поэзиясе. — Казан: Таттосиздат, 1953.
[4] Алда күрсәтелгән хезмәт.

*Кучеп тиз-тиз бер йолдыздан бер йолдызга,*
*Бик күп еллар матур гөлләр җыеп йөрде...*
*Кайтса кире җир өстенә: нинди дәһшәт!*
*Сөякләрдән таулар, каннан күлләр күрде.*
*Хәят иле, матур йолдыз, янып сүнгән;*
*Тапталып гөл баглары көлгә дүнгән;*
*Матур кырлар, бәхет-җәннәт урманнары*
*«Гакылсызлар» йорты булып әверелгән.*

Хәер, сугышның кайсы да начар инде. «Газраилләр» шигырендә сугышның дәһшәтен, халыкка бетмәс-төкәнмәс кайгы-хәсрәт китерүен «күз яшеннән һәйкәл кою» дәрәҗәсендә көчәйтеп сурәтләнгән.

*Мин караңгы сахраларда*
*Канлы күз яшьләр җыям,*
*Ил каны һәм күз яшеннән*
*Зур, бөек һәйкәл.*

Сәяси хәлләр Такташ кебек киң карашлы татар язучыларын битараф калдырмый, билгеле.

"Нәләт» шигырендә лирик герой җирдәге гаделсезлек, вәхшәт өчен борчыла.

*Күк читендә канлы пәрдә,*
*Әллә кемнәр:*
*— «Тан» диләр,*
*— «Таң» түгел ул, җиргә төшкән*
*Шомлы каргыш, кан диләр.*

*Алда, артта шаулый туплар,*
*Уйный уклар шәүләсе,*
*Баскан эз — гүрлек — каберлек,*
*Канлы илнең гәүдәсе...*

Егерменче еллар башындагы чынбарлык — гражданнар сугышы илне хәерчелеккә төшергән, завод-фабрикалар эшләми. Җир сөрелеп бетми, мал таланган. 1921 ел ачлыгы. Сыйнфый көрәш белән булышу. Җыен булдыксызның җитәкче булуы. Бюрократизм көчәю. Такташ боларның барысын да «вәхшәт», «гаделсезлек» дип атый.

*Бер баһадир чыкты мәйданга —*
*Кылычын ташлады,*
*Кайгылы илгә торырга*
*Йорт корырга башлады...*
*Тик анын йорт нигезенә*
*Куйган авыр ташлары*
*Булды гәүдә һәм батырларның*
*Киселгән башлары...*

Мәетләр өстенә салынган сарай Такташ кебек намуслы, шәфкатьле кешенен идеалы була алмый. Кан кою бәрабәренә төзелгән тормышның шатлык, бәхет китерәсенә ышанмый шагыйрь. Берәүләр шатлык белән «таң» атуы турында хәбәр итә. Икенче берәүләре аңа каршы төшә дә, таң түгел ул, «кан» ди. Ягъни кемдер кемнедер: «Бәхетле тормыш корабыз, таң ата, яна, матур, мул җәмгыятьтә яшәячәкбез», — дип шатландырырга тырыша; икенче берәве: «Юк, бу алдау гына, ялган гына, бернинди дә тигезлек, мул тормыш булмаячак, бары тик туган туганны кырыш, үтереш булачак», — ди. Менә шушы шик, шушы янгыраш Такташнын беренче чордагы иҗатында буеннан-буена бара.

Илнең эчке һәм тышкы мәнфәгатьләре белән яшәү Такташ өчен иң әһәмиятле һәм матур сыйфатлардан берсе булып әверелде. Ул сәяси атмосфераны бик яхшы сизә торган шагыйрь булды, үткен сәяси вакыйгаларны образлы чагылдырырга омтылды.

«Күктән сөрелгәннәр» шигырендә үз иленнән, үзенең яши торган җиреннән куылган шәхесләр турында сүз бара. Үзе яшәгән җирдә ул «йолдыз», яки күренекле кеше булган:

*Ул да шулай кайчандыр бер күк кызы иде,*
*Янып торган күкнең шәфкать йолдызы иде.*

Кешелеккә гаделлек, яхшылык теләгәне өчен аны:

*Хаинә син! Синең урының — суык зиндан! —*

дип үзенең яши торган җиреннән куалар, зинданга ябалар.

Күренекле татар зыялыларын да халыкка, милләткә хезмәт иткәннәре өчен, «милләтче», «халык дошманы» ярлыгы тагып, нахак гаепләр ягып, сөргеннәргә озаталар, төрмәләргә ябалар, юк итәләр. «Күктән сөрелгәннәр» шигырендә дә нәкъ шушы тарихыбыз, чынбарлык турында сүз бара булса кирәк. Киләчәктә бу хакыйкатьне барыбер белерләр дип ышана Такташ һәм Газраил сүзләре белән шуны раслый.

*«Сөйлим хаклык мәзлум адәм улларына!» —*
*дип чорга яный, шулай юана шагыйрь.*

Шигырьдәге «оҗмах» — ул большевикларның киләчәктә яхшы, бәхетле тормыш булачак дип алдаулары. Ә шушы оҗмахны вәгъдә итүчеләрнең җитәкчесен бу шигырендә «Алла» дип атаган шагыйрь.

*Мин беләмен, бар күкләрең, гаршең синең*
*Энҗеләнгән җирдәге күз яшь, кан белән!*
*Хәзер белдем, бар фәрманың, хөкмең синең*
*Тулган алдау, канлы үлем, ялган белән!*

Кеше каны бәрабәренә төзелгән тормышның яхшыга илтмәячәген шагыйрь күңеле аңлый. Тарихка мөрәҗәгать итик әле: «Илне идарә итүче большевиклар, җәмгыятьтә бай да, ярлы да булмасын, дип барсалар да, киләчәктә һәммә кешене фәкыйрьлеккә төшерергә генә сәләтле булып чыгалар[1]».

Шул фаҗигане аңлап торган шагыйрь йөрәге ничек сыкранмасын?! Кешелеккә ярдәм итә алмау чарасызлыгыннан ул «Үтерелгән пәйгамбәр» шигырен яза.

Фәүзия Бәйрәмова бу шигырьгә багышланган «Дардагы пәйгамбәр» исемле мәкаләсендә шагыйрь фаҗигасе турында саллы гына фикерләрен әйтә. Шагыйрьне, иҗатының башлангыч чорында ук, «җидегәнчеләр» ярлыгы тагып, эзәрлекләүләре турында сөйләнә ул мәкаләдә. М. Җәләлиеваның «Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре» хезмәтендә «Үтерелгән пәйгамбәр» шигыренең идеясе турыдан-туры Һ.Такташның шәхси язмышы аспектында ачылганлыгы әйтелә.

«Үтерелгән пәйгамбәр» шигырен Такташ 1918 елда яза. Пәйгамбәр — лирик герой — гаделсезлеккә каршы көрәшүче зыялы шәхес.

*Кояш — шаһит: илем, иркем өчен*
*Сугышып йөрдем, әнкәй, ул күрде!*

[1]Госман Х. Такташ поэзиясе. – Казан: Таттосиздат, 1953.

Хаклыкны әйтергә ярамый, дин һәм милләт өчен тугры хезмәт итү тыела — шагыйрь көчсез, үле кеше белән бер. Шуңа күрә ул үзен «үтерелгән» дип атый.

*Мин киң хәят теләп илгә чыктым;*
*Албастылар кисте юлымны.*
*Мин «Азатлык!» дидем.*
*Алар, көчләп,*
*Бәйләп куйды ике кулымны.*
*Мин сандугач булып, талга кунып*
*Сайрамакчы булган чагымда,*
*«Алар» аучы булды тагын да.*
*Мин сайрамак теләп ил багында,*
*Канат кактым; шунда тагын да*
*Кан эчкече ерткыч каракошлар*
*Шаулап торды тирә-ягымда.*

Газиз халкына ирек, азатлык теләүче пәйгамбәр шагыйрь «сандугач» символына төренеп, гаделлек хакында сайрамакчы була. Ләкин гаделлек җырчысын «албастылар», «аучылар», «кан эчкече ерткыч каракошлар» гел сагалап торалар, эзәрлеклиләр».

«Үтерелгән пәйгамбәр» шигыре астына җәя эченә «Октябрь революциясенә кадәр үлгән берәүнең авызыннан» дип язып кую нигә кирәк булды икән? Чөнки, шулай язмаса, шигырьнең 1918 елдагы вакыйгаларга каршы язылганлыгы ап-ачык аңлашылып торыр иде. Андый әсәрне кем бастырсын да, безнең көннәргә хәтле ул ничек килеп җитсен?!

Такташ әлеге шигырен иҗат иткән чорга академик Әгъдәс Борһановның бәяләмәсен алып карыйк» ...революциядән соң байлар шундук хосусый милекләреннән мәхрүм ителә, вак-төяк милек ияләре 10-15 елдан мәхрүм ителә, һәммә кеше бертигез булып кала. Дөресрәге, номенклатурадагылар хәлле яшәп тә, күпчелек исә ачлы-туклы көн күрә[1].»

Шундый ач-ялангач тормыш турында 1920-елда язылган тагын бер шигыре — «Ачлык патша» дип атала. Исеменнән үк аңлашылганча, элек патша хакимлек итсә, хәзер ачлык хөкем сөрә, ди Такташ әлеге шигырендә. Такташ чор фаҗигасе турында уйлана, борчыла, аны хәзер булмаса, киләчәктә бу тайгак юлдан йолып калу өчен тырыша. Илдәге вакыйгаларны трагедия дип атый. Шундый аянычлы, ачы язмышны чагылдырган иң уңышлы, иң күләмле әсәрләреннән берсе — «Җир уллары трагедиясе».

Р. Батулла «Кем ул Иблис?» мәкаләсендә Такташның «Җир уллары трагедиясе»ндәге Идеяне Ш. Бабичның «Газазил» поэмасындагы шул исемдәге әдәби герой белән чагыштырып, әлеге образның прототибы турында уйлана. Аның фикеренчә, Такташның Идея-Газазил дип куюы идеологияне алдакчы Иблискә тиңләвеннән туган. Әлеге фикерләр дөреслеккә туры килә кебек.

Безнең эзләнүләрдән күренгәнчә, Кабил образы аша шагыйрь үз чорындагы идеология тәэсирендә кыйбласын югалткан, адашкан кешеләрне тасвирлый. Кабил үзе үк адашканлыгы турында кат-кат әйтә.

*Төнге золмәттән адаштым,*
*Мин бу тауларга кереп;*
*Тапмадым бер җир кунарга,*
*Төн буе шунда йөреп;*
*Һәр тарафта коточыргыч*
*Юлбарыслар ыжгыра,*
*Баскан эз дә куркыныч, —*

[1] Борһанов Ә. Кайлардан килүең дә кайларга баруың. Рәсәй? — Казан: Татар. китап нәшр., 1998.

*Уклы еланнар сызгыра...*
*...Гаиләмнен язмышында*
*Мәңгелек михнәт күрәм,*
*Кайдадыр очмак булам да,*
*Юл табалмыйм, тилмерәм...*

Андый кешене алдавы Газазилгә кыен булмый билгеле.

Һади Такташның «Жир уллары трагедиясе»ндә Кабил Идея биргән хәнҗәр белән аның котыртуы буенча җинаять эшли, димәк Идея үзен «гали зат», «ак күнел» дип санаса да, андый булудан бик ерак тора.

Идея-Газазил һаман ут атып торучы янар тауларның йә өстендә, йә ул янар тауларга ышыклана. Анын «нур эчендә» булуы Иблис икәнлегенә ишарә булып тора, моны Такташның Һабилдән «Мәңгелек сөрген Газазил» дип әйттерүе дә раслап тора. Такташ аны Кабилдән мактаткан булып, «утлы гөл» дип тә атый.

*Кем син, әй, рух! Барлыгымны*
*Мәфтүн иткән утлы гөл?*
*Кем җибәрде монда сине?!*

Биредә «Утлы гөл» атамасы соңрак язылган Ә. Еникинең «Саз чәчәге» әсәрендәге ут чәчәге шикелле метафора буларак кулланылган. Ут чәчәге үзе сокландыра, җәлеп итә, әмма янына барам дисәң — харап итә. Кабил сүзләреннән Газазилнең яшеренеп йөрүен дә белеп алабыз.

*Яшеренеп һәрбер кара төндә,*
*Минем янга килеп*
*Сөйлисең:*
*«Мәңге газап, хәсрәткә син*
*Мәхкүм!» — диеп...*

Газазилнең яшеренеп йөрер өчен сәбәбе бар: ул гадел, ихлас, намуслы түгел. Аның сүзләренең, вәгъдәләренең мәгънәсенә төшенә алмый аптыраган Кабил икеләнә:

*Сөйлисең мин аңламас сүзләр.*
*Тагын куллар сузып,*
*Күргәзәсең әллә кайда,*
*Нурлы ак юллар сузып.*

Һ. Такташ Идея-Газазил сүзләренә идеологиянең (Идеянең идеология икәнен Мамин хезмәтендә дә күргән идек) киләчәктә халыкны ут эчендә яшәргә мәҗбүр итәчәк дигән фикерне төреп биргән. Кая очканын үзе дә абайламыйча, нурга алданып, ут эченә барып кергән һәм янып үлгән күбәләк язмышы кебегрәк киләчәк көтә икән халыкны. Житмәсә, Идея үзе югалу белән, ул күрсәткән «матур сарайлар» да юкка чыга. Димәк алар булмаган да. Идея-Газазил юкны бар дип күрсәткән. Бу матурлыкның иллюзия генә икәнлегенә шунда кабат төшенәсең.

Әкълимәгә зарлануыннан аңлашылганча, киләчәктә куркыныч, шомлы язмыш буласын Кабил дә сизенә кебек.

*Әкълимәм! Мин йоклый алмыйм,*
*Төн йокымнан уйганам, —*
*Уйганам да, нәкъ юләр-шашкан кеше, —*
*Кан елыйм, беркем дә белми, —*
*Мин тәмугларда янам!!*

Киләчәктәге үлекләр Кабил кебекләрнең дусты, ягъни халык. Алар әдип кисәтергә теләгән гражданнар сугышы һәм репрессия корбаннары булса кирәк. Шулай да, Кабил башта шикләнсә дә, Идея-Газазилгә буйсына, аңа ышана. Кабил хәзер Идея күрсәткән ялган матур тормышка барырга Әкълимәне дә үгетли.

*...Әйдә, без анда табарбыз*
*Кин, ходайсыз дөньялар.*
*Һәм дә аннан яудырырбыз*
*Мәңге ләгънәтләр анар!*

Дөрес шул: совет чорында, атеистик караш хөкем сөргәндә, мәктәпләрдә диннең яхшы яклары турында бер сүз дә әйтергә ярамаган заманда дингә ләгънәтләр күп яудырылды. Кешеләр Ходай урынына коммунистик тәгълиматларга табынды, стеналарга Ленин, Сталин портретларын элеп куеп, сүз саен аларның исемен телгә алды. Такташ Кабилнең мәсхәрәле сүзләре аша менә шулар хакында яза.

*Тезләнергә?!*
*Ха-ха-ха-ха-ха-ха-ха!!*
*Юк, минем өчен*
*Җирдә башка Алла бар...*

Трагедия юллары Газазилнең тагын бер сыйфатына ачыклык кертә: ул безнең алдыбызга урлаучы, талаучы; башка берәүнең мал-мөлкәте белән батыраеп йөрүче бернәрсәсез мактанчык булараk килеп баса. Андый кешене тарихчыларыбыз «пролетариат» дип атыйлар. Менә бер мисал: «Марксизм-ленинизм яңа җәмгыять төзү вазифасын пролетариат диктатурасына — милектән бөтенләй мәхрүм ителгән, кимсетелгән, зәһәрләнгән сыйныфка йөкләде[1]».

Такташның кан коюга карашы билгеле. Кылыч, сугыш, кан коюлар белән нәрсәгә ирешеп буласын Идея үзе дә бик ачык әйтә:

*Ул кылычның ялкыныннан*
*Күк янар, гөлләр шиңәр, —*

ди ул, җирдә матурлык калмас дигән мәгънәгә ишарәләп. Такташның фикере үткен, кыю, ул революцияне җилдә тузынган шайтан туена тиңли: «Мин хәзер җеннәр туенда...»

Кешеләрнең якты хыял-өметләре «кан» һәм «караңгылык», чарасызлык белән тәгәлләнә. Такташ революциянең нәтиҗәсен «төн», «караңгылык», «упкын» символларына төреп күрсәтә:

*Бар да бетте... Мин кара*
*Төндә югалттым юлларым...*
*Канга батты зур теләкләргә*
*Сузылган кулларым...*
*Алда упкын... Артта ут...*
*...Бар да каннарга күмелде,*
*Кап-караңгы — мин бетәм...*

Такташның 1918 — 1922 еллардагы иҗаты сәнгатьчә фикерләү тибының романтик булуы һәм нигездә романтизм принципларына таянуы ягыннан бер шигъри система төзи. Бу шигъри система Такташка хас романтик ашкынулы шашкын хисләр дөньясы, дөньяны масштаблы итеп күрсәтүе һәм социаль контрастларда сурәтләве, сугыш, кан коюларга, дини йола, гореф-гадәтләрнең юкка чыга баруына каршы

[1]Борһанов Ә. Кайлардан килүең дә кайларга баруың, Рәсәй? - Казан: Татар. китап нәшр., 1998.

бунт күтәрүе, дини образ сурәтләрне, трагик язмышлы геройларны, фаҗигале мотивларны яратып тасвирлавы белән әчке бер бөтенлек һәм даимилек тудыра. Шушы яктан, мәсәлән, «Газраилләр», «Күктән сөрелгәннәр», «Нәләт», «Җир уллары трагедиясе» кебек төрле елларда язылган төрле жанрдагы әсәрләрдә уртак мотивлар һәм сурәтләр булуын күрү кыен түгел. Әмма шул ук вакытта бу охшашлык һәм уртаклык абсолют характерда да түгел: аның сурәтле фикерләве чынбарлык тәэсирендә туктаусыз янара бара.

1922 елда иҗат ителгән «Бакчачылар» шигырендә ерак тарихлардан килгән хакыйкать яшерелә, ул хакта берәү дә дәшми «Бакчачылар» шигырендә күтәрелгән проблема «Мәңгелек әкият» шигырендә тагын да ачыграк күренә. Биредә дә чорның авырлыгы тасвирлана. Бу очракта шагыйрь максатка ирешү алымы итеп, «кара», «шомлы», «мәңге караңгы урман» образын сайлаган.

Җыеп әйткәндә, «Бакчачылар» шигыре үткән тарихка, шәҗәрәгә балта чабучы, гореф-гадәт, йолаларны юкка чыгаручы сәясәткә Такташның гыйсъян авазы булып яңгырый.

«Эшлиләр» шигырендә исә тимер куллы эшчеләрнең «нидер» эшләве турында языла.

*Алар эшли, күптән эшли инде*
*Тимер куллы даһи эшчеләр;*
*Айлар, еллар үтә, һаман шунда:*
*«Даң! доң! — Даң! доң!...»*
*Нидер эшлиләр.*

Шагыйрь, махсус рәвештә, «нидер эшлиләр» дип куя, чөнки төгәл ни эшләгәннәрен эшчеләр үзләре дә белми. Җәннәт төзибез дигән ният белән хәтта табигатьнең көчләренә каршы барудан да тартынмыйлар.

*— Табигать! Кит минем юлларымнан!*
*Ташла сәнгать коралларың кулларыңнан!*
*Менә саниг҃ь сиңа! Юл бир миңа!*
*Төзим җәннәт ташландык ил, кырларыңнан!*

Шагыйрьнең «тимер куллы» дигән эпитет куллануы да, эшчене «батыр үгез» белән чагыштыруы да юкка түгел:

*Әнә эшче, батыр үгез кебек,*
*Нидер бөгеп ята тимердән!*

Җәннәт кебек матур тормыш төзү өчен, үгез кебек көчле булу гына җитми, кешелек сыйфатлары да кирәк, дип әйтергә теле төсле Такташ, җәмгыятьтәге әхлаксызлык өчен борчылып.

Совет идеологиясе җәннәткә тиңләгән тормыш, ниһаять, төзелеп бетә. Ләкин, мәгълүм булганча, әлеге җәмгыятьтә Ходай кушканча яшәмиләр. Шуна күрә серле Күк тыныч түгел, җирдәге хәлләр аны тәмам аптырашта калдыра.

*«Яңа җәннәт җирдә төзелде!» — дип,*
*Җибрил күккә хәбәр җиткерде.*
*Мәгърур патша көчле күк алласы*
*Әүвәл көлде,*
*Шуннан —*
*Тилерде...*

Күкләрне тетрәтерлек, акылдан яздырырлык итеп тасвирлавы Такташның әлеге җәмгыятькә карата мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Һади Такташ башлангыч чор иҗатында җир йөзендәге бөтен сугышларга каршы нәфрәт белдерә һәм, шул исәптән, революциянең, гражданнар сугышының да барлык башка кан коюлар кебек үк ерткычлыгын тасвирлый. Җирдәге вәхшәт, гаделсезлек өчен борчыла. Кан кою бәрабәренә төзелгән тормышның шатлык, бәхет китерәсенә ышанмый шагыйрь.

Шагыйрьнең бу чор иҗаты илдәге вакыйгаларга, ягъни чор трагедиясенә, каршы гыйсъян авазы булып яңгырый. Димәк Такташның символик романтизмы үзәгендә реаль чынбарлык ята. Әмма шагыйрь өметен өзми, ул яза. Киләчәк өчен яза. Хәзер булмаса, киләчәктә илне тайгак юлдан йолып калу турында уйлый. Хакыйкатьне киләчәк буыннарга җиткерү өчен, җәмгыять күренешләрен символик образлар аша гомумиләштерү ысулына таяна.

Такташ иҗатында гаделлек сакчысы — «пәйгамбәр, сандугач», аны эзәрлекләүчеләр — «албастылар, аучылар, кан эчкече ерткыч кара кошлар».

Такташ үз әсәренең идеясен аңлап, цензура бәйләнмәсен өчен эз яшергеч аңлатмалар бирә. Мәсәлән, «Газраилләр» шигыренең исеме астына, җәя эченә алып, «1914 нче елгы Европа сугышына каршы», «Үтерелгән пәйгамбәр» шигыренең исеме астына «Октябрь революциясенә кадәр үлгән берәүнең авызыннан» дип язып куя.

Шагыйрь революциянең нәтиҗәләрен «төн», «караңгылык», «упкын» символларына төреп бирә. Иҗатын «гөл» дип атый. Гөлләре үсеп, һәйкәлгә әвереләчәгенә ышана.

Шулай итеп, алда китерелгән мисаллардан күренгәнчә, Һади Такташның башлангыч чор иҗаты үз заманыннан канәгатьсезлек

рухы белән сугарылган. Һади Такташ кешене талау юлы белән бай, рәхәт тормышка омтылучыларны һәм шул системаның җитәкчеләрен аяусыз тәнкыйтьли. Ул революциягә, гражданнар сугышына, зыялыларны, һәм булдыклы кешеләрне сөргенгә озату, юк итүгә, үткәнне юкка чыгаруга, чын тарихның яшерелүенә, динсезлеккә, табигатьне буйсындырырга тырышуга, рухи ярлылыкка каршы бунт күтәрә.

**Миңзифа ТАҖЕТДИНОВА,**
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*
*Чүпрәле.*

❋

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

# ӘГӘР УЛ ҖЫРЧЫ БУЛМАСА...

«Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз», — ди безнең халык. Әлбәттә, шулай. Нинди генә «житмеш төрле һөнәр»ле кешеләр юк безнең хезмәт сөйгән асыл ирзатларыбыз арасында! Ә менә сәнгать өлкәсендә бер кешенең югары дәрәҗәдә камил итеп берничә эшне башкара алуы — сирәк күренеш һәм дә моңарчы булмаганрак хәл дип әйтер идем. Шөкер, бар бездә дә андый осталар...

30 гыйнварда, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахмановка 50 яшь тулган көнне узган концертка килгән тамашачы моның шаһиты булды, минемчә. Без күптән белгән, яраткан җырчыбыз үзенең чын мәгънәсендә «житмеш төрле һөнәр» иясе булган ир-егет икәнен тагын бер кат исбатлады: үзе уйнады, үзе җырлады, үзе җитәкчелек иткән Татарстан Республикасы фольклор музыкасы Дәүләт ансамбленең чарланып беткән, сәнгати яктан өлгереп җиткән, менә дигән коллектив икәненә инандырды, бездә горурлык уятты. Тәнәфес вакытындагы фикер алышуларда бары тик бер генә сүз яңгырады сыман — «Шәп!» Әйе, артист егетебез Айдар Фәйзрахманов кыска гына вакыт, нибары ике ел эчендә, ансамбльне үзебездә генә түгел, ә чит илләрдә дә танытуга иреште.



Ансамбльнең уңышларын саный китсәң, гаҗәпләнүнең чиге юк: татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге конкурсында һәм Әстерханда узган Идел буе халыкларының фольклор коллективлары конкурсында лауреат исемнәрен алды; ансамбльнең «Яңа гасыр» телевидениесе фондына кергән дүрт концерты тасмага төшерелде; ике компакт-дискы чыгарылды; Финляндиянең Хельсинки шәһәрендә уздырылган «Җанлы татар музыкасы» фестивалендә иң мәртәбәле «Савои» театрында уңышлы чыгыш ясады; Кырым автономияле республикасында Татарстан көннәре барышында узган сәнгать осталары концертының икенче бүлеге тулаем ансамбльгә тапшырылды һәм ул аны күркәм итеп башкарып чыкты. Шулай ук Истанбулда, Төркия бәйсезлеге көненә багышланган фестивальдә һәм Германиянең Франкфурт на Майне шәһәрендә «Бөтендөнья китап базары» кысаларында ачык һавада (димәк, меңнәрләгән тамашачы дигән сүз) узган фестивальдә дә ансамбль татар моңын төрле милләт кешеләренә җиткерде. Шушы чыгышлардан соң кызыксынып бирелгән бихисап сораулар — аның югары профессиональ дәрәҗәдә эшләвенә, сәнгать җитәкчесе Айдар Фәйзрахмановның моның өчен күпме көч куйганына ачык мисал иде. 20 апрельдән аларның Финляндиядә гастрольләре башлана — Хельсинкида, Тампереда һәм башка

җырләрдә — барлыгы 7 шәһәрдә концерт бирәчәк алар. Май аенда исә ансамбль Австриягә юл алачак.

Инде Айдар Фәйзрахмановның башка һөнәрләренә күчик. Муса Җәлил исемендәге Татар Дәүләт опера һәм балет академия театрында 24 ел эшләү дәверендә ул онытылмаслык образлар иҗат итте: «Борис Годунов»та (Мусоргский) Мисаил, «Тоска»да (Пуччини) Сполетто, «Риголетто»да (Дж. Верди) Борса, «Князь Игорь»дә (Бородин) Брошка, «Снегурочка»да (Римский-Корсаков) Бобыль, милли операларыбыз «Алтынчәч»тә (Җиһанов) Урмай, «Башмагым»да (Җ. Фәйзи) Галимҗан, «Кара йөзләр»дә (Б. Мулюков) Үрәтник, «Наемщик»та (С. Сәйдәшев) Гәрәй. Шушы операларда, музыкаль спектакльләрдә уйнау дәверендә Айдар Фәйзрахманов үзенчәлекле, оста актер булып өлгереп җитте.

Аның сәхнәгә чыгуын опера тыңлаган тамашачылар һәрчак көтеп алдылар. Ә инде Мисаил, Сполетто, Борса партияләре белән ул күп кенә Европа илләрендә — Германия, Голландия, Франция, Бельгия, Швейцария, Португалия сәхнәләрендә чыгышлар ясады. Айдар белән эшләгән режиссерлар, дирижерлар ул иҗат иткән образларга югары бәя бирделәр. Ә «Культура» (18. 02. 1995) газетасында чыккан «Зал полон, ложи блещут» диган язманың авторы Мариам Игнатьева Айдарның «Алтынчәч»тә уйнавы турында болай язды: «...Зато прямое «попадание» в роль продемонстрировал А. Файзрахманов. Его Урмай (коварный советник хана) — не самое главное действующее лицо в спектакле, но стоит артисту появиться на сцене и внимание зрителя прямо-таки концентрируется на нем! Это тот счастливый случай, когда красивый голос, выразительность пения и актерской игры делают эпизодическую роль наиболее запоминающейся».

Опера сәхнәсендә чыгышлар ясавы белән беррәттән, Айдар Фәйзрахманов — халкыбызның иң матур борынгы җырларын киң катлам тамашачыга җиткерүче җырчы да. Татар халык җырларының «Сагыну», «Сандугач-күгәрчен», «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Борынгы көй», «Эрбет», «Озату», «Корбаш авылы көе» дигәннәрен нәкъ менә Айдар Фәйзрахманов эстрада сәхнәсенә беренчеләрдән булып алып чыкты һәм алар Татарстан радиосының алтын фондына аның башкаруында кертелделәр дә.

Шунысы кызыклы, Айдар профессиональ җырчы гына түгел (консерваторияне тәмамлаган вокалист), ә профессиональ музыкант та (педагогия институтының музыка факультетын тәмамлаган баянчы). Аның аккомпаниаторлык сәләте дә таң калырлык. Халкыбызның данлыклы җырчылары Илһам Шакиров, Хәйдәр Бигичев, Зөһрә Сәхабиева, Мөнир Якупов, Галина Казанцева, Руслан Дәминов, Рафаэль Ильясовларның Айдар Фәйзрахманов баянына кушылып җырлаган җырларының язмалары шулай ук радио фондында саклана.

Айдар Фәйзрахманов — үзе уйнап, үзе җырлаган иң беренче профессиональ җырчы. Бу уңайдан Рафис Корбанның Айдарга багышлап язган шигыре искә төшә:

*Әгәр ул җырчы булмаса,*
*Гармунчы булыр иде.*
*Әгәр гармунчы булмаса,*
*Ул җырчы булыр иде.*
*Әгәр мыеклы булмаса,*
*Мыексыз булыр иде,*
*Гармунын алып кулына*
*Берне сыздырыр иде!*
*Әле дә гармунчы булган,*
*Әле дә җырчы булган.*
*Мыегынны бер сыпыр да,*
*Җырла син, Айдар туган!*

Шаян шигырь, әмма чыны шулай — Айдар җырлый да, уйный да, йә тальянын, йә баянын сузып җибәрә дә сәхнәдән җанлы, тере җыр яңгырата. Аның болай җырлавы Мәскәүдә Муса Җәлилнең тууына 80 ел тулган юбилей кичәсендә Сара Садыйкованың «Чит илләргә чыкса» җырыннан башланды. Ул вакытта Мәскәү тамашачысы «ярылып» кул чапты ана. Әйе, менә инде 30 ел дәвамында диярлек Айдар Фәйзрахманов профессиональ сәхнәдә халык җырларын һәм композиторларыбыз әсәрләрен бер үк дәрәҗәдә оста башкарып, аларны төрле уен коралларында — гармунда, баянда, курайда уйнавы белән бизәп тамашачыны кинәндерә, моңыбызны яшәтә, башка милләт кешеләренә татар җыр сәнгатенең гүзәллеген таныта.

Хәтердә, 80 нче еллар ахырында Мәскәү телевидениесенең 1 нче каналыннан Айдар Фәйзрахмановның 25 минутлык концертын ике тапкыр күрсәттеләр. Россиянең төрле төбәкләреннән, чит милләт кешеләреннән бик күп рәхмәт хатлары алганын беләм Айдарның. Менә бер хатта русча болай язылган иде: «Я смотрел по телевидению 17 мая 1988 года в 19 час. 10 мин. Татарские народные песни, где пел Айдар Файзрахманов.

Айдар Файзрахманов отлично исполнял свои татарские народные песни.

Я всегда рад слушать, как он, Айдар Файзрахманов поет.

С дружеским приветом, инвалид Великой Отечественной войны II группы Бобков Петр Никитович».

Воронеж шәһәреннән җибәрелә бу хат.

Бүгенге көндә Айдар Фәйзрахманов үз һөнәренә яшьләрне өйрәтә. Казан Дәүләт педагогия университетының музыка факультетында җыр кафедрасын җитәкли ул. Доцент Айдар Фәйзрахмановның остаз буларак тәрбияләгән шәкертләре инде халык арасында күренә башлады. Мәсәлән, беренче укучысы — Гүзәл Уразова — киң тамашачы алдында танылган, үз итеп кабул ителгән җырчы инде.

IV курс студенткасы Эльвира Гафурова—татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге II халыкара конкурсында өченче премиягә лаек табылды, фольклор ансамблендә җырлау сәләтен үстергән Илшат Вәлиев исә I премия лауреаты булды.

Җырчы, музыкант, актер, педагог, сәнгать җитәкчесе һәм, ниһаять, — бүгенге көндә иң югары рейтинглы «Җырлыйк әле» тапшыруының (авторы Татарстанның атказанган артисты Нәҗип Бәдретдинов) алып баручысы Айдар Фәйзрахманов бу эшен дә югары дәрәҗәдә башкара. Халык арасында танылган, Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан якын итеп кабул ителгән бу тапшыру халкыбызның милли аһәңнәре булган халык җырларын, татар композиторларының классик җыр үрнәкләрен саклап калуга, шуларны яшь буынга җиткерүгә, башка милләт вәкилләренә танытуга хезмәт итә.

Айдарның «җитмеш төрле» һөнәре турында уйланганда, аның үзе язган җырларына тукталмый булмый: «Туган җиреңнән китмә» (Г. Афзал), «Ак болыт» (Р. Корбан), «Нурлы Казан» (Р. Харис), «Айлы юл» (Ш. Җиһангирова), «Әллә күрешәбез, әллә юк» (И. Юзеев). Сүз авторларының ниндиләрен сайлаган бит! Айдар Фәйзрахманов шигърияттне тирәнтен аңлый, сүз фәһеменә игътибарлы, шунлыктан җырлары да бер көнлек түгел, радио фондына кергән затлы җырлар.

*«Бу ядкәрем булсын Айдарга,*
*Җырың алып китә көн-күрештән*
*Еракларга, әллә кайларга.*
*Рәхмәт сиңа, милләтебез моңын*
*Күтәрәсен кояш, айларга!»* —

дип яза 1997 елда халык шагыйре Илдар Юзеев Айдарга бүләк иткән «Уйлый күңелем төрлесен» дигән шигырь җыентыгында.

Каян килгән соң Айдарга «житмеш төрле һөнәр иясе» дәрәҗәсенә ирешү сәләте? Кайда башлана соң Айдар Фәйзрахмановның чишмә башы? Ул — милләтебезгә бик күп шәхесләр биргән Арча районының гүзәл табигатьле Урта Бирәзә авылында, жыр-моңга гашыйк Фәтхрахман абый һәм Бибинур апа гаиләсендә алтынчы, төпчек бала булып дөньяга килә. Әтисе тальянда уйнагангадыр инде, аның да музыка дөньясына «тәпиләп» китүе, бик күп танылган сәнгать кешеләренеке кебек, тальян гармуннан башлана. (Юкка гына ул үзенә махсус «Аулак өй» жырын яздырмагандыр.) Бу турыда язганда, ирексездән Ә. Атнабаевның шигъри юллары искә төшә:

*Абыйлардан калган бишмәт киеп,*
*Бергә йөрдек аулак өйләргә,*
*Җырлап йөрдек урам яңгыратып,*
*«Баламишкин» дигән көйләргә.*

Газиз әтисе кулыннан тальян гармун күчкән булса, баян буенча беренче дәресләрне аңа абыйсы Марсель бирә (ул вакытта Казан дәүләт педагогия институтының музыка факультеты студенты, хәзерге көндә Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, РСФСРның мәгариф отличнигы, «Егетләр» халык ансамбленең 30 елдан артык сәнгать житәкчесе, Арча педагогия көллиятенең әйдәп баручы укытучысы). Менә шул көннәрдән бирле төшми аның кулыннан тальяны, баяны. Ә җыр — Айдарның күңеленә бигрәк тә Илһам Шакиров җырлары аша керә. Әйе, җырчы буш урында туа алмый. И. Шакировның: «Энекәш, әгәр дә ки, Гөлсем апа (сүз күренекле җырчы Гөлсем Сөләйманова турында бара) булмаган булса, мин дә булмый идем», — дип әйткәне бар. Айдар Фәйзрахмановның үсмер еллары Илһам Шакиров иҗатының чәчәк аткан чорына туры килүе булачак җырчыга зур йогынты ясамыйча калмый, әлбәттә. Шуңадыр, җырлый башлавының беренче елларыннан ук, халык җырларын үзенә генә хас осталык белән башкарып, моңарчы билгеле булмаганнарын да халыкка кайтаруда җиң сызганып эшли башлый ул.

Менә ун ел инде Айдар Фәйзрахманов Татарстанның халык артисты дигән мактаулы исемне йөртә. Аның иҗаты һаман үргә менә, тагын да камилләшә бара. Бүгенге көндә халкыбыз алдында башкарган титаник хезмәте киләчәктә дә дәвам итсен, тагын да мәртәбәле исемнәргә лаек булсын иде дигән теләктә мин.

**Хәйдәр САФИН,**
*РСФСРның мәгариф отличнигы.*

# ТӨС-БИЗӘКЛӘР — МИЛЛӘТ САГЫНДА

Бездә милләтне йокыдан уятырга омтылган, аны алга әйдәгән шәхесләр шактый. Шуларның берсе — рәссам Рифкать Вахитов.

1969 елда Ташкент шәһәрен хәрабә хәленә китергән җир тетрәү була... Бу фаҗига Казан сәнгать училищесын, Харьков сәнгать институтын тәмамлаганнан соң рәссам булып эшләүче Рифкать Вахитов иҗатына зур йогынты ясаган. Ташкент ул вакытта Бөтенсоюз күләмендә зур төзелеш мәйданына әйләнгән, һәм рәссамга, монументаль-декоратив сәнгать өлкәсендә дәүләт заказларын үтәп, осталыгын чарлау бәхете эләгә. Ташкенттагы Р. Вахитов бизәгән «Ләззәт» кафесын, «Динамо» стадионын, «Ташкент-2» аэропортын барып үз күзләре белән күрә алмаган сәнгать сөючеләр бу рәссамның иҗат өслүбен Чаллының «Татарстан» кунакханәсендәге «Сабан туе» дип исемләнгән керамик рельефыннан да чамалый ала. Хәер, чамалый ала иде дисәк, дөресрәк булыр. Чөнки, дәүләт милкенең шәхси кулларга күчә баруы сәбәпле илдә урнашкан хуҗасызлык аркасында, әлеге гаҗәеп матур сәнгать әсәре вәхшиләрчә юк ителде.



*Рәссам Рифкать Вахитов.*

Бу сәнгать әсәренең гомере кыска булса да, панно белән бәйле бик күп шатлыклы вә хәсрәтле мизгелләр кичерергә туры килә аның авторына. Миллилекне өнәмәгән, бердәй совет халкы тәрбияләү идеясе белән агуланып яшәгән чиновниклар әлеге иҗат әсәренең тууына каршы төшә, зур гауга куптара. Әмма 1978 елда «Декоративное искусство СССР» журналында бу панного сәнгать белгечләре тарафыннан бик югары бәя бирелде. Француз язучысы Андре Ремакль дә үзенең «Легенда о КамАЗе» китабында әлеге хезмәткә соклануын белдереп язды. Сәнгать әсәрен юк итәргә әмер биргән акча капчыклары бу мәкалә һәм китапларның берсен дә укымаган, билгеле. Гомумән, юләрләр илендә һава торышының ни рәвешле үзгәреп, иртәгәсе көндә безне ни-нәрсә көтәчәген алдан белеп булмаганга күрә, Казан метросының «Тукай мәйданы»нда рәссам Рифкать Вахитов мозаика ысулы белән башкарып чыккан берничә панноны кичекмичә барып карарга киңәш итәбез. Рәссам аны кызы Наилә белән бергәләп эшләгән. Р. Вахитовның ике кызы: Наилә дә, Майя да — профессиональ рәссамнар.

Әйе, Р. Вахитовның Урта Азия якларында үткән гомере аның иҗатына зур йогынты ясый. Чөнки рәссам анда борынгы шәрык миниатюрасын «терелткән», аны үстергән, шәрык шигъриятенең фәлсәфилеген, миниатюра сәнгатенең шартлылык һәм гомумиләштерү сыйфатын, Аурупа рәссамнарының реалистик осталыгын бергә туплап, дивар сурәтчелеге өлкәсендә үз мәктәбен булдырган мәшһүр рәссам Чыңгыз Әхмәров белән

таныша. Нәтиҗәдә, Р. Вахитовның пейзаж, портрет, натюрмортларына да шәрык мотивлары үтеп керә башлый.

Миниатюра - сынлы сәнгатьнең урта гасырларда чәчәк аткан аерым бер төре. Анда предметлар, кешеләр - барысы да яссы итеп сурәтләнә. Перспектива (ягъни предметның еракта яки якында булуына карап картинада тиешле зурлыкта һәм ачыклыкта бирелүе) сакланмый. Башлыча ярымтоннарсыз ачык төсләр файдаланыла. Миниатюрада, гадәттә, күңел ачу мәҗлесләре, бәйрәмнәр, патшаның ауга баруы, ир-атларның көч-гайрәтләрен күрсәтүләре, мәхәббәт маҗаралары сурәтләнә. Шәрык миниатюрасының стиле татар сәнгатенә бик якын. Тарихта күп чорлар кичеп бүгенгәчә килеп житкән шәмаил сәнгатенә, мәсәлән, миниатюраның ачык төслелек, предметларның яссы сурәтләнүе, перспектива закончалыклары сакланмау кебек сыйфатлар хас. Шуңа күрә ата-бабаларыбызның гореф-гадәтләрен балачактан ук күңеленә сеңдергән рәссам Рифкать Вахитовның шәрык миниатюрасы белән мавыгып китүе бик табигый хәл дияргә кирәк.

90 нчы елларда илдә сәяси, икътисади вәзгыять үзгәрү архитектура белән бәйле заказларның кимүенә китерә, рәссамнарны күбрәк сынлы сәнгатьнең кечерәк формаларына - картина, зур булмаган скульптураларга мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр итә һәм, иң мөһиме, иҗатларында милли традицияләргә юл ача. Шул вакыттан башлап Р. Вахитов та халкыбызның үткәне белән горурлану хисен картиналарында гәүдәләндерә башлый. Ә иҗатында милли теманың шәрык миниатюрасы стиле белән бергә берегеп килүе аны тарихи темага иҗат итүче бүтән рәссамнарыбыздан аерып тора.

«Болгар иленә мәдхия» триптихы - рәссамның яңа юлда ясаган беренче адымы, тәүге тәҗрибәсе. Ул бәйрәмчә якты төсләр, нәфис сызымнар белән сурәтләнгән, гаҗәеп бай колоритлы, җыйнак композицияле. «Чишмә янында», «Сабан туе», «Ау» дип исемләнгән иҗат әсәрләреннән торган әлеге триптих 1991 елда Ленинградта узган «Татарт» төбәкара күргәзмәдә зур уңыш казана. Ленинград телевидениесендә «Татарт» күргәзмәсе турында әзерләнгән тапшыруда «Болгар иленә мәдхия» әсәре экрандагы алгы рәсем (заставка) буларак файдаланыла. Мондый зур уңыш рәссамны тагын да дәртләндереп җибәрә һәм ул биш әсәрдән торган «Татарнамә» шәлкемен иҗат итә. «Татарнамә» шәлкемендә халкыбыз тарихындагы хәлиткеч вакыйгалар, тарих сәхифәләрен язган бөек шәхесләр күңелгә ятышлы тыныч төсләр белән сурәтләнгән. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Фазланның X гасырда Болгар җиренә килеп пакьтин пакь, камилләрдән камил ислам динен таратуы, әлбәттә, тарихыбызда иң зур вә иң мәртәбәле вакыйгаларның берсе. XIV гасыр ахырында Туктамышны җиңеп, Алтын Урданың бердәмлеген торгызган Идегәй әмирнең дә тарихта тоткан урыны, һичшиксез, зур. Р. Вахитовның Идегәй әсәре исә кайчандыр дәүләтебез бердәмлеге өчен көрәшкән барлык каһарманнарга мәдхия булып аңлашыла, аларның гомумиләштерелгән образы кебек кузаллана.

«Мәдрәсә» дип исемләнгән урта картина — «Татарнамә» шәлкемендәге хезмәтләр арасында иң якты төслесе. Рәссам, якты төсләр ярдәмендә гыйлемле, затлы, зыялы татар халкына дан җырлау белән бергә, аның киләчәге якты буласына өметен дә белдергән. Глобус һәм китап киштәсе мәдрәсәнең муллалар өчен мендәр өстендә корсак шиндереп утыру урыны гына булып калмыйча, нәкъ Тукаебыз хыялындагыча, хөррият заманындагы мәктәп, дөньяви фәннәрдән дә белем биргән чын уку йорты икәнлеген искәртеп тора. «Укымак - дөреснең ялганны, яктының карангыны, турының кәкрене, сафлыкның бозыклыкны җиңүләренә иң үткен, иң кирәкле коралдыр. Укымак - фикерләрне җирдән күккә җибәрмәк... Укымак - үзеңне һәрнәрсәне белергә вә һәр максудка ирешергә, вә бөтен дөньяга солтан булырга лаек дип танымактыр...» , - дип язган олуг Тукаебыз. Р. Вахитовның «Мәдрәсә» картинасы — әлеге «алтын сүзләрнең» төсле, образлы чагылышы диярсең. Бу сурәтләрдән бер-бер артлы күз йөрткәндә, «Татарнамә» шәлкеменең

ахырына таба киндердә сурәтләнгән куе зәңгәр төстәге авыр шомлы болытларның якты күк йөзен каплый баруына игътибар итәсең. Бу - татар жиренә хәвеф якынлашу билгесе. Казанның данлы ханбикәсе Сөембикә образы иҗат ителгән картинада кояшның тотылган вакытын күрәбез. Сөембикәне ике ут арасында утыртып, ә ханнар таҗын һәм патшалык билгесе скипетрны идәндә аунап яткан көе тасвирлап, татар иленә илбасарлар хуҗа булу сәбәпле, ханлыкның җимерелгән вакытын рәссам оста итеп күрсәтеп бирә алган.

«Кара урман» картинасы — арада иң караңгы төслесе, иң шомлысы. Биредә чукындыручылардан качып, гомерләрен мөһаҗирлектә уздырырга мәҗбүр булган татарларның ачы язмышы бәян ителә. Әмма яшь аналар кулында матур төшләр күреп елмая-елмая, тыныч кына йоклап яткан сабыйлар, атлар тирәсендә шукланып сикереп йөрүче колыннар бар. Болар - киләчәкнең якты буласына өмет билгесе. Төсләрнең тоныклыгы, аларның бер-берсенә йомшак күчүе, яшел, зәңгәр, шәмәхә буяуларның күп очравы «Татарнамә» шәлкеменә ниндидер гаҗәеп бер серлелек бирә. Шәмәхә-зәңгәр төстәге серле томан урыны-урыны белән таралып китеп, тамашачы алдында билгеле бер тарих сәхифәсен ача кебек тәэсир кала. Картиналарның темасы һәм киндерләргә иңгән серлелек күңелдә моң тудыра. Ул вакыты-вакыты белән яктырып китә дә, «Асылъяр», «Мәдинәкәй», «Хафизәләм иркәм», «Ал Зәйнәбем» булып ишетелә. Ә аннары шатлыклы ноталарны кинәт зарлы моң каплап ала һәм, халкыбызның михнәтле, күз яшьле тормышын күргәндә, «Кара урман», «Уел», «Зөлхиҗә» җырларын ишеткәндәй буласың.

«Олугъ Мөхәммәд портреты» — Татарстан сынлы сәнгатендә тантаналы бәйрәмчә портрет булуы белән истәлекле. Олуг Мөхәммәд - Казан ханлыгының нигез салучысы һәм беренче ханы. Тәхеткә килгәч, Казанны талап яшәгән урысларның арт сабакларын укыткан кеше. Бөек князьләре Василий II гаскәрен җиңгән, Мәскәүгә яу оештырып, Түбән Новгород, Муром калаларын алган батыр. Олуг Мөхәммәд үзеннән соң Казан ханы итеп үзе кебек үк зирәк акыллы, гайрәтле улы Мәхмүтне калдырган һәм ул идарә иткән вакыт Казан ханлыгының иң көчле, иң куәтле чоры булган. Шуңа күрә рәссамның әнә шундый зур шәхесне кылган эшләренә тиң шөһрәтле итеп сурәтләргә омтылуы бик табигый.

Ә бүгенге көндә рәссам Р. Вахитов яңа картина иҗат итә. Анда ул Олуг Мөхәммәднең урыс вәкиллеген кабул итү, урыс князьләренә үз җирләрендә идарә итүне рөхсәт иткән ярлык бирү күренешен сурәтләргә тели.

Рәссам тарихны, милләт язмышын мәшһүр шәхесләребез портретлары аша да оста чагылдыра. Бу җәһәттән сүзне олуг рәссамыбыз Бакый Урманче портретыннан башлыйсы килә. Бакый ага, үзенең Р. Вахитов кулы белән башкарылган сурәтен күреп, бу — үзем исән чакта иҗат ителгән иң шәп портрет, дип аңа зур бәя биргән булган.



*Илһам Шакиров портреты.*

Мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров портреты да бик кызыклы. Картинадагы пейзаж - күк йөзендә кызыл ут булып янган кояш та, Болгар манараларының берсенә борыны белән төртелүче дуңгыз башы рәвешендәге кара болыт та, аңа каршы яктагы бөркеткә охшаган яшел яктылык та рәссамның тел төбендә нәрсә ятканын ачык сиздерә. Яр буенда суда көймә тирбәлә. Көймә - ирек

символы. Ярга бер-бер артлы бәргән өч дулкын (алар татар халкына иң зур зыян китергән чорларны - Явыз Иван, Әби патша, коммунизм заманнарын гәүдәләндерә) менә-менә көймәне аударып капларлар сыман. Ә көймә биктә, көймә беркая да ычкынып китә алмый. Мәшһүр җырчыбызның милләтебез язмышы турында уйлануларын рәссам әнә шулай оста итеп тасвирлап бирә алган. Каһарман-шагыйрь Муса Җәлилне әле бер генә рәссамның да кулына Коръән тоттырып сурәтләгәне булмады. Гомумән алганда, ислам диненең асыл билгеләрен ачып, аның тормышыбызда иң зур таяныч булуын төшендерергә омтылу рәссам Р. Вахитовның бүтән хезмәтләрендә дә сизелә. «Татарнамә» шәлкемендә, әйтик, «Сөембикә» һәм «Идегәй» картиналарының бизәлешендә Коръәннән дә зуррак китап, Аллаһыдан да көчлерәк ярдәмче юклыгын искәртүче сүрәләр файдаланылган. Бәлки шуңадыр да, беренче карашка бик шомлы тоелсалар да, әлеге хезмәтләрдә өметсезлек, чарасызлык, төшенкелек сизмисең. Р. Вахитовның «Мәңгелек алдыннан» исемле сурәтне, бигрәк тә Җәлилнең бернинди киеренкелек әсәре булмаган нурлы йөзен күргәч, җанга гаҗәеп бер рәхәтлек иңә. Моның хикмәте шагыйрьнең нәкъ менә кулына Коръән тоткан көе сурәтләнүендә. Рәссам каһарманнарның якты дөньядан үлемнән курыкмыйча, тыныч күңел белән, кешелек дәрәҗәләрен төшермичә, башларын горур тотып китүенең серен ачкан. Бер Ходайдан куркып яшәгән мөселманнарга гына хас сыйфат бу. Югыйсә, үлем бусагасында торганда җырлар җырлаган кеше турында, куркудан акылына зәгыйфьлек килгән, дип тә уйларга мөмкин булыр иде бит. Ә Р. Вахитовның «Мәңгелек алдыннан» картинасы мондый ялгыш уйларга урын калдырмый. Рәссам Ташкентта яшәгән вакытта ук җәлилчеләрнең көрәштәшләре Рушад Хисаметдинов һәм Гарәф Фәхретдинов белән очрашкан, аларның портретларын язган. Плетцензее төрмәсендә утырган мөселманнарга, шул исәптән җәлилчеләргә дә, үләр алдыннан имам белән очрашу мөмкинлеге тудырылганлыгы турында шул елларның шаһитләре булган бу кешеләрнең үзләреннән ишеткән.



*«Читен хәл» картинасы.*

«...Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклагангынамы?... Соң инде аны ничек һушына китерик? Бу тугърыда минем фикре касыйрем болай дип әйтә: без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, ...җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карансын, гакылын җыйсын...», — дип язган Тукаебыз. Шөкер, шагыйрьнең хыялы тормышка ашты, безнең арадан да милләтнең үз хәлен үзенә сурәтләп күрсәтерлек рәссамнар үсеп чыкты. Р. Вахитовның Габдулла Тукайның тууына 120 ел тулу уңаеннан иҗат ителгән яңа картинасы шагыйрьнең бер әсәрендәгечә «Читен хәл» дип атала. Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында юбилейга атап оештырылган экспозициядә ул — тамашачыны янында тукталып уйланырга этәргән бердәнбер картина иде дияргә була. Трагизмы ап-ачык беленеп торган әлеге хезмәт шагыйрьнең юбилеен якты бәйрәм, тантана рәвешендә үткәрергә теләгән кайбер затларның күңеленә хуш килмәгәнгә күрә, күргәзмәдән чак кына төшеп

калмый. Рәссам шагыйрьне авыру хәлдә сурәтләгән. Ә Тукай белән татар халкы, татар милләте — аерылгысыз бербөтен. Шагыйрьнең иҗатында милләтебез тормышы көзгедәй чагылган. Димәк, рәссам Тукай образы аша татар халкының бүгенге хәлен күрсәтеп бирергә теләгән. Картинаның караңгы-кызыл фоны без яшәгән канлы илнең бүгенге вәзгыятен чагылдыра кебек. Анда шартлы алымнар белән күрсәтелгән кисек башлар, бүре башлары, авторның идеясен тәгаенли төшеп, кешенең дә, хайванның да бәрелүдә-сугылуда яшәгәнлеген искәртә сыман. Читлеккә охшаган сызымнар Тукаебызның күңел кошы тарсынган дөнья читлеген гәүдәләндерә һәм шул ук вакытта халыклар төрмәсе дип аталган илдә яшәгәнлегебезгә киная кебек аңлашыла. Читлектән күтәрелеп югарыга омтылгын зәңгәр кошлар - Сак белән Сок - дини, рухи кысулардан, һәртөрле җәбер-золымнан котылырга теләп, дөнья буенча сибелгән татарлар символы. Кара кош, бәхетебездән көнләшеп, байлыкларыбызга үрмәләүче куркыныч, җирәнгеч кара көч, төн кошлары ярканатлар – болар барысы да Вахитов картинасына Тукай шигырьләреннән күчкән. Алар — читлек эчендә яшәүче җан ияләре, реакция, искелек, ирексезлек, тирания символлары, һәркайсы картинага шом өсти. Ә Тукай утырган сәке астында тыныч кына йоклап ятучы мәче - ачы күңелле шагыйрьнең ачы шигъриятен чагылдыручы җан иясе «...Очырмакчы булсам былбыл күкрәгемнән, Әллә ничек! - мыр-мыр итеп мәче чыга!..» Тукай фигурасы караңгы-кызыл фонга капма-каршы рәвештә ачык төсләр белән сурәтләнгән. Төсләр каршылыгы шагыйрь һәм ул яшәгән мохит арасындагы каршылыкны көчәйтебрәк күрсәтә һәм шуның белән милләт язмышының трагизмын тагын да тирәнәйтә. Шул ук вакытта аксыл төсләр ярдәмендә рәссам Тукайның хәлсезлеге, сырхау хәле турында да искәртә, күңеле пакъ булуына да ишарәли. Әмма төсләрнең кискен каршылыгы, нәкъ менә шул нәрсә Тукай фигурасын алга чыгара да инде, шул рәвешле картинада гомуммилләт образының әһәмияте арта, һәм ул укмашкан ак төер, көчле бербөтен булып кабул ителә. Милләт авыру хәлдә булса да, бөтенләй көчсез, зәгыйфь түгел, аның читен хәлдән чыгу юллары да бар, барысы да үзебездән тора, ди сыман рәссам. Һәм сырхаудан котылу юлын да күрсәтеп бирә. Картинада күктән иңгән яктылык, төшә килеп, шагыйрь өстәлендәге иҗат шәменең утына барып тоташа. Бу ут бөтен өстәлне яктырта. Ә өстәл уртасында - Коръән китабы. Югарыда исә Коръәннән бер аять язылган: «Саклау йөзеннән Аллаһ хәерледер, Аңарга тапшырдым, вә Ул шәфкать итүчеләрнең иң шәфкатьлеседер...». Дәүләтчелек югалу, милләт таркалу - барысы да дин югалудан, димәк. Гаяз Исхакыйның да бу хакта әйткән сүзе бар: «Башта дин бетә, аннары әхлак югала, аннары милләт үзе бетә», - дигән язучы.

Кыскасы, рәссам Р. Вахитовның «Читен хәл» картинасында һәм, гомумән, иҗатында гражданлык позициясе ачык чагыла. Ул шанлы үткәнебез белән горурланырга өйрәтүне, бүгенге кыен хәлебезне үзебезгә күрсәтеп тетрәндерүне, кыйбланы барларга чакыруны үзенең намус эше, изге бурычы саный.

**Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА**

*Гази Кашшафның тууына 100 ел*

# ҖӘЛИЛ ДУСТЫ КАШШАФ

Нәфис-матур бизәкле касә кебек калкулыклар һәм урманнар, болын-кырлар уртасындагы инкүлек-үзәнлектә урнашкан Туймазы районының Иске һәм Яңа Арсланбәк авыллары... Ике авылны аерып, башын өч-дүрт чакрым аралыктагы Сәрән авылы янәшәсендәге урман-куаклыктан алган Нөгеш елгасы салмак-сабыр һәм талгын гына ага. Бу ике бертуган-игезәк кебек авылны Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгының мәһабәт-горур һәм кырыс таулары каймаган...

1907 елның 15 апрелендә Яңа Арсланбәк авылында мулла һәм мөгаллим Шаһисолтан гаиләсендә булачак тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме, язучы Гази Кашшаф (Миргази Кашшафетдинов) дөньяга килә...



Гази абый белән мин — якташлар. Яңа Арсланбәк белән минем туган авылым Сәрән арасы нибары өч чакрым.

Тәү тапкыр Гази абыйны мин үз өебездә күрдем (миңа ул вакытта биш-алты яшьләр булгандыр). Ямьле җәйнең матур бер көне иде. Иске өебездә мич чыгару өчен Туймазыдан кирпеч алып кайттылар. Шуларны ишегалдына ташып өеп беткәндә ихатабызга урта буйлы, мөлаем йөзле, пөхтә итеп киенгән һәм таяк таянган бер ир килеп керде. Аның житдилеге, акыллылыгы һәм зыялылыгы әллә кайдан аңкып-бөркеп тора. Әти белән кочаклашып күрештеләр. Алар күптәнге танышлар һәм дуслар икән: яшь чакларында Әкрам Даутов һәм Гали Махияновлар белән бергәләп авылларда концерт-спектакльләр куеп йөргәннәр. Ул арада әни бик мул-тәмле итеп аш-су әзерләде. Ике дус табында, сыйланып һәм ашап-эчеп, бик озак гапләшеп-серләшеп утырды. Вакыт соң булганлыктан, әти белән әни Гази абыйны куна калырга күндерделәр. (Әни апам һәм сеңлем белән сәкедә, без өчәү агач кроватьта яттык, ике ир-ат төне буе сөйләшеп чыктылар.)

Икенче көнне, төшкелекне ашагач, без Гази абыйны капка төбендә озатып калдык. Шул чакта мин әтидән: «Бу абый ния таяк таянган, ния аксый ул?» — дип сорадым. «Аның аягы авырта, улым», — дип җаваплады әтием (соңрак миңа шул мәгълүм булды: Гази абый сугыш алдыннан, трамвай астына эләгеп, бер аягын өздергән икән). Әти: «Улым, Гази абыең Казан каласыннан кунакка кайткан, ул бик зур галим һәм язучы», — дигәч, авызым ачылды да калды. Мин «Казан», «галим», «язучы» дигән тылсымлы сүзләрне беренче тапкыр шул чакта ишеттем...

Миргазиның ата-бабасы һәм нәсел-ыруы асыл заттан һәм укымышлы кешеләр. Аның бабасы Кашшафетдин Казан мәдрәсәсендә белем алган, Татарстанның Азнакай районы Сарсаз авылында мулла булган, ә баштарак шунда ук мөгаллимлек иткән. Гомумән, Гази Кашшафның нәселендә мөгаллимнәр, муллалар һәм укытучылар күп булган, берничәсе Мәккә-Мәдинәгә хаҗга барган.

Әти-әнисеннән мәдрәсәдә һәм мәктәптә төпле белем алгач, Гази 1920 — 1925 елларда Бәләбәй шәһәрендәге укытучылар педагогия семинариясе-училищесында (хәзер педагогик техникум-колледж, ул бик тә абруйлы уку йорты) укый. Әйтергә кирәк, аның дүрт сеңлесе дә — Таиба, Фатыйма, Мөкәрәмә һәм Сажидә шул училище-техникумны һәм югары уку йортларын тәмамлаганнар, гомерләре буе укытучы булып эшләгәннәр, дан-шөһрәт казанганнар. Мәсәлән, Фатыйма күрше-янәшәдәге Шаран районында укыта, Ленин һәм Хезмәт Кызыл байрагы орденнары белән бүләкләнә,

«Башкортстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исемгә лаек була. Гомумән, Кашшафетдиновлар нәселе — педагог-укытучылар династиясе (шунысын да өстик: Газинең әтисе Шаһисолтан укыткан 28 бала соңыннан укытучы һөнәрен сайлый).

Бәләбәйдә Гази авылдашы һәм яшьтәш дусты Муллаян Габдуллин белән бергә укый. Соңрак алар патриот-шагыйрь Муса Җәлилнең язмышында зур роль уйныйлар...

* * *

...1943 елның 19 сентябрендә Чернигов өлкәсе Прилуки шәһәре тирәсендә фашист тоткынлыгыннан качкан, элекке 2 нче удар армиянең аерым чаңгычылар батальонының 165 нче рота командиры Габдуллин Ян (Муллаян) Тимеркәй улы Кызыл Армия частьлары ягына чыга. Ул дошман территориясендә хәрәкәт итүче яшерен оешманың әлемтәчесе булуы турында хәбәр итә һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты исеменә (Габдуллин партия сафына 1929 елда кабул ителгән) түбәндәге донесение тапшыра: «Әгәр ВКП(б) ҮК хәзергә кадәр яшерен оешма яшәве хакында хәбәрдар түгел икән, мин, тоткынлыктан кача алган бу оешма әгъзасы буларак, Сезгә бу хакта хәбәр итүне партия алдындагы бурычым дип саныйм һәм бу хакта ВКП(б) ҮКна бик ашыгыч рәвештә хәбәр итүегезне үтенәм». Шул рәвешле совет иленә Муса Җәлил җитәкчелегендәге яшерен оешма эшләве турында хәбәр мәгълүм була.

* * *

Бәләбәйдә укуын тәмамлагач, Гази, Уфада кыска вакытлы әзерлек курслары үтә дә, Казанга юл тота һәм Көнчыгыш педагогия институтына укырга керә.

Гази Кашшаф институтта да укый, бер үк вакытта Вахитов исемендәге сабын заводы каршындагы ФЗӨ мәктәбендә дәресләр дә алып бара. Институтны тәмамлагач, 1929 елдан 1937 елга кадәр, Казанның төрле уку йортларында — Татрабфакта, авыл хуҗалыгы-коммунал мәктәбендә (Комвуз), тире һәм мех сәнагате техникумында, авыл хуҗалыгы институтында татар теле һәм әдәбияты фәннәре укыта. Студент елларында ул бик күп иҗат әһелләре — язучылар, шагыйрьләр, артистлар... белән якыннан таныша һәм ныклап аралаша, мәкаләләр яза башлый (аның беренче тәнкыйть мәкаләләре дә студент чагында — 1928 елда басыла). Муса Җәлил белән дә танышлыгы-дуслыгы институтта укыган елларда башлана.

1937 елда Гази Кашшаф Таттосиздатка эшкә күчә: анда башта өлкән әдәби консультант, ә 1939 елның җәеннән 1942 елның көзенә кадәр матур әдәбият секторы мөдире булып эшли. 1940 елда аның «Каләм мастерлары» (тәнкыйть мәкаләләре җыентыгы), «Чүл буенда» (повесть) һәм «Шәриф Камал» дигән өч китабы дөнья күрә (әтигә бүләк иткән «Чүл буенда» повестенең 1968 елда чыккан икенче басма китабы бүген дә миндә саклана әле). Гази Кашшаф 1938 елда СССР Язучылар берлегенә кабул ителә.

Бу елларда Гази Кашшаф белән Муса Җәлил ныклап дуслашалар. Ә инде бер йорттан (Горький һәм Гоголь урамнары чатында) 1940 елда фатир алып, күршеләр булып яши башлагач, бу дуслык тагын да көчәя-ныгый төшә. 1940 елның сентябрь аенда Муса — Әминә Җәлилләр һәм Гази — Һаҗәр Кашшафлар гаиләләре белән Ялтада ял итәләр. Сугыш башлану хәбәрен дә алар Гази Кашшафларның дачасында ял иткәндә ишетәләр. Муса Җәлил сугышка киткәч, әлеге ныклы дуслык сагыш-юксынуга әйләнә: алар үзара хатлашып торалар, Муса «Васыятьнамә»сен дә Гази Кашшаф исеменә яза...

1942 елның октябрендә Гази Кашшафны «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына мөхәррир итеп билгелиләр. Ул елларны Гази ага шулай хәтерли: «...Бөек Ватан сугышы еллары хәтердә нык уелып калган. Партиянең Татарстан өлкә комитеты «Совет әдәбияты» журналын саклап калырга булды. Ул чакта журналны Гомәр Бәширов редакцияли иде. Озак та узмастан, партия оешмасы Гомәр Бәшировны фронтка, озак сроклы командировкага җибәрде... 1942 нче елны Гомәр Бәшировны мин алыштырдым (Гомәр аганы Татарстан радиосының баш мөхәррире итеп билгелиләр — З. Н.). Журналдагы хәл авырлыгына котып салкыннары килеп кушылды. 1941 нче елның кышыннан бирле матбугат йорты

ягылмый иде... Бүлмәдә бер сәгатьтән артык утырып булмый. Салкын үзәккә үтә. Һәм без урамнан әйләнеп керәбез. Матбугат йортына караганда урамда жылырак шикелле тоела безгә... Сугыш сузылган саен кыенлыклар арта бара: кәгазь кытлыгы, типографиядәге авырлык, кульязмалар житмәү һәм башкалар. Өстәвенә баш мөхәррир айлар буе чәчү, урып-жыю кампанияләрендә йөри. 1943 нче елның жәендә типографиядә жыелмыйча хәрәкәтсез яткан журналларыбызның саны жидегә житте. 1943 нче елның октябрендә миңа тагын бер эш йөкләделәр. Мөхәррирлектән бушатмыйча гына Татарстан Язучылар оешмасының житәкчесе итеп сайладылар. Бер көнне кич белән мине житәкче итеп сайладылар, икенче көнне Мәскәүгә юл алдык. Тажи Гыйззәт, Кави Нәжми, Нәкый Исәнбәт һәм мин Мәскәүгә китәргә һәм СССР Язучылар союзының президиум утырышында Татарстан Язучылар союзының эше турында хисап бирергә тиеш идек. Язучылар союзы президиумында хисап докладын мин ясадым. Безнең эшебез мактанырлык түгел иде. Шуңа күрә кимчелекләрне һәм аның сәбәпләрен түкми-чәчми сөйләп бирдем. Утырышны Александр Фадеев алып барды. Моңа кадәр ул Казанда ике тапкыр булып киткән һәм безнең хәлләр белән яхшы таныш иде. Бу безнең мәсьәләне президиум утырышына куеп, кулдан килгәнчә гамәли ярдәм күрсәтү, булышу теләге белән эшләнгән иде... Икенче көнне Тажи Гыйззәт, Кави Нәжми һәм мин Александр Фадеев белән Үзәк Комитетка (ВКП(б) ҮК — З. П.) юнәлдек. Үзәк Комитетның пропаганда бүлегендә миңа шактый зур хисап доклады сөйләргә туры килде: Татарстандагы әдәби хәрәкәтнең торышы, нәшрият эшләре, язучы кадрларның барысы диярлек фронтның алгы ут сызыгында булуы, аларның солдат хезмәтен үтәү белән бергә язучылык эшен дә алып барулары, үзебезнең дә бик авыр шартларда яшәвебез хакында сөйләдем... Кызып киткәч, бердәнбер әдәби журналыбызның бик мөшкел хәле турында да сөйләргә туры килде. Кинәт мине сөйләүдән бүлдерделәр: «Ничек, сездә журнал чыгамени?..» «Ә сез, Александр Александрович, бу хәлне беләсезме?» Фадеев бик гади нәрсәне раслаган төсле үзенең ягымлы тавышы белән: «А как же, без житәклибез», — диде... Үзәк Комитеттагы иптәшләр безнең хәлне яхшы аңладылар, авырлык белән булса да журналны туктатмыйча чыгарып килүебезне хупладылар. Бу сезнең «подвиг» диделәр...


*Сулдан уңга: Ә. Ерикәй, Ә. Исхак, Г. Минский, Н. Арслан, И. Гази, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин, Г. Кашшаф, М. Әмир, М. Хөсәен. 60нчы еллар.*

«Совет әдәбияты»ның һәрбер саны, кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан кулга күчә иде. Тылдан кадерле бүләк төсендә фронтка юнәлә... Шул рәвешчә, «Совет әдәбияты» журналы сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды»...

Гази Кашшаф 1945 — 1947 елларда Татарстан язучылары оешмасында референт-консультант, ә 1947 — 1950 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында өлкән лаборант булып эшли. Аннары сигез ел буе (1950 — 1958 елларда) яңадан «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире вазифаларын башкара.

1960 елда, кандидатлык диссертациясен яклагач, Гази Кашшаф үзенең хезмәт

эшчәнлеген тулысынча Казан дәүләт университеты белән бәйли: 1961 — 1964 елларда тарих-филология факультетының татар әдәбияты кафедрасында, ә 1964 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр яңа ачылган журналистика кафедрасында укытучы-доцент булып эшли.

Гази Кашшаф студент елларыннан ук саллы-төпле фикерле мәкалә-рецензияләр яза һәм үзен югары зәвыклы, киң карашлы, таләпчән-гадел тәнкыйтьче итеп таныта. Әйтик, 1928 — 1952 еллар арасында Гази аганың матбугатта әдәбият һәм театр сәнгате турында 150 дән артык тәнкыйть мәкаләсе дөнья күрә. Шул ук вакытта ул урта мәктәпләр өчен дәреслек-хрестоматияләр дә төзи, иҗат портретлары яза...

* * *

Илленче еллардан башлап галим калган гомерен, бай тәҗрибәсен һәм күпкырлы сәләтен, киң эрудициясен герой-шагыйрь Муса Җәлилнең легендар тормышын, каһарман иҗатын тикшерүгә, әдәби мирасын туплауга һәм халыкка җиткерүгә багышлый. Менә Муса Җәлилнең Гази Кашшаф исеменә хәрәкәттәге армиядән 1942 елның 27 маенда җибәрелгән «васыятьнамәсе» (ул каләм белән гади кәгазьгә рус телендә язылган) тулы хокук бирә. Беренчедән, алар якын дуслар, ут күршеләр булган (соңрак галим үз фатирын герой-шагыйрь музеена бирә), икенчедән, шул вакытта ук Гази Кашшафның, галим-тәнкыйтьче һәм кеше буларак, абруе бик зур була. Муса Газиның аның васыять-ышанычын аклаячагын яхшы аңлый. Җәлил, шулай итеп, үзенең тормыш һәм иҗат юлын барлауны, барлык әдәби публицистик һәм эпистоляр мирасын, аларның киләчәген, язмыш-тәкъдирен хәл итүне тулысынча (һәм бары тик аңа гына!) ышанып тапшыра.

Казан дәүләт университетының журналистика, социология һәм психология факультеты деканы вазифаларын башкарган Флорид Әгъзамов язганча: «Гази Кашшаф—күренекле әдәбиятчы, тәнкыйтьче, журналист, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Гази аганың бөтен гомере әдәбият һәм журналистика белән бәйле булды. Ул әдәбият гыйлеме һәм тәнкыйте өлкәсендә дә зур мирас калдырды. Аның игътибарыннан читтә калган берәр танылган әдип булдымы икән! Бик күп яшь әдипләр һәм журналистлар иҗатка аннардан фатиха алдылар. Ул Казан дәүләт университетында журналистика бүлегенә нигез салучыларның берсе иде...»

Гази Кашшаф дусты-каләмдәше Муса Җәлилнең васыятенә һәм аңа биргән вәгъдәсенә гомере буе тугры булып калды. Ул гомеренең иң җимешле-юмарт һәм өлгереп җитлеккән елларын герой-шагыйрьнең мирасын җыюга, барлауга, бастырып чыгаруга, фәнни тикшерүгә һәм киң пропагандалауга багышлады. Ул, шагыйрьнең соңгы язмышын ачыклау өчен, архивларда эзләнә, шагыйрь йөргән урыннарда була, аны якыннан белүчеләрне — туганнарын, дусларын, Муса белән бергә әсирлектә газап чиккән кешеләрне күреп сөйләшә, бик күп хатлар алыша. Нәтиҗәдә, «Муса Җәлил» дигән зур күләмле, тирән-бай эчтәлекле монография яза (ул рус һәм татар телләрендә өч тапкыр басылып чыга).

Гази Кашшаф түбәндәгеләрне яза:

*«—Муса турында истәлек кирәк!*

*Шушы сүзләр белән мин кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәдем! Язучыларга, артистларга, композиторларга, белеш-танышларына, дусларына, күрәштәшләренә... Берсе дә тәкъдимне кире какмады, бик яхшы эш, изге эш, диделәр, андый истәлекләрнең киләчәк буыннар өчен аеруча кыйммәтле булачагын искә төшерделәр һәм... истәлекләр ява башларга тиеш иде, билгеле. Тик алай булмады... Моның вакыты юк, тегесе иртәгә тотыначак, өченчесе фикер туплый, чөнки ул бер генә тапкыр очрашкан кеше турында язмый, бәлки көн саен, сәгать саен аралашкан кешесе турында язачак... Ә менә бу үзе бик матур итеп язар иде дә, гаепләп булмый, ул язучы булып тумаган...*

*Шулай итеп, истәлекләр туплау эше шактый катлауланып китте һәм чамадан тыш авырлашты. Миңа дистәләрчә кешеләр белән хат язышырга, дистәләрчә иптәшләр янына барып кайтырга, бик күпләрне күреп сөйләшергә һәм хәтерендә сакланган энҗе бөртекләрен «инә белән казып» алырга туры килде...»*

1953 елның 25 апреле — каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең икенче тапкыр

дөньяда туган көне. Шул көнне К. Симоновның баш сүзе белән «Литературная газета» басмасында Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ннән беренче тапкыр алты шигыре дөнья күрә һәм күпмилләтле Советлар иле халкын тетрәндерә. Шуннан соң галим герой-шагыйрь иҗатын, аның бөеклеген һәм дөньякүләм әһәмиятен, рухи һәм гражданлык батырлыгын, гуманистик табигатен гәүдәләндергән йөзләрчә мәкаләләр һәм гыйльми комментарий-аңлатмалар яза («васыятьнамә»сен җибәргән хатта Муса сугышка кадәр үзенең иҗади мирасын тәртипкә китерә алмавы турында да язган). Тынгысыз-тырыш галим Җәлилнең әсәрләрен халыкка җиткерү һәм популярлаштыру буенча да зур фидакарьлек күрсәтә. Ул «Моабит дәфтәре»нә беренче гыйльми комментарийлар яза, 1955-56 елларда шагыйрьнең татар телендә өч томлыгын, 1962 елда русча бер томлыгын һәм 1966 елда фотоальбомын әзерләп чыгара. Муса Җәлил турында истәлекләрне оештырып, җыеп һәм туплап ике телдә бастыра, аның тормыш һәм иҗат юлы турында күләмле очерк-монография яза. Әдип-галимнең Җәлил турындагы күп кенә мәкаләләре чит телләргә дә тәрҗемә ителеп басыла, шулар аркылы герой шагыйрьнең каһарманлыгы һәм иҗаты турында дөньяга мәгълүм була. Әминә Җәлилова галим турында хаклы рәвештә: «Гази Кашшаф — дуслык хакына чын батырлык күрсәткән зур йөрәкле, тыйнак кеше...»

Муса Җәлил патриот шагыйрь булса, Гази Кашшаф каһарман галим!

* * *

Данлыклы шагыйрь белән олуг галимнең эчкерсез-самими, ныклы дуслыгы да, Җәлилнең Кашшафка язган васыяте дә, Газинең Мусага биргән вәгъдәсе дә мәңгелек изге антка тиң. Аларның бер-берсенә язган хатлары да моны ачык раслый-дәлилли. Мин бу язмамда Муса Җәлилнең Гази Кашшафка язган ике хатыннан өзекләр китерү белән чикләнәм:

*«Кашшаф, кадерле дус!*

*Синең хатың беренче булып килде һәм мин бөтен йөрәгемнән игътибарың өчен һәм чын дуслыгың өчен сиңа рәхмәт белдерәм. Мин һәрвакытта да синдә үземнең иң яхшы һәм сизгер дустымны күрдем һәм мине бервакытта да онытмавыңа тирән ышана идем. Синең хатың бик җылы язылган һәм мин анда үземнең сагынган йөрәгемә кирәкле нәрсәләрнең барысын да таптым. Рәхмәт, кадерле дус!..*

*Кайнар үбәм — Муса.*
*17 сентябрь, 1941 ел. Щигры».*

*«Кашшаф дус!*

*...Хатыңны алгач, бик шатландым. Ләкин... укыгач, әлеге шатлыгым зур кайгы һәм борчылу белән алмашынды: син чынлап торып ашказаны белән авырып, больницада ятасың икән.*

*Бу минем өчен соңгы елларда кичергән иң каты кайгы булды. Чөнки мин сине бик яратам. Хөрмәт итәм һәм сиңа синең турыда хәвефле хәбәрләр ишетү бик күңелсез. Тизлек белән яз: операция ничек узды, сәламәтлегең ничек һәм үзеңне ничек сизәсең? Мин, әлбәттә, фән һәм безнең врачларның — якташларның көченә ышанам, барысы да уңышлы булыр. Ләкин... тизрәк хатны алуга бу хакта миңа яз һәм мине тынычландыр...*

*Кулыңны кысып: Мусаң.*
*27 май, 1942 ел. Волхов фронты».*

Бу сүзләргә өстәп нидер әйтү мөмкин түгелдер һәм кирәкмидер дә. Шуңа күрә күренекле әдәбият галиме, филология фәннәре докторы Нил Юзиевнең сүзләрен китерү белән генә чикләник: «...тормышта да, һәлак булгач та, язмыш бу ике бөек шәхесне гел очраштырып тора: китапларда, газет-журналларда, документаль фильмнарда, романнарда, кешеләрнең йөрәкләрендә...»

* * *

«Иҗат процессы беркемгә дә җиңел бирелми, иҗат итү — бик авыр һәм җаваплы эш. Шул хакта Пушкин, Маяковский кебек даһи шагыйрьләр дә язганнар. Өзлексез

эзләнүләр, газаплы уйланулар нәтиҗәсендә генә талант үзен күрсәтә ала. Эзләнү тукталса, талант сүнә...» дип язды Гази Кашшаф. Бу сүзләр авторның үзенә дә карый: галим эше икеләтә җаваплы — күп укуны, аналитик акылны һәм күпкырлы фикер сөрүне таләп итә...

Гази Кашшаф көндәлекләр дә алып барган. Аларга татар театры тарихы кереп яткан. Көндәлекләр Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать гыйльми институтының мирасханәсендә саклана. Шунысы аяныч: Гази ага тырышлыгы белән Г. Тукай бүләге алган талантлы галим Нил ага Юзиев аларны матбугатта бастырып чыгарырга өлгермәде...

Гази Кашшаф Татарстанның иҗтимагый-сәяси тормышында да актив катнаша. Ул күп тапкырлар КПССның Татарстан өлкә комитеты, Казан каласы һәм аның Бауман районы комитеты әгъзасы итеп сайлана, Казан шәһәр Советы депутаты була. Әдәби-гыйльми һәм җәмәгать эшчәнлеген югары бәяләп, аны Хезмәт кызыл Байрагы (1957 елда), «Почет Билгесе» (1967 елда) орденнары һәм медальләр белән бүләклиләр. Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты турындагы тикшеренүләре, хезмәтләре өчен Гази Кашшаф 1976 елда, вафатыннан соң, Рафаэль Мостафин (ул Җәлилнең исемен мәңгеләштерүгә гаять зур көч-тырышлык салды һәм Тукай премиясе белән бүләкләнде) белән бергә Татарстан комсомолының Муса Җәлил исемендәге бүләгенә лаек булды...

«Ул кеше, гаилә башлыгы, галим, журналист, язучы һәм укытучы буларак иң яхшы Кеше иде», — дип хәтерли Гази аганың тормыш иптәше Асия ханым Пермьнән мина җибәргән хатында...

* * *

Дустының ядкаренә тугрылык йөзеннән, Муса Җәлилнең тууына 70 ел тулуга әзерләнгәндә, Гази Кашшаф шагыйрьнең тормыш юлын һәм иҗатын пропагандалау җәһәтеннән үзенә гаять зур йөк ала. Аның болай да авыру йөрәге кызганычка каршы бу йөкне күтәрә алмый: олуг галим 1975 елның 9 декабрендә 68 яшендә вафат була...

Аның бертуганы Фатыйма ханым (алар ике анадан туган) түбәндәгеләрне хәтерли: «1975 елның 25 ноябрендә Казаннан хат алдым. Асия килен «Гази телсез калды. Больницада ята. Мин шунда аны тәрбиялим. Килә алсаң — кил», дип язган. Икенче көнне Октябрьскийдан, Туймазыга барып, «Уфа — Казан» поездына утырып, Газиларга киттем. Казанда Асиянең апасы Разия кодача больницага илтеп куйды. Асия белән икәү көне-төне Гази янәшәсендә булдык, икәүләп тә, чиратлашып та карадык. Кайчак улы Ренард та дежурга килә иде. Медиклар күпме генә карасалар да, профессорларның даими күзәтүе астында тотылса да, кыйммәтле дарулар белән дәваласалар да, кирәкле шартлар житәрлек булдырылса да Газины терелтә, үлемнән йолып кала алмадылар. Чире бик тә авыр-көчле иде: инсульт булган, гәүдәсенең уң ягын паралич суккан, ике үпкәсе дә ялкынсынган, ике бөере дә ныклап зарарланган, бәвеле агулана башлаган. Калак-кашык белән генә ашаттык. Үзе әйбәт ишетә иде, ләкин сөйләшә алмый — кәгазьгә язып кына аралаштык...

Шул ук елның февралендә Газиның чакыруы буенча Казанга киленебез Асиянын 60 еллык юбилеена барган идем. Гази: «Эш бик күп, вакытның минуты да кадерле. Көне-төне эшлим (Гази Кашшаф ул вакытта 120 сум персонал пенсия ала — З. П.). Муса Җәлилнең 70 еллык юбилее якынлаша бит, шуна кадәр аның 4 нче томын әзерләп чыгарырга кирәк», — диде. Бик йончыган, арыган иде. Ай ярым больницада яткан. Анда да эшен өзмәгән. Ә 11 нче ноябрьдә өендә чакта инсульт булган. Гази ул көнне Муса Җәлил китапларының 4 нче томын нәшриятка илтеп биргән. Кабул иткәннәр, әмма аңа: Җәлилнең юбилеена чыгарып өлгермәячәкбез», — дигәннәр. Өйләренә бик тә кәефсез, нык борчылып кайткан Гази...

Үләсе көнне дүрт катлы юеш бинт-мамык белән бөтен битен, ияк астын, борын-күз тирәләрен, колак артларын сөрткәләп чистарынды. Аннары, суына башлаган куллары белән Асиянын һәм минем кулларыбызны кысып тотып, күзләребезгә тутырып, бик озак карап торды. Без, аны юатырга теләп: «Тиздән тереләсең, Гази, борчылма берүк», — дидек. Ул, «юк!» дигәндәй, башын аркылыга чайкады... 9 декабрьдә Мәскәү вакыты белән кичке 6 сәгать 20 минутта җаны өзелде, гомере киселде.

Газинең һәрчак эше күп, вакыты тыгыз булды. Вакытын, гомерен бушка үткәрмәде. Еш чирләде. 1931 елдан бирле сыңар аяк белән яшәде, шулай да аңа командировкаларда күп йөрергә туры килде. Беренче иптәше Һаҗәр яшьли вафат булды. Икенче иптәше — балдызы Асия белән 4 бала тәрбияләп үстерделәр.

Гази бик тә туган җанлы, акыллы, сабыр, кечелекле иде, һәрчак туган Туймазы, Кандыр якларын, туып-үскән авылын сагынып, үз-якын күреп яшәде. Ләкин Яңа Арсланбәккә еш кайта алмады, үз туганнары белән еш аралашырга туры килмәде аңа...»

...Сәрән урта мәктәбе музеенда (хәзер ике Арсланбәктә дә мәктәп юк, балалар Сәрән авылына йөреп укыйлар) Гази Кашшафның Казаннан бүләк итеп җибәргән автографлы «Муса Җәлил» дигән китабы кадерләп саклана. Анда галимнең үз куллары белән шундый сүзләр язылган:

*«Туган авыл! Туган мәктәп!*

*Изге йорт, изге җирләр! Беренче тапкыр мин Сездә хәреф таный башладым, беренче тапкыр Сез тормышка юл күрсәттегез, күземне ача башладыгыз! Тормышта бик күп юллар барлыгын әйттегез! Мин шуларның берсеннән киттем...*

*Дөрес сайладыммы мин юлны — анысын Сез әйтегез!*

*Туган авылыма, туган мәктәбемә минем мәхәббәтем көчле! Шунын билгесе итеп җибәрәм бу китабымны!*

*14.III. 69.*
*Казан»...*

* * *

Гази Кашшафның Башкортстан әдипләре һәм сәнгать әһелләре арасында да дуслары, хөрмәт иткән шәхесләре күп иде. Әлеге язмамны мин галимнең фикердәше һәм сердәше — Башкортстанның халык шагыйре, Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты, башкорт әдәбияты аксакалы (милләте белән чын татар!) Сәйфи ага Кудашның акыллы-зирәк сүзләре белән тәмамлыйм: «Минемчә, Гази Кашшаф татар совет әдәбиятының Сабан туйларында яки ипподромнарда елына бер тапкыр чаба һәм юырта торган аргамаклардан түгел. Ул татар совет әдәбиятының ел әйләнәсенә муеныннан камыт төшерми торган йөк аты булды. Аны нинди зурлыктагы арбага җиксәләр дә, күпме йөк салсалар да (һәм сыртлап-бастырыклап төясәләр дә! — З. Н.), ул шуны бөтен көче белән тарта һәм алга таба сөйри бирде. Шунын белән бергә татар әдәбиятының төп көчләрен тәшкил иткән барлык язучылардан Гази Кашшаф каләме белән тормыш һәм иҗат юллары яктыртылмаган әдип һәм шагыйрьләр калмагандыр. Шуңа күрә дә аның әдәби-гыйльми йөгендә шалдыр-шолдыр, вак-төякләр түгел, бәлки татар әдәбиятының алтын фондларын тәшкил иткән иҗатлар турындагы җитди хезмәтләр урын алдылар. Шунын өстенә безнең Гази Кашшаф үзаллы әдәби-гыйльми һәм фәнни-педагогик эшләрен һәрвакыт җәмәгатьчелек һәм партия эшләре белән янәшә алып барды. Бу хәлләр инде Гази Кашшафның хезмәтләрен иҗтимагый баектырырга һәм гыйльми әһәмиятләрен күтәрергә ярдәм иттеләр. Аның Муса Җәлил турындагы хезмәтләре инде бәяләп бетерергә мөмкин булмаган батырлык булып торалар.

Гадел Кутуйның Гази Кашшафка бик зур өмет баглавы, Муса Җәлил үзенең соңгы васыятен дә аңа ышанып калдыруы әдәбият белгече Гази Кашшафның намусы һәм тыйнаклыгы, кешелек һәм самимилек сыйфатлары турында бик күп нәрсәләр сөйлиләр. Чөнки бу сыйфатлар кеше өчен, гомумән, бер тапкыр кирәк булсалар, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече өчен ун тапкыр кирәк булган чын бизәкләр. Ә чын бизәкләрне заманаларның бернинди җилләре һәм явымнары да үндыра алмыйлар»...

Чиксез горурланам мин күренекле якташым Гази ага Кашшаф белән!..

**Замир НИЗАМЕТДИНОВ.**
*Башкортстан,*
*Туймазы каласы.*

Салих
Шамов

# МӘҢГЕЛЕКТЕР СӘЙДӘШ МОҢНАРЫ

*Нужа белән бәхәсләшә Сәйдәш,*
*Ваклыклардан үзен аралап.*
*Күңеленә язмыш бәлзам коя,*
*Яки бәгърен китә яралап...*

Композитор гомереннең күп өлешен ике ут арасында яшәгән дидек. Боларның берсе — эшсез калу, Камал театрыннан читләштерү булса, икенчесе Кәрим Тинчурин, Фәтхи Бурнаш кебек иң якын иҗади дусларын югалту, аларның төрмәдәге билгесез газаплары иде. Шушылар янына тагын гаиләсендәге кыенкатлаулы хәлләрне дә өстәсәк, күп нәрсәләр аңлашыла...

Әләк ташучылар Сәйдәшнең кулга алынган «халык дошманнары» белән дус булуын, хезмәттәшлеген күз уңаеннан ычкындырмыйлар. Маэстроның тормышы, иҗаты куркыныч астында! Ул, әнә шундый әләк кармагына эләкмәс өчен, төрле дусларында яисә гади кешеләрдә кунып йөри... Менә шул чакта, теләге булса, композиторлар союзы ярдәм итә алмас идемени ана?

Бу шаукым, композиторның талантын «күрмәмешкә салышу» шактый дәвам итә әле. Бер генә мисал. 1950 ел, 3 декабрьдә Сәйдәшнең 50 яшьлек юбилее көтелә. Язучылар союзыннан сорыйлар: «Бу уңайдан нинди чаралар үткәреләчәк?» Композиторлар союзының җитәкчесе сүзне бик коры тота: «Бу обком компетенциясендә, бүтән сүзем юк!»

Куштаннар, яраннар һәм, әлбәттә ВКП(б) обкомы булышлыгы белән, Сәйдәшнең милли, халыкчан иҗатына Ватан сугышына кадәр үк инде күпмедер дәрәҗәдә «табу» салына. Тыштан караганда Н. Җиһанов белән аралары җайлы, ипле генә кебек. Җиһанов Сәйдәш исеменә начар сүзләр әйтми әйтүен. Рәсми тантаналарда ул кайчакны Сәйдәшкә мөлаем мөнәсәбәт күрсәтә, беркатлы тыңлаучылардан алкышлар яудыра. Ләкин болар чын ихластан түгел, нибары рольгә керү. Яшерен яткан аскы агым бүтәнчәрәк юлдан бара.

## Скрипка елавы

...1954 елның яңгырлы сентябрь көннәре. Вакыт берни белән исәпләшмичә Сәйдәш гомереннең соңгы айларын саный. Үзенең саулыгына борчылып, композитор клиник тикшерену уза. Табибларның тәкъдиме исә бер дә юанырлык түгел: кичекмәстән операция ясарга кирәк һәм бары тик Мәскәүдә.

Сәйдәшев Мәскәүгә китәр алдыннан фронтовик шагыйрь Мөхәммәт Садри аңа Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре»н тапшыра. Шул көнне күпне күргән-кичергән маэстроның күңелендә якты вә кайнар сагыш белән сугарылган «Җырларым» мелодиясе туа. Гомереннең соңгы көннәренә аяк басканда да шушы җырны иҗат итә алган композиторга карата ничек инде даһи димисең! Бу — аның тормышына яңа музыкаль-эпик бөеклек өстәгән даңлы әсәре. Җырның язмышында гаять тирән символик мәгънә — шагыйрь белән композиторның гомер финишына нинди зур рухи бөеклек, кешелекле васыять белән килүләре ярылып ята лабаса. Шушы ике шәхес, татар халкының газиз уллары килер буыннарга нинди гүзәл иҗади һәйкәл

*Дәвамы. Башы 3 нче санда

калдырып китә белделәр.

Дистә еллар узды, инде берничә буын тыңлаучылар И. Шакиров, Х. Бегичев, Г. Дәминов башкаруында ләззәт алдылар. Дөньяга билгеле эстон җырчысы Георг Отс «Җырларым»ны Мәскәү тамашачыларына да житкерә алды. Аның нәфис-бәрхет һәм илаһи баритон тавышын Кавказ тарлавыгыннан агып төшкән куәтле шарлавыкка тиңләп булыр иде, мөгаен.

...Менә 1954 елның декабрь уртасына да аяк бастык. Бервакыт Гоголь һәм Горький урамнары чатына килеп чыккач, мин Камал театрына таба агылган ифрат озын чиратны күрдем дә кинәт туктап калдым. Гадәти хәл түгел иде бу: көлү-сөйләшүләр юк, хәтта тәртип сакчылары да күренми. Йөрәкне нидер чәнчеп алды. Ирексездән чиратка килеп кушылгач та авыр сулап үзалдына нидер сөйләнә торган берәүнең: «Әй, Сәйдәш, Сәйдәш!..» дигән сүзләрен ишеткәч, имәнеп китә яздым. Күз алларым караңгыланды, бу шомлы хәбәргә — Сәйдәшнең юклыгына һич тә ышанасы килми иде.

Театрның матәм билгеләренә уралган фойесы: биегрәк урында, чәчәкләргә күмелеп, композиторның гәүдәсе салынган ачык табут тора. Югалту ачысын тагын да көчәйтеп, кайсыдыр почмактан туктаусыз рәвештә «Тәфтиләү» моңнары агыла. Заһид Хәбибуллин, скрипкасын үксетеп-елатып, остазы һәм җан дусты белән әнә шулай саубуллаша икән. Өске каттан исә Фәйзи Биккинин «Хуш, авылым» көен концерт гармунында башкара...

Бөтен Казан аягүрә басты диярлек, сөекле композитор белән хушлашу ташкыны ике көн буе дәвам итте. Республикабыз районнарыннан, Башкортстаннан, башка шәһәрләрдән килүчеләр дә күп. Сәйдәшевнең вафатын ишетеп, Көнчыгышка баручы поезддан махсус төшеп калган Себер гаиләсенең барлыгына шаһит булдым мин. Хәрби кешенең алты яшьлек баласы бигрәк тә хәтердә калган. Әтисе янәшәсеннән атлап бара һәм сорый ул:

—Ә бу яхшы абыйга һәйкәл куячаклармы?

Әтисе, чәчләре чаларган офицер, сүзен өзеп әйтте:

—Әйе, улым, һичшиксез. Биш-алты елдан соң Казанга тагын килербез һәм композиторның шәһәр уртасындагы һәйкәленә рәхмәт йөзеннән чәчәкләр салырбыз!

Матәм барышында бер «аңлашылмаучылык» та килеп чыкты әле: обкомнан килгән бер вәкил, процессия эшенә катнашасы итеп, мәрхүмнең югары дәүләт бүләкләрен чыгарырга тәкъдим ясады. Мөхәммәт Садри шундук: «Ә сез аларны бирдегезме соң?» — дип кычкырды. Мескенкәй, вәкил буларак килгән килүен, ә менә иҗатыннан һәм язмышыннан бөтенләй бихәбәр икән үзе.

Үз заманының «ханы» С. Батыев, сигез ел узганнан соң,зиннәтле кабинетында утырган килеш кенә телефоннан Сәйдәшнең исемен «мәңгеләштереп» куя: ягъни Казанның Пелатән төрмәсе тирәсендәге ямьсез-пычрак бер урамга Сәйдәшев исемен бирәләр. Композиторның иң якын дуслары Ф. Бурнаш белән К. Тинчурин кыйналган, газап чиккән, юкка чыккан шушы шомлы төрмә тирәсен сайлап алу — күрәләтә эшләнгән яман эш, билгеле.

1963 ел, Эрмитаж бакчасы. М. Әмир, И. Гази һәм А. Шамов кебек танылган әдипләр белән очрашудан файдаланып, сорадым:

—Сәйдәш исемен мыскыл итеп, Пелатән тирәсен сайлаганнар. Язучылар Союзы моңа каршы килә алмады микәнни?

Җаваплары төрлечә булды. Ибраһим Гази, обком ягына ишарәләп, үпкәчел төстә әйтә:

—Төкерә алар безнең каршы килгәнгә!..

Мирсәй Әмир исә тагын да ачыклабрак әйтә белде:

—Композиторлар союзында Батыевның әшнәсе бар. Мөгаен кинәш-тәкъдимне ана ул биргәндер.

Афзал Шамов, елмая төшеп, үзенчә бер нәтиҗә ясады:

—Мина сезнең белән килешергә генә кала.

Хезмәт ветераны Ф. Тимербулатова республика житәкчелегенә язган хатында композитор турындагы кайбер истәлекләрен сөйли, Пелатәндәге Сәйдәшев урамын М. Горький урамы белән алмаштырырга үтенә. Ләкин, ни кызганыч, шушы көнгә кадәр аның үтенеченә колак салучы күренми...

* * *

С. Сәйдәшевне җирләү көннәреннән тагын бер нәрсә искә төшә. Тормышы һәм иҗатының соңгы дистә еллары узган, ул яшәгән йорт янында җыелышканнар арасында үзара сөйләшү, фикер алышулар да хәйран булды, билгеле. Менә шул чакта композитор яшәгән йортта музей оештыру кирәклеге турында сүз чыкты. Утыз-кырык ел узганнан соң, 1993 елның кояшлы бер көнендә, ниһаять, җәмәгатьчелекнең якты теләге чынга ашты: зиннәтле музей үзенең ишекләрен ачып җибәрде.

Ачылыш тантанасының онытылмас минутлары!

Сәйдәш иҗат иткән легендар Маршның куәтле авазлары белән урамны һәм күкләрне тутырып, музейга таба тынлы оркестр якынлаша. Ораторларның кайнар чыгышлары шатлык һәм куану, горурлык хисләре белән тулы. Менә зәңгәр тасма да киселде. Сәйдәш көенә язылган Татарстан Гимнының Әзһәр Абдуллин тарафыннан эшкәртелгән варианты тантаналы яңгырый. Кояшлы, шат күңелле лирикага кучкәнче дәртле көйнең нинди дер шартлаулы оптимистик башлангычы, күрәсең, күпләрнең күңеленә хуш килде: җыелганнарның барысы да дәррәү кул чапты.

Янәшәмдә басып торучы ветеран, Камадагы «Мулланур Вахитов» пароходының элекке капитаны, С. Сәйдәшев белән аралашып яшәгән Зиннәтулла ага Яһүдин, керфегендәге шатлык бөртекләрен сыпырып, әкрен генә әйтеп куйды:

—Ходаем, республикабызның әзер гимны бит бу! Искиткеч көй...

Ризалыгымны белдереп, мин дә кушылдым:

—Әйе, татарның «Марсельеза»сына тиң әсәр ул. Кояшлы гимн!

* * *

Татарстан Югары Советы эшләгән сценарий нигезендә Татарстанның гимны расланды. Тавыш бирү вакытында, Фәрит Яруллин музыкасы белән бергә, Сәйдәшев көенә язылган вариант та игътибардан читтә калды.

Кызганыч, бер көнлек проблемалар белән яшәүче кайбер түрәләрдә халыкның яраткан композиторларына тиешле бәя, җылы караш җитеп бетми. Заманында Сәйдәшев һәйкәленә дип халыктан җыйналган зур фондны таратып бетерү, аннары 12 ел дәвамында һәйкәлне куюга аяк чалу — болар барысы да зур гамьсезлек турында сөйли.

Бу урында композитор музеендагы директорларның «еш алмашынып» торуын да дәлил итеп китерергә мөмкин. Соңгы ике ел эчендә бередә ике хуҗа алышынды: берсе пенсиясен көч-хәл белән көтеп алгач кына китә, икенчесен хулиганлык өчен эштән азат итәләр. Өченчесе, ягъни бүгенгесе исә — элеккеге хәрби кеше, китәргә җыенмый.

Монысы да кызганыч! Бөек композитор музееның директоры итеп музыкаль белеме һәм тәҗрибәсе булмаган, музей эшенең нечкәлекләрен аңлап җиткермәүче отставкадагы пенсионер офицерның билгеләнүе сәер. Бәлки, бу хәл комендант вазифаларын башкарырга ярдәм итәдер. Әмма татарның туган телен яхшы белмәгән, музыкасын аңламаган, әдәбияты белән якыннан танышмаган, Сәйдәшев турындагы язмаларны газет-журналдан, китаптан укып бармаган, композитор архивын бөтенләй өйрәнмәгән директорга, белмим, нишләргә генә каладыр?

## Абыем белән әңгәмәләр

Мина калса, бу язмадагы истәлекләремдә танылган язучы, хикәяләр остасы һәм рус классикасыннан менә дигән тәрҗемәләр биргән Афзал Шамов белән сөйләшкәннәрнең хатирәсен кулансам да артык булмас.

Сугыш алды елларыннан башлап 70 нче елларга кадәр җәмгыять тормышының алгы сафларында булган ул: «Совет әдәбияты» журналын редакцияләгән әдип, ТАССР Язучылар Союзы идарәсе рәисе, Республиканың Югары Советы депутаты, КПСС Өлкә комитеты әгъзасы һ. б. Музыка-әдәбият өлкәсеннән дә ерак тормады. Аралашуымның никадәр мөһим икәнлегенә тукталмыйм, ләкин композиторлар

һәм музыка әһелләре турында бер генә сөйләмәде. Кайчакны мин аңа усалрак сораулар бирүдән дә тайчанып тормый идем.

Сөекле композитор иҗатына табынучыларның Сәйдәшев һәйкәле дип янып йөрүчеләре турындагы «Кадерле мирас» дигән мәкаләне укыгач («Социалистик Татарстан», 25 ноябрь, 1987 ел), ул минем инициативаны, гомумән, бу мәкаләнең кузгатылуын хуплап чыкты. Әмма бер урында кинәттән генә ни өчендер Сәйдәшевнең шәраб белән «дус» булуын телгә алды...


*А. Шамов*

Әлеге юрамасын тынлагач, мин: «Абый, син бит тамчы да эчмәгән зыялы кеше, Салих абый белән рюмка күтәргәнең булмады дип беләм. Хәмергә һәвәс танышларың белән дә бәйрәм итмәдең. Сәйдәшевнең шәрабкә мөкиббән булуы турындагы сүзләрең озын колаклардан ишеткән имеш-мимешләргә генә кайтып кала түгелме соң?»

Әлеге сүзләремә реакциясе тиз һәм кискен булды:

—Юк! — Бераз тын алганнан фикерен менә болайрак дәлиллисе итте: — Әле Сәйдәшев үзе исән вакытта ук бу хакта, кайвакыт уен-көлке катнаштырып, обком секретаре Батыевның сөйләгәне бар иде.

Моңа каршы мин:

—Батыев әфәнденең дә бит такыр кесәле, акча кытлыгында утырган композитор белән эчеп йөргәне булмады. Димәк, Сәйдәшевнең хәмер тоткалаган чакларын озын телле дусларының берсе сөйләп йөргән ана!

—Алай булуы да бик мөмкин, — дип җавап бирде абыем. — Әмма бервакыт композиторны сәрхүшрәк хәлендә үземнең дә күргәнем булды. Бу хакта Җиһановтан да ишеткәнем бар. Ул — коммунист, ялган сүз сөйләп йөрмәстер.

Абыем белән бәхәстә беренче тапкыр кызып китеп, ачу белән сүзләремне дә русча әйтеп ташладым:

—Вот где, оказывается, была зарыта эта «дохлая собака»!

Гафу үтенгәч, сүзне туган телемдә дәвам иттем:

—Хәер, Сәйдәшев талантына сокланучылар әлеге имеш-мимешләрнең кай тарафтан искәнен әллә кайчан, ул үзе исән чакта ук тоемладылар. Мисаллар булгандыр, күрәсең. Синең композиторны «бервакыт» сәрхүш очратуың Сәйдәш кебек олуг шәхесне әхлаксызлыкта гаепләргә бернинди дә нигез бирми! Коммунист Батыев «авторитеты»на сылтау исә бөтенләй көлке. Ходай аңа намус һәм зыялылык сыйфатларын бирмәгән булса кирәк...

М. Мусоргскийның аяныч язмышын исенә төшереп, дәвам иттем:

—Даһи композиторның кайчандыр эчү белән мавыгуы хәзер берәүне дә борчымый. «Хованщина», «Борис Годунов» кебек иҗат җимешләре исә яңадан-яңа буын тамашачыларын сокландыра. Шуның кебек, рәхмәтле халкыбыз да яраткан композиторларының вак-төяк кимчелеген гафу итәчәк. Ә инде төптән уйлап карасаң, гафу итәрлек нәрсә дә юк ич биредә. Биредә, хакыйкатьтән дә бигрәк, котырту максаты һәм имеш-мимешләр күбрәк.

Афзал абыем бик нык уйланып калды.

Ул бу четрекле мәсьәләне тәгәл генә белеп бетермәвен таный иде бугай. Мин, акыл сатарга тырышмыйчарак кына, фикерләремне әйтеп бетерергә ашыктым:

—Син «айсберг»ның өске өлешен генә күрәсең, дип саныйм. Аның иң мөһим булган аскы өлеше — ачы язмыш тарафыннан бирелгән драматик өлеше — бик күпләргә, шул исәптән җәмгыятьнең өске эшелонындагы байтак чиновникларга да бөтенләй күренмәде. «Су асты»нда ниләр булганын композитор үзе һәм аның күңел халәтенә сизгер аз санлы дуслары гына белеп торган...

Әйткәннәремә абыем каршы чыкмады.

Вакытында аның «Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр» тупламасын әзерләүдә зур көч түккәнен, илһамланып эшләгәнен хәтерлим. Менә шуны истә

тотып, композиторның 80 еллыгы уңаеннан чыккан «Салих Сәйдәшев турында истәлекләр» китабы хакында аның фикерен сорадым. Бераз уйланып торганнан соң, ул миңа болай җавап бирде:

—Кайбер мәкаләләрнең иң әһәмиятле урыннары төшеп калган. Бу — истәлек авторларына карата хөрмәтсезлек күрсәтү. Күренекле шәхесләр турында истәлекләр җыентыгын эшләгәндә халтурага юл куелмаска тиеш. Бигрәк тә кул астында зур әһәмиятле материалларның күплеген истә тотсак. Бу китапчык — әштер-өштер генә, ашыгычлык белән эшләнгән юбилей заказы. Биредә яхшы гына язмалар да бар, әмма күп кенә истәлекләр салкын кан белән язылган, алар хезмәткә мәхәббәт һәм хөрмәт хисләреннән азат...

Сүзен тәмамлап, ул мәкаләсе китапка кергән Галия Кайбицкаяның фикерен дә белешергә киңәш итте.

Ялгышмасам, әле 1952 елның көзендә үк абыем С. Сәйдәшев белән аралашуының янә бер хатирәсе белән уртаклашты. Композиторның матди кыенлыкта утырганын белеп, ни өчен консерваториядә укыту эшләренә тотынмавы хакында сораган ул. Һәм җавап көтелмәгәнчә була:

—Консерватория хуҗасы чакырмаячак, партия обкомы аны мәҗбүр итмәс. Ә Сәйдәш, үтенүче сыйфатында эшләпәсен салып, аларга ялынып йөрергә җиенмый...

Монда сүз укларының кая таба җибәрелгәнен чамалау кыен түгел.

1990 елның гыйнвары. Сәйдәшевнең 90 еллык юбилей тантанасына әзерлек эшләре барган чак. Әнә шулар хакында сорашкач, Афзал абыемнан композитор турындагы соңгы фикерләрен ишетеп калдым.

Болай дип җаваплаган иде: «Хәзер инде бик ачык — Сәйдәшев профессиональ музыкабыз сәнгатенә нигез салучы гына түгел, ул XX гасыр мәдәниятебез тарихында бөек шәхесләребезнең берсе. Ул Тукай белән янәшә, бай тарихыбызда калырга тулысынча лаек».


*Г. Кайбицкая*

Бу инде бөтенләй бүтәнчә, барыннан да бигрәк гадел, объектив бәя иде.

Профессор Мөхәммәт ага Гайнуллинның ташып торган хисләреннән аермалы буларак, абыем Афзал Шамовның тойгылары шактый басынкы иде. Әмма, 1991 елның гыйнварында, вафат булыр алдыннан, Сәйдәшкә карата кызыксынуы тагын бер кат калкып чыкты. Астма белән бик нык интегүенә карамастан, телефоннан миңа Салих Сәйдәшевнең 90 еллык юбилей тантанасында Мансур Хәсәнов мактаган чыгышны мактады. Дистәләрчә еллар буена хакыйкать бозып һәм яшереп бирелде, дип тә өстәде әле.

Кинәттән Сәйдәшевнең 1951 елгы 50 яшьлек юбилее хакындагы фикерен дә әйтте. Күңелендәге горурлык белән ул: «Белеп тор һәм исеңдә тот! Татарстан язучылар союзы инициативасы һәм фронтовик шагыйрьләрнең үзсүзлелеге, кат-кат кисәтүләреннән башка юбилей узмаска да мөмкин булган», — дип белдерде.

Бу мәсьәләдә Казакъстан, Үзбәкстан, Әзербайҗан, күрше Башкортстан зыялыларының ярдәмен дә телгә алды. Йөткереп алганнан соң: «Һәйкәленә акча җыелды инде. Хәзер Сәйдәшевкә Камал театры янәшәсендәге йорт-музеен чынга ашырыр вакыт җитте. Арабыздан китүче бик күпләрнең васыяте бу...»

Чираттагы тапкыр сулышы кыса башлагач, сүзен тәмамлый алмады ул. Бу — безнең соңгы сөйләшүебез иде.

*Ахыры киләсе санда.*

*Габдерәшит Ибраһимовның тууына 150 ел*

# АРМАС-ТАЛМАС КАҺАРМАН

Татар халкының мәшһүр сәяхәтчесе, үз чорының танылган дини, иҗтимагый һәм сәяси эшлеклесе, үткен публицист, нашир һәм журналист Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимов 1857 елда Себердәге Тара шәһәрендә дөньяга килгән. Казан өязенең Кышкар авылы мәдрәсәсендә укыганнан соң Мәдинә шәһәренә барып белем алган. Аннан 1884 елда кайтып, туган каласында имамлык иткән. 1892 елда Диния нәзарәтенә казый итеп сайланган. Шуна бәйле рәвештә халык арасында «Рәшит казый» дип танылган, XX гасыр башы татар әдәбияты һәм матбугатында да аны шулай язганнар. Казыйлык вазифасыннан баш тартып, ул 1894 елда Төркиягә китә һәм Истанбул каласында яши, матбугатта мәкаләләр бастыра.

1895 елда төрек телендә «Чубан йылдызы» (Чулпан йолдызы) исемле, 59 битле китапчык бастырып тарата. Китапның ахырына авторның Мисырдагы «ән-Нил» газетасында чыккан мәкаләләре дә кертелгән. Татар иҗтимагый фикере тарихында Рәшит казыйның бу әсәре мөһим урын тоткан. Анда Россия мөселманнарының кыскача тарихлары һәм шул чордагы халәтләре тасвирланган. Автор элекке татар ханлыкларында ислам диненең таралуы, көчләп чукындыру вакыйгалары турында яза. Диния нәзарәтенең эшчәнлеге һәм эчке төзелеше белән тәфсилләп таныштырып, аның мөселманнар мәнфәгатенә хезмәт итүгә караганда, хакимият кулындагы күндәм бер коралга әверелүен фаш итә. Дини идарәдә һәм мөселман мәгарифендә кичекмичә ислах (реформа) кирәклеген яза. Хөкүмәтнең христианлаштыру һәм руслаштыру эшчәнлеген тәнкыйтьли. Патша хөкүмәтенең сәясәтенә кискен каршы эчтәлектәге, татарларны һәм, гомумән, мөселманнарны дини һәм милли азатлыкка өндәгән бу китапны Россиягә кертү һәм тарату тыелган. Әмма әсәр төрле юллар белән ватандашларына килеп ирешкән. Бу китап 1907 елда С.-Петербургта янадан нәшер ителгән. Галимҗан Ибраһимов Рәшит казыйны халыкны самодержавиегә каршы көрәшкә уяткан «тарихи кыңгыравык» дип атаган һәм «Чулпан йолдызы» китабы унаеннан: «Бу — татар дөньясының беренче эмигрантының беренче эмигрант әсәре — Бишенче ел революциясенә чаклы аңлы татарлар арасында, полиция ишетмәсен дип, колактан-колакка сөйләп, яшереп бер-беренә биреп укылган бердәнбер әсәрдер» дип язган.



Хәзерге вакытта «Чулпан йолдызы»ның нөсхәләре фәнни китапханәләрдә һәм шәхси кулларда саклана. Халык арасында электән калган гарәп язулы иске китаплар арасында, йөз елдан артык элек үк тыелган бу әсәр, сирәк булса да, һаман табылгалый. Замандаш тарихчыбыз Фәрит әфәнде Шәкүров, татар шәкертләре арасында шушы татар китабы яшерен рәвештә күмәкләп

укылган дип яза һәм, гомумән, аны милләтебездә хөр фикер уянуга сәбәпче булган өч китапның берсе дип бәяли. Галим андый өч китап дип, Ш.Мәржанинең «Мөстәфадел-әхбар...», Г.Ибраһимовның «Чулпан йолдызы» һәм Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәрләрен күрсәтә.

Габдерәшит Ибраһимов 1899 елда Россиягә кайта һәм Петербургта «Миръат» (Көзге) исемле, журнал рәвешендәге җыйнак кына публицистик альманахлар язып нәшер итә. 1900-1909 елларда Петербург һәм Казанда бу басманың барлыгы 22 чыгарылышы дөнья күргән. Ибраһимовның бу «көзге»се мөселман дөньясындагы торгынлыкны һәм Россиядәге иҗтимагый-сәяси, дини, милләтебезнең мәгариф, әдәбият, матбугат һәм мәдәният мәсьәләләрен аеруча үткен яссылыкта яктырткан. Халыкка җәдитчелек фикере таралуда бу җыентыкларның тәэсирләре зур булган.

XX гасыр башында илдә үзгәрешләр булуга ук Габдерәшит Ибраһимов Петербургта шәхси матбагасын ачып, 1905-1907 елларда үз наширлеге һәм мөхәррирлегендә татарча «Өлфәт» һәм гарәпчә «Әт-тилмиз» (Шәкерт) газеталарын чыгарган. 1907 елда «Өлфәт» газетасы хөкүмәт тарафыннан ябылгач, «Нәҗат» (Котылу) журналын нәшер иткән. Монысы да ябылып, хуҗасы кулга алынган. Шул елда тагын казакъ телендә «Сиркә» (Лидер) исемле журнал нәшер итәргә керешсә дә, анысы да туктатылган. Галим Җамал Вәлиди иң тәүге татар журналистлары дип атаган биш шәхес арасында, бу каләм әһеленең журналистлык эшчәнлеген зурлап, иң беренче итеп Габдерәшит Ибраһимов исемен язган.

Рәшит казый 1905-1907 елларда иҗтимагый-сәяси эчтәлекле брошюралар язып та тараткан. Алар арасыннан «Автономия» исемлесе аеруча әһәмиятле. «Мең бер хәдис шәриф шәрхе» исемле, төрек теленнән тәрҗемә иткән китабында патша хөкүмәтенә һәм кадимчеләргә каршы хөр фикерләр, көчле тәнкыйть үткәргән. Бу – Г.Ибраһимовның иң күп гауга чыгарган хезмәтләреннән берсе. Аның әсәрләрен укуны һәм таратуны хөкүмәт тыйган, басылып чыкканнарын полиция конфискацияләгән, җыеп алган. Бубый мәдрәсәсе мөгаллимнәрен хөкем иткәндә Габдерәшит Ибраһимовның тыелган «Мең бер хәдис...» әсәре китапханәләрендә табылу – төп гаепләрнең берсе булган.

Бу мәшһүр шәхес гарәп һәм мөселман, шулай ук Европа илләре буйлап, Һиндстан, Урта Азия, Себер, Кытай һәм Япония буенча сәяхәт иткән. Японнарны мөселманлыкка дәгъвәт кылуда зур тырышлык күрсәтеп, Токиода мәчет төзергә рөхсәт алуга ирешкән. Юлъязмалары Казанда XX гасыр башында чыккан «Бәянелхак» газетасында һәм Истанбулдагы төрек матбугатында басылып торган, аерым китап итеп тә нәшер ителгән. Үз чорының яшь каләм әһелләре аның дин юлындагы тырышлыкларыннан әче көлгәннәр.

Россия мөселманнарының «Иттифакы мөслимин» исемендәге партиясен оештыручыларның берсе шул ук шәхес булган. Беренче бөтендөнья сугышы вакытында ул Берлинга барып, мөселман әсирләре өчен «Җиһадел-ислам» исемендә татарча газета чыгара.

Габдерәшит Ибраһимов туган иленнән соңгы мәртәбә 1921 елда бөтенләйгә китеп барган. Аның 1922 елда Ташкентта вафат булуы турында хәбәр таралгач Галимҗан Ибраһимов «Татарстан хәбәрләре» газетасында Рәшит казыйга багышлап «Тарихи кыңгыравык өзелде» мәкаләсен бастырган. Ләкин күренекле шәхеснең үлеме турындагы сүз ялгыш булып чыга. Ул башта Төркиядә яшәп, 1934 елда Япониягә барган һәм 1944 елда Токио шәһәрендә дөнья куйган.

Габдерәшит Ибраһимовның 1909 елда Казанда чыккан «Дәүре галәм» (Дөнья тирәли) исемле китабын һәм 1912 елда Петербургта дөнья күргән «Тәрҗемәи хәлем» әсәрен галимә Флора Әхмәтова-Урманче «Иман»

нәшриятында 2001 елда гамәлдәге татар язуында аерым китаплар итеп бастырып чыгарды.

Гаҗәеп кызыклы тормыш юлы кичергән бу зат турында Тәүфикъ Әйди, Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов, З.Алимов, Ф.Галимуллин, төрек галиме Исмәгыйль Төрекуглы, француз галиме Ф.Жоржон һ.б. мәкаләләре һәм китаплары бар. Дөрес, аның туган елын 1850 яки 1853 дип, ялгыш язучылар булды. Ләкин «Тәрҗемәи хәлем» китабында үзе күрсәтүенчә, ул 1857 елда туган. Г.Ибраһимовның публицистик хезмәтләрен XX йөз башы татар иҗтимагый-сәяси хәрәкәте тарихы өчен чыганак буларак өйрәнеп, Фәрит Галимуллин гыйльми диссертация язып яклады.

XX гасыр башыннан алып соңгы көннәргәчә аңа багышланган мәкаләләр һәм хезмәтләрнең авторлары тарафыннан Габдерәшит Ибраһимовны корама телдә чуар эчтәлекле әсәрләр язган, тотрыксыз шәхес буларак бәяләү күзәтелә. Әмма аның, үз чорына һәм мөмкинлекләренә күрә, гаҗәеп киң колачлы актив эшчәнлеген, шулай ук ялгыз башы кылган бихисап гамәлләрен мәгънә бизмәне белән үлчәгәндә, бу зат турында нинди дә булса җайсызрак сүз әйтү килешмәс кебек. Аның милли тарихыбыздагы үзенчәлекле урынын замандашлары билгеләгән инде. Галимҗан Ибраһимов сүзләре белән әйткәндә, «Бөтен гомерен әле Себердә, әле Уфада, Казанда, Питерда, Каһирәдә, Әлҗәзаирдә, Истанбулда, Калькуттада, Бәгъдадта йөреп, «Бетәбез, уяныгыз!» дип кычкырып, ...үзен сатмаган бер ихлас дәрвиш булганга, аның Шәрыкне коткару юлында тырышуы онытылмаячактыр. Ул бер кыңгыравык! Туктамый шалтырата торган тарихи кыңгыравык иде. Рәшит бабай мәгълүм бер тарихи дәвернең, үткән баскычның бер көрәшчесе — кадимнән җәдиткә чыгуда алга өстерәүче буларак урын алачак». Әдәбият галиме Габдрахман Сәгъди дә Рәшит казыйны дин һәм милләт юлында фидакяр хезмәт иткән, «армас-талмас каһарман» дип хаклы бәяләгән.

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире ияләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**

Алексей Литвин

# КҮПТӘНГЕ ДУСКА ХАТ

### (АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВНЕҢ ЯКТЫ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА)

Кадерле Аяз Мирсәетович!

Менә инде берничә ел Сезнең белән күрешеп сөйләшә алганыбыз юк, ә бит элегрәк очрашулар һәм телефон аша сөйләшеп торулар көн саен була торган иде. Хәзер башка заманнар, каберегез янына барам да, янәшә басып истәлек-хатирәләргә күмеләм! Язмышның безне шулай бик тиз һәм кайгылы-фаҗигале рәвештә аеруы бик кызганыч.

Ә бит барысы да Восстание урамында, безнен йортта очрашудан башланган иде. Казан университетының тарих факультетында бергә укучы уларыбыз Саша һәм Искәндәр таныштырды безне. Сез Нәкыя ханым Илһамовна белән безгә килеп кердегез, шунда без дусларча чәй эчү барышында Казандагы 1918 елларның җәйкөз айлары турында бергәләшеп китап язарга ниятләгән идек, ул чорда илдә Гражданнар сугышы бара, шәһәр йә кызыллар кулына, йә Учредительное собрание яклыларга күчә. Безне ул чорның аерым кешеләре, бигрәк тә ЧКда хезмәт итүчеләрнең башкаларның язмышлары белән уйнаулары, шул властьтан исерүләре кызыксындырган иде. Мине Казан ЧКсы архивыннан табып алган бер документ шаккатырды. Башка гомерләргә «хуҗа» 19 яшьлек бер чекист, ярты битлек кенә сорау алудан соң, 50 яшьлек йорт хуҗасына, аны-моны уйлап тормастан, шундый хөкем чыгара: «Совет властена файдалы була алмаячак. Атарга!» һәм теге кешене атып үтерәләр. Шундый тизлек һәм җиңеллек белән шуңа охшаш карарлар чыгарылуы Сезне дә тетрәндергән иде.

Без иске Казан урамнарында йөри башладык, үземнең элегрәк экскурсовод булып эшләгәнемне хәтерләп, Сезгә Привокзальный (хәзерге Чернышевский) урамы, Болак, Гоголь һәм элек губерна ЧКсы урнашкан Толстой урамнары турында сөйләдем. Без бергәләп Зур Проломный (хәзерге Бауман) урамындагы Банкның идарәчесе Мансур Галимовтан 1918 елда республика алтын запасы тотылган саклагычны күрсәтүен үтендек, комуччылар аны шуннан төяп алып чыгып киткәләр бит инде. Ул алтыннар 1920 елда гына һәм яртылаш урланып кына кайтып керә. Тар гына баскычтан төшкәч, галәмәт зур корыч сейф тора, аны 1913 елда Берлинда ясаганнар. Ул безгә көчле тәэсир итте, 1918 елның 6 августында бу подвал берничә сәгатькә бөтенләй саклаусыз калгач, бирелдәге байлыкның нигә шулай аз гына талануын да аңладык.

Аннары без шул чордагы Казан тормышы турында роман-хроника яза башладык. Романдагы бик күп вакыйгалар документларга нигезләнгән иде, кешеләрнең, башлыча тәгаен шәхесләрнең образлары шул заманның җыелма образлары булып, кылган гамәлләрен төрле документлардан, истәлекләрдән, төрле тикшеренүләрдән дә җыйган идек.

Иҗади эшебезне болай оештырдык без: мин сюжет сызыгын билгелим дә, аннары аны икәүләп тикшереп чыгабыз. Сез минем текстның беренче вариантын: вакыйгаларны сурәтләү, андагы шәхесләрнең монолог һәм диалог-әңгәмәләрен кәгазьгә төшерүне йөкләдегез. Сез русча язылган текстны ала идегез дә, аның татарча вариантын үз кулыгыз белән әдәби телдә язып чыга идегез. Улыгыз Искәндәр Сезнең вариантка юлга-юл русчага тәрҗемә эшли, шуның нигезендә мин русча соңгы текстны язам.

Без бу романны рус телендә дә, татар телендә дә бастырып чыгардык, аерым өлешләрен кисәкләп-кисәкләп «Казан утлары» журналында да бастырдык, роман күпмедер вакытка иң яратып укыла торган әсәргә әйләнде. Жирле чекистларның аерым тәнкыйть сүзләренә дә карамастан, Дәүләт иминлеге комитетының (КГБ) әдәби премияләре конкурсына жибәрелгән роман, гажәпләнүебезгә каршы, безгә лауреат медальләре ирештерде. Мактау грамоталары һәм «Зорький» фотоаппаратлары белән дә бүләкләделәр әле үзебезне. Ул бүләкләр хакында без фикер алышып тормадык, болар безгә ижат эшебезне тыныч-имин дәвам итү мөмкинлеге бирер дигән мәгънәдә карашып кына алдык.

Шуннан соң без сугыш кырын ташлап качкан Петроград эшче полкының һәр унынчы сугышчысы 1918 елның августында атып үтерелүгә багышланган «Реввоенсовет» дигән пьеса яздык, еш кына хаксыз булган хөкем карарларын башкарган чекист палачы турында, аның психологик язмышы турында «Идел» журналында «Мостафа» дигән повесть бастырдык.

Без Сезнең белән илебезнең дистәләрчә еллар дәвамында мәжбүр итү һәм көчләү шартларында яшәгәнен ишетеп кенә белмәдек, моны үз күзебез белән күреп тордык. Без бу шартларны тудырган, кадерләп саклаган һәм барлык «жинаятьчел боерыкларны» үтәгән затларны аңларга тырыштык. Без икебез бергәләп сәяси корбаннарга карата булган репрессияләрне күрсәтеп документаль киносценарий яздык, Евгения Гинзбург, Галимжан Ибраһимов, Василий Слепков, Кәрим Тинчурин, Хәсән Туфан һәм күп кенә башкаларның «жинаять эшләре» турында сөйләп бирергә теләдек, шунда ук аларның палачларын да күрсәтмәкче идек. Ни өчендер Казан телевидениесе аны кабул итмәде, шулай булса да мин ул сценарийны һаман саклыйм әле. Без Сезнең белән 1919-1920 елларда Казанда булып үткән вакыйгалар турында «Убыр» («Оборотень») дип исемләнгән бик мавыктыргыч фильм ижат итәргә дә теләк белдергән идек. Әмма жирле телевидение моны да хупламады.

Иң мөһиме—без, һәркайсыбыз аерым-аерым эшләсәк тә, ижади хезмәттәшлекне дәвам итә килдек.

2004 елда Казан университеты үзенең 200 еллык юбилеен бәйрәм итте. Шул вакытта бу борынгы уку йортының хезмәткәрләре һәм аны тәмамлаучыларга багышланган күптомлы био-библиографик сүзлек әзерләнә башлады. Сез төрле хәлләр аркасында университетны тәмамлап чыга алмый калсагыз да, мин Сезнең хакта очерк язуны намус эшем дип санадым. Бу энциклопедик басмага әзерләнгән башка мәкаләләр шикелле үк, очерк кыска гына язылган иде. Мин аны әзерләгән чакта зур кызыксыну белән Сезнең университет архивында сакланып калган «эш»егезне укып чыктым. Нindидер моңсу гажизлек хисе белән Сезнең хакта Казандагы КГБ идарәсе архивындагы тикшерү «эше»н дә карап алдым.

Сезнең студентлык елларыгыз хакындагы материаллар 69 биттән тора икән. Ул 1945 елның 28 июлендә ачылган да 1957 елның 28 октябрендә ябылган. Әлеге 12 ел эчендә Сезнең белән нинди хәлләр булган соң? Үзегез язган автобиографиядән күренгәнчә, Сез Татарстанның Сарман районы Чукмарлы авылында укытучы гаиләсендә 1928 елның 17 гыйнварында тугансыз. 1930 елда Сезнең әти-әниләрегез эшкә Югары Баграж мәктәбенә күчеп килгәннәр. Сез шунда башлангыч мәктәпне, 1945 елда Сарман урта мәктәбен тәмамлагансыз. Сакланып калган өлгергәнлек аттестатыгызда 12 бишле, 3 дүртле һәм бары тик физикадан гына өчле билгесе тора.

Шул елны ук, 1945 елның августыннан Сез, унжиде яшьлек егет—Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Сезнең зачет кенәгәсендә курсның 1 семестры өчен имтиханнар тапшыруыгыз турында да мәгълүматлар бар. Сез бик авыр-ярлы яшәгәнсез, декан исеменә язган гаризагызда үзегезне матди хәлегез бик начар булу сәбәпле уку өчен түләүдән азат итүләрен сорагансыз. «Туганнарым ягыннан ярдәм ала алмыйм, стипендия минем өчен яшәвемнең бердәнбер чарасы», — дип язгансыз. Үзем дә 1950 елда студент булганлыктан, туганнарыннан ярдәм ала алмаучыларның ничек интеккәннәрен беләм идем.

Беренче курсны Сез тәмамлый алмагансыз, 2 семестрда укуга йөрмәвегез аркасында университеттан чыгарылгансыз. Сонрак Сез университеттан китүгә

авыруыгыз сәбәпле булды дип язгансыз, аннары башка сәбәпләр дә күрсәтелә. 1949 елның 14 июнендә сорау алган вакытта Сез ТАССР Дәүләт иминлеге министрлыгы оперуполномоченные лейтенант Михеевка университетның тулай торагында (Чернышевский, хәзерге Кремль урамы, 4 нче йорт) 20 студент белән бер бүлмәдә яшәгәнегез турында сөйләгәнсез. Алар арасында күп укыган, белдекле студент-филолог Александр Кузнецов аерылып торган. Ул дини эчтәлекле шигырьләр, ә Сез лирик шигырьләр язу белән мавыккансыз. Ул Сезгә Мережковскийның һәм башка ярымтыелган әсәрләрне укырга кинәш иткән. Сез аның йогынтысында булуыгызны, икәүләп университетны ташлап чыгарга теләвегезне әйткәнсез. Чөнки уку кешеләрнең тормышын яхшырта алмый дип уйлагансыз. (Кузнецов 1941-1943 елларда фашистлар басып алган җирләрдә яшәгән, шуның өчен эзәрлекләнгән. Сез исә шул чордагы татар авылы тормышын, аннары 1946-1947 елгы ачлык елларын күреп үскәнсез). Кузнецов университеттан 1946 елның гыйнвар аенда, ә Сез июньдә китеп баргансыз. Сез өегезгә кайтып, бераз уйланып йөргәннән соң, 1947 елның апреленнән Зәй комсомол райкомында кадрлар һәм оештыру бүлеге мөдире булып эшли башлагансыз. Шул чорда авылларга демобилизацияләнгән солдатлар кайта башлый, Сез бигрәк тә Гурий Тавлин белән дуслашып киткәнсез. Ул исә сугыш елларында Көнчыгыш Европа илләрендә булган, андагы крестьяннарның безнекеләргә караганда яхшырак яшәгәнлекләрен күреп кайткан.

1954 елның 8 сентябрендә сорау алу вакытында Сез Тавлин армиядән кайткан чорда чит илләрдәге тормыш турында бернәрсә дә белмәвегез, әмма ул сөйләгәннәр белән килешүегез турында әйткәнсез, ләкин ул да, Сез дә хакимият белән көрәшергә беркайчан да өндәмәвегезне искәрткәнсез. Шулай да һәр икегезнең дә авыр тормыш шартларыннан канәгать булмавыгызны раслагансыз.

1948 елны Сез университетка яңадан керү өчен гариза биргәнсез һәм шул ук факультетның беренче курсына кабул ителгәнсез. Бик яхшы укыгансыз. 1949 елның 16 сентябрендә ректор исеменә гаризагызда барлык фәннәрдән дә «бик яхшы» билгеләренә укуыгызны күрсәтеп, үзегезгә югары стипендия билгеләүләрен сорагансыз. Сезгә югары стипендия биргәннәр, әмма икенче курсны укып бетерә алмагансыз, 1950 елның 7 апрелендә шул ук «дәресләргә йөрмәгән өчен» дигән билгеләмә белән янә университеттан чыгарылгансыз. Бер яктан караганда, бу чыннан да шулай: Сез дөрестән дә укырга йөрми башлагансыз, әмма моның сәбәбе Сезнең язмышыгызда фаҗигале борылыш булу аркасында килеп чыга.

Сезнең 25363 нче тикшерү эшегез меңнәрчә шундый ук эшләрдән аерылып тормый. Шул ук кат-кат сорау алу беркетмәләре, үзегез шикелле үк бичаралар белән күзгә-күз очраштырулар, гадел хөкемгә ышаныч, бу хәлләр тиздән бетсен дип күрсәтелгән гаепләүләр белән килешү... Башыннан ахырына кадәр оештырылган бу провокацион гаепләүләргә дучар булучылар, башкарган гамәлләрендә бернинди җинаять составы да булмау сәбәпле, күптән акланган инде. Аларны совет хакимияте исеменнән хөкем иткәннәр, соныннан шул ук хакимият бу гаепләүләрнең, «вакыйгаларның янача ачылуы сәбәпле», хата икәнлеген таныган. Бернинди дә «янача ачылган вакыйгалар» булмаган, хакимият кенә алышынган, гаепсезләрне ГУЛАГтан азат итү чоры башланган... Акланганнарның күбесенең язмышы сындырылган, аларны бер гаепсез килеш ни өчен соң адәм актыклары, җәмгыятьнең төшеп калган мәхлуклары дип санаганнар? Ни кызганыч, аларның кайберләре, үз язмышларын кешелексез, тоталитар режим сындырганлыгын аңларга теләмичә, бер-берләрен гаепли башлый, бәхетсезлеккә дучар ителгән үз иптәшләрен әхлакый-мораль яктан гаепләүне таләп итә.

Немец философы Георг Гегель «чынбарлыкта булган һәрнәрсә акыллы» дигән. Кемнәр өчен акыллы? Көчләү-ирексезләүне, дәүләт террорын, хакимиятне үз кулларында саклап калу өчен үз халкын идеологик яктан аңгырайтуны хуп күргән партия-совет хакимияте өченме? Ә бу террорның миллионнарча корбаннарына нәрсә кала? Ул чордагы эзәрлекләү-репрессияләр беркемне дә аяп тормаган бит. 1953 елда ГУЛАГта өч миллионнан артык тоткын булган, шуларның өчтән бере чамасы үзләре кылмаган «сәяси җинаятьләр» өчен хөкем ителгән. Алар арасында төрле милләт кешеләре, шул исәптән күпмеләгән татарлар да булган.

Сәяси эзәрлекләү корбаннарын аклау комиссиясендә эшләгәндә мин йөзләрчә эш белән таныштым, күпләрнең тикшерү-сорау алу вакытында физик һәм психологик газаплаулардан ничек тә булса котылырга, исән калырга омтылганын аңладым. Шуның өчен генә булса да, алар кылмаган гамәлләрен дә таныганнар, тикшерүче алдан әзерләп куйган сорау алу беркетмәләренә кул куйганнар, киләчәктә хезмәттәшлек итәргә ризалык биргәннәр. Бары тик бик азлары гына тикшерүченең «вербовкага бирелми» дигән нәтиҗәсенә ирешкән. Соңрак, аклау чорында алар кагыйдә буларак үзләренең башта сөйләгән сүзләреннән ваз кичкәннәр, тикшерүченең бик каты басым ясавын әйткәннәр.

Сезнең һәм иптәшләрегезнең эшләре белән танышканда, миндә сез барыгыз да бер тикшерү провокациясе корбаннары булгансыз дигән тәэсир калды. Хәер, һәммәсен дә тәртип белән сөйлик әле. Сез 1950 елның 20 мартында кулга алынгансыз. Сезне лейтенант Михеев кулга алган. Ул һәм аның ярдәмчеләре Сез яшәгән Бехтеров урамы, 15 нче йорт 7 нче квартирда тентү үткәргәннәр. Тентү вакытында пунәтәй сыйфатында Сезнең белән бергә яшәгән курсташыгыз Нил Юзиев карап торган. Ана Сезнең студент китапханәсендәге 47 китапны сакларга дип тапшырганнар.

Сездән элек тә сорау алгалаганнар. Башта мин Сезне Жирле чекистлар аерым шик астында тотмаганнардыр, аларны күбрәк Сезнең сабакташларыгыз, инде сугышны кичергән, күпне күргән өлкәнрәк иптәшләрегез кызыксындыргандыр дип уйлаган идем. Янәсе, алар мавыгучан, хыялга бай, кызыксынучан яшь егеттән башка студентлар турында мәгълүмат алырга теләгәннәр. Әмма Сезнең белән бергә «советка каршы агитациядә» гаепләнеп кулга алынган Г. Тавлин белән М. Рәфыйковның тикшерү эшләре белән танышкач, Сезне кулга алу аларны кулга алуга караганда җентекләбрәк әзерләнгәнен аңлагач, ул фикеремнән кире кайттым, чекистларның төп максаты, әлеге «чекист операциясенең» үзәге Сез икәнлеккә инандым.

Казандагы татар студентлары арасыннан «советка каршы оешма эзләп табу» чекистлар өчен гадәти һәм күнегелгән бер эш булган, күрәсең: алар булачак корбаннарын чакыртып алганнар да хезмәттәшлек итәргә, «операциягә» катнашырга тәкъдим ясаганнар—«советка каршы» сөйләгез, ә аннары әңгәмәдәшегезнең үзен ничек тотышы турында безгә хәбәр итәрсез, дигәннәр. Шулай тупланган компроматны аларның үзләрен үк кулга алганда гаепләү өчен кулланганнар. Тавлин белән Рәфыйков сугыш кичергән кешеләр, ә Сез әле яшь, аларныкы кебек тормыш тәҗрибәгез дә юк, шуна күрә бу «операцияне» әзерләүчеләр сезне «эшкәртү»— җинелрәк, тиешле сорауларга җавап алу тизрәк булыр дип уйлаганнардыр. Алдан ук әйтеп куям—Сезне һәм иптәшләрегезне «советка каршы оешма» оештыруда гаепләп, Сезне шул оешманың башлыгы итәргә тырышулары барып чыкмаган.

Сезгә каршы компромат җыю планы әле 1949 елда ук гамәлгә ашырыла башлый. Сорау алу өчен Михеевка студентлар Наил Ганиев, Хәйбрахман Мөхәммәдиев, Бәһрам Хәйруллиннар чакыртыла. Алар 1945 елда сезнең белән бергә студентлар тулай торагында яшәгәннәр. Барысы да Сезнең белән таныш икәнлекләрен әйткәннәр, әмма советка каршы шигырьләр укыганыгызны хәтерләмәгәннәр. 1950 елның 23 гыйнварында Гурий Тавлин кулга алына. Икенче көнне сорау алу вакытында ул 1946 елда авылда Сезнең белән танышуы турында сөйли. Сезнең йогынтыгыз аркасында «советка каршы карашларыгызны» да уртаклаша башлавын әйтә.

Сезнең кулга алынуыгыз турыдан-туры тарих-филология факультетының өченче курс студенты Зөммәрә Тумашеваның республика дәүләт иминлеге министрына язган гаризасына нигезләнгән булган. Ул болай дип белдергән: «ВЛКСМ әгъзасы һәм совет гражданкасы буларак, сезгә түбәндәгеләрне хәбәр итүне үземнең бурычым дип саныйм: 1948 елның көзендә мин КДУның 1 нче курс студенты Гыйләҗев Аяз белән таныштым. Гыйләҗев А. Казан педагогия студенты Тавлин Г. белән дус иде. Күптән түгел Гыйләҗев мина Тавлин Г.нын дәүләт иминлеге органнары тарафыннан кулга алынганлыгын әйтте. 1 мартта Гыйләҗев бик борчулы иде, бу мине кызыксындырды. «Нәрсә булды?»—дип сорадым. Гыйләҗев шуннан ана каядыр барырга кирәклеген әйтте, «үземне энә өстендә кебек хис итәм»,— диде. Мин моның Тавлин эше белән бәйле түгелме икәнлеген сорадым. Гыйләҗев раслап җавап бирде. Ниһаять, мине бер читкә алып китеп, Гыйләҗев болай дип сөйләде:

Элек ул да Тавлин шикелле үк советка каршы кеше булган. Хәзер ул үзенең карашларын үзгәрткән, әмма элекке гаебе өчен авыр хак түләргә туры киләчәк икән: дәүләт иминлеге органнары ана, советка каршы кеше булып кыланып, шпионнар оешмасын ачу бурычын йөкләгәннәр. Гыйләжев мина бу эшнең бик газаплы булуыннан зарланды, бөтен вакытын алуын әйтте, эшнең асылын белмәгән хәлдә галәмәт зур механизмнын бер шөребе кебек эшләргә туры киләчәк, диде. Бу эше өчен ул ышаныч та казана алмый, аз гына бүләк-фәләне дә тәтеми икән... Гыйләжев үзе сөйләгәннәрне беркемгә дә әйтмәскә кушты, юкса конспирацияне бозган өчен аны каты җәза көтәчәк икән...»

Бу гариза бик тә әләккә, доноска охшаган. Ләкин бу очракта Сезнен ышанучанлыгыгыз гаҗәпләндерә, моны бары тик Сезнен гажизлегегез, гасабилануыгыз яки нишләргә белмәвегез белән генә аңлатып була. Ә бәлки... Сез әлеге кыздан шикләнеп, анын карашларыгыз үзгәргәнлеген хәбәр итүен теләгәнсездер? Монын урынына гаепләү маддәләрегез арткан гына: 58-10, 1нче өлеш—«советка каршы агитация» һәм 58-11—«советка каршы оешма төзергә ниятләү» дигән маддәләргә 121 нче маддә—«ачарга тиеш булмаган мәгълүматларны ачу» дигәне дә өстәлгән.

Мәҗит Рәфыйков Сез бер атна сак астында утыргач, 1950 елнын мартында кулга алынган. Аннан алда, 28 мартта Сездән, анын турында нәрсәләр беләсез, дип сораганнар. Сез таныш икәнегезне әйткәнсез, мөнәсәбәтләрегез «иптәшләрчә генә» булганлыгын, ике арада шәхси исәп-хисап юклыгын белдергәнсез. Сүзләрегезне раслап: «Рәфыйков үзен Ватаннын чын патриоты итеп тотты һәм бер төрле дә советка каршы уйдырмалар сөйләмәде»,—дигәнсез. Сонрак Сез икегез дә тәнкыйть рухындагы бер сөйләшүегезне исегезгә төшергәнсез. Аны төрлечә шәрехләп булыр иде, әмма тикшерүче ана гаепләүгә туры килә торган эчтәлек кенә салган. Сез Рәфыйков белән студентларча гына тамак ялгап алгач, йөреп керергә чыккансыз. Әдәбият турында фикер алышкансыз, аннары Рәфыйков хан улы турында бер легенда сөйләгән. Хан үзенең улына үткен алтын уклы җәя бүләк иткән, җәяне һәрвакыт—иңендә, укларны исә кында сакларга кушкан. Әмма хан улы җәя белән укларны каядыр куйган да оныткан. Исенә төшереп алып караса, җәя дә, кын да яраксызга әйләнгән, бары тик алтын уклар гына сакланып калганнар. Нәтиҗә шул: уклар белән җәя һәрвакыт янда булырга һәм халыкка кирәк чакта атарга тиеш. Сез шул чакта Рәфыйковка колхозчыларнын авыр тормышы турында әйткәнсез һәм тук яшәү өчен, мөгаен, Америкадагы кебек фермерлар булу кирәктер, дигәнсез.

Рәфыйков сорау алулар вакытында үзен кискенрәк һәм ачыграк тота. Ул үзенен дәүләт иминлеге органнары белән 1944 елдан ук хезмәттәшлек итүен таный. 1950 елның 29 маенда сорау алганда Сезнең белән лейтенант Михеев кушуы буенча танышканлыгын әйтә, Сезне советка каршы сөйләшүләргә махсус котыртуын да яшерми. «Шул рәвешле,— ди ул, —Михеев өйрәткәнчә, 1949 елның ноябрендә Гыйләжев белән сөйләшкәндә мин үземне советка каршы кеше итеп күрсәттем, аңа теләктәшлек белдердем һәм Гыйләжевка алга таба да советка каршы сөйләшүләр өчен шартлар тудырдым». Кыскасы, ул яшь иптәшен һәртөрле котыртып тора.

Әлбәттә, ул чордагы сорау алу беркетмәләренә тәнкыйть белән карарга кирәк. Мина тикшерүченен, гаепләнүчедән сорау алып та тормыйча, үз кулы белән тутырган беркетмәләре белән дә очрашырга туры килде. Еш кына тикшерүче кулга алынган кешенең сөйләгәннәрен язып барганда анын «бер танышым белән сөйләштем» дигән сүзләренә «советка каршы сүзләр сөйләштек» дип өсти торган булган. Шулай да Сезнең эшегездәге беркетмәләрне һәм Тавлин белән Рәфыйковтан сорау алу беркетмәләрен укып өйрәнеп чыккач, мин җиңел сулап куйдым: Сез аларга карата гаделрәк һәм дөресрәк тоткансыз үзегезне. Мин мона игътибарны тагын шунын өчен дә юнәлтәм, 90 нчы елларда алар тарафыннан Сезне, 1950 елда үзен лаеклы тотмады, дип гаепләү омтылышы да булды. Шул чагында Татарстан Язучылары берлеге идарәсе Рафаэль Мостафин җитәкчелегендә комиссия төзеде. Ул комиссия дә, мин караган материаллар белән танышып чакканнан сон, аларнын бәхетсез язмышында Сезнең гаебегез юк, дигән нәтиҗәгә килде. Өчегез дә язучылар булып киткәнсез, ләкин Сез алар арасында талантлырак булгансыз.

1950 елның 28 октябрендә СССР Дәүләт иминлеге министрлыгы каршындагы Махсус киңәшмә Сезне 7 елга хезмәт белән төзәтү лагерена ябарга дигән карар чыгара. 1950 елның 30 ноябрендә Сезне этап белән Казаннан Караганда өлкәсенең Долинское авылындагы 9 нчы лагерьга озаталар. Ул лагерь (Карлаг) 1931 елдан 1959 елга кадәр эшли. Сез анда чагында лагерь башлыклары полковниклар В. М. Маевский белән З. П. Волков була. 1951 елның гыйнварына лагерьда 45675 тоткын булып, аларның яртысы диярлек сәяси маддәләр белән хөкем ителгән. Тавлин белән Рәфыйковлар да лагерьга җибәреләләр.

Контрреволюцион җинаятьләре өчен хөкем ителеп, СССР Эчке эшләр министрлыгы лагерьларында, колонияләрендә, төрмәләрендә һәм сөргеннәрдә тотылган кешеләрнең эшләрен яңадан карау буенча Үзәк комиссиянең карары белән 1955 елның 13 февралендә Сезнең эшегез туктатыла, һәм 1955 елның 6 июлендә Сез азат ителәсез. Шул вакытта ук Тавлин белән Рәфыйков та аклана һәм азат ителә.

Сез туган якларыгызга кайтып, Югары Баграж авылы клубына мөдир булып урнашасыз. Шул ук вакытта үзегезне университетның тарих-филология факультетына читтән торып уку өчен 2 нче курска кабул итүләрен үтенеп гариза бирәсез. 1956 елның февралендә татар әдәбияты кафедрасы мөдире Х. Г. Госманов тәкъдиме белән Сезне көндезге укуга күчерәләр, отличник буларак, югары стипендия ала башлыйсыз, пенсионер улы булганга уку өчен түләүдән дә азат итәләр. Ләкин бу юлы да университет студенты булып озак йөри алмыйсыз. Профессиональ язучы булырга ниятләп, 1957 елның октябрендә Мәскәүгә китеп барасыз һәм Югары әдәби курсларга укырга керәсез, аны шәп кенә тәмамлап та чыгасыз.

Сез үзегезнең җәфа чигеп йөргән елларыгызны искә алырга яратмый идегез. Сезне һәрвакыт яңа сюжетлар кызыксындыра иде, моның матур бер нәтиҗәсе дүрт томлык әсәрләрегез (Казан, 1993-1994) булды. Сез бик күп дәрәҗәле әдәби премияләр алдыгыз, пьесаларыгыз илнең күп кенә театрларында куелды. 1993 елда Сез Татарстан Республикасының халык язучысы исеменә лаек булдыгыз.

Сез 75 яшегездә, язучы, кеше һәм гражданин буларак, даныгызның иң югары ноктасында бу фани дөньядан китеп бардыгыз. 2002 елның 13 марты иде бу. Сез Тавлин белән Рәфыйковтан озаграк яшәдегез. 1990 елларның яңа мең ьеллыкка аяк басалган соңгы халык язучысы булдыгыз. Мин Сезнең белән соңгы тапкыр Сез инде каты авырган чакта сөйләшеп утырдым. Нәкыя Илһамовнаның, улларыгызның, оныкларыгызның нинди зур игътибар белән кайгыртуларын күрдем. Авыруыгыз Сезне төшенкелеккә салмады, Сез күтәренке күнелле булырга тырыштыгыз. Шулай да физик авыруыгыздан тыш Сезне илдәге вәзгыять тә борчый, җәмгыятьнең Сез теләгәнчә үк булмавы кәефегезне кыра иде шикелле.

Ышаныгыз, бу хатны тәмамлавы бик кыен миңа. Без озак еллар бергә булдык, Сезгә беркайчан да җавап алынмаячак хат язарга туры килер дип кем уйлаган! Хәер, Аллаһының кодрәте киң, бәлки төштә булса да ул миңа Сездән хәбәр китерер әле...

***Марс Шабаев** тәрҗемәсе.*

**Редакциядән**

*Күп еллар үткәч мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайтуыбызның сәбәбе шул: булачак эдипләрне хөкем итү вакыйгасы һаман әле төрлечә шәрехләнеп килә. Тикшерү материалларын өйрәнгән авторның ошбу язмасы 57 ел элек булган хәлләргә ачыклык өсти, аларның аерым фаҗигаләр суммасы гына түгел, гомум, уртак фаҗига булуын ачып сала.*

*1950 елгы хәлләр «Сүнмәс утлар балкышы» дигән китабыбызда да чагылдырылды. Мәсьәләне махсус өйрәнгән Рафаэль Мостафин язган «Аныклагыч мәгълүмат»та (384 бит) татар студентлары өстенә төшкән җәбернең асыл сәбәбе дә, аларны пычрату-гаеплэү системасы да аермачык күрсәтеп бирелә. Дүртенче студент та була әле анда. «Аныклагыч мәгълүмат»та аның соклангыч ныклык-фидакарьлеге дә бәян ителә.*

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ҮЛЕМ*** – "Үлем–йокының карендәшедер" дигән сүз бар. Һәркемнең үзе теләгәнчә үләсе килә. Моның чарасы исә Алла теләгәнчә тереклек итүдер.

*Ләззәтләрне кисә торган нәрсәне (үлемне) күп зикер кылыңыз! Үлем искә төшү сәбәпле кечкенә генә дип хисап ителгән бер бозыклыкның кылынмый калуы да бик файдалыдыр. Ләкин үлемне искә төшерү дөнья эшләренең юлда калуларына кайгырып түгел, бәлки барачак җиргә барыр өчен хәзерлек күрү касды берлә булырга тиешле. Үлемгә хәзерләнү намазлык өстендә утырудан түгел, бәлки фарыз гамәлләрне ихлас берлә кылу вә мәмнүг эшләрдән тыелу, адәмнәрне рәнҗетмәү, үткәндәге кимчелекләр өчен үкенү, халыкларга мәнфәгать китерү вә дөнья могамәләләрен пөхтә вә тәртипле йөретүдән гыйбарәтдер* (Ризаэддин бине Фәхреддин).

Аллаһы Тәгаләнең Коръән-кәримендә: "Үлем дә хәят кебек бер нигъмәт булып яратылган",–диелә.

Гомере буе изгелекләр эшләгән инсаннарның үлемнәре дә яхшылыктыр һәм бер нигъмәттер, чөнки мәңгелек җәннәт тормышына бара торган ахирәт сәфәре үлем белән башлана. Картайгач хәятнең авырлаша баруы һәм дөнья тормышының җаваплылыгыннан үлем белән азат ителеп, мондагы бер фани дус урынына җәннәттәге туксан тугыз бакый дусларга кавышуга сәбәп булу аркасында, ул–зур бер нигъмәттер. Үлем ул изгеләр өчен тар, дәгъвалы һәм куркынычлы дөнья читлегеннән чыгарылып, киң, шатлыклы, газапсыз һәм мәңгелек Аллаһының рәхмәте даирәсенә ирешүдер.

Әлбәттә, үлемнең рәхмәт һәм нигъмәт булуы чын иман әһелләре өчендер, ә явызлар һәм кяфирләр өчен үлем–газап эчендә газаптыр.

Коръән-кәримдә "Мөэмин" ("Гафыр") сүрәсенең 11 нче аятендә кешенең ике тапкыр туувы һәм ике тапкыр үлүе турында сүз бара. Беренче кат туу–бу дөнья өчен, икенчесе–соңгы Хөкем өчен; беренче үлем–туганга кадәр терек булмау, сизү-тоюдан мәхрүмлек халәте, икенчесе–дөньялык белән аерылышу.

Тәсаувыфта суфи кеше исән вакытында ук берничә төрле үлем белән очраша дип карала, мәсәлән: 1)*ак үлем*–ашамыйча һәм су эчмичә торып, нәфесне үтерү; 2)*кара үлем*–халык тарафыннан кабул ителмәү газапларына дучар булу; 3)*кызыл үлем*–нәфсең сораган барлык дөньяви рәхәтләрдән баш тарту; 4)*яшел үлем*–киемеңә ямау өстенә ямау салу.

Тарихка кешенең "үлеп терелү" фактлары билгеле. 1244 елда король Людовик IX ны дизентериядән үлде дип игълан итәләр, ләкин күмәр алдыннан чиркәүдә гыйбадәт вакытында ул аңына килә һәм шуннан соң тагы 26 ел яши.

// *Ару үлем*–яхшы үлем, ягъни хәвефсез, фаҗигале түгел. *«Ару үлем, ак кәфен!»* дигән сүз бар.

***"ҮЛЕМ МАНАРАСЫ"*** *тар.* – Зәрдәшт дине тотучыларда ни күмәргә, ни яндырырга ярамаган мәетләрне ачык һавада козгыннарга калдыра торган махсус бина (*дахма*). Мөселман авторларында бу термин кайчакта төрбә, мавзолей мәгънәсендә дә очрый.

---

*Дәвамы. Сүзлек 2004 елның 1нче санынннан басылып килә.*

Бохарадагы Кәлъян мәчетенең 45,3 метр биеклектәге манарасын да "үлем манарасы" дип атаганнар. Үлемгә хөкем ителгән җинаятьчеләрне шушы манара башыннан җиргә ыргыта торган булганнар. Мәс., Габденнасыйр Курсавины шушы манарадан ташларга ниятләгән булганнар һәм ул көч-хәл белән генә яман үлемнән котылып калган.

**УЛҖӘ, УЛҖА** *бор.тат.*—Трофей, ганимәт (ганимәт мал), хәрби табыш. // *Яманга улҗа төшсә, өләшә алмый җаны чыга. Мәкаль. Улҗа белән кайту.*

**ҮРНӘК**—Өлге, нәмунә, мисал; модель. Р.Әхмәтьянов "үрнәк" сүзенең "үрү" тамырына бәйле булуын күрсәтә. Ягъни үрнәк—"яфраклы ботакчык рәвешендәге бизәк". Элегрәк кышын тәрәзәгә боз чирап хасил булган матур-матур үсемлек бизәкләре дә челтәр бәйләүче кызлар өчен үрнәк булып хезмәт иткән.

**УТӘ КУРУ**—Бу сүзне Нурихан Фәттах русча "ясновидение" мәгънәсендә куллана. //*Мондый сиземләүләр, утә кұрұләр турында бүген күп язалар. Бәлки миндә дә шундыйрак берәр нәрсә булгандыр.* Н.Фәттах.

**ФАЛЛОС КУЛЬТЛАРЫ**—*Фаллос*—грек телендә ирләрнең җенес әгъзасы. Мондый культ асылда ирләрнең җенес әгъзасына табынуга кайтып кала. Борынгылар фаллосның аеруча көчкә ия булуына ышанганнар һәм аңа табигатьнең уңыш бирү символы итеп караганнар, аны аллалаштырганнар. (мәс., Грециядә–Адонис, Һиндстанда–Шива һ.б.). Кайбер халыкларда фаллоска багышлап төрле догалар укыганнар, аның сурәтен тагып йөргәннәр, йола биюләрендә җенси актка охшаш хәрәкәтләр ясаганнар. Кызлык гыйффәтен фаллоска корбан итү, үз-үзеңне печү йоласы да булган. Ибне Фазлан үзенең сәяхәтнамәсендә башкорт җирләре аша узганда җирле халыкның фаллоска табынулары турында аермачык яза. Алар фаллос зурлыгындагы таяк кисеп ясап, шуны муеннарына асып йөргәннәр. Сәбәбен сорагач, алар: "Мин шушыңа охшаштан чыкканмын һәм үземне аңардан башка тудыручыны белмим",— дигәннәр (Ризаэддин Фәхреддин тәрҗемәсе буенча).

Хәзерге вакытта һиндуизмда, тантризмда, синтоизмда, кайбер Африка халыкларында фаллоска табыну яшәп килә. Русларда "скопецлар"да ("печелгәннәр"дә) һәм "христоверлар"да да фаллос культының эзләре сакланган.

**ФАГФУР, БАГБУР**—Фарсыларда Кытай императорының аталышы. "Алла улы" мәгънәсендә. *Фарфор* сүзе дә шушыннан килеп чыккан дип уйлыйлар. *Фәгъфур* язылышы да бар. Соңгысы кайчагында ялгызлык исеме буларак та файдаланылган.

**ФАМИЛИЯ**—Көнбатыштан кергән бу сүзне Гаяз Исхакый асыл мәгънәсендә–"гаилә", "нәсел" сүзе урынына да куллана. //*Вакыйган, хәзер үзенең хәленең нинди мулла фамилиясеннән чыгып, шундый әхлаксызлык галәменең һәр тарафыннан җыелган кешеләре арасында сакчысыз-нисез торуын һәм дә үзенең тамагын туйдырыр өчен шул көтү-көтү теләнчеләр берлән урамнан-урамга йөрергә мәҗбүр икәнлеген уйлап, күзеннән яшьләр мөлдерәргә тотынды.* Г.Исхакый.

**ФӘЗА** *г.*—Бу гарәп сүзе грекча *физос*—тирәлек сүзенә барып тоташа. Күктәге бушлык; галәм киңлеге; космос; пространство; ачык урын. "Шуннан физика-тирәлек турындагы фән" (Р.Әхмәтьянов). "Фәза" сүзен, мәсәлән, Такташ та куллана. Шул рәвешле, гарәп телендә чарланып, татар теленә килеп кергән бу грек сүзе русча "пространство" кебек асылда ясалма сүзгә караганда телебенең табигатенә ятышлырак икән. //*Дөнья фәзасы, галәм фәзасы*—космик пространство, космик киңлек *Киң фәзада йон-мамык төсле матур ак кар оча.* Җамалетдин Юмаев. *Фәзави (фәзаи)*—күләмле; рус телендәге *пространственный* сүзе мәгънәсен бирә. *Яссылыктагы һәм фәзадәге геометрия*–планиметрия һәм стереометрия.

*Фәзә* язылышы да очрый.

**ФӘКЫЙРЬ** *г.*—Ярлы (кеше), мохтаҗ. Телдә тагын фәкыйрь мәгънәсендәге "*бинәва*" сүзе дә йөргән. *Дәрвиш* һәм *суфи* мәгънәләренә дә ия.

Фәкыйрьләрне байларга каршы кую Коръәннән үк килә (35:15/16).

"Фәкыйрьлек–ике дөньяда да йөз каралыгы" дигән сүз бар, ләкин Мөхәммәд Пәйгамбәр: Фәкыйрьләр–минем шатлыгым",–дигән. //*Фәкыйрь әфрады*–ярлылар катлавы. *Һәрнәрсәнең ачкычы буладыр. Җәннәт ачкычы мескен вә фәкыйрьләрне сөюдер.* Хәдис.

Суфичылыкта матди байлыклардан ваз кичеп, мал-мөлкәтен Аллаһка багышлаган колны фәкыйрь диләр (*фәна филлаһ* мәкамы, бу вакытта кеше Аллаһ белән кушылган була).

Рус телендәге "факир" термины исә Һиндстан аскетларына һәм йогларга карата әйтелә, аннары ул "тылсымчы", "фокусчы", "күз буучы" мәгънәләрен алган. Соңгы мәгънәсендә "факир" термины татарча китапларда да очрый.

Күплек саны шәкеле: фөкарә, фокара, фөкъра. Телдә фәкыйрь–фөкъра, фәкыйрь–фокара гыйбарәсе дә бар.

**ФӘЛӘН** *г.* –Теге, ни. Фарсы телендә–*фолан, фелан* (А.К.Курышжанов). Татар телендә мәгънәгә җыймалык, аныксызлык төсмере өсти. //*Фәлән Фәләнов. Фәлән-тогән. Фәлән-фәлән нәрсәләр. Фәлән-фәсмәтән.*

**ФӘН ҺӘМ ИМАН**–Табигать фәннәре буенча галимнәр, теге яки бу фәнне тирәнрәк белгән саен, динне, иманны кире кага торган дәлилләрне күбрәк таба дип уйлаучылар байтак. Чынлыкта исә фән үзеннән-үзе галимне беркайчан да алласызлыкка алып бармый. Чын галим,–биологмы, физикмы яки математикмы ул,–әйләнә-тирә дөньяның чиксезлегенә, дөньядагы тәртипнең искиткеч оешканлыгына, максатчанлыгына, анда мәгънәсез бер генә нәрсәнең дә булмавына торган саен ныграк ышана. Бу тәртипнең очраклы рәвештә генә килеп чыга алмавына кире каккысыз математик дәлил бар.

Галимнәрнең эзлекле фикер сөреше ахыр чиктә аларны бөтенесен колачлый торган көчкә–Аллаһыга ышануга китерә.

Герман галиме Динард, дөньякүләм танылган галимнәрнең бер төркеменнән фикерләрен сорашып, мондый нәтиҗәләргә килгән: галимнәрнең 20 се нинди дә булса дини карашны якламаган, 242 галим Аллаһыга ышана башлаган, фәкать 20 се генә дин белән кызыксынмауларын белдергәннәр. Шулай итеп, 90 проценты–дингә ышанучылар һәм бик азы гына дәһри–атеист булган. Өстәвенә соңгылары дингә ышанучы хезмәттәшләренә карата бернинди дә ихтирамсызлык күрсәтмәгәннәр.

Дин һәм фән һич тә бер-берсенә каршы торучы системалар түгел, табигать белгече булган хәлдә дә табигатьтән өстен көчләргә ышанырга мөмкин икән. Алар–фән һәм дин бер үк медальнең ике ягы гына, һәм, баксаң, алар бер-берсеннән башка яши дә алмыйлар. Фән–кара пессимист, ул бу дөньяның максаты һәм мәгънәсе юк дип саный, дин исә–якты оптимист, ул дөнья яратылышында олуг максат күрә һәм хәтта шушы принцибы белән генә дә фәнне яңа эзләнүләргә этәрә, асылда фәннең яшәешенә мәгънә бирә. Ихтимал, материя белән рухны капма-каршы куюның дөрес түгеллеген исбат итүгә дә ерак калмагандыр инде. Рух төшенчәсе, әйтик, тереклек ярату, фикерли белүче адәм кауменең килеп чыгышы, илһамлану, төштә фәнни ачыш ясау һәм пәйгамбәрләргә вәхий килү һ.б. кебек бүгенге материалистик фән тәше үтми торган мәсьәләләрне җиңел хәл итә. Тәкъдир (язмыш һәм ихтыяр) турында Ислам философиясе белән материалистлар арасында барган бәхәсләргә дә урын калмаска охшаган.

Әлбәттә, фән белән динне килештерергә омтылышлар элек тә булган. Мәс., бөек Иоганн Кеплер алланың кодрәтен тикшерүне һәм аны аңлауны максат итеп куйган, дини традицияләрне һәм фәнни белемнәрне синтезларга омтылган. Ләкин күпчелек очракларда галимнәрнең фәнни тикшеренүләре аларның иманыннан аерым яшәгән. Һәрхәлдә аларның эшчәлегендә дин йогынтысы чагылмаган (Ньютон, Кеплер һ.б.).

Бөек микробиолог Луи Пастер: "Әгәр бүген минем белемем кичәгегә караганда күбрәк икән, бу инде минем Аллаһыга ышануым да кичәгегә караганда артыграк дигән сүз,"–дип яза.

Бөек рус физиологы Павлов та дингә нык ышанган кеше була.

Даһи Эйнштейнның: "Фәнни эзләнүләрнең иң олуг нәтиҗәсе–Аллага ышану,"–дигән сүзләре белән югарыда әйтелгәннәргә йомгак ясарга мөмкин.

**ФӘРЕЖ** г. – **1**.Тишек, ярык. **2**.Хатын-кызның җенес әгъзасы. //Мин, гадәттәгечә, аның янына барып уйнап торганда, алдым торып бәдәненә тигәнне кыз күреп, кинәт

торып мине аркама екты, чалбарымны ачып, фәреҗенең тышында зәкәремне йөртә башлады. "Мең дә бер кичә" әкиятләреннән.

***ФӘРЕШТӘЛӘР*** *ф.* – Күк әһелләре. Аллаһу тарафыннан хәлык ителгән өч төрле акылга ия затларның берсе (башкалары–*кешеләр* һәм *җеннәр*). Фәрештәләр башкача *мәләк* дип тә атала. Алар–Аллаһының илчеләре һәм хезмәтчеләре, аның карарларын һәм әмерләрен үтәүчеләр. Коръәндә әйтелгәнчә, фәрештәләр нурдан яратылган (Адәмгә кадәр үк). "Фәрештәләр" сүрәсендә Аллаһуның фәрештәләрне икешәр, өчәр, дүртәр пар канатлы итеп яратканлыгы әйтелә ("Тәфсир Ногмани"да "фәрештәләр икешәр, өчәр, дүртәр канатлылардыр" диелгән, әмма күпчелек фикеренчә монда "пар канат"лар турында сүз бара). Фатих Әмирхан фәрештәләрне "ал канатлы" дип телгә ала. Фәрештәләрдә ир вә хатын җенесләре булмый дип санала ("Рисаләи Газизә"дә: "анларны Аллаһу шәһвәтсез, ягъни җенси дәртсез итеп яратды" диелә), ләкин шулай да кайбер очракларда аларда җенес аерымлыгы күзәтелә (*Һарут* һәм *Марут;* кайбер риваятьләргә караганда, *Иблиснең* дә *Лиһа* исемле хатыны булган). Фәрештәләр гәүдәле түгел (ягъни җисми түгел), аларда ашау-эчү, йоклау кебек "эшләр юкдыр". Йәһүд һәм христиан диннәрендә җиргә төшкән алла угылларының (ангелларның, ягъни фәрештәләрнең) адәми зат кызларына өйләнүе турында хәбәрләр риваятьләрендә сакланган ("Яшәеш", VI:1-4). Фәрештәләр күкләрдә яшиләр, оҗмах сагында һәм Аллаһының тәхете әйләнәсендә торалар, Аллаһыга дан җырлыйлар (39:75; 40:7-9). Алар изге бәндәләр янына иңәләр (41:30), кешеләрне саклыйлар, пәйгамбәрләргә Аллаһы сүзләрен җиткерәләр (15:7; 16:2), бәндәләрнең тәкъдир белән билгеләнгән кылыкларын күзәтеп торалар һәм аларны язып баралар (43:80-*кирамән кятибин* яки *сәфәрәтел-кирам* фәрештәләре). Кыямәт көнендә алар Аллаһы хөкеменең (16:28/30;25:22/24; 37:1-3; 69:17; 78:38; 89:22/23) һәм җәзасының (47:27/29) барлык гамәлләрендә катнашалар, җәннәтне һәм тәмугны каравыллыйлар. Аллаһыга иң якын торган фәрештәләр *мөкаррәбүн* дип атала (Җәбраил фәрештә, Исрафил фәрештә). "Суфичылык серләре" китабында башкарган вазыйфалары буенча тагын түбәндәге фәрештәләр атап кителә: хафиза, һәмәләмүгъл-Гарше мәләкләре, әл-Галун вә Муһеййемун, сәййах мәләкләр, әл-мәләгъүл-әгъля, тауларның мәләге, җир һәм күкләрнең вәкиле булган мәләкләр, каберләргә вәкил булган мәләкләр, Коръәнгә вәкил булган мәләкләр, намазга, җеназага вәкил булган мәләкләр һ.б. Бер хәдистә: "Җир йөзендә әйләнеп йөрүче фәрештәләр бар, алар өммәтемнең сәламен миңа җиткерерләр,"–диелә (сәййах мәләкләр).

Коръәндә телгә алынган фәрештәләр әлләни күп түгел. Фәрештәләр турындагы күпчелек мәгълүматлар Коръән тәфсирен төзүчеләр һәм суфилар хезмәте нигезендә тупланганлыгын әйтергә кирәк. Бу мәгълүматларда каршылыклар һәм фикер башкалыклары да очрый. Фәрештәләрнең хисабына килгәндә, риваятьләрдә аларның санын Аллаһы Тәгаләнең үзеннән башка һичкем белмәс диелгән. Гомумән, "фәрештәләр җәмәгатеннән күбрәк җәмәгать юк" ("Рисаләи Газизә"). Фәрештәләр һичбер сәгать гыйбадәтсез тормыйлар. "Сыер" (2) сүрәсенең 28-34 аятьләреннән күренгәнчә, Аллаһ Адәм галәйһиссәламне фәрештәләрнең исемнәренә өйрәткән, ә фәрештәләр үзләре моны белмәгәннәр булып чыга (шигыйлар Аллаһ Адәмгә фәрештәләрнең генә түгел, бәлки 12 шигый имамының исемнәрен дә атап күрсәткән дип ышаналар).

Түбәндә төзүче кул астында булган төрле чыганаклар буенча фәрештәләрнең шактый тулы исемлеге китерелә.

1.Әхрәмийүн фәрештәләр.

2.*Гаднән.* Оҗмах сакчысы.

3.*Газазил фәрештә.* Җәннәттән сөрелгән фәрештә. Кара: *Иблис.*

4.*Газраил фәрештә.* Аңа адәмнәрнең тәннәреннән җаннарын аерып алу вазифасы йөкләнгән.

5.*Гатид фәрештә.* Кирамән кятибин (язып баручы) фәрештәләрнең берсе.

6.*Дудаил фәрештә.* Рамазан аенда җиргә очып төшә, ярлыкауны сораган бәндәләрнең үтенечен Аллаһу Тәгаләгә җиткерә.

7.*Җәбраил фәрештә (Җибрил фәрештә).* Иң югары дәрәҗәле фәрештәләрдән. Аллаһы һәм Мөхәммәд Пәйгамбәр, шулай ук Гайсә белән Мәрьям-ана арасында төп арадашчы. Җәбраил галәйһиссәламне *Әминел-вәхий, Рухыл-әмин, Рухыл-котдус,*

*Намусы-әкбәр, Тависы-мәләикә* дип тә атыйлар.

8.*Зәуман фәрештә*. Кайбер хикәятләргә караганда, бәндәне үлгәч кабергә куеп киткәннән соң, аның ләхетенә бер ишек ачылып, иң әүвәле килеп кергән куркәм фәрештә.

9.*Зөбани фәрештәләр*. Газап фәрештәләре, тәмугта яндырып торучылар. Тәмуг капкаларын да саклыйлар. Аларның саны унтугыз (66:6; 74:30-31; 96:18). Житәкчеләре–*Мәлик фәрештә*.

10.*Исмәгыйль фәрештә*. Беренче кат күкнең сакчысы.

11.*Исрафил фәрештә*. Кыямәт көнендә сур өрүче. Мөкәррәб (Аллаһыга якын) фәрештәләрдән.

12.*Ифраил фәрештә*. Җиденче кат күкнең баш сакчысы (Фуратида-*Вайил*).

13.*Касыйм фәрештә*. Икенче кат күкнең сакчысы (Фуратида-*Әркаил? Ркаил?*).

14.*Катаил фәрештә*. Алтынчы җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

15.*Кирамән кятибин*. Төгәл итеп әйткәндә, *кираме-л-кятибәйн*–ике бөек кятиб. Кешенең ике җилкәсендәге фәрештәләр, яхшы-яман эшләрне гамәл дәфтәренә язып баручылар. *Сәфәрәтел-кирам* фәрештәләре дип тә атыйлар. Популяр әдәбиятта ул фәрештәләрнең берсен *Кирамән* фәрештә дип, икенчесен *Кәтиб* фәрештә дип атау очраклары бар, ләкин чыганакларда аларның берсе–*Рәкыйб*, икенчесе *Гатид* дип атап күрсәтелә. Аларны *ходавәнде рәкыйб*, ягъни илаһи күзәтүчеләр дип атаганнар.

16.*Кәлкаил фәрештә*. Сактаил фәрештәнең башка исеме.

17.*Кәррубиййун-гарше*. Җиденче кат күк янындагы гайрәтле фәрештәләр.

Христианнардагы *херувимнарга* туры килә.

18.*Марут*. Һарут белән Марут фәрештәләргә (Бабил шәһәрендә) сихер иңдерелгән була. Аллаһы Тәгалә аларны сынар өчен җир йөзенә җибәргән, әмма алар анда гөнаһка батканнар. Ривайәткә караганда, баштагы исемнәре *Газа* (Һарутныкы) һәм *Газая* (Марутныкы) булган.

19.*Микаил фәрештә* (Микяил). Үзе белән яңгыр китерүче.

20.*Мәлик фәрештә*. Тәмуг капкаларын саклаучы фәрештәләрнең башлыгы.

21.*Мәләкел-Мәвет*. Үлем фәрештәсе, Газраил.

22.*Мәләкел-Мөвәккәл*. Мөнкир белән Нәкир фәрештәләр мәеттән сорау алырга тотынгач, бәндәнең дөньялыкта кылган яхшы гамәлләре аны яклау өчен Мөвәккәл фәрештәләр суратендә килеп җитәләр имеш.

23.*Мәләкур-руәа*. Төш фәрештәсе. Чыганакларга караганда, Аллаһы Тәгалә аны кешеләр һәм язмыш тактасы Ләүхүл-мәхфүз арасында вәкил иткән. Бу фәрештәне *Садыйкун*, ягъни "иптәш, дус, яр" дип тә йөрткәннәр.

24.*Мөнкәр* (яки *Мөнкир*). Кабер фәрештәсе. Алар икәү: *Мөнкәр* һәм *Нәкыйф* (*Мөнкир* һәм *Нәкир*). Кабер фәрештәләрен *сәаль фәрештәләре* дип тә атыйлар.

25.Нәкир (Нәкыйф). Кабер фәрештәсе. Мөнкир һәм Нәкир.

26.*Рәкыйб фәрештә*. Кирамән кятиб (язып баручы) фәрештәләрнең берсе.

27.*Ризван*. Гаднән белән бергә оҗмах сакчысы.

28.*Ругаил фәрештә*. Алтынчы кат күкнең баш сакчысы (Фуратида-*Әрнәс*).

29.*Саклаучы фәрештәләр*. Һәр кешегә бирелгән "кизү" фәрештәләр. Алар иртә-кичләрен алмашына дип исәплиләр.

30.*Сактаил фәрештә*. Бишенче кат күкнең баш сакчысы (Фуратида-*Әсфаил*).

31.*Салсаил фәрештә*. Дүртенче кат күкнең баш сакчысы (Фуратида-*Каил*).

32.*Сатаил фәрештә*. Бишенче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

33.*Сафура / Сафирә*. Кешенең күңел-холкын төзәтүче фәрештә.

34.*Сәгада фәрештә*– Өченче кат күктә (Магун яки Зәйлүмдә) хезмәт итүче андагы барлык фәрештәләрдән дә өстен фәрештә.

35.*Сәййах фәрештәләр*. Җир йөзен гизеп, мөселманнарның сәламен Аллаһка җиткереп торучылар.

36.*Сәмхаил фәрештә*. Ифраил фәрештәнең башка исеме.

37.*Суһаил фәрештә*. Өченче кат күкнең баш сакчысы (Фуратида-*Кябил*). Кайбер ривайәтләрдә беренче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә дә Суһаил исемле.

38.*Тамтаил фәрештә*. Дүртенче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

39.*Таркаил фәрештә*. Икенче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

40.*Тарфаил фәрештә*. Өченче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

41.*Хатраил фәрештә*. Җиденче җәһәннәм ишеген саклаучы фәрештә.

42.*Хәзин җәһәннәм*. Җәһәннәм сакчысы.

43.*Һади*. Юл күрсәтүче фәрештә. Аны Аллаһ Иблис мәкерләреннән саклаучы итеп яраткан.

44.*Һарут*. Марут фәрештә белән бергә аңа да сихер иңдерелгән була.

45.*Шәмхаил фәрештә*. Ругаил фәрештәнең башка исеме

46.*Шуйбә фәрештә*. Иске фалнамәләрдә телгә алына. Күрәзәлек итү, фал ачу белән шөгыльләнгән.

47.*Иблис*. Башка исеме–*Шайтан*. Аллаһы Тәгалә Адәмне барлыкка китергәч, Аллаһының Адәмгә сәҗдә кылырга кушкан сүзләрен тыңламаган бердәнбер фәрештә (аның фәрештәлеге хакында фикер төрлелеге яши). Моның өчен Аллаһы аны күктән сөрә. Шуңа күрә Иблис турында *рәҗим*, ягъни таш атып сөрелгән дип әйтәләр. Коръәннән соңгы риваятьләргә караганда, Иблис сөрелгәнгә кадәр *Газазил* яки *әл-Харис* дип аталган. Хәзер ул җирдә яши һәм явыз көчләрнең–*шайтаннар* белән *җеннәрнең* башында тора. Ул үзе әлеге явыз көчләрне тудырырга сәләтле. Иблис җимерек-харабәләр арасында, зиратларда, мунчаларда, базарларда көн кичерә, хәмер эчә, җыр-биюне, шигырьне ярата. Еш кына кешеләргә гыйбадәт кылырга комачаулый, зәкят малын урлый. Иблисне үз яныңнан куып җибәрү өчен Коръән аятьләрен кычкырып укырга кирәк (мәс., 2:268/271 не).

Һәр кешенең ике саклаучы фәрештәсе була дип ышаналар. Кирамән кятибиннәр булмаган очракта, алар кешенең кылган гамәлләрен дә язып баралар икән. Саклаучы фәрештәләр иртәнге һәм кичке эңгердә алмашыналар, шуңа күрә бу фәрештәсез вакытында кешегә Иблис коткысы аеруча хәтәр.

Бер мөселман риваятендә *Әл-Хәҗәр әл-Әсвәд*, ягъни Кәгъбәдәге Кара Таш Аллаһы җиргә җибәргән һәм ташка әйләнгән фәрештә дип тә сөйләнә.

Фәрештәләр–Аллаһының коллары, ул аларны хөрмәтли, шуңа күрә Адәм баласы да фәрештәләрнең күпчелеген хөрмәт итәргә тиеш. Ләкин без аларның берсенә дә сәҗдә кылмыйбыз, аларга дога укып ялвармыйбыз.

Фәрештәләр Аллаһы белән сүз ярыштырмыйлар, Аллаһы әмере белән генә эш кылалар. Аллаһы фәрештәләрнең алларындагы һәм артларындагы эшләрне белә.

Чыганакларга караганда, фәрештәләрнең теле гарәби, ләкин алар үзара сөйләшмиләр, даим Хак Тәгаләне зикер кылалар. Сурәтләре төрле-төрле, кайберләре адәм кыяфәтендә, кайберләре ат яки сыер сурәтендә, бөркет вә арыслан сурәтендә дә булалар.

Фәрештәләр һәм Әл-Рух (Җәбраил фәрештә) "озынлыгы илле мең ел булган көнне Аллаһ билгеләгән югары урынга ашарлар" (70:4).

Суфи авторлар язганча, Ахырзаман көнендә Газраил фәрештә иң әүвәле Иблиснең җанын алачак, аннары Җәбраил, Микяил, Исрафил фәрештәләрне һәлак кылачак, ахырда, Аллаһ әмере белән, үзенең җанын үзе алачак дип сөйләнелә. Вакыты җиткәч, Аллаһы Тәгалә аларны тергезәчәк.

*//Бәүбаве җәннәт*–җәннәт ишеген саклаучы фәрештә. *Газап фәрештәләре. Гаршене (җиденче кат күкне) күтәреп торучы фәрештәләр. Зөбани фәрештәләр. Рәхмәт фәрештәләре.*

Сөйләм телендә *фирештә* язылышы да очрый. Керәшеннәрдә: *пәриштя* (ангел), ә "өлкән фәрештәләр", мәсәлән, Гавриил (Җәбраил), архангеллар дип атала. Христианнарда аллага каршы фетнә күтәргән Люциферга (Иблискә) иярүче ангелларны *аггел* дип атыйлар

Татарда гөнаһсыз сабыйны *фәрештә валчыгы* диләр. *Фәрештә кияве*–тол калган ир.

"Борынгы болгар мәҗүсилегендә *Әләк*–тәңрегә кешенең ни кылганын әйтеп торучы фәрештә." (Р.Әхмәтьяновтан.) Хезмәт функциясе белән Кирамән кятибиннәргә охшаса да, Әләкне ислами фәрештәләр исәбенә кертеп булмый, әлбәттә.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Күлле Киме

Күлле Киме авылы Әтнә районында, район үзәге Олы Әтнә авылыннан 15 чакрымда, Коркачык станциясеннән—45, Казан шәһәреннән 86 чакрым ераклыкта урнашкан.

Археологлар Күлле Киме авылы янында XVI-XVII йөзләргә мөнәсәбәтле зират булуын ачыклаганнар.

XVIII йөздә Күлле Киме авылында 147 ясаклы татар һәм 2 керәшен татары яшәгәнлеге мәгълүм. А. Артемьев (1866) Күлле Киме авылы турында түбәндәге мәгълүматларны китерә. Үртәм суы янындагы бу авылда 148 хуҗалыкта 467 ир-ат һәм 504 хатын-кыз көн иткән һәм анда бер мәчет булган. 1898 елгы китапта Күлле Кимедә татарлар яши дип әйтелә. К. П. Берстель (1908) авылда 1129 татар кешесе яшәгәнлеген теркәгән.

Н. Борһанова мәгълүматларына караганда, Күлле Киме авылы халкы күршедәге Күәм, Әйшиасты, Үртәм, Казак Үртәме, Жилгелде, Бактачы, Каенсар авыллары белән бергәләшеп июнь аеның беренче декадасында Калатау җыены үткәргән.

Авыллар оешу тарихын өйрәнү өчен шәҗәрәләрнең әһәмияте зур. «Күлле Киме нәсел шәҗәрәсе» дип аталган шәҗәрәдә сөйләнелгәнчә, Бөерле авылыннан өч бертуган чыгып, өчесе өч авылга нигез салган: Айтуган—Каенсарга, Көнтуган—Ары авылына, Иртуган—Күлле Киме авылына төп баба булганнар.

«Күлле Киме авылы шәҗәрәсе» 1973 елгы археографик экспедиция вакытында Татарстан Республикасының Күлле Киме авылында Хәмитова Саимә Хәйретдин кызыннан (1901 елда туган) язып алынды. Анын сүзләренә караганда, шәҗәрәнең язма варианты китап рәвешендә булып, шәхес культы елларында югалган. Анын күчермәләре булу ихтималы да юк түгел. «Язып алынган текст мирасханәдә 99 кол., 1 тасвир, 36 эш берәмлеге булып саклана»,—дип яза М. Әхмәтҗанов.

Олылар сөйләве буенча, авыл башта ялгыз карама үсеп утырган җирдә, ягъни иске зират дип йөртелгән төштә, урнашкан булган.

Көннәрдән бер көнне Бөерле дигән татар авылыннан өч бертуган егет авылның иске урынына, ягъни урман, су буендагы каравылчы мари йортына килеп чыкканнар. Йорт хуҗасы мари аларны күреп шулкадәр курыккан ки, хәтта өеннән чыгып йөгергәндә аягына кия торган итеген дә оныткан. Бераздан туктап хәл алгач, итеге юклыгын абайлаган һәм яңадан килеп татар егетләреннән «кимем пу» дип сораган. «Кимем, кимем» дип кабатлаган, ялварган, бирүләрен үтенгән, ди. Бу егетләр марига итеген биргәннәрдерме, юкмы—билгесез. Әмма шунысы билгеле: алар үзләре урнашкан урынны Киме дип атаганнар. Тирә-юньдә су, күлләр күп булганлыктан, соңыннан күлле сүзен дә өстәп, бу урынны Күлле Киме дип йөртә башлаганнар, ди...

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Өч ир туган бер урында озак тора алмаган. Иң өлкәне Иртуган Күлле Кимедә яшәп калган. Айтуган исемлесе елга-суның аргы ягына чыгып, үзенә төпләнү өчен каенлыкны сайлаган һәм ана Каенсар исеме биргән. Өченче туганнары Иртуган арырак киткән һәм Ары дип аталган авылга нигез салган.

Киме халкы беренче килеп урнашкан шушы урында 300 еллар чамасы яшәгән. Елга-су буендагы җирләр җитми башлагач, берничә гаилә хәзерге Киме урынына күченеп килгән. Тора-бара Арыслан, Әшер, Җәгъфәр исемле кешеләрнең йорт-алачыклары янәшәсенә башка гаиләләр дә килеп утыра башлыйлар.

Киме халкы урманнарны кисә-кисә чәчү җирләре хәзерләгән. Сука сукалаган, чәчкән, урган, үз көнен үзе күргән. Җирне җан башына аркан белән үлчәп биргәннәр. Мәшкә исемле карт зуррак җир өлеше алу максатыннан кечерәк келәтен Бактачы җиренә илтеп салган һәм җир бүлүче (землемер) белән бер сүздә булып үзенә яхшы җирне эләктереп калган. Шуның өчен бу җир хәзер Мәшкә җире дип йөртелә.

Борынгы бабалар килеп утырганда авыл янында күлләр күп булса да, вакыт узу белән аларның берсе дә калмаган, хәтта исемнәре дә онытылып бара...

Авыл урманнан шактый ерак. Авылга берничә чакрымда, үзенә күрә шактый гына тарихы булган, алпавыт урманнары башлана. Бу урман күрше Мари иле республикасында үсә торган катнаш урманга килеп тоташа.

Күлле Киме—тирә-як авыллар арасында иң зыялы, ягъни мәдәниятле авылларның берсе була. Бирелә 1913 елда ук Чар өязенең мәгариф бүлеге инспекторы Гыймран Уразов тырышлыгы белән «Башлангыч рус-татар мәктәбе» (Начальная русско-татарская школа) ачыла. Ул вакытта авылда дин мәктәбе дә була. Бу мәктәптә бары тик ир балалар гына укый.

Киме мәктәбе совет чорында да абруен төшерми, база мәктәп, өйрәнү мәктәбе булып кала. Хәзерге көндә дә Күлле Киме урта мәктәбенең абруен төшермичә, республиканың югары уку йортларында белем эстәүче яшьләр күп.

Авылның иң тын почмагында, агачлар арасында, ике бина тора. Бу—Күлле Киме участок хастаханәсе. Хастаханәдән бераз киткәч, кечкенә генә бинада балалар бакчасы урнашкан. Авыл уртасында мәдәният йорты бар, каршында гына мәчет калкып чыккан. Ул авылга ямь, матурлык биреп тора.

Авылда татар халкының яраткан шагыйре Сибгат Хәким һәм шагыйрә Лена Шагыйрьҗан туып-үскән.

Күлле Киме авылы мәхәлләсе 1829 елда оешкан.

1848 елда төзелгән мәчет XX гасыр башында ярымҗимерек хәлгә килә.

Авыл халкы яңа гыйбадәтханә төзүгә рөхсәт сорап Казан губерна идарәсенә мөрәҗәгать итә һәм 1908 елның 26 апрелендә ризалык ала. Крәстиәннәр, төзеләчәк гыйбадәтханәнең проекты расалануын көтеп тормыйча, мәчет төзелешен башлыйлар. Пристав Гладышевның төзелеш эшләрен тоткарлавына карамастан, мәчет төзелә. 1909 елның декабрендә губерна идарәсе гаеплеләрне җавапка тартуны таләп итә (мәчет расланмаган проект буенча төзелгән була); төзелеш уставында каралганча, гыйбадәтханәнең 20 сажин аралыктагы тирәлеген чистартырга, корылмалардан арындырырга фәрман бирелә. Әмма бу билгеләнгән вакытта үтәлә алмый, чөнки дүрт гаиләнең йортлары—Х. Насыйбуллин, Ф. Әхмәдуллин, Н. Ризванов һәм В. Ризвановларның хуҗалыкларын яңа урынга күчерергә туры килә. 1910 елның августында гына проект раслана (бу вакытта мәчет төзелгәнгә бер ел тула!) һәм гыйбадәтханә үз вазифаларына керешә.

1863 елның июненнән башлап, илле ел дәвамында, Сибгатулла Фазлулла улы Арсланов (туган елы—1838) имам-хатыйб булып тора. 1899 елның августында, аңа ярдәмгә, икенче имам сыйфатында, Апанай мәдрәсәсен тәмамлаган Габдрахман Арсланов (туган вакыты—09. 04. 1876) билгеләнә. Габдрахман хәзрәт 1916 елның декабрендә ахун дәрәҗәсен алуга ирешә.

Мәхәлләдә 444 кеше исәпләнгән, мәчет каршында яна ысул белән 92 ир бала укыган, 84 кыз бала Г. Арслановнын хатыны Гарифә абыстайдан дәресләр алган.

Авылда С.Хәкимнең музей-йорты бар. Бер катлы агач йорт XIX-XX гасырлар чигендә төзелгән. Биредә 1911 елның 4 декабрендә Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның Г. Тукай, Россия Федерациясенен А. М. Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты, татар әдәбиятының классик әсәрләренә әверелгән шигырьләр, поэмалар һәм публицистик хезмәтләр авторы Сибгат Хәким (Сибгат Тажи улы Хәкимов, 1911—1986) дөньяга килгән.

Сибгат Хәким үзе турында болай яза. Төгәллек өчен аны русча бирәбез. «Я крестьянский сын. Мои корни довольно глубоки. В рассказах матери сохранилась память о восьми поколениях нашего рода. В далеком начале этого, не прерывающего до сих пор рода когда-то стоял старик по имени Мэмкэ.

Говорят, наш дед Мэмкэ был размежевателем, он делил между крестьянами землю. И сейчас еще в деревне ходят рассказы о нем. Будто в далекие годы, когда жители соседнего села при разделе полей прихватили полоску земли нашего Кулле-Киме, старик Мэмкэ упал на межу и зарыдал, приговаривая: «Совсем не останется земли нам... Пусть же не уродится ни один злак на ваших полях, обидчики, жить вам на черной пустой земле...». После этого, рассказывают, будто на полях того села три года ни травинки не было. И тогда соседи решили ублаготворить деда Мэмкэ: «Бери, старик, земли, сколько хочешь бери!»

Помню я и овраг Мэмкэ. Маленьким ходил я с мамой туда на ржаное поле, на жатву. Нет, не было там вдоволь хорошей земли, не могло, конечно, быть и урожая на скудных клочках, доставшихся в свое время и деду Мэмкэ...

Крепко люди держались за землю. Из-за нее—раздоры, кровавые столкновения... И я рос на той земле, играл в ее бороздах. И запала она навек в душу мою в образе Заказанья, как какой-то таинственный и грустный уголок, скудный хлебом, вечно томившийся в страхе голод».

*Дәвамы киләсе саннарда*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

# Радик Фәизов

## Акча кодрәте

Без, хәзерге өлкәннәр, бик беләбез: теге Сталин репрессияләре елларында халык дошманы дип табылган кешеләрне төрмәгә ябылудан, Себер китүдән, хәтта чыгарып атылудан да берни дә коткарып кала алмады. Бернинди ялынуялварулар, зур түрәләр белән танышлык, кода-кодагыйлык, төрле әшнәлекләр дә. Хәтта Молотов, Калинин кебек бөтен ил белгән һәм хөрмәт иткән җитәкчеләрнең дә хатыннары кулга алынган.

Әмма шул хәтәр, имансыз елларда да төрле хәлләр була иде...

Безнең кечкенә генә Дусым авылында (Әтнә районы бу), аргы якның үр өстендә Каюм исемле бер агай гомер итте. Чын баһадир сынлы, зур башына гел түбәтәй киеп йөргән, куе озын мыегы белән төрек солтанын хәтерләткән, аракы вә тәмәкенең ни икәнен белмәгән бер тәкъва иде Каюм абзый. Гаять тә эшчән, көндезләрен колхозның тау астындагы тимерчелегендә чүкеч суга, ә төннәрен өендә, мунчасында киез итек баса. Үзе искитмәле юаш, сүгенми, кычкырып сөйләшми, гаять диндар. Ул заманда да, бик астыртын гына булса да, өйләнешкәннәргә никах уку, үлгәннәргә ясин чыгу, йорт нигезенә дога кылу кебек дини йолалар гамәлдә иде. Мондый очракта инде кешеләр шыпырт кына Каюм абзыйны дәшеп ала. Димәк ки, авылыбызның мулласы вазифасын да үтәгән инде ул.

Каюм абзыйның җәмәгате Гайшә апай да ире кебек үк нык бәдәнле, олпат, әмма аннан үзгә буларак, бик ачык, сүзчән һәм кыю хатын иде. Алар заманасы өчен ныклы тормышта яшәделәр, йортлары иң иркен һәм матурдан, үр өстендә балкып торды. Һәм шул иркен йортны тутырып балалар үстерделәр. Авылда, Гайшә ирен бик карый икән, аны казан кабартмасыннан өзми икән, дип сөйләделәр.

Сугыш башланып китүгә, әлбәттә инде, гренадирдай Каюм абзыйны да армиягә алдылар. Авылдан чыгып киткәндә ул урам башына утырып бик озаклап дога кылды. Әмма китеп тә барды һәм шул китүдән юк та булды. Гаиләсенә бер генә хаты-хәбәре дә килмәде. Бөтен сугыш буена һәм аннан соң да. Әллә ничә бала әнисе Гайшә апа ирен, бер кәлимә урысча белмәгән, чебенне дә рәнҗетмәгән юаш, күндәм Каюм абзыйны, күптән инде һәлак булганга чыгарып куйган иде.

Шунда, инде сугышлар бетеп тә бер-ике ел үткәч, авылга бик сәер дә, куанычлы-көенечле дә хәбәр килде. Бактың исә Каюм абзый һәлак булмаган, исән икән. Ул чолганышта калып немецларга әсир төшкән, бу гөнаһсыз адәмгә хәтта фашистлар да артыгын каныкмаган, концлагерьга илтеп тыкмаган, ул шунда Германиядә, кайдадыр тимерче булып эшләп йөргән. Ә менә үзебезнекеләр килеп кергәч, аны шунда ук якасыннан алганнар, син хыянәтче, халык дошманы дип лагерьга ябып куйганнар. Ошбу лагерь Украинада икән, Каюм абзый анда да тимерчелектә чүкеч суга икән.

Боларның барысын да Гайшә апайга күрше авылның шахтадан кайткан бер кешесе килеп сөйләгән. Ул Каюм абзыйны үз күзләре белән күргән, алар лагерь коймасы буенда сөйләшеп торганнар.

Шуннан ары Гайшә апай, беләсезме, ни эшләде?

—Минем ирем гөнаһсыз җан. Ул кемгә дошманлык кылсын да хыянәт итсен. Булмаганны! Барам шул Украинасына, кеpәм төрмә түрәләре катына. Әйтәм үземнең сүземне. Алып кайтам иремне! — диде Гайшә апай авыл халкына.

Һәм сыерын, сарыкларын базарга чыгарып сатты, туган-тумачадан, күршекуләннән әҗәткә алды, күп итеп акча туплады. Ул вакытта кәгазь акчалар бик эре, кечерәк бер капчык акча тупланды. Гайшә апа юлга җыйналды.

—Гайшәбикә, йөрмә! Бирерләр сиңа анда иреңне. Үзеңне кушып ябып куярлар. Бар йөрүең шул булыр, — диделәр ана.

—Барам! Акча дигән нәрсәнең кодрәте житмәгән нәрсә юк бу дөньяда. Рәтен-чиратын бик беләм мин аның. Алып кайтам Каюмны! — диде Гайшә апай.

Һәм ул, Казаннан ары беркая да чыкмаган надан бер авыл хатыны, җилкәсенә биштәр тулы акча асып, әллә кайдагы Украинага сәфәр чыкты.

Шуннан ни диярсез?! Барган ул Украинага, эзләп тапкан теге лагерьны. Аның начальнигы янына да үтеп керә алган. Барлык алып килгән акчаларын өстәлгә чыгарып салган.

—Минем ирем хыянәтче дә, дошман да була ала торган адәм түгел. Менә сезгә акча. Бирегез миңа иремне! — дигән.

Теге начальник төрле хәлләрне күргән адәм булгандыр. Авылдан килгән бер татар хатынының гакылына, кыюлыгына хәйран калып, шактый вакытлар сүзсез торган. Аннары тәвәккәлләп кулын селтәгән.

—Ну апакай! Акча — безгә, ирең — сиңа. Алып кит хәзер үк! — дигән.

Менә акчаның могҗизасы. Сталин лагерына да үтеп кергән, үз гамәлен кылган ул.

Шулай итеп, Гайшә апай Каюм абзыйны житәкләп кайтып та керде. Бөтен авыл халкы «аһ!» итте бу хәлгә.

Аннан соң да әле Каюм абзый белән Гайшә апай озак еллар гомер иттеләр. Каюм абзый янадан тимерчелеккә төште, киез итек басты. Мул тормышта яшәделәр. Икесе дә сиксәнне үтеп бакыйга күчтеләр.

## Апа ниләр сөйләде

Яшьлегемдә, әле егет чагымда, мин Казан каласында хәрби заводта эшләдем. Ошбу завод бомбалар төяп барып дошманның баш өстенә ташлый торган очкычлар эшләп чыгара иде. Бинаһая зур, кодрәтле очкычлар. Без исә, бөтен бер цех халкы, шул очкычларның тәгәрмәчләрен ясадык. Бу тәгәрмәчләр үзләре «Беларусь» тракторы чаклы, гаять катлаулы агрегатлар иде.

Калада мин барак сыман йортта, бер апада фатирда тордым. Бу апаның исемен атамыйк, аны шул Апа дип кенә йөртик. Аның ире юк, кечкенә бер кызы гына бар. Үзе илле яшьләр тирәсендәге, озын буйлы, ябык кына бер хатын, чәче чем кара, йөзе җыйнак, күзе җете зәңгәр. Заманында чибәр булган, күрәсең. Тик хәзер аның йөзендә тирән генә яра эзе бар, чырае һәрчак караңгы, күз карашы астыртын. Кайчак бу күзләрдә дуамаллык, тирән кайгы-хәсрәт, тормыштан, ә бәлки язмышыннан канәгатьсезлек, ачыну чагылып үтә. Аз сүзле, усал гына бер хатын. Йөргәндә бер аягына яхшы ук аксый төшә.

Миңа — нәрсә? Иртә белән Апа мине чәй куеп эшкә озатып җибәрә, кичен ризыгын әзерләп каршы ала, кайчак кичләрен кинога барып соңарып кайтсам да, сукранмый. Торыр урыным бар, фатир хакын түләп килəм. Апа минем тормышым белән әлләни кызыксынмый, мин дә аныкын сорамыйм. Ягъни бер түбә астында булса да икебез ике дөньяда яшибез.

Әмма, шулай бит инде ул, тора-бара бергә яшәгән кешенең холык-

фигыленә, кылган гамәлләренә барыбер игътибар итә башлыйсың. Миңа иң беренче булып беленгәне: Апа бик тә фәкыйрь иде. Ул агач эшкәртү комбинатында ниндидер вак-төяк урында гына эшли, анда хезмәт хакын бик аз түлиләр. Апа аннан көн саен бер сумка йомычка күтәреп кайта, чөнки баракта үзәктән җылыту юк, бүлмәләрне кечкенә мичкә ягып җылытабыз. Аннан килеп бу Апаның бик сәер, аңлаешсыз бер танышлыгы бар. Ул безнең заводтагы бер очучы-сынаучы янына барып йөри, ул сынаучы да хатын-кыз икән. Апа шуның квартирын җыештыра, идәннәрен юа, ә тегесе аңа моның өчен үзенең өстеннән салган күлмәкләрен, ә кайчак акча да бирә. Ул сынаучыдан Апа еш кына сыйланып, бераз салган килеш тә кайткалый.

Мине тагын гаҗәпләндергәне шул булды: Апа чират торуны белми иде. Ул замандагы чиратлар! Кала кибетләрендә шикәр, күмәч, сөт кебек ризыкларга су буе була, халык сәгатьләр буена рәткә тезелеп тора. Безнең Апа исә кибет ишеге төбендә тәртип саклаган милиция янына килә дә, аларга нидер әйтә. Һәм тегеләр аны шунда ук берсүзсез үткәреп җибәрәләр. Бик сәер хәл иде ул.

Берчак исә мин Апаның күп ирләргә дә тәтеми торган йөрәклегенә, усаллыгына тап булдым... Ул кайчак шәһәр урамнарына да аягына өйдәге галошын өстерәп чыга иде. Барабыз шулай бергәләп каядыр трамвайда. Шунда миннән ерак та түгел басып барган Апа кинәт хәтәр итеп кычкырып җибәрде, янәшәсендәге әзмәвердәй бер адәмнең җиңеннән тотып алды, икенче кулына аягыннан салып галошын тотты һәм... шул галошы белән тегене кыйный да башлады. Ярыпмы яра! Ә теге әзмәвер берни эшли алмый, бер кулы белән башын каплаган. Ападан ычкынмак була, ә ул исә аңа ябык гәүдәсенә һич хас булмаган көч белән ябышкан.

—Кесә карагы бу! — дип кычкырды Апа халыкка һәм «Трампарк» тукталышында адәмне җилтерәтеп вагоннан алып та чыкты. Шуннан үтеп барган милиция кулына тапшырды. Вагонга кергәндә аның күзләре ниндидер кыргый бер усаллык белән ялтырыйлар иде.

—Кесәмә кереп бара, бәдбәхет! Минем тиеннәрем кирәк булган аңа. Тотып алдым кулыннан... Менә бирсен хәзер җавабын! — диде ул халыкка. Бу хәлгә бөтен вагон таң калды. Ә мин исә... куркуда идем. Менә нинди хатында фатир торам икән!

Гомумән, инде олыгаеп барган бу хатынның кайчандыр зур бәхетсезлекләр, фаҗигаләр кичергәне, тормыш аны ныклап кыйнаганы сизелеп тора иде. Ул күпне күргән, әмма анда әчке бер ныклык, гаделлек хисе сакланып калган. Монысы да сизелә. Минем исә аның үткән тормышын беләсем килә башлады. Бер получкадан хатын-кызлар өчен ясалган затлы шәраб алып кайттым. Кичен утырып, нәни генә бәйрәм корып алдык. Мин җай гына башлап җибәрдем:

—Ай-яй, Апа! Йөрәк тә бар икән үзегездә. Ни эшләттегез беркөн трамвайда теге кесә карагын, — дидем.

—Ярый, наныем. Күзеңнән сизәм, синең мине беләсең килә инде. Тыңлап тор алайса, — диде ул. Һәм түбәндәгеләрне сөйләде.

Сугыш башланганда ул Казандагы зур кибетләрнең берсендә мөдир булган. Алар азык-төлек сатканнар. Билгеле инде, ире шунда ук фронтка китеп барган. Мәгълүм ки, сугыш башланып күпмедер вакытлар үтүгә азык-төлеккә, шул исәптән ипигә дә карточка системасы кертелде. Һәм... тиз арада Апа эшләгән кибет коллективы, андагы кайберәүләрнең мәкерле коткысына бирелеп, җинаять юлына баскан. Болар ялган икмәк карточкалары ясап сата башлаганнар! Бик күп бәхетсезләрнең ач калуына сәбәп булган ошбу гамәл җинаятьчеләргә зур табыш, байлык китергән.

Бу шайка әгъзалары тиз арада әкияттәгедәй баеп китәләр. Безнең Апа да күп итеп яхшы киемнәр, затлы туннар, бизәнү әйберләре, алтын-көмеш сатып ала. Ул заман ач халык мондый әйберләрне юк бәягә дә сатып җибәрде.

Апа бу әйберләрне үз квартирына гына җыймый, күп танышларына, дусларына да тарата. Андый-мондый хәл килеп чыкса дип.

Ә хәл килеп чыкмый каламы соң? Мондый ук хәерсезлек җәзасыз торып каламы? Көннәрдән бер көнне бөтен шайкалары белән тотып алалар боларны. Нәкъ менә бергә җыйналып табыш бүлеп, тәмле ризыклар, кыйммәтле шәраблар белән сыйланып утырганда.

Җәза шул замандагыча кырыс һәм бик тиз була. Шайканың ин актив сигез кешесен, судсыз-нисез диярлек, чыгарып аталар. Шул исәптән карточкаларны ясап утырган нибары унҗиде яшьлек егетне дә.

—Мине, шул кибетнең мөдире булсам да, атмадылар. Мин башлап йөрмәдем. Барысын да товар белгече хатын эшләде. Шуна күрә, ике нәни баласы булса да, аны ин беренче аттылар да, — дип сөйләде Апа. — Ә мин исән калдым һәм... тәмуг газапларына килеп төштем. Таза-таза ирләр сорау алалар, һәр сораган сүзләре саен тимер йодрыклары белән авызыма китереп сугалар. Авызымда бер тешем исән торып калмады, барысы коелып бетте. Ике айга сузылган бу мәхшәрдән сон мине ун елга хөкем иттеләр.

Тик төрмәдә дә озак яткырмадылар. Бездән, үзем шикелле җинаятьче хатыннардан, штраф батальоны төзеделәр. Хатын-кызлар батальоны, барысы йөз кеше. Кулга мылтык бирделәр. Өч ай өйрәткәч, сугышка алып киттеләр. Кайсыдыр шәһәр янында, аны саклап, ут эченә кердек. Безнен арттан кулларына автомат тоткан ирләр керде. Аларга: «Менә болар сезнен хатыннарыгызны, балаларыгызны ачлыкта калдырган, алар ризыгын тартып алган имансызлар. Чигенә башласалар, качсалар, атыгыз да үтерегез!» дип әйтеп куйдылар.

Кердек сугышка, немецлар белән йөзгә-йөз килдек. Исән калуга өмет тотып, ярсып, үз-үзебезне белештермичә сугыштык. Безне күргәч, фашистлар да каушауга төштеләр. Шул кадәр котырган идек. Мин үзем әзмәвердәй бер ирне штыгым белән чәнчеп үтердем. Тик немецлар бик күп иде. Безне кырып салдылар. Минем аягыма арба тәртәсе белән китереп суккандай булды. Бер чокырга авып төштем, әмма исән калдым. Без йөз кешедән нибарысы өч кеше исән калганбыз.

Яралангач, мине үзем киткән төрмәгә кире кайтардылар, төрмә больницасына салдылар. «Син инде гаебенне каның белән юдың, икенче кат сугышка җибәрмибез, калган срогынны төрмәдә утырасың», — диделәр. Больницадан терелеп чыктым. Ун аягым аксап калса да, бик тырышып эшләдем, — дип сөйләде Апа. Мин тетрәнеп тынлап утырдым.

Тик аның өлешенә тигәннәр моның белән генә дә бетми әле. Апага, шушындый мәхшәрләрдән сон да матурлыгын җуеп бетермәгән яшь хатынга, төрмә начальнигының күзе төшә. Андый зур түрә каршысында мәхбүс ни кыла алсын? Ниндидер юллар белән фронттан котылып кала алган бу карсак әрмән кешесеннән аның баласы була. Нәни кызчыгы тугач, аны төрмәдән азат итәләр.

Апа Казанга кайта, сәүдәгә инде аны якын да җибәрмиләр. Агач эшкәртү комбинатына, анда да элекке танышлар ярдәмендә, эшкә урнаша. Элеккеге иркен квартиры күптән икенче кешеләр кулына күчкән була. Шушы баракта көн итеп, кызын тәрбияли башлый. Ул арада сугыш бетә, аның сугыш юлларын үтеп исән калган ире кайтып төшә. Өйдә уйнап йөргән нәни кызчыкны күрә.

—Хәтерем ялгышмаса, мин фронтка киткәндә безнең ни малаебыз, ни кызыбыз юк иде. Бу кем баласы? — дип сорый.

Апа иреннән берни яшереп тормый. Барысын да бәйнә-бәйнә сөйләп бирә.

Ире аны битәрләп бер кәлимә сүз әйтми. Заводка урнаша, әйбәт кенә эшли дә башлый. Тик күп тә үтми, эчүгә сабыша. Еш кына кичләрен, ә кайчак төннәрен дә өйгә кайтмый.

—Таныш-белешләремә, элекке дусларыма таратып, яшереп куйган алтын-көмешләрем, яхшы туннарым бар иде. Шуларның кайсыларын кире кайтарып та ала алган идем. Барысын да сатып эчте. Түздем, — дип сөйләде Апа. — Чит хатыннар белән йөри башлады. Түздем. Хезмәт хакының бер тиенен дә кайтарып бирмәде. Бер сүз дә әйтмәдем. Әмма берзаман минем дә түземем төкәнде. Бер көнне кухнәдәге зур пычакны алдым. Аны кайрап, әзер итеп куйдым. Ишек катына табуретка илтеп куйдым да, шунда утырып көтә башладым.

Төн урталары үткәч, исерек килеш, ишекне киң ачып кайтып керде теге. Ишектән атлап керүенә, башына табуретка белән китереп суктым. Гөрселдәп идәнгә барып төште. Пычагымны кулыма алып, күкрәгенә менеп утырдым. Тик тегене суя алмый калдым. Кызым чырыйлап кычкырып җибәрде дә, кулыма килеп ябышты. Ул арада ирем дә һушына килде.

—Иртәгә үк Казаннан чыгып юк буласың. Больше монда әйләнеп кайтмыйсын. Монда калсаң, шундук үтертәм мин сине. Үзем түгел, дусларыма әйтеп юк итәм. Минем андый дусларым да бар! — дидем.

Идәннән күтәреп торгыздым. Кулына әйберләре төйнәп салынган чемоданын тоттырдым, акча бирдем. Ишеккә төртеп күрсәттем. Шуннан бирле, менә ничә ел инде, минем ул адәмне Казанда күргәнем юк.

Менә шундый кеше мин, наныем. Менә шундый язмыш, — дип сөйләде Апа.

Һәм мин, язучы буларак, монда нинди дер аңлатма биреп, өстәмә ясап торуны кирәк санамыйм.

## Ахыр заман булмый калды

«Казан утлары» журналының былтыргы 4 нче санында чыккан «Тормыш язган хикәя»сендә («Әмәйгөл әби») Лаеш районыннан Тәфкил Вафин авылларына һава шары очып килүен бәян итә. Аларда бу хәл әлләни хәвефле вакыйга да булмаган. Ә менә безнең авылда!..

Сугыштан соңгы еллар, бик матур җәйге бер көн. Мин, уналты яшьлек егет, төштән соңгы ялны файдаланып, баз түбәсендә китап укып утырам. Шунда кинәт кенә урамнан гаять гаугалы итеп, соң дәрәҗәдә куркынган тавыш белән сөрән салдылар:

—Замана ахыры! Замана ахыры килеп житте! Югары очка, авыл башына Әҗүз-Мәҗүзләр килгән! Алар зиратка кереп киткән!..

Мин, комсомол егет, әлбәттә инде, мондый хорафатлы хәбәргә ышанмадым. Алай да китабымны куеп урамга чыктым. Ә анда... чын мәхшәр, тамаша! Бездән ике йорт аша түбән капка төбендә Җиһан әби, Югары күршебез Маһирә әби урамга чыгып басканнар. Ак яулыктан, чиста күлмәктән. Кулларында Коръән. Шәррән ярып, моңлы сузып шуны укыйлар. Аларның көйле тавышлары нигәдер гаять шомлы яңгырый. Ә урам буйлап Югары очка ирләр, хатыннар, малайлар, кызлар йөгерә. Бик каты куркып акыру-бакыру, ачыргаланып елау авазлары ишетелә. Бу хәлдән минем дә йөрәк урыннан купты. Гомуми ташкынга ияреп Югары очка чаптым.

Анда менсәк, авылның барча халкы янгын сарае янында, иң алда янгын дружинасы начальнигы Габдрәшит абый басып тора. Барысы да якындагы зират ягына текәлгәннәр. Ә анда, якты йөзем!... Анда карагач инде бернинди хорафатларга ышанмаган минем дә баш түбәм кайнарланып чыкты. Зиратта, агачлар арасында, үзе ап-ак, үзе кибән чаклы кабарынкы бер нәмәрсә! Туктаусыз хәрәкәтләнә, селкенә, кабарына... Карап торырга галәмәт куркыныч.

Гадрәшит абый, бик юка, тәбәнәк кенә булса да, йөрәкле кеше иде. Ул сарайга кереп кулына озын саплы багор тотып чыкты.

—Янына барып карыйк, җәмәгать. Ни-нәрсә булыр икән бу? Белергә кирәк аны, — диде.

Шундагы ир-атлар кулларына сәнәк-көрәк, хатыннар тырма ише әйберләр алдылар. Коралланып киттек шулай. Иң алдан Галрәшит абый бара. Конюшня янынnан үтеп, зират коймасы буена чыктык. Һәркем саклыкта, куркуда. Ә теге нәмәрсә якынайган саен дәһшәтлерәк, серлерәк күренә. Озынча түгәрәк, бинионая дәү, кибәннән дә артыктыр, ике күзе дә бар сыман! Үзе янәшә үсеп корыган ике агач арасына кереп кысылган. Ычкынмак була, яман талпына. Нәкъ Тукай диюе кебек дулый. Халык зират коймасы буенда тукталды. Эчкә үтәргә беркемнең дә йөрәге житми. Хәтта Галрәшит абыйның да.

Бераз шулай карап торган идек, Габдрәшит абый кинәт шаркылдап көлеп жибәрде.

—Бернинди жен-пәри дә, Әжүз-Мәжүзләр дә түгел бу! — диде ул. —Һава шары бу! Хәрбиләр шары. Ниндидер хәрби частьтән ычкынып киткән дә, монда очып килгән. Жил алып килгәндер инде.

Чыннан да, көн бик жилле иде. Ул арада болыннан ат менгән Үти Зиннәте килеп житте.

—Болын буйлап очып килде ул, Ашытны да сикереп кенә чыкты. Мин аны Мәтрүшкә белән куып та, артыннан житә алмадым, — диде көтүче.

Инде хәзер халык, курка-саклана гына булса да, зиратка керде. Шар ниндидер баулары белән агач ботакларына эләккән икән. Аны сак кына ычкындырып алдылар, бауларыннан тотып зираттан алып чыктылар. Шунда ул, нәкъ тере әйбер кебек, тотып алганга жене чыккандай, тагын тартыла, югары ыргыла башлады. Таза-таза ирләр аны көчкә тотып калдылар.

—Янгын сараена алып барыйк әле. Бәлки түбә астына сыяр. Кертеп ябарбыз шунда, — диде Габдрәшит абый.

Ирләр шарны тотып киттеләр. Ул һаман ычкынмак була, үзен тотучыларны жирдән күтәреп-күтәреп куя иде. Аны инде малайлар һәм хатыннар юл буе тырмалар, таяклар белән кыйнап бардылар. Халык аны һаман ниндидер тере, явыз бер нәрсә кебек кабул итә иде.

Янгын сарае катына життек. Сәнәкләр, тырмалар белән кыйный, этә-төртә торгач, шар ниһаять түбә астына кереп урнашты. Аннан куркып Арандагы атлар яман кешни, тибенә башладылар. Галрәшит абый исә сарай очырмасына менеп, шар өстенә сикерде.

—Хәзер эченнән газын чыгарам. Агулы газ булмасын, читкә китегез! — дип хәбәр салды ул. Кешеләр тагын паникага төшеп, әллә кайларга каләр йөгереп киттеләр.

Шар исә яман пышылдады, чыжылдады да, шинә, кечерәя башлады. Аннары тәмам жиргә ишелеп төште, тукыма булып калды. Ак төстәге, бик тупас тукыма. Бернинди начар исе-фәләне чыкмады. Габдрәшит абый аны жыеп алды да, арбага салып куйды. Үзе кәнсәләргә, ул замандагы авылда берденбер телефоннан Әтнәгә хәбәр итәргә дип кереп китте.

Иртәгесен Әтнәдән ике милиция килде. Алар тукыманы арбага салып алып киттеләр.

Менә шулай итеп безнең авылда чак кына замана ахыры булмыйча калды. Соңыннан бу мажара вакытындагы хәлләр турында бик кызыклы әйберләр сөйләделәр. Барый абыйның янчыкка салып өй матчасына асып куйган киндер орлыклары булган. Замана ахыры житсә шул орлыкларны алып, өстәлгә таратып салырга гына кирәк икән. Ул орлыклар шундук сикерә башлыйлар, кеше шуларга карап көлә һәм... үлемнән котылып кала икән. Барый абзый шактый вакыт орлыкларга карап утырган дип сөйләделәр. Мәһитап апай исә башы белән түбән базга сикергән. Печәнлеккә менеп качучылар да күп булган.

*Чын вакыйгалардан гыйбарәт мондый хикәяләрне сездән дә көтәбез, кадерле укучылар!*

# Г

**ГАЗИ** (Мингазиев) Ибраһим Зариф улы (4.2.1907, Тәтеш өязе Иске Карамалы а. - 21.2.1971, Казан), язучы, җәмәгать эшлеклесе. 1924-26 елларда Казанда өлкә партия мәктәбендә укый. 1931гә кадәр комсомол эшендә, бер үк вакытта «Кызыл яшьләр» г-тасы һәм «Колхоз яшьләре» ж-лы мөхәррире. 1932 дән Татарстан дәүләт нәшриятында мөхәррир. Бөек Ватан сугышы елларында фронт газеталарында әдәби хезмәткәр. Сугыштан соңгы елларда Татарстан китап нәшриятында, «Азат хатын» һәм «Казан утлары» ж-ллары редакцияләрендә эшли. Аның беренче лирик парчалары «Көлмә, Идел!», «Соңгы чаң» матбугатта 1929 елда басылып чыга. «Кич алтыда» (1929), «Байраговның көндәлек дәфтәреннән» (1930), «Көмеш сулы Нурминкә» (1930), «Бригадир кыз» (1931), «Катя Сорокина» (1938) хикәяләрендә шәһәрдә һәм авылда барган социаль үзгәртеп корулар турында бәян ителә. Сугыш елларында язылган «Әхмәт бабай» (1943), «Малай белән эт» (1943) хикәяләренең һәм «Алар өчәү иде» (1944; рус теленә тәрҗемәсе «Их было трое», 1947), «Без әле очрашырбыз» (1947) повестьларының үзәк темасы - үткән вакыйгаларга карата кешенең җаваплылыгы һәм аларда патриотизм хисе тәрбияләү. Г. иҗатының иң югары ноктасы - аның сугыштан соң язган әсәрләре. Г.нең «Тургай картаямы?» (1966) хикәясе, «Алмагачлар чәчәк ата» (1950), «Онытылмас еллар» (1949-66; русчага тәрҗемәсе «Хлеб, винтовка и любовь» (1950-75) повесте, «Гади кешеләр» романы (1955; рус теленә тәрҗемәсе «За городом, за Казанью»,М., 1957) татар прозасының иң гүзәл үрнәкләреннән санала. Язучының 1933 елда ук язылa башлаган «Онытылмас еллар» трилогиясе бигрәк тә уңыш казана. Авыл малаеның үсмер чагын хикәяләүдән башланган бу әсәр, Идел буенда барган тарихи вакыйгаларны эченә алып, Совет хакимияте урнашу һәм социаль җирлектә яңа тормыш коруны тасвирлауга багышланган киң планлы тарихи-революцион эпопея булып үсә.

1969 да трилогия Г.Тукай исем. Дәүләт премиясенә лаек була. Г. шулай ук публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән дә чыгыш ясый. А.П.Чехов, М.Горький, М.Е.Салтыков-Щедрин , Г.Мопассан, Э.Золя хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1968-71 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсе рәисе, РСФСР Язучылар берлеге идарәсе сәркәтибе. 1970-71 дә СССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы һәм ике тапкыр «Почёт Билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: За городом, за Казанью. М., 1957; Хлеб, винтовка и любовь. К., 1967; Онытылмас еллар. 1-2 кит. К., 1970; Әсәрләр. Т.1-3. К., 1987-88.

Әд.: Мустафин Р. Живые традиции // Образ времени. К., 1981; Сафуанов С. Ибраһим Гази. К., 1968; Ахунов Г. Гомер буе үзе булып калган кеше // Казан утлары. 1972. N1.

*Р.Х.Сверигин.*

**ГАЗИЗОВ** Мәхмүт Минәхмәт улы (8.2.1940, элекке Шөгер р-ны Туктар Урдаласы а.), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлагач (1963), Лениногорск р-ны мәктәпләрендә укытучы, завуч, директор булып эшли. 1970 елдан Яр Чаллы шәһәрендә. «Миләш сиртмә» исемле беренче җыентыгы 1969 да басыла. Эш, хезмәт, төзелеш темасы шагыйрьнең «Тәгәри китте йомгагым» (1972), «Мәйдан» (1990) җыентыкларында үзәк урынны алып тора. Балалар өчен язылган «Бер, ике, өч...» (1972), «Ике куян койрыгы» (2001) исемле кыска шигырьләр китаплары авторы. Публицистик һәм әдәби-тәнкыйть мәкаләләре матбугатта басылып килә.

Әд.: Вәлиев М.Җиде җил үзәнендәге имтихан // Татарстан яшьләре. 1975. 30 авг.; Баянов Ә. Сүздән алда эш // Социалистик Татарстан. 1986. 1 февр.

**ГАЗИЗОВ** Рафаил Шәкүр улы (26.4.1947, Мамадыш р-ны Кече Кирмән а.), язучы, ТРның атказ. укытучысы (1994). Казан ун-тын һәм Казан пед. ин-тын тәмамлый (1972; 1986). 1972 елдан Кече Кирмән урта мәктәбе директоры. Язмалары 1960 еллардан «Яшь ленинчы», «Татарстан яшьләре» г-таларында, «Ялкын», «Чаян» ж-лларында басыла башлый. «Бөре керфекләре» (1985), «Җи-

ләкле алан» (1988), «Чөгендер хикмәтләре» (1990) исемле шигырь җыентыкларында автор туган як табигате, тыныч хезмәткә дан җырлый. «Хат» (1993) җыентыгында башлыча тарихка мөрәҗәгать итә. «Кичер, кичерә алсаң» (1998), «Түбән оч малайлары» (1998) китапларына тупланган хикәяләрендә яшүсмерләрне тәрбияләүдә әдәп-әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Г. әсәрләренә образлар байлыгы, кеше психологиясен тирәнтен анализлау хас.

Әд.: Зөлкарнәев Ф. Бөрене тамыр уята // Казан утлары. 1987. N 7; Шабаев М. Төшсез чикләвекләр // Казан утлары. 1988. N 2; Минһаҗева Л. Хаталар да булмаса // Казан утлары. 2000. N3.

**ГАЗИЗОВА** Лилия Рифкать кызы (6.6.1967, Казан), шагыйрә. Казан медицина ин-тын (1990), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1996, Мәскәү) тәмамлый. Рус телендә яза. 1990-96 елларда «Казанский» санаториясендә эшли. 2002 дән ТР Язучылар берлегенең идарә әгъзасы, 2003 тән рус әдәбияты һәм тәрҗемә секциясе җитәкчесе. Г. шигырьләренә төгәллек, метафорага байлык, эчкерсез кичерешләр хас. Шигърияте рус поэзиясенең классик юнәлешенә тартым. Иҗаты: «Кара энҗе» («Чёрный жемчуг», 1995); «Лирик проза» («Лирическая проза», 2001), «Кышкы арабескилар» («Зимние арабески», 2002), «Дау белән дустанә» («В ладу с размирьем», 2006). Рус теленә С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин, Р. Харис, Л. Шагыйрьҗан, И. Иксанова шигырьләрен тәрҗемә итте. .

Әд.: Балашов Ю. Поэтическая Вселенная Лилии Газизовой // Казань. 2001. N5.

**ГАЙНАНОВ** Рашат Рәшит улы (27.10.1925, Башкортстан АССР, Салават р-ны Нәсибаш а. - 6.10.1990, Казан), әдәбият галиме, текстолог, тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1952-65 елларда «Совет Татарстаны», «Яшь ленинчы» г-таларында, «Азат хатын», «Татарстан коммунисты» ж-ллары редакцияләрендә эшли, 1965-86 та СССР ФА Казан филиалының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1986-90 да Казан ун-тының татар халкы тарихы каф. каршындагы Археография лабораториясендә эшли. Н.Думави (1960), Г.Тукай (т.1-4, 1975-77; т. 1-5, 1985-86), Г.Ибраһимов (т.1-8, 1974-86) әсәрләрен текстологик яктан әзерләүдә катнаша (шәрехнамәләр, искәрмәләр яза). Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Газиз, Ф.Кәрим, Н.Исәнбәт, З.Байчурина, М.Җәлил, Һ.Такташ, Г.Кутуй иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. 752 шәхес исеменнән торган, татар мәдәнияте тарихына (1900-17) караган белешмә өчен сүзлекчә төзи (кульязма рәвешендә). Татар теленә В.А.Осееваның «Васёк Трубачёв һәм аның иптәшләре» («Васёк Трубачёв и его товарищи», 1953), М.Твенның «Принц һәм теләнче» («Принц и нищий», 1954) повестьләрен, М.Шагинянның «Ульяновлар гаиләсе» («Семья Ульяновых», 1962) роман-хроникасын тәрҗемә итә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татар вакытлы матбугаты (1905-1924). К., 1999 (автордаш); Татарская периодическая печать начала XX века: Библиогр. указ. К., 2000.

Әд.: Урманчеев Ф. Кадерлерәк була бара // Казан утлары. 1987. N 4; Исламов Р. Тукайга, Ибраһимовка: Яңа томнар өстәгән галим // Кызыл таң. 1998. 28 авг.

**ГАЙНАНОВА** Фәния Гариф кызы (15.11.1929, Әтнә р-ны Олы Әтнә а.), тәрҗемәче. Казан ун-тын тәмамлый (1951). 1952-86 елларда Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә, 1999-2003 тә ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тында эшли. Русчадан татарчага В.А.Осееваның «Тылсымлы сүз» («Волшебное слово», 1953) хикәяләр китабын, Ж.Вернның «Капитан Грант балалары» («Дети капитана Гранта», 1974), «Серле утрау» («Таинственный остров», 1981) романнарын, И.С.Тургеневның «Язгы сулар» («Вешние воды», 1975) повестен, И.А.Гончаровның «Гыйбрәтле язмыш» («Обыкновенная история», 1979) романын, гарәп һәм әзәрбайҗан авторларының «Мисыр хикәяләре» (1958), «Әзәрбайҗан хикәяләре» (1963) җыентыкларын, шулай ук Л.Голосницкийның балаларга багышланган «Үткән заманга сәяхәт» («Путешествие в прошлое», 1960), А.М.Макушаның «Егет булыйм дисәң» («Мужчинам до 16 лет», 1969), шулай ук «Мәктәптән галәмгә» («Из школы во вселенную», 1973) фәннипопуляр китапларын тәрҗемә итә.

Әд.: Даутов Р.Н., Нуруллина Н.Б. Совет Татарстаны язучылары: Биобиблиогр. белешмә. К., 1986; Миңлебаев К. Урының түрдә, Фәния // Мәдәни җомга. 1999. 19 нояб.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Тәлгат
Нәҗмиев

# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Муса Җәлил пионеры

*Бу бер елда баштан кичкәннәрдән*
*Ми күперде, йөрәк кабарды.*
*Егермедә битем җыерчыкланды,*
*Егермедә чәчем агарды.*

М. Җәлил.

Муса Җәлил белән гомер буе горурланучы Тәскирә Бибарцева Саба төбәгендә алтмыш елга якын гомер итә. Ул Оренбург өлкәсенең Шарлык районы, Яңа Муса авылында туган. «Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы» исеменә, II дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденына, Жуков медаленә, башка бүләкләргә лаек Тәскирә Хәсән кызы булачак ватанпәрвәр шагыйрьне, Советлар Союзы Герое М. Җәлилне— ВЛКСМның Оренбург өлкә комитеты инструкторын болайрак искә ала:

«Ул бик чибәр, кап-кара күзле иде, өстендә ап-ак күлмәк булыр. Бер минут та тик торганын хәтерләмим. Без аның җитәкчелегендә, әлбәттә, кәгазьдән галстук ясап кызылга буядык та, парталар өстенә куеп киптердек. Аннары, укучыларны сафка тезеп, оешмага кабул итү, ягъни, муенга шул галстукны бәйләп, Ватанга хезмәт итәргә ант бирү тантанасы башланды.

Казан педагогия училищесында укыганда яшь кыз Муса Җәлил белән кабат күрешә. Шагыйрь Тәскирәне бик тиз таный...

Диплом алганнан соң яшь педагогны Тәкәнеш районына (хәзер Мамадышка керә) эшкә җибәрәләр. Олыяз авылында бер ел укыткач, мәгариф бүлегенә инспектор итеп күчерелә Тәскирә Хәсән кызы. Бу инде сугыш вакыты була. Берзаман аны хәрби комиссариатка чакыралар. Аның фронттан калу мөмкинлеге бар, әлбәттә. Әмма ул сугышка алуларын сорап гариза яза.

...Кызларга солдат формасы биргәндә чәчләрен кисеп, озын толымнарын үзләренә тапшыралар. Тәскирә киемнәре белән бергә озын толымнарын да посылка итеп авылына сала. Әнисе, кызын үлгән дип белеп, бик нык елый башта.

Тәскирә кебек кызларны прожекторчы һөнәренә укыткач, Можайск янына һава һөҗүменә каршы торучылар сафына җибәрәләр. Аларның бурычы— әҗәл төяп килгән бомбардировщикларга көчле яктылык белән тәэсир итеп, очучыны каушатудан-бутаудан гыйбарәт була.

1943 елның сентябрь аенда яндырылган самолетның берсе прожекторчылар өстенә төшә. Тәскирә бик каты яралана. Алты айдан соң шәфкать туташы аны озата кайта. Җәрәхәтләре ябылып бетмәгән кызны туган нигезендә мәңге төзәлми торган яра көткән икән: бәби тапканда җан биргән әнисе Мәргубәне җирләп кенә кайткан булалар. Тугыз бала анасыз кала. Әмма, никадәр авыр булса да, үлгән артыннан үлеп булмый. Тәскирә башта колхозда хисапчы булып эшли. Аннары, әтисе өйләнгәч, җиде һәм тугыз яшьлек ике сеңлесен алып, Татарстанга

Актаныш районының Суксу мәктәбенә килеп, укытучы булып урнаша.

Менә шулай җепкә тезелгән сәйләннәр кебек көн артыннан көн үтә. Алга таба Тәскирә Хәсән кызының хезмәт юлын тасвирлау кирәк булмас. Район мәгариф бүлеген дә җитәкли, Солтан районында чыга торган (хәзер Балык бистәсенә керә) «Октябрь юлы» район газетасы редакторы да була. Шуна күрә ул гомере буе матбугат белән элемтәсен өзми. Мине, каләмдәшен, үзенең 85 яшьлек юбилеена да чакырды Тәскирә апа.

...Тантана буласы залда, кунаклар килеп беткәнче диптер инде, ветеран турындагы «Саба дулкыннары» телевидениесе әзерләгән тапшыруны видеотасмада кабат карыйлар иде. Телевизор алдына ук үзе утырган язма герое. Нәкъ тапшырудагы кебек орден-медальләрен таккан, шул ук костюм-күлмәгән кигән, чәче дә нәкъ тапшыруга төшергәндәге кебек ясалган. Әмма иң гаҗәпләндергәне шул булды: экрандагы Тәскирә апа да, телевизор алдындагы тере герой үзе дә, ягъни икесе дә елыйлар һәм бер үк вакытта икесе дә ап-ак кульяулык белән күзләрен сөртәләр...

Тәскирә Хәсән кызы Бибарцеваны—газетабыздан ун яшькә олы хәбәрчене, гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган мөгаллимәне «Саба таңнары»ның 75 еллык кичәсенә чакырдык.

—Киләм, киләм, барыгыз белән дә бәхилләшеп кайтам,— диде ул башта ук телефоннан. Килде. Бик матур итеп чыгыш та ясады әле ветеран үзенең якташы Муса Җәлил турында...

—Безнең район газетасы редакциясе машина да, суыткыч та, телевизор да, иттарткыч та, ат та, бозау да, печән дә өләшми. «Уртак түшәк» хәлләрен дә язмый. Болай да алдыралар аны,— дип сүзен дәвам итте ул. Аннары мөхәррир вазифасының җаваплылыгына тукталды. —Мине мәҗбүриләп куйдылар редактор итеп. Үч иткәндәй, бер хәреф хатасы китте бит. «Кул чабып озаттылар» дигән җөмләдәге «кул» сүзендә «л» хәрефе урынына «т»ны җыйганнар типография кызлары. Ярый әле тираж таралмаган иде.

Бөтен гәзитне яндырдык та, редакторлыктан азат итеп, теләсә кайсы колхозга эшкә җибәрүләрен сорап гариза яздым КПСС өлкә комитетына...

Озаталар, билгеле, Тәскирә Хәсән кызы Бибарцеваны шул ук районның мәгариф бүлеге мөдире итеп. Әмма кул чапмыйча гына...

## Кунакка йөрешү

...1993 елның 8 июнендә йөз илле кеше төялгән автобуслар колоннасы Сабадан кузгалды. Тәүге тукталыш Актаныш җирендә булды. Район хакимиятенең ул вакыттагы башлыгы Таһир Әхмәев җылы сүзләр әйтеп, чәйгә чакырды. Яшел аланда җыр-музыка яңгырады, баяннар һәм тальяннар бию көйләрен мул сипте. Җырларда җырлана торган гүзәл Актанышның үзе белән танышкач, Башкортстанга—Дүртөйлегә таба кузгалдык, аннан без барасы Яңавыл да ерак калмый икән.

Менә район чигенә якынлашабыз. Безне каршы алырга хуҗалык, оешма җитәкчеләре, үзешчәннәр кубарылып чыккан иде.

—Сезне, Саба районы мәдәният һәм сәнгать көннәренә килүчеләрне, ипи-тоз, әйтеп бетерә алмаслык җылы хисләр белән каршы алабыз,— дип сүзен саф татар телендә башлады хакимият башлыгы Нәзир Зиязов. Җавап сүзен безнең район хуҗасы Фәрит Гыйльмиев әйткәннән соң, китте танышулар, аралашулар, кочаклашулар... Ә инде икенче көнне бик күп хезмәт коллективларында очрашулар дәвам итте. Байтак якташларыбызны очраттык. Бигрәк тә өязгә чыккан, ягъни киез итек басарга килгән җирдән Башкортстандагы матур-матур апаларга йортка кереп калган ир-ат сагынып көткән булып чыкты безне.

Татарлар иң күп яши торган әлеге районлагы әдәбият-сәнгать көннәребезнең

югары ноктасы тәнәфессез дүрт сәгатькә сузылган концерт булгандыр, мөгаен. Анын беренче бүлегендә «Сабада сабантуй» дигән музыкаль-хореографик күренеш күрсәтелде. Концерт өлешендә үзешчәннәребез аягүрә торып алкышланды, чәчәк букетлары ташкын булып агылды.

—Һушыбызны алып, талантыгыз белән гашыйк иттегез,— диде үзенең җавап сүзендә район мәдәният бүлеге мөдире Римма Фазыл кызы.

Әйе, табигать тә миһербанлык күрсәтте бу көннәрдә. Кояш та елмайды, җил дә вакытында исеп, янгыры да явып китте. Никадәр күнелле, рәхәт, өс бөтен, тамак тук булса да, барыбер аерылу мизгелләре җитте.

Әмма бу инде туганлашып саубуллашу иде. «Идегәй» халык дастанына «Урмандагы Саба» дип кергән борынгы җиребезгә рәхим итегез!»— дигән сүзләр кат-кат әйтелде.

Кунак ашы кара каршы дигәндәй, ун көннән соң, Янавыл районының Татарстандагы мәдәният һәм сәнгать көннәре башланып китте. Казанның Вахитов районында ике көн дәвам иткән очрашулардан соң кунаклар безгә килде. Алар хөрмәтенә шагыйребез Илдар Яхин белән Татарстан Республикасының атказанган артисты, танылган музыкант Нәҗип Бәдертдинов җыр да язганнар иде. Анын кушымтасы әле дә хәтердә саклана.

«Саба—Янавыл,
Саба—Янавыл,
Дуслар бар чакта
Яшәп була ул».

Дуслык тантанасына Казандагы шефларыбыз—Вахитов районы хакимияте башлыгы Сабирхан Мөхәрләмов җитәкчелегендәге делегация дә килде. Башкортстан кунаклары әдәбият-сәнгать осталары белән якташларыбыз академик Әбрар Кәримуллин, профессорлар Азат Әхмәдуллин, Мәхмүт Нигъмәтҗанов, Янавыл районында туып, Казанда яши һәм иҗат итә торган милләттәшләребез, икесе дә Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган бертуган филология фәннәре докторы Нил һәм шагыйрь Илдар Юзеевлар, Татарстанның халык язучысы, 1992 елда Бөек Британиянен Кембридж биография үзәге «Ел кешесе» дип игълан иткән Нурихан ага Фәттах кебек мәшһүр шәхесләр бар иде.

Хәзер район «капкасы» янында булган бер истәлекле вакыйганы тасвирлап үтим әле. Кунакларны ипи-тоз һәм чәчәк бәйләмнәре белән каршылау һәркайда матур гадәткә керде бит инде. Әллә буталып, әллә танымыйча, бер нәни кыз мина да зур букет китереп тоттырды. Башта аптырап калдым. Аннары башыма бер фикер килде: бу тере чәчәкләрне Нурихан абыйга (янына балалар барып житкәнче, билгеле) тапшырырга булдым. Матур итеп елмаеп, үзенә генә хас тыйнаклык белән кабул итеп алды букетны Сабага тәүге тапкыр килгән олы язучыбыз.

Ярар. Ике көн барган очрашулар, үзара концерт алмашулар шаулап-гөрләп үтте, кунакларны район чигендәге «Юлларыгыз ун, Саба җиле юлдаш булсын!» дигән панно янында елый-елый озатып калдык.

Шуннан сон, бер атна үткәч, Казаннан кирпеч калынлыгы бандероль килеп төште мина. Ачып карасам, ике күзем шакмак булды: Нурихан ага үзенең «Сызгыра торган уклар» романын (беренче һәм икенче китаплар) җибәргән. Форзацка болай дип язып та куйган: «Татарстанда Янавыл көннәре унаеннан, изге Саба җиренә аяк басу белән, беренче булып мина чәчкә китереп тоттырган Тәлгат энем Нәҗмиевкә, каләмдәшкә, чын күнелдән сөенеч һәм ихтирам тойгысы кичергән автордан:

Н. Фәттах (имза), 22 июнь, 1993 ел, Казан».

Гомумән, ошатып китте Саба төбәген тарихи романнар остасы. Шулай булмаса, мондый хат юлламас иде: «Без әледән-әле сабалыларны искә төшерәбез. Сездә үткәргән күнелле көннәр, елмаюлы йөзләр, мул табыннар, яшел басулар һаман күз алдында тора. Радиодан Саба турында сүз чыкса,

шундук колаклар үрә тора—туган якларны ишеткәндәй булабыз. Сезнең үзегезгә, барлык сабалыларга исәнлек-саулык, илгә иминлек, муллык теләп калучы Нурихан».

Күренекле әдип, безнең төбәккә, аның борынгысына һәм бүгенгесенә битараф булмавын «Саба» исемле күләмле һәм тарихилыгы белән кыйммәтле мәкалә язып та раслады. Хезмәт «Сөембикә» журналының 1992 елгы 2-3нче саннарында (автор Сабага килгәнче) басылды. Әдип һәм галим Нурихан Фәттах Саба тарихы, бу атаманың килеп чыгышы турында тәфсилле сөйли, Саба авылының Казан ханлыгы чорында ук булуын, 1184 елгы вакыйгалар (руслар белән болгарлар арасында сугыш) уңае белән Сабаның рус елъязмаларында да телгә алынуын искәртә.

Бервакыт телефон шылтырады.

Нурихан аганың җәмәгате Руфинә ханым икән.

—Тәлгат энем,— диде ул. —Нурихан абыеның 75 еллык юбилее Кәрим Тинчурин театры бинасында була. Чакыру кәгазе барып житмәскә мөмкин. Килегез. Нурихан абыең хәбәр итәргә кушты.

Әйе, бардым мин ул тантанага. Кичә башланганчы арткы бүлмәдә очраштык олуг язучы белән. Тәбрикләп, Саба урман хуҗалыгында эшләнгән сувенирлар тапшырдым. Ул миңа үзенә багышланган «Мәйдан» журналын бүләк итте.

Бу—соңгы күрешү һәм саубуллашу булган икән...

Әлеге язмама «Кунакка йөрешү» дигән баш юкка гына куелмады. Шулай булгач, бу теманы язучылардан ишеткән кызыклы хәл белән тәмамлыйк та инде.

...Мәрхүм Нурихан Фәттахның кырыгын үткәргән мәҗлестә Руфинә ханым дуслар, туганнар алдында зарланып ала: «Казан мэриясеннән Камил Исхаков имзасы белән Нуриханга атап әлегә кадәр котлаулар килеп тора. Менә тагын Совет Армиясе көне белән тәбрикләделәр, исәнлек-саулык телиләр».

«Ә син аларга Нурихан исеменнән мондый җавап яз»,—дигән табында утыручы Илдар Юзи (аның да авыр туфрагы җиңел булсын): «Котлавыгызны алдым, рәхмәт, сезне үземә кунакка чакырам».

## Тәки сүзендә торды

Чаллы шәһәренең Сара Садыйкова исемендәге концертлар залында язучы Газиз Кашаповның 60 яшенә багышланган искә алу кичәсе булды. Чаллыныкылар бу чарага зурдан кубып әзерләнгәннәр иде. Кырык тугыз яшендә арабыздан киткән әдип бик күпләр яратып укырлык «Сәмум җиле», «Солдат иртә ир була», «Җир җылысы», «Убырут», «Гомернең утлы өлеше», «Лачын кошка күкләр кадерле», «Язмышына ышан», «Вөҗдан хәтере», «Гыйфрит», «Дисбат», «Киек каз юлы» кебек әсәрләр иҗат итеп, биш китап чыгарырга өлгергән иде.

Газизҗан белән мине чал университет дуслаштырды, аннары гаиләләр белән аралашып йөрдек. Кыскасы, туганлаштык. Сессия вакытларында алты ел бер бүлмәдә яшәдек. Кунакханәдән урын алып калу өчен чиратлашып, Яңа елны өйдә каршыламыйча, анда 31 декабрь көнне үк килеп урнаша идек...

Газизҗан бик авыр холыклы, үҗәт, кимчелекләргә түзеп тора алмаучан, кешенең «дуңгызлыгын» йөзенә бәреп әйтә торган шәхес иде. Бигрәк тә милләт җанлы булды. Туган ягының табигате, матурлыгы өчен көрәште.

...Казанның кыл уртасында—«Татарстан» кунакханәсендә торган чагыбыз. Германия Демократик Республикасы галимнәре катнашкан ниндидер гыйльми конференция уңаеннан безне торган җиребездән куып чыгарырга маташалар. Газизҗан башта яхшылап әйтеп карады. Совет Армиясенең инвалид офицеры

икәне турындагы таныклыгын да күрсәтте. Ыжгырып торган администратор маржа апа анларга теләмәде. Ятимлектә үсеп, гомер буе язмышы тарафыннан кыерсытылган татар малае, ниһаять, түзмәде.

—Германиядән килгән фашист балаларына бүлмә бар, совет офицерына урын юкмыни сезнең гостиницада?— дип кычкырды...

Теге маржа апага шул гына кирәк иде.

—Хәзер күрсәтәм мин сиңа урын?— дип директоры кабинетына таба йөгерде.

Бүлмәбезгә күтәрелдек. Телефон шалтырады. Чыгып китмәскә куштылар. Дәүләт куркынычсызлыгы комитетыннан, ягъни КГБдан киләчәкләрен хәбәр иттеләр.

—Тәлгат,— диде дустым, —син яхшы чакта чыгып тай. Беренчедән, райкомда эшлисең, икенчедән, балаң яшь, хатының да тол калыр.

Әлбәттә, мин күлмәгемә сыймый башладым. Дөрес әйтә бит Газизҗан. Әмма дуслык хакы да бар. Уйладым-уйладым да:

—Юк, китмим. Ни күрсәк, бергә күрербез,— дидем.

Менә ишек шакыдылар. Бүлмәгә кап-кара костюм, якасы кыршылмаган зәп-зәңгәр күлмәк, төсе туры килгән галстук таккан, төз гәүдәле кеше килеп керде. Башта исем-фамилияләребезне язды бу. Аннары кем булып эшләвебез белән кызыксынды.

—В райкоме КПСС,— дидем мин, маңгаемдагы тир бөртекләрен сөртә-сөртә.

Каш астыннан дөмренеп карады да:

—В райком ВЛКСМ, наверное?— ди.

—Нет, Кэ-пэ-эс-эс...

Безгә үзе артыннан иярергә кушты ул. Мин, канаты сынган кош сыман, икенче булып атлыйм. Кулымны артка куйганмын, җитмәсә. Шуны күреп, Газизҗан миңа ак кәгазь бите күтәрә алмаслык татарча бер яман сүз әйтте. Әйтсә-әйтер, аңа игътибар итәрлек дәрәҗәдә түгел идем инде. Башта хуҗам—КПСС райкомының беренче секретаре иптәш Камалов күз алдыма килеп басты. «Безнең партоешмага тап төшердең, шәкерт!»— дигән сыман күзлек аша карап тора кебек. Аннары Байлангардагы әти-әнием, Сабадагы алма кебек улым Нияз, кыш көне пешкән чия шикелле Лемарам (февральдә туган) телевизордан күрсәткән кебек күз алдыннан тиз-тиз генә үтеп киттеләр. Башыма тагын әллә нинди уйлар килде: «Камералары ничә кешелек икән?»— дим.

Бүлмәсендә кунакханә директоры үзе көтеп тора иде. КГБ кешесе безне кертеп утыртты да:

—Документлары тәртиптә, минем миссия үтәлде,— дип паспортларыбызны өстәлгә куйды да чыгып китте.

Күктәге кояшны бүләк иттеләрмени! Янадан иректә бит без! Ур-ра!

Кунакханә директоры Габделхак Кафиятуллин үзенең дә отставкадагы полковник, Бөек Ватан һәм империалистик Япониягә каршы сугышлар ветераны булуын әйтте. Ул фронтта шагыйрь Фатих Кәрим белән очрашкач, аның шигырьләрен сөйләп күрсәткән. Саперлар батальоны составында атакага күтәрелеп Фатих Кәримнең каты яралануын үз күзләре белән күргән, шагыйрьнең вафатыннан соң аның шинелен һәм кыр сумкасын туган ягына җибәргән шәхес булып чыкты.

«Бер өч көнгә генә чыгып торыгыз, егетләр, аннары янадан урнаштырам, сүземдә торам»,— дип вәгъдә бирде Габделхак ага.

Без Газизҗанның туганнарына—Риза абыйларга күчтек. Икенче көнне Газиз Кашапов миңа:

—Тәлгат, әгәр дә мин бер әйтүгә ташлап чыгып киткән булсаң, бүтән эндәшми идем мин сиңа!»— диде.

## Ярып карагач...

2001 елнын 10 сентябрендә Саба урман хужалыгынын 70 еллыгы билгеләп үтелде. Тантанага Президент Минтимер Шәймиев килде, анын белән Премьер-министрыбыз Рөстәм Миннеханов кайтты. Гомумән, йөздән артык рәсми кунак чакырылган иде. Бәйрәм әйбәт булды. Бер танышым әйтмешли, андый «мач» гел килми бит...

«Әбиләр чуагы» дип йөртелә торган матур көндә булган юбилей тантанасы бөтен гомерен урман хужалыгына багышлаган Нургали Миннехан улынын каберенә чәчәкләр салудан башланып китте. Ул бу тармакта 43 ел эшләде.

Нургали Миннехан улы—Россия Федерациясенен һәм Татарстан Республикасынын атказанган урманчысы. Ул шулай ук Октябрь Революциясе, «Почет билгесе» орденнары, жиде медаль, «Дәүләт урманнарын саклауда һәм үстерүдәге хезмәтләре өчен» билгесе белән бүләкләнгән иде.

Әлбәттә, бәйрәмнен үзәгендә атаклы урманчыга һәйкәл ачу булды. Аны танылган сынчы, Олы Арташ авылында үскән, Татарстан Республикасынын атказанган сәнгать эшлеклесе, Татар рәссамнарынын Бөтендөнья ассоциациясе президенты, Мәскәү рәссамнары берлеге әгъзасы, Казандагы «Хөррият», Оренбургтагы Муса Жәлил һәйкәлләре авторы, атаклы Третьяков галереясында дистәләгән әсәре мәнгелеккә куелган, ижат үрнәкләре Австрия, Германия, Бөекбритания, Япония, Америка, Канада, Төркия кебек илләрнен музейларына урнаштырылган якташыбыз Кадим Жәмитов ясады.

Һәйкәл өстендәге япма төшерелгәч, Минтимер Шәрипович Нургали Миннеханов адресына, анын 70 ел яшәү дәверендә башкарган эшләре, жәмәгате Васига ханым, уллары турында жылы сүзләр әйтте.

—Сезгә, ничектер, мина Кадимнен хезмәтләре ошый,— диде ул сәнгать әсәрен ерактанрак караганда. —Кешене исән вакытта бер дә күрмәгән килеш һәйкәлне шулай итеп тудырырга кирәк бит, ә?!— дип өстәде. Аннары Кадим Жәмитнен үзенә сорау бирде. —Мондый талант Сездә ничек барлыкка килде икән?

—Бардыр инде,— диде автор тыйнак кына.

—Юк, әйт әле, каян килеп чыга ул шулай?— дип янадан кайтарып сорады Президент.

Кадим жавапсыз калмады:

—Вскрытие покажет,— диде, ярып карагач күренер, ягъни.

Президент та, халык та кычкырып көлде.

## Тели белсән... теләк

Данлы-шанлы Актаныш егете, журналист, язучы, шагыйрь, коеп куйган мөхәррир һәм житәкче Әмиржан Моталлапов белән еш булмаса да, очраштыргалап торабыз.

Жае килгәндә, иркенләп әнгәмә корабыз. Чөнки сөйләшер сүзебез бар: язмышларыбыз уртак. Әмиржан аганын да гомере кәгазь арасында, язу-сызу эше белән үткән, редакторлык та иткән, типографияне дә житәкләгән. Үзе язганча, күтәрелеп киткән вакытлары да күп булган, төшкаләгән дә ахыры. Югыйсә:

> Дөбер-шатыр итеп төшерәләр,
> Туган-тумачаны, дус-ишне.
> Монысын инде яшереп булмый—
> Үземнен дә төшеп килешем...

—дип язмас иде.

Кәрим Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры бинасында Татарстан Язучыларының чираттагы корылтае бара. Тәнәфескә чыктык.

—Әнә, теге озын кешене күрәсезме? Сезнең кебек мәзәк хәлләрне дә яза ул. Әмиржан Моталлапов була,— дип таныштырган иде ул вакыттагы мәдәният министры урынбасары, шагыйрь Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза). Аннары ул болай дип өстәде.

—Мин элегрәк, район эчке эшләр бүлеге нәчәлниге урынбасары булып эшләгәндә, Сабадан ике генә кешене белә идем: Тәлгат Нәҗмиевны укып, хезмәттәшем капитан Фоат Әхмәтшинны күреп,— дип тә өстәгәч, күңелем тәмам эреде дә куйды.

«Пирамида» мәдәни күңел ачу үзәгендә узган Татарстан Язучылар берлегенең 70 еллык юбилее кичәсендә Әмиржан Моталлапов, Мамадыштан Рафаэль Газизов белән бер өстәл артында утырдык. Рәхәтләнеп серләштек. «Үзеңнеке—үзәктә» дигән китабын да бүләк итте Әмиржан ага. «Без—актанышлылар» җыентыгын укыган бар иде. Сүз җае белән бер кызык вакыйга да сөйләде әле ул.

...Безнең район Советы башкарма комитетының иске бинасы янындагы бакчада Ленин һәйкәле тора. Ул, Актаныш районы оешу белән, утызынчы еллар башында ук урнаштырылган булган. Ленин сыны, уң кулын алга сузып, карашын еракка төбәгән. Аның бу кыяфәте ни аңлатканны белүче дә, белергә теләүче дә юк иде.

Түбәтәй асты бераз кызган Исламхуҗа абзыйның чыршы бәйрәменнән кайтып килеше икән. Аның юлы шушы бакча турыннан үтә. Башына нинди фетнәле фикер суккандыр, Исламхуҗа бакчага керә дә Ленинның алга сузылган кулына өч тиенлек бакыр китереп сала.

—Күптәннән теләнеп торасың, бичаракай. Мә инде, файдасын күр,— дип сөйләнә-сөйләнә китеп бара абзый.

«Файда»сын күрсәтәләр аңа! Алдагы өч Яңа елны тимер рәшәткә артында каршыларга туры килә «фетнәче»гә!

Утырып чыккач, тегеннән сорыйлар икән:

—Үз гаебеңне таныйсыңмы соң?

—Анда эләксәң таныталар агайне. Срукны бакыр акчаның бәясенә карап чәпиләр икән. Ярый әле бер тәңкәлек тоттырмаганмын,— дип җаваплый Исламхуҗа абзый.

Моңа охшашрак хәл безнең Сабада да була бит. Бик гаярь кеше җитәкли бер оешманы. Кыскасы, иртән баштан кешенең нервысында уйнамаса, эт итеп «авызын-борынын майлап» сүкмичә, көне булмый моның. Үзенең бер урынбасарының һәм аның шоферының иманын кикертә бу чираттагы «ковер»да. Кулындагы күзлеген болгый-болгый «майт»ларын акыра-акыра сиптерә. Кыскасы, сүгенүнең ләззәтен татырга ярата ул, хәтта күз бәбәкләре зурая, борын тишекләре киңәя. Ә тегеләр Казанга китәргә тиеш була. Шуннан урынбасарның шоферы, ниндидер ырым буенча, өч тиенлек бакырны машина ишегеннән ачып ташлый да: «Без кайтканчы паралич суксын иде, ярраббый Ходаем!— дия-дия каргыш тели.

Ярар, кушылган боерыкларны үтәп, кичкә исән-имин әйләнеп кайталар болар һәм хуҗаларының аягы сынганын ишетәләр.

Шуннан соң теге шофер:

—Их, бер сум ташлыйсы калган икән,—дип куя.

*Рафаил Газизовка 60 яшь*

# ЧИШМӘЛӘР ШАГЫЙРЕ

Чишмәләрне карап, чистартып, улагын төзәтеп, алыштырып, язын-көзен-кышын бирегә юл ачып торучы кешеләр була. Чишмәле һәр авылда бар алар. Шагыйрь җанлы агайлар...

Танылган әдип һәм мөгаллим Рафаил Газизов — агай түгел, әле егет чагында ук нәнә шул сакка — чишмәләр сагына баскан зат. Рафаил Шәкүр улы инде менә чирек гасырдан артык Мамадыш районындагы туган авылы Кече Кирмәндә мәктәп директоры булып эшли. Бала чагыннан ук шигырь язып үскән, аннары Казанда тел һәм тарих буенча югары педагогик белем алган егет, әлбәттә, башкалада да үзенә лаеклы эш-урын тапкан булыр иде. Әһле каләмнең калага тартылуы да табигый. Үзе белән бер тирәдә Түбән Ушмы урта мәктәбендә укыган, бер әдәби түгәрәктә каләм чарлаган Нәзифә Кәримова, Ринат Мөхәммәдиев, Шаһинур Мостафин һәм Зиннур Мансуровлардан аермалы буларак, ул авылны сайлый. Туган телебезнең чишмәсе авылда лабаса! Ә инде әдәби телнең бишеге — минемчә, безнең якларда.



Рафаил Газизовның иҗади уңышларына сөенгән, аны эзләп туган авылына ук килгән кеше — якташы, күренекле шагыйрь Шәйхи Маннур була. Шигъри чишмәбез сагында торучы ил агасының җылы сүзләре, әлбәттә, яшь шагыйрьгә дәрт вә илһам өсти. Бераздан беренче китабы — «Бөре керфекләре» дә дөнья күрә. Балалар өчен «Җиләкле алан», «Чөгендер хикмәтләре» исемле җыентыклары чыга. 1992 елда ул Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

Кайчандыр шагыйрь Зөлфәт: «Кем-кем, ә менә Рафаил Газизов образлар кытлыгыннан тинтерәүче шагыйрь түгел, бай шагыйрь!» — дигән иде. Минемчә, бу фикер әдипнең чәчмә әсәрләренә дә туры килә. Әйе, соңгы елларда ул проза жанрында да актив иҗат итә. Аның «Кичер, кичерә алсаң», «Түбән оч малайлары» исемле повесть һәм хикәя җыентыклары дөнья күрде.

«Гасырларны йөзтүбән каплаган шарлавыклар, илләрне йоткан чоңгыллар, дәверләрне җир өстеннән кырып-үтүкләп киткән бозлыклар, кыйтгаларны теткәләгән бусагалар аша исән-имин чыккан бу авылга тарихта алга таба да Ак Кирмән ханлыгының дәвамчысы булырга язгандыр» — әлеге җөмлә «Ак болыт» («К. У.» 12 сан. 2003 ел) эссесыннан. Бер җөмләдә никадәр образлар тыгызлыгы... гына түгел. Һич тә. Туган авыл аша Ватанны күзаллау, аның үткәне һәм киләчәге өчен борчылу, милләт язмышында үз җаваплылыгыңны тою хисе дә чагыла бирәдә.

Ә инде язучының теленә килгәндә, ирексездән, Мөхәммәт Мәһдиев искә төшә. Һич арттырусыз! Рафаил Газизовның авылдашлары — Аю Гаяны, Түтүт Гарифы, Үчтеки Миңнеханы, Токмач Гаязы — йомры, шаян-шук, кайчагында тәмле генә түгел, борыч телле авылдашлары — һәммәсе дә безнеңчә, татарча, авылча. Аларның холык-фигыльлен, шатлык-сөенеч вә борчуларын автор үз итеп, яратып тасвирлый.

Рафаил Газизовның язмышын туган авылы белән гомерлеккә бәйләү сере аның һәрдаим радиодан башкарыла торган «Тәрәзаләр — әни күзләре», янсә туган якка багышланган бүтән җырларында да чагыла.

Ул — үз иҗатына гаять зур таләпчәнлек белән карый торган язучы. Бөегебез Габдулла Тукай белән бер үк көнне туу (1947 ел, 26 апрель), кемгә-кемгә, ә шагыйрь

кешегә олы җаваплылык та өсти, минемчә.

«Танылмыйдыр кеше гәрчә тышыннан,
Танып була аны кылган эшеннән»

— дигән бөек Дәрдмәнд. Моннан берничә ел элек Мамадыш районының Кече Кирмән урта мәктәбе укучылары белән очрашкан идек. Кирмән ягы борын-борыннан үзенең чишмәләре белән дан тота. Бакырчы, Изгеләр чишмәсе — җәмгысе йөздән артык чишмә ургып ята бу якларда. Һәркайсының — үз тәме, үз аһәңе. Рафаил Газизов җитәкчелек иткән мәктәп бинасына килеп кергәч тә, иң әүвәле сине диварларда Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Кандалый, Мәрҗаниләрдән башлап, Шәйхи Маннур, Сара Садыйковаларга кадәр тезелгән йөздән артык олуг шәхеснең затлы портретлары каршы ала. Ә инде республика һәм ил күләмендә уздырыла торган һәртөрле мәктәп олимпиадаларында, «Иделем акчарлагы» кебек иҗади бәйгеләрдә укучылар һәрдаим алдынгы урыннарны яулыйлар икән, бу мәктәптә гел милли рух мохите хакимлек итә икән, нигә моңа гаҗәпләнергә?! — Яңа чишмәләрнең әнә шулай дөньяга аваз салуы лабаса бу. Мәктәп директорының, мөгаллимнәрнең, тыштан кыяфәт ясамыйча, үз эшен җиренә җиткереп башкаруы нәтиҗәсе! Бер мәкаләмдә «Туган як һәм әдип кадере» («К. У.», 1 сан. 2005 ел): «Ш. Маннур — язучыны олылый белү гадәтенә түрәләрне өйрәткән әдип», — диелгән. Рафаил Газизовны халык та, җитәкче даирәләр дә, мөгаллим һәм әдип буларак, Мамадышта гына түгел, республикада да яхшы белә, хөрмәт итә. Чөнки ул аңа кылган эше белән лаек.

Мөгаллим-шагыйрьнең балалар өчен язуы, әлбәттә, табигый. Әле күптән түгел генә Рафаил Газизовның «Бүләгем» исемле яңа китабы өчен балалар әдәбияты буенча дөньякүләм булдырылган иң югары бүләк — Г.-Х. Андерсен исемендәге Халыкара диплом белән бүләкләнүе дә табигый. Бала күңеле — үзе чишмә. Ә ул — чишмәләр шагыйре.

---

**Марат ЗАКИР**

Рафаил
Газизов

# «БҮЛӘГЕМ» КИТАБЫННАН

## Безнең урам

**Урамыбыз — гөл урамы.**
**Килегез, ышанмый кемнәр?!**
**Аяк очларына басып,**
**Рәшәткәдән карый гөлләр.**

**Ул гөлләрдән дә үрелеп**
**Әле мин карап торам.**
**Бер җирдә юк шундый матур**
**Йортлары булган урам.**

**Ә шулай да иң сөйкемле,**
**Күп сөмбелле һәм сиреньле**
**Гаҗәеп өй бар урамда —**
**Әйтче, кемнәр яши анда?**

**Гөлгә чумган өй хакында**
**Нәрсә генә әйтсәм дә аз.**
**Сиңа гына чишәм серне:**
**Яши анда**
**Гөлназ,**
**Гөлназ!**

## Ял көнендә

Ачык дәрес бирә бүген дөнья:
Чишмәләре дәшә безне дә.
Бака шигырь сөйли —
туган җирне
Олылау бар һәрбер сүзендә.

Ә инештә — йөзү бәйгеләре,
Маймычлары гаҗәп тереләр!

Күләгә-шәл җиргә төшә шуып, —
Тик берәү дә алмый үрелеп.

Ачык дәрес бирә бүген дөнья...
Чишмә чыңы күккә үрелә.
Туган җирем,
Мең төсләре белән
Җәйгор* булып җанга чигелә.

## Хәлне әни күрәсе бар

Кар өсте — яп-якты калай,
Уйнап йөри кояш-малай,
Өйдән чыктым яңа гына,
Мендәр сыры яңагымда.

Кояш-малай белән уйнап,
Чабып киттем урам буйлап,
Һәр гөрләвек шаулап ага,
Итегеңә кертми кара!

Киемнәрем лыч су булды,
Бабай әйтә: «Көн сындырды...»
Минем тырышканны белми,
Җиңнән су тамганны күрми.

Хәлне әни күрәсе бар...

## Кем ул?

Әни — таңда уятучы,
Әти — каеш уйнатучы,
Абый — кыйнап елатучы,
Апа — сыйпап юатучы.

Әбием — экият иле,
Бабаем — юкә балы,
Энем — өзми-куймый елап
Болгатучы дөньяны.

Ә кемне күрүгә мәче
Диван астына сыза?
Һәм урамның барлык эте
Өреп чыга каршыга?
Кем бакчабызда кошларның
Котын алган таш атып?
Кем икән ул? Вәт — табышмак,
Йә, карагыз баш ватып.

## Саескан кунса...

«Очып йөреп, өй тирәңә
Саескан кунса килеп —
Озакламас, кунак килер,
Тор, улым, шуны белеп».

Әбисе нәни Наилгә
Беркөнне шулай дигән.

Көннәр үткән, малай көткән,—
Саескан очып килгән.

Наил көнозын көтсә дә,
Никтер кунак килмәгән...
Чәчәк аткан алмагачны
Ул кунак дип белмәгән.

*Җәйгор — салават күпере.

## Якуб Зәнкиевнең тууына 90 ел

Татар дөньясының географик киңлеге иксез-чиксез. Халкыбыз кайларга сибелгән—әдәби байлыгыбыз да әнә шуннан килеп барлана һәм мәркәзебездә мирас булып туплана.



Төмән ягы Булат Сөләйманов, Якуб Зәнкиев, Шәүкәт Сибгатуллиннар кебек талантлы шәхесләрне үстергән. Алар иҗатында кырыс Себернең рухи җылысы саклана.

Якуб Камали улы Зәнкиев 1917 елның апрелендә, Иркутск шәһәрендә туа. Балачагы Гражданнар сугышы чорына, ә яшьлеге колхозлашу һәм шәхес культы елларына туры килгән ачы язмышлы буын вәкиле ул.

Якуб Зәнкиев, унҗиде яшеннән башлап, укыту-тәрбия эшләренә керешә. 1940 елда Төмәннең укытучылар институтын тәмамлагач, аның педагогик эшчәнлеге шушы төбәк белән бәйләнә. Ул—укытучы, мәктәп директоры һәм Тобол шәһәренең Халык мәгарифе бүлеге мөдире.

1957 елны, хезмәттәге уңышларын бәяләп, аңа «РСФСРның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелә. Сугышта катнашып, батырлыклары өчен Беренче һәм Икенче дәрәҗә «Ватан сугышы ордены», төрле медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, ул педагогик эшчәнлеге белән беррәттән, Себер татарлары тормышын сурәтләп роман язар өчен материал туплый башлый.

Бары тик 1994 елда гына Якуб Зәнкиев үзенең хыялына ирешә, аның «Иртеш таңнары» дигән роман-дилогиясе, аерым китап булып, Аяз Гыйләҗевнең әдәби эшкәртүендә басылып чыга.

Әлбәттә, язучы һәм педагог Якуб Зәнкиевнең балалар өчен язылган хикәяләре дә бар. Мәгәр аның «Иртеш таңнары» үзенең колачы, вакыйгалар тыгызлыгы һәм геройларының четерекле язмышы белән иҗатының югары казанышы булып тора. Роман 2002 елда Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясенә лаек булды.

## Фәрит Гыйльминең тууына 60 ел

Үткән гасырның 70 нче елларында татар әдәбиятына Мөслим төбәгендә туып-үскән бер төркем талантлы яшьләр килде. Зөлфәт Маликов, Фоат Садриев, Харрас Әюпов, Флүс Латыйфи, Наис Гамбәр... Алар арасында үзенчәлекле каләм иясе Фәрит Гыйльми дә бар иде.



Фәрит Гыйльми (Фәрит Гыйльметдин улы Гыйльметдинов) 1947 елны Мөслим районының Уразмәт авылында туган. Үз авылындагы урта мәктәптән соң ул 1965 елны Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә һәм аны 1970 елда тәмамлый. Армиядә хезмәт иткән елларны исәпләмәгәндә, Ф. Гыйльминең калган гомере Әлмәт белән бәйле. Ул анда мәгариф һәм хуҗалык эшләрендә төрле вазифалар башкара: укытучы, инженер, бүлек мөдире... Нинди генә хезмәт башкармасын, язучылыкны ул үзенең төп эше санады.

Фәрит Гыйльми үзенчәлекле язу стиленә ия язучы иде. Әсәрләрендәге персонажларның халыкчан җор теле, тасвирланган вакыйгаларның ышандыргыч тәэсире турында тәнкыйтьчеләр, А. Гыйләҗев, Р. Төхфәтуллин кебек проза осталары матбугатта язып та чыктылар. Аның укучыларга билгеле повестьлары—«Урсай тау итәгендә», «Елганың борылган төшендә». Һәр икесе дә үз вакытында безнең журналда дөнья күрде. Повестьларыннан тыш Ф. Гыйльми дистәләгән хикәяләр авторы да. «Су өстендә чәчәкләр», «Горур», «Кунак кызы» һ. б. Алар татар прозасы сәхифәләренең матур үрнәкләреннән саналырга лаек.

Фәрит Гыйльми күп томлыкларга сыешлы зур мирас калдырырга өлгермәде, иҗаты чәчәк аткан чорда—1993 елны 46 яшендә вафат булды.




*Бер очрашу истәлеге. Сулдан уңга—шагыйрь Әдип Маликов, журналист Венера Ихсанова, галим Гыйлем Камай, шагыйрь Мөхәммәт Садри, композитор Нәҗип Җиһанов. 1962 ел.*



*«Казан утлары» редакциясендә. Сулдан уңга—Рашат Низами, Фәния Хуҗиәхмәтова, Равил Фәйзуллин, Фәрит Иделле, Гали Акыш. 1993 ел.*



*Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев өлкән әдибебез Рәис Даутовка Татарстан Дәүләт премиясе дипломын тапшыра. 2006 ел.*



*Артист, әдип Габдулла Шамуков (1909-1981).*



*Җырчы Эмиль Җәләлетдинов һәм журналист-язучы Шәһинур Мостафин. 1999 ел.*

## Марсель Гарипов



Марсель Мөхәммәтша улы Гарипов (псевдонимы—Мирсәй Гариф) 1946 елның 1 маенда Татарстанның Азнакай районы Зур Сукаеш авылында туып, Ютазы районы Кызылъяр мәктәбендә башлангыч сыйныфларда, аннан соң Баулыда урта мәктәптә укый. 1970 нче елда Томск төзүче инженерлар институтын тәмамлап, «Архитектура» кафедрасында ассистент, фәнни хезмәткәр булып эшли. 1976 елда «Томск реставрация» остаханәсенә өлкән архитектор эшенә күчә. 1977-80 елларда Новосибирск төзүче инженерлар институтында аспирантурада укый. Яңадан «Томскреставрациягә» кайтып фәнни-тикшеренү бүлеген җитәкли. «Спецпроектреставрация» институты оешкач өлкән сәнгать белгече булып эшкә күчерелә. 1983 елда—Томск дәүләт университетында өлкән фәнни хезмәткәр. 1987 елдан Башкортстанның Октябрьск шәһәренең архитекторы булып эшли. 1989 елда татар-башкорт иҗтимагый үзәген оештыра. 1982 елдан Бөтен татар милли мәҗлесе депутаты итеп сайлана. Ул халыкара социаль-экологик союзның (МСОЭС) региональ бүлеге рәисе.

1970 нче еллардан бирле публицистик әсәрләре Татарстан, Башкортстан, Себер матбугатында басылып килә. 1990 нчы елларда Ык буе авыллары тарихлары, Октябрьский шәһәренең истәлекле урыннары буенча берничә китап-брошюралары чыкты. «Патриот шагыйрь Х. Мөҗәй» (1997), «Яшәеш» (2001), «Тяжелые грани золотой звезды» (2004), «Тымызык кына Ык ага» (2004) китаплары басылды.

2002 елдан—«Ык таңнары» региональ әдәби берләшмә җитәкчесе.

2006 елның 29 ноябрендә Кабул итү комиссиясе карары нигезендә (тәкъдимнамә бирүчеләр: Илдар Юзеев, Роза Кожевникова, Альберт Хәсәнов) Язучылар берлеге идарәсе Марсель Мөхәммәтша улы Гариповны Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алды.

♣

## ЯЗУЧЫЛАР ХИСАП ТОТТЫ

«Казан» милли мәдәният үзәгендә Татарстан язучыларының әдәби ел йомгакларына багышланган гомуми җыелышы булып узды. Анда Казанда һәм республикабыз районнарында, күрше төбәкләрдә һәм чит өлкәләрдә яшәп иҗат итүче каләм әһелләре катнашты.

Әдәби ел йомгаклары җыелышын Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов ачып җибәрде һәм узган әдәби ел йомгаклары буенча доклад ясады. Хисап җыелышында каләм әһелләренең халык белән аралашуы-очрашуы, нәшриятларда басылып чыккан китапларны халыкка тарату, бу эшнең яңача ысулларын эзләп табу хакында да сөйләшү булды. Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимовның чыгышыннан күренгәнчә, узган ел күп кенә районнарда әдәбият көннәре узган, язучыларның иҗат төркемнәре 12 районда булып, төрле очрашулар үткәргән. Быел исә мондый очрашуларны һәм китап тарату эшен җанландыру буенча эшлекле тәкъдимнәр әйтелде.

Жанрлар буенча төп чыгышларны Ә. Рәшит (шигърият), Л. Лерон (чәчмә әсәрләр), Г. Морат (публицистика), Г. Арсланов (драматургия), Л. Газизова (урыс телле әдәбият), А. Әхмәдуллин (әдәби тәнкыйть), Р. Рахмани (балалар әдәбияты) ясады. Фикер алышуларда Т. Галиуллин, Р. Бәшәр, А. Хәлим, Р. Рахман, М. Хәбибуллин, Л. Шагыйрьҗан, Н. Сафина, Д. Салихов һ. б. катнашты.

Җыелышта Татарстан Премьер-министры урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева катнашты һәм чыгыш ясады. Ул, узган елның Татарстан Президенты тарафыннан Әдәбият һәм сәнгать елы дип игълан ителгән булуын искәртеп, ел дәвамындагы мөһим вакыйгаларны билгеләп үтте, чыгышларда күтәрелгән кайбер мәсьәләләргә карата үз фикерен әйтеп, күп кенә сорауларга җавап бирде. З. Вәлиева шагыйрь, прозаик, «Идел» журналының бүлек мөхәррире Р. Зәйдуллага «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнең таныклыгын, язучы, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире К. Кәримовка «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» медален тапшырды. Ул, шулай ук, язучы, «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының баш мөхәррире З. Хөсниярны, драматург, Әлмәт язучылар оешмасы җитәкчесе Д. Салиховны Татарстан Мәдәният министрлыгының «Мәдәнияттәге казанышлар өчен» дигән күкрәк билгесе белән бүләкләде. Шагыйрьләр Л. Газизова һәм С. Малышев, Язучылар берлеге хезмәткәрләре Л. Гәрәева, Ш. Бәдретдинов, М. Борһановага Татарстан Мәдәният министрлыгының Мактау грамотасы бирелде.

Татарстан Югары Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Р. Вәлиев шагыйрьләр Н. Акмал һәм Р. Аймәткә Татарстан Дәүләт Советының Рәхмәт хатын тапшырды.

Аннары каләм әһелләре Рөстәм (Фәйзуллин) Акъегеткә—Г. Исхакый, Лена Шагыйрьҗанга—Һ. Такташ, Марат Әмирханга—Ф. Хөсни, Азат Әхмәдуллин белән Фәрит Хатыйповка—Ж. Вәлиди исемнәрендәге әдәби бүләкләр тапшырылды.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов Әдәбият һәм сәнгать елында активлык күрсәткән бер төркем каләм әһелләрен акчалата премияләр белән бүләкләде.

*(Әдәби ел йомгагы материаллары киләсе саннарның берсендә журналыбызда басылып чыгачак).*

## МАТБУГАТ БАЗАРЫ НИ ХӘЛДӘ

«Идел-Пресс» нәшрият комплексы бинасында үткәрелгән киңәйтелгән киңәшмәдә «Татмедиа» гаммәви коммуникацияләр агентлыгының узган еллагы эш йомгаклары тикшерелде һәм 2007 елга бурычлары билгеләнде.

Киңәшмәдә Премьер-министр Р. Миннеханов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова, Татарстан прокуроры К. Әмиров, республика Үзәк сайлау комиссиясе рәисе А. Фомин, республика һәм районнарның гаммәви мәгълүмат чаралары җитәкчеләре катнашты.

Утырышка кадәр Р. Миннеханов «Татмедиа» агентлыгы генераль директоры М. Моратов һәм «Идел-Пресс» ачык акционерлар җәмгыяте генераль директоры И. Әхмәтҗанов белән нәшрият цехларын карады, республиканың иң зур полиграфия комплексы эшчеләре һәм белгечләре белән аралашты, полиграфчыларның хезмәт һәм көнкүреш шартлары белән кызыксынды.

«Татмедиа» генераль директоры М. Моратов утырышта ясаган чыгышында 1 февральгә Татарстанда 1133 гаммәви мәгълүмат чарасы теркәлгәнлеген искәртте. Татарстан Россия төбәкләре арасында газета-журналларны иң күп укучы төбәк булып тора.

М. Моратов республикада иҗат интеллигенциясе өчен матбугат басмаларын саклап калуга ирешүне аерым билгеләп үтте.

Бүген матбугат базарында республика һәм җирле газета-журналлар тиражларының артуы, үзәк басмаларның кимүе күзәтелә. Әйтик, газета-журналларга яздыру кампаниясенең соңгысында республика матбугатын укучылар саны 13 процентка арткан. Газеталар, радио һәм телевидениенең иң мөһим бурычларыннан берсе, М. Моратов фикеренчә, коррупциягә каршы көрәш.

«Татмедиа» җитәкчесе үз чыгышында республиканың гаммәви мәгълүмат чаралары базарын реформалау, аерым алганда, агентлыкны акционерлаштырып, холдингка әйләндерү планы белән уртаклашты.

Фикер алышулар барышында чыгыш ясаучылар республика мәгълүмат чаралары проблемаларына кагылып үтте. Сүз җирле, шулай ук республика телерадиокомпанияләренең техник яктан начар тәэмин ителеше, мөхәррирләрнең, журналистларның хезмәт хаклары түбән булуы, күп кенә министрлыклар һәм ведомстволарның мәгълүмати яктан ябыклыгы турында барды.

Премьер-министр Р. Миннеханов, көндәлек матбугатны әбүнәчеләргә җиткерү бәясе арту җәһәтеннән, республикага гомумфедераль почта килгән очракта да «Татарстан почтасы» компаниясе тегe яки бу рәвештә сакланып калырга тиеш, дип искәртте. Премьер-министр Татарстанда Россия почтасының филиал челтәрен булдыруга каршы түгеллеген әйтте. Әмма көндәшлек булсын өчен, республика почтасы да калырга тиеш, диде ул. Р. Миннеханов шулай ук матбугатка һәм журналистларга карата мөнәсәбәтен дә белдерде.

—Бүген без гаммәви мәгълүмат чараларыннан башка бер генә мөһим проектны да башкарып чыга алмыйбыз. Әмма без журналистлардан фактларны бәян итүне, кайдадыр нәрсәдер булуын сөйләп чыгуны гына түгел, тегe яки бу мәсьәләне хәл кылу буенча тәкъдимнәр, проблемаларны анализлау да көтәбез. Тәнкыйтьчеләрне көтәбез, дип әйтер идем. Тәнкыйтьне эшне тирәнтен белүгә корылган булса, әлбәттә, дөрес карарлар кабул итү өчен бу бик мөһим,—диде Р. Миннеханов.

Премьер-министр искәрткәнчә, халыкка республикабызда чынбарлыктагы хәлләр турында объектив төстә һәм төрле яклап мәгълүмат җиткерү электрон, шулай ук басма мәгълүмат чараларының төп бурычы булып тора.

### БӨЕК ӘДИПКӘ БАГЫШЛАП

Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында татар әдәбияты классигы, күренекле галим, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 120 ел тулуга багышланган «түгәрәк өстәл» булып үтте. Анда әлеге институтның танылган галимнәре, телевидение-радио, матбугат вәкилләре катнашты.

«Түгәрәк өстәл» утырышын Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, филология фәннәре докторы К. Миннуллин алып барды. Ул әүвәл кыскача гына олуг юбилей уңаеннан планлаштырылган эшләр һәм алда торган мәсьәләләр белән таныштырды. Казанның Декабристлар урамы һәм Ибраһимов проспекты тоташкан урында Г. Ибраһимовка һәйкәл кую турында хөкүмәткә тәкъдим кертелүе, апрель аенда әдипкә багышланган зур фәнни-гамәли конференция узачагы һәм башка күп төрле чаралар турында хәбәр итте. «Түгәрәк өстәл» утырышында институт галимнәре тарафыннан әзерләнгән, «Мәгариф» нәшриятында басылып чыккан «Галимҗан Ибраһимов. Милләт—тел—әдәбият» дигән китапның, Г. Ибраһимовның төрле елларда язылган фәнни һәм тәнкыйть мәкаләләре тупланган җыентыкның беренче әзер нөсхәләре күрсәтелде.

Утырышта шулай ук Г. Ибраһимовның барлык әсәрләрен дә колачлаган яна күптомлык һәм әдипнең энциклопедик басмасын әзерләү хакында да сүз барды.

«Түгәрәк өстәл»дә Ф. Урманчиев, М. Әхмәтҗанов, Х. Мәхмүтов, Н. Хисамов, Р. Исламов, З. Рәмиев, Г. Арсланов, М. Зәкиев кебек күренекле галимнәр катнашты.

Утырышта катнашучылар соңыннан Казанның 17 нче гимназиясенә бардылар, Г. Ибраһимовның гимназия каршында куелган бюстына чәчәкләр салды, гимназиянең укучылары һәм укытучылар коллективы белән очрашты.

* * *

Г. Ибраһимовны олылау көннәре Яр Чаллы дәүләт педагогия институтында да үтте. Бирегә «Галимҗан Ибраһимов мирасы һәм хәзерге заман» исеме астында фәннигамәли конференция узды. Әлеге чарада Казан, Уфа, Яр Чаллы, Алабуга, Минзәлә кебек шәһәрләрдән әдәбият галимнәре, 120ләп мәктәп укытучысы, филология белгечлеге буенча белем алучы студентлар һәм аспирантлар катнашты.

Конференцияне институтның ректоры Фәйрүзә Мостафина ачты.

Конференциянең пленар утырышын КДУ профессоры, тәнкыйтьче һәм язучы Тәлгат Галиуллин алып барды.

Язучының иҗатын заман таләпләрен истә тотып өйрәнү кирәклеген шулай ук пленар утырышта чыгыш ясаган галимнәребез Хатыйп Миңнегулов, Фоат Галимуллин, Дания Заһидуллина, Мирфатыйх Зәкиев тә искәртеп үтте. Галимнең исемен йөрткән Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры урынбасары Рамил Исламов

белдергәнчә, бүгенге көндә Г. Ибраһимов иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнү буенча зур эшләр башкару сорала, аның әлегәчә өйрәнелмәгән язмалары да шактый, хәзергә кадәр хәтта җәсәденен кайда күмелгәнлеге дә төгәен билгеле түгел.

Конференция үз эшен өч секциягә бүленеп алып барды. Секцияләрдә ясалган чыгышлар Галимҗан Ибраһимовның иҗатын, татар әдәбияты, тел гыйлеме, тәнкыйте, публицистикасы үсешенә керткән өлешен төрле яклап өйрәнүгә багышланды.

## БАКЫЙ УРМАНЧЕ ЮБИЛЕЕ

Җәмәгатьчелек бөек сынчы һәм рәссам Бакый Урманченың 110 еллыгын билгеләп үтте. Шул унайдан бер төркем рәссамнарга Бакый Урманче исемендәге бүләкләр тапшырылды. Ул республикабызның Мәдәният министрлыгы тарафыннан 1998 елда гамәлгә куелган иде. Дәрәҗәле бу бүләк ике елга бер мәртәбә бирелә, күләме — 70 мең сум. Быел ана 64 рәссам һәм сәнгать белгече дәгъва кылды. Алар арасыннан нәкыш төрендә «Көзге Истанбул» циклы өчен рәссам Рәшит Газиев, графика төрендә «Өй мәшәкатьләре» циклы өчен рәссам Булат Мәрданов һәм «Тарихи Казан» циклы өчен рәссам Ирина Колмогорцева, скульптура төрендә «Су ташучы» скульптурасы өчен сынчы Асия Миннуллина, сәнгать фәне өлкәсендә «Бакый Урманче» альбомы өчен Анатолий Новицкий Б. Урманче исемендәге абруйлы бүләккә лаек булды. Ә гамәли сәнгать төрендә быел бер бүләк тә бирелмәде.

Юбилей уңаеннан Татарстанның «Хәзинә» милли сәнгать галереясендә рәссам әсәрләреннән зур күргәзмә оештырылды. Март аенда Б. Урманче иҗатына багышланган фәнни-гамәли конференция узды.

## ЭНЦИКЛОПЕДИЯНЕҢ ЧИРАТТАГЫ ТОМЫ

Татар энциклопедиясенең 3 нче томы рус телендә дөнья күрде. Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты директоры Мансур Хәсәнов билгеләп үткәнчә, бу энциклопедиянең нәшер ителүе—хәзерге Россия өчен уникаль күренеш. Совет чорында илдә бары тик бер генә—Совет энциклопедиясен чыгару гына рөхсәт ителә иде. Соңрак искәрмә рәвешендә рус, украин, үзбәк энциклопедияләре пәйда булды. Ниһаять, хәзер Татарстанның да үз энциклопедиясе бар, тиздән ул татар телендә дә бастырылачак.

Энциклопедия туплау чорында белгечләр татарча белешмаләрнең, этимологик сүзлекләрнең житешмәвеннән шактый иза чиккән. Татарстандагы күп кенә торак пунктларның рәсми атамалары бары тик урыс телендә генә булуы да өстәмә кыенлык тудырган. Шуңа да карамастан, энциклопедиянең 3нче томы татарчага тәрҗемә ителгән һәм җәй башында дөнья күрәчәк.

Энциклопедиянең 663 битле 3 нче томында меңгә якын күренекле кешенең биографиясе урын алган. Басмада 2930 мәкалә, 1234 иллюстрация (шуларның 773е—төсле) бар. Энциклопедиянең тиражы 5 мең данә булып, ул республиканың эре китапханәләренә бушлай таратылачак, сатуга да чыгарылачак. Татар энциклопедиясен 6 том итеп чыгару планлаштырылган.

## КАМАЛ ТЕАТРЫ—ҖИҢҮЧЕ

Беренче татар актрисасы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяга багышланган спектакльнең премьерасы (Нәкый Исәнбәт, «Гөлҗамал») алдыннан Галиәсгар Камал театры директоры Шамил Закиров тамашачыларга шатлыклы хәбәр җиткерде.

Мәскәүдә яңа гына «Театрның музыкаль йөрәге» дип аталган II милли фестиваль тәмамланды. Анда Россиянең йөздән артык театры катнашкан. Сайлап алынган унбише арасында Галиәсгар Камал исемендәге академия театры да бар. Фестивальдә камаллылар Геор Хугаевның «Кара чикмән» әсәре буенча сәхнәләштерелгән спектакльне күрсәттеләр. Нәтиҗәдә театр төп призларга лаек булды. «Иң яхшы спектакль» номинациясендә — театр үзе, «Иң яхшы режиссура» номинациясендә — Фәрит Бикчәнтәев, «Иң яхшы ирләр ролен башкаручы» номинациясендә Искәндәр Хәйруллин җиңде.

## КАТЛАМ-КАТЛАМ БЕЗНЕҢ ТАРИХ

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә Евразия далаларының урта гасыр археологиясенә багышланган Халыкара Конгресс үтте. РФ Фәннәр академиясенең археология институты һәм ТР Фәннәр академиясе тарих институты, Казан дәүләт университеты һәм ТР Милли музее оештырган әлеге чарада Мәскәү, Санкт-Петербург кебек шәһәрләрдән, Россиянең төрле төбәкләреннән һәм чит илләрдән килгән галимнәр катнашты.

ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты, тарихчы галим Миркасыйм Госманов әйтүенчә, моннан 130 ел элек археологиягә караган беренче Бөтенроссия конференциясе дә нәкъ менә Казанда узган. Шуннан бирле фәнни өлкәдә шактый эш башкарылган. Борынгы мирасны этник яктан билгеләү, рухи мәдәниятне һәм бөтен дөнья диннәрен өйрәнү, казылма мирасны куллану, саклау һәм башка мөһим мәсьәләләрнең әһәмияте арта гына бара. Урта гасырга караган дала зонасын тагын да тирәнрәк өйрәнү таләп ителә. Евразия илләрендәге тикшеренү үзәкләрен берләштерү, археология өлкәсендә халыкара элемтәләрне ныгыту—Конгрессның максаты менә шушы.

## ШАЛЯПИН ФЕСТИВАЛЕ

Казанда Федор Шаляпин исемендәге XXV Халыкара опера фестивале тәмамланды. Фестивальнең соңгы ике көнендәге гала-концертны Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җәмәгате белән бергә карады. Концерт фестивальнең дәвамы булды. Дөньяның мәшһүр опералларыннан гүзәл арияләрне дирижер Марко Боэми җитәкчелегендәге театр оркестрына кушылып Россия Зур театры җырчысы Сергей Мурзаев, Петербург Мария театры җырчылары Ольга Бородина һәм Паата Бурчуладзе кебек мәшһүрләр җырлады. Концертны күренекле музыка белгече Святослав Бэлза алып барды. Халыкка мөрәҗәгать итеп, ул бөек композитор Сергей Рахманиновның бөек җырчы Шаляпин турындагы сүзләрен искә төшерде: «Шаляпин—киләчәк буыннар өчен легендага әвереләчәк кеше».

Шаляпин чыннан да җыр сәнгатенең легендасы ул. Һәм аның исеме Казан белән бәйле булу безнең күңелләргә горурлык өсти. Казан кешеләре бу горурлыкны бронза һәйкәл итеп бастырып куйган булсалар, Шаляпин исемен йөрткән фестиваль аның исемен дөньяда яңгырата. Фестивальдән таралганда җырчыларның һәркайсы бу фестивальгә тагын килү турындагы хыялларын әйттеләр.

## БИЕКТАУДА ОЧРАШУЛАР

Февраль аенда Биектау районында әдәби очрашулар булып узды. Танылган балалар шагыйре һәм драматург Рафис Корбанга 50 яшь тулу уңаеннан аның туган төбәгендә уздырылган әлеге әдәбият-сәнгать бәйрәмендә Татарстан Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов җитәкчелегендәге бер төркем әдипләр һәм артистлар катнашты. Аның составында Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин, Язучылар берлеге рәисе урынбасары Әлфәт Закирҗанов, «Салават күпере» журналы баш мөхәррире Зиннур Хөснияр, Татарстан китап нәшрияты директоры Дамир Шакиров, язучылар Альберт Хәсәнов, Равил Рахмани, Солтан Шәмси һәм Рафис Корбан, шулай ук композитор һәм башкаручы Илгиз Закиров, җырчылар Зөһрә Шәрифуллина, Фәридә-Алсу дуэты, Фәрит Фәйзрахманов һ. б. бар иде.

Ике көн дәвамында үткән әдәбият һәм сәнгать бәйрәменең программасы гаять тә бай һәм кызыклы иде. Башта кунакларны Салих Сәйдәшев туган Өбрә авылына композиторның музей йортына алып бардылар. Аннары татар халкының икенче бер күренекле улы, татар профессиональ музыкасына нигез салучы Солтан Габәши туган Кече Солабаш авылында, шулай ук аның музее белән танышу һәм мәктәп укучылары белән очрашу булдылар. Солабаштан соң кунаклар Альберт Хәсәнов үскән һәм укып чыккан Дөбъяз авылы мәктәбендә Рафис Корбан иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичәдә катнаштылар, чыгышлар ясадылар.

Кунаклар шулай ук Айбаш, Мәмдәл авыллары мәктәпләрендә булдылар, Биектау районының татар теле һәм әдәбияты укытучылары, мәктәп һәм авыл китапханәчеләре алдында чыгыш ясадылар, аларның сорауларына җаваплар бирделәр.

## ЭЗТАБАР ӘДИПНЕ ЗУРЛАУ

РФ Җәмәгать бүләкләре Милли комитеты Президиумының 2007 елгы 19 февраль карары нигезендә, эзтабар язучы, шагыйрь, Казандагы «Сүз» нәшриятының баш мөхәррире **Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафин**, илебез мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә керткән хезмәтләре өчен, Михаил Ломоносов исемендәге премиягә һәм алтын медальгә лаек булган. Шул хактагы «Лауреат дипломына Милли комитет президенты —генерал-полковник, юридик фәннәр докторы, академик В. Г. Шевченко кул куйган.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Бүгенге татар әдәбияты һәм сәнгатен үстерүдәге казанышлары өчен язучы, «Идел»—«Идель» журналы мөхәррире **Зәйдуллин Ркаил Рафаил улына** (Ркаил Зәйдулла) «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Тукай төше». ***Абрек Абызгилдин*** *картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Миргалим Харисов**.

# Яңа китаплар




**Мөдәррис Вәлиев.** Милли нәшрият һәм китап редакторы: югары уку йортлары өчен уку әсбабы. —Казан: «Мәгариф» нәшр., 2006. —351 б. Тиражы—1000 данә.

Тарихта без китаплы халык дип исәпләнәбез. Әмма китапны «тудыру» нечкәлекләрен бик азлар белә. Китапчылык тарихын яна бер баскычка күтәргән бу гыйльми-гамәли хезмәт бүгенге шартларда милли китапчылык эшен оештыру, әлеге системада редактор хезмәтенең үзенчәлекләрен ачуга багышланган. Китап, беренче чиратта, дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә татар телендә «Нәшрият эше һәм редакцияләү» белгечлеген үзләштерүче студентлар, нәшрият тормышы белән кызыксынучы яшьләр, авторлар, шулай ук китап сөюче һәммә кеше өчен файдалы булачак.




**Нурулла Гариф.** Казан ханлыгы: оешу тарихы, идарә системасы, административ бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре. Чаллы олысы мисалында.—Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. —175 б. Тиражы—3000 данә.

Нурулла Гариф—безнең журналның даими авторы. Ул—галим, язучы-публицист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Туган төбәгендә урнашкан борынгы Чаллы тарихы буенча бүгенге көндә төп белгечләрнең берсе.

Мәгълүм булганча, Казан ханлыгы әлегә иң аз өйрәнелгән урта гасыр татар дәүләтләренең берсе булып тора. Бу дәүләтнең иң әһәмиятле үзәкләренең берсе—Чаллы каласы (хәзерге Балык Бистәсе территориясендә).

Хезмәттә 1437/1445—1552/1557 елларда яшәгән Казан ханлыгының оешу тарихы, идарә системасы, административ бүленеше һәм феодал вассаллык мөнәсәбәтләре аның бер олысы—Чаллы феодал биләмәлеге мисалында каралган. Ханлык чорын өйрәнү тарихи методларга нигезләнгән.

Хезмәт тарих белән кызыксынучы киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.



Миргалим Харисов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)